ISSN 0206—418

# КАЗАН УТЛАРЫ

5. 1994



## ХӨРМӘТЛЕ ДУСЛАР!
## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

**Бу журнал кулыгызга килеп кергәндә инде матбугатка язылу мәшәкатьләре кызып киткән чак булыр. «Казан утлары»н даими алдыру өчен 1994 елның икенче яртыеллыгына (июль – декабрь айлары) язылу янәдән дәвам итә. Без сезгә ашыгырга киңәш бирәбез, чөнки кем алданрак язылса — шул отачак!**

**Онытмыйк: «Казан утлары» журналы — татар телендә чыга торган күләмле бердәнбер әдәби-нәфис журнал. Ул үзенең 70 елдан артык яшәү дәверендә халкыбызның яраткан, көтеп алынган басмасына әверелде. Чит илләргә һәм элекке СССРның төрле төбәкләренә сибелгән газиз милләттәшләребез өчен һәм элек тә, һәм хәзер дә бердәмлек, аралашу, аңлашу мәйданы булып хезмәт итә.**

**Тагын бер үзенчәлекне искә төшерик: калын һәм кызыклы өр-яңа романнар, повестьлар белән тулысынча килеш фәкать безнең журнал аша танышырга мөмкин. Нәшриятларда татар милли китапларын чыгару елдан-ел кыенлаша. Менә шуңа күрә, «Казан утлары»ның һәрбер саны — әдәбият сөючеләргә үзе бер бүләк, яңа китап ул. Әдипләребез исә безнең белән һәрчак якын элемтәдә, редакциябез хәзинәсендә барлык жанрлар буенча да яңа әсәрләр, язмалар җитәрлек.**

**Мәгълүм ки: рәхәтләнеп укыгыз мине дигән изге ният белән, журнал укучылар өчен чыга. Шөкер, аларның ярдәме, дуслыкка тугры калулары нәтиҗәсендә, без быел да тиражыбызны чагыштырмача әйбәт саклап кала алдык. Бүгенге көндә аның тиражы — 23 мең данә.**

**Кыйммәтчелек үсүгә карамастан, безгә шушы тиражны алга таба да бергә-бергә саклап калу бик мөһим. Чөнки бу — милләтебезнең киләчәгенә, рухи дөньясына, ничек яшәвенә бәйле бер күрсәткеч тә булачак.**

**Журнал язмышы — әдәбият һәм халык язмышы ул. Шуңа күрә дә «Казан утлары» халкын яраткан, аның шатлык һәм борчуларын үз иткән ватандар рухлы һәркемне үз учагы янына чакыра. Без исә сезнең ярдәм һәм теләктәшлеккә журналдагы кызыклы, тирән эчтәлекле сәхифәләр белән җавап бирербез.**

**«Казан утлары» журналы редакциясе.**

*(Журналыбызга язылуның шартлары һәм квитанция үрнәге белән соңгы битләрдә таныша аласыз).*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**5**

**(858)**

**1994**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

М. ӘГЪЛӘМ. Түземлекләр бирсен. *Шигырьләр* . 3
З. ЗӘЙНУЛЛИН. Урам. *Повесть* ........ 9
Ф. ГАБДРӘХИМ. Урда. *Шигырьләр* ........ 90
К. ЛАТЫЙП. Турагачта кош оясы. *Шигырьләр* . 95
Л. БАДЫЙКШАН. Мөртәт. *Роман* ........ 99
Ш. БИККОЛ. Туфан елмаюы. *Шигырьләр* ........ 130
Э. МӨЭМИНОВА. «Мин сине я-ра-там!» *Шигырьләр* ........ 134
Татарстан язучыларының XII съезды алдыннан 137

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Аның яшәү рәвеше ........ 142
М. ГОСМАНОВ. Котсыз еллар кайтавазы ........ 146

БЕР ӘСӘР ТАРИХЫ

Ф. ЯРУЛЛИН. «Сөембикә егет сайлый» ........ 162

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ӘХМӘТҖАН. Шигърият аша тәрбия ........ 166
Н. ХИСАМОВ. Алтын Урданың шигъри мәдәнияте ........ 174

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕНДӘ—ТАТАР ШӘХЕСЛӘРЕ

Б. СОЛТАНБӘК. Затлы нәсел улы ........ 178

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Шагыйрьнең прозасы ........ 180

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Р. ЯГЪФӘРОВ. Фольклор күгендәге чулпан (*Х. Ярминең тууына 90 ел*) ........ 184
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 187

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрваз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: повесть З. ЗАЙНУЛЛИНА «Улица»; начало романа Л. БАДИКШАНА «Вероотступник»; стихи М. АГЛЯМОВА, Ф. ГАБДРАХИМА, К. ЛАТЫЙПОВА, Ш. БИККУЛА, Э. МУКМИНОВОЙ.

«Навстречу XII съезду писателей Татарстана».

«Публицистика»: статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА к 60-летию М. Усманова; статья М. УСМАНОВА «Эхо страшных лет»;

«История одного произведения»: статья Ф. ЯРУЛЛИНА «Сююмбикэ выбирает жениха»;

«Литературная критика»: статья М. АХМЕТЗЯНОВА «Воспитание поэзией».

Статья Н. ХИСАМОВА «Поэзия Золотой Орды».

«Книжное обозрение»: статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА «Проза поэта».

«Наш календарь»: статья Р. ЯГЪФАРОВА посвящена к 90-летию Х. Ярми.

Дневник общественно-культурной жизни.

«На наших обложках»: «Затмение луны» — картина художницы А. Ильясовой; известный поэт М. Аглямов.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: Z. Zainullin's article «The Street»; the beginning of L. Badikshanov's novel «The Apostate»; M. Aglyamov's verses, the verses of Ph. Gabdrahim, K. Latipov, Sh. Bikkula, E. Mukminova.

«Meeting the XII Congress of Tatar Writers».

«Publicism»: R. Phaizullin's article devoted to the 60th anniversary of M. Usmanov; M. Usmanov's article «Echo of the Terrible Days».

«The History of One Work»: Ph. Jarullin's article «Syumbika is Choosing a Fiance».

«Literary Critique»: M. Akhmetzyanov's article «The Education by Poetry». N. Khisamov's article «The Poetry of the Golden Horde».

«Book Review»: Ph. Galimullin's article «The Prose of the Poet».

«Our Calendar»: Ph. Jagapharov's article devoted to the 90th anniversary of Kh. Jarmi.

«The Diary of the Social and Cultural Life.

In our covers: A. Ilyasova's picture «Lunar Eclipse»; the eminent poet M. Aglyamov.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 1.04.94 ел. Басарга кул куелды 10.05.94 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 19,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 22 422. Заказ А-175. Бәясе 330 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1994 ел.

# ШИГЪРИЯТ

## Мөдәррис Әгъләм

БҮГЕН

### Түземлекләр бирсен

Түземлекләр бирсен сиңа, илем,
Түземлекләр бирсен!
Башкаеңны горур тоткан хәлдә
Каршыларга язсын иртәгесен.
Үз дәүләтең аяк баскан чакта,
Түземлекләр бирсен!

Сиңа һәркөн Зәең, Сөнең, Ыгың
Бәхет теләп ага...
Сулар кире акмый. Ил бәхете
Кабатланып кына канатлана.
(Үз дәүләте аяк баскан чакта,
Бәхет телик аңа!)

Син бүгенгә әнә килеп чыктың
Канлы юллар аша...
Уяныргa киерелгән милләт
Халыклашып кына калыплаша.
Дәүләт булдырырга килдек бит без
Канлы еллар аша...

Түземлекләр бирсен сиңа, илем,
Түземлекләр бирсен...
Төннәрең дә тулы айлы булсын,
Бирсен аяз күкне — көннәреңә,
Шәһит китәр әллә кемнәреңә
Түземлекләр бирсен!

Чык Иделгә авыр көннәреңдә,
Син Иделгә таян!—
Нәкъ төбеннән чыккан гәрәбә без,
Төшмәгәнбез күктән — әллә каян!

---

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ (1946) — *шагыйрь, дистәләгән («Кыңгырау», «Учак урыннары», «Киләчәккә кайту» һ.б.) китап авторы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты. Казанда яши.*

Дәүләт бүген бар ул, иртәгә юк,—
Син Иделгә таян!

Үткәннәрдән үткәнебез затлы,
Бөтен дөнья күрсен:
Бүгенгесе шөкер,
Һәрбер кеше
Якты күрсен изге иртәгесен...
... Түземлекләр генә бирсен, илем.
Түземлекләр бирсен!

*1990. 30 август*

## Бүген

Таралган бу халык, китап барган читкә,
Кемгә киткән алар?
Кая киткән?
Нигә?
Китеп барган алар — җылы кермәгәнгә
Байлык өстендәге шушы җылы өйгә.

Изге өем минем, изге Татарстан,
Ничә буын инде синдә тапмый җылы,—
Яки уңга китә,
Яки сулга китә —
Уңга-сулга китә улларының юлы.

Монда килгәннәргә тудырылган кебек
Китәр өчен дә бит тудырылган шартлар...
Баскынчылар, әйе, уйламыйлар гына —
Әнә шундый шартлар
Көн килер дә шартлар!

Дары мичкәсенә күнеккәннәр алар,
Ә бит бу мичкәдә
Түгел дары гына!
(Ничә гасыр инде күнегелгән бит, әй,
Дары белән генә кисеп барылуга.)

Бу мичкәдә бүген милләтләрнең каны —
Аккан тамырлары кыршау кебек кипкән...
Изге өем минем, газиз Татарстан,
Синең нигезләрең шартлап китмәс микән?

Башы да бит монда,
Ахыры да монда,
Шуңа башлау кирәк безгә уртаклыктан,
Мәскәү кушкан кебек, йә ахырдан башлап,
Йәки баштан башлап,
Шартлар диеп куркам.

Безгә башлау кирәк,
Бүген.
... урталыктан...

Җигелеп тарту өчен фани дөнья йөген.
«Бөек Русь иле» дип, сүгенергә түгел,
Тиенергә тели татар халкы бүген.
Тиенергә тели,
Үз кул көче белән
Тапкан байлыкларга тели тиенергә.
Кеше дип санарга тели балаларын,
Эшенә тиң итеп тели киенергә.

Кан да бирдек, әйе,
Җан да бирдек, әйе,
Изге йортым минем —
Язмыш шулай кушкан.
Ханлы да идек, әй,
Данлы да идек, әй,
Изге йортым минем —
Газиз Татарстан!

... Камыр изеп биргәч,
Дөнья гизеп биргәч,
Дәүләт төзеп биргәч,—
Тылмач кирәк түгел,
Китеп бара дуслар.

... Аңла, Татарстан!

*1990*

* * *

Йәки еллар буе дәвалана,
Йә актара узган ярасын —
Бер минутта мең сурәткә керә,
Аңламассың адәм баласын.
Кайвакытта тиктомалдан гына
Яраларның тели яңасын.

Үткәннәргә йә ул йөз чөерә,
Йә түгә ул күзе карасын,
Бер минутта мең сурәткә керә,
Аңламассың адәм баласын.
Әйтерсең лә белми үзенең дә
Үткән заман булып каласын.

Я күбәләк кебек утка керә
Белә-белә үзенең янасын,
Мин
        үземне
                үзем
                        аңлый
                                алмыйм,
Аңлый алмыйм адәм баласын.
Сез, кешеләр, шундый акыллылар,
Мин акылсыз, килми танасым.

Тик бер генә тапкыр аңлагыз сез
Шул акылсыз адәм баласын.

## Пар алка

Яшел дөньяны саргайтып
Тышта көзге җил искәндә.
Аерылып та,
Каерылып та
Яфраклар җиргә төшкәндә —
Баш өстендәге букетның
Яктысына коенып кына,
Бәхетле парлар шикелле
Бер-берсенә сыенып кына
Пар алкаң ята өстәлдә.

Көнлек мәшәкатьләр белән
Берәм-берәм көрешкәндә,
Ялгыз калып,
Каләм алып
Җыр язарга керешкәндә —
Көнләшүдән түзәлмичә
Чәчәкләр дә борылып карый,
Өзелеп төшкән һәрбер чугын
Берәм-берәм саный-саный
Пар алкаң ята өстәлдә.

Алдагы ап-ак кәгазьдәй
Алга дәшә киңлекләр дә,
Кошлар кебек
Канатларын
Кагына мөмкинлекләр дә.
Шундый чакта килер көннең
Барлыгына сөенәсең —
Юккамыни кичкә кадәр
Көтеп назлы үз иясен,
Пар алкаң ята өстәлдә?!

## Бары шулай гына

Син үлемнән кайтып килә идең,
Яфрак булып ява бары сагыш...
Нәрсә эзләп киткән идең анда?
Аңладыңмы —
яшәү
үзе
табыш.

Син үлемнән кайтып килә идең,
Күкрәгемә бәрде салкын сулыш;
Җавап бирдем:— Андагысы анда,
Мондагысы кирәк, бергә булыш...

Син үлемнән кайтып килә идең,
Бергә рәхәт,
Аңлый башладыңмы?

... Учларыма салып уйнап торам
Күкрәгендә йөрткән ташларыңны.

Син үлемнән кайтып килә идең,
Кайтып киләсең күк су буеннан...
Тик онытма, бәгырь, яшәү өчен
Син суелган кадәр мин суелган...
мин суелган...

Бары шулай,
Бары шулай гына...
Ә башкача дөнья хәшәп була.
Бары шулай,
Бары шулай гына...
Бары шулай гына яшәп була.

*1993. Октябрь*

## Ашыкмачы, җырым...

Син туктарга ашыкмачы, җырым!
Ахыргача әле йотмадылар...
Яшәү өчен туган яшеллекне
Таптаудан да бәлки туктарлар...
Син туктарга ашыкмачы, җырым!

Сандугачлар булып сандугачлар
Кала урамына күнектеләр.
Наз-сөюдә узган минутлар да,
Шомыртлар да әнә күбекләләр...
Син юк-барга ялыкмачы, җырым!

Син туктарга ашыкмачы, җырым,
Халык сала коллык богауларын,
Аның белән бер чор үтә-үтә
Кичтең лә син юлның урауларын —
Шул ук сафтан син чыкмачы, җырым!

Гөлбакчаны сазлы күл иттеләр,
Җир байлыгын һава-көл иттеләр,
Көнне төнгә әйләндерә бару —
Олуг максат, диеп күнектеләр.—
Син бу хакта онытмачы, җырым!

Син йокларга ашыкмачы, җырым,
Күз сал әнә язгы игеннәргә.
Дөнья буйлап таралган бу халкың
Күккә багып, күкрәк киергән лә —
Үз-үзенә каныкмачы, җырым!

Һәммәбез дә яттык без биләүдә,
Җан ул — шигырь,
Ә тән иде — гәүдә...
Тән кушканны җан кылганы өчен

Әйтәсе бар әле: тәүбә! тәүбә! —
Син шул хакта онытмачы, җырым...

Юатты бит безне өмет кереп,
Без дә барып керик өмет кебек,
Әмма кемгә?
Тәңре әйтә безгә:
Үзегезгә!
... Ашыкмачы, җырым, бөтен өмет
Үзебездә бит ул,
Үзебездә...

*1991. Июль*

## Дөрес юлдан бара

Юк, еракта түгел безнең тарих,
Саный китсәң мең гасыр гына...
Аның рухы татар көрәшедәй
Баса безнең кан басымына.

...Ил бәхете, Ил шатлыгы өчен
Канга батты күпме сөлгеләр...
Ир канына баткан сөлгеләрне
Байрак итеп кенә элделәр.

Шул байраклар безне әйдәп барды
Йә фронтка, йәки «Гулаг»ка...
Тарих безне алып китәр сыман
Чиста көрәш барган — еракка.

Ул без шаһит, баш күтәргән милләт
Һәм илләрнең бил алышына —
Күрәсезме, әнә шул көрәштә
Күзгә карап ил алышына.

Үзгәрә бит Татарстан йөзе —
Кешеләрнең йөзе үзгәрә —
Сөлгеләрдә ир-атларның каны,
Хет кырыкка аны өзгәлә.

Беркайчан да онытмагыз, диеп
Оран сала тарих киңәше:
Максат илә дөрес юлдан бара
Мең гасырлык татар көрәше —
Дөрес юлдан бара!



Зәки Зәйнуллин

# УРАМ

ПОВЕСТЬ

**Сугышка кадәрге татар авылларында булган урамнар хәзер юк инде. Урыннары бар барын, ә үзләре бөтенләй үзгәрделәр. Урамнар да, заман агышыннан калышмыйча, төсләрен алмаштырдылар. Каз үләнле, күбесенчә читәнле, сиртмәле коелы, ат эчерә торган агач улаклы, шаралы уйный торган чокырлы-казанлы урамнар инде юк. Алар урынына сирәк-мирәк кенә асфальт җәелгән, күбесенчә кызыл-кара балчыкларын трактор-машиналар чокып бетергән, такта коймалы, бизәкле чибәр капкалы, су килә торган колонкалы урамнар хәзер авылда. Машина күп йөргәнлектән, күпчелек урамнарда үлән бөтенләй үсми. Кое, улаклар юк. Сирәк-мирәк кенә урам буйлап арба өстерәп, тыркылдап юыртып үтеп киткән атлар да урамга элекке ямьне кайтара алмыйлар. Чөнки алар бик аз авылда.**

**Авыл урамнарының җәй көннәрендә төп матурлыгы булган, чебиләнеп, каралып каткан яланаяклы, түбәтәй-кәләпүшле чая малайлар да авылда юк хәзер. Алар урынына авылда бүген озын чәчле, кеды, сандали, ботинка, эрзинкә итекле һәм күлмәкләренең алдына йә артына кеше бөтенләй аңламый торган телләрдә язылган, әллә нинди мәнсез рәсемнәр төшерелгән малайлар барлыкка килгән. Күбесенең кул астында велосипед, мопед, матай. Кичләрен күпчелегенең кулында радиоалгыч, магнитофон, гитара, авызларында тәмәке һәм ... урыс маты. Авылларда татар малайлары бетеп баралар.**

**Бу әсәрне язу максаты минем өчен, автор буларак, бераү генә: сугышка кадәр һәм сугыштан соң мин туып үскән чын татар авылы Эстәрлебашның бер урамы нинди булган, шул урам кешеләре кемнәр булган, нинди булганнар, ничек яшәгәннәр. Күпчелеге инде аларның бу дөньядан күчеп киттеләр һәм авыл очындагы таш койма белән уратылып алынган зират эчендә яталар. Алар бу дөньяда юньле кием, юньле аш күрмичә, нужалы еллар уздырдылар. Урыннары оҗмахта булсын барсының да! Җир йөзендә күрмәгән рәхәтне бәлки анда күрерләр, Алла боерса!**

## Пожарный урамы

Авыл халкы ул урамны бүген дә Пожарный урамы дип йөртә. Мин белгәндә урамның Совет хөкүмәте бер-бер артлы атаган ике исеме бар иде. 1967 елга кадәр Нуриман урамы һәм аннан соң «Октябрь-

---

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН (1933) – *әдип, техник фәннәр докторы, фәнни хезмәтләр һәм «Үрләр аша», «Сугыш алды малайлары», «Полковникны озату» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

нең илле еллыгы» исемендә. Тик төп Эстәрле халкы өчен урам, элеккедән килеп, әлеге көнне дә Пожарный урамы булып калды. Чөнки урам башында, авылда ут чыкса, шуны сүндерү өчен төзелгән каланчалы, зур пожарный бинасы тора. Бина егерме метрлар озынлыкта булып, аның эчендә атлар җигеп тарттыра торган, һәрберсе кул пешкәкле, өч бричка-арба тора. Һәрберсенә, чыгарга дигәндә, икегә ачыла торган такта капка бар. Берсе җәй көннәрендә ачык булып, шул ачык капка төбендә «Пожарный» бабай утыра торган иде. Җил көчле көннәрдә тагын бер бабай каланча башында утыра һәм ул авыл өстен бертуктаусыыз карап, тикшереп торырга тиеш. Андый җил нык искән көннәрдә тиз генә чыгып чабар өчен бер пешкәкле арбага ат җигелеп куела. Каланча башына ярты чиләк зурлыгында җиз кыңгырау эленеп куелган һәм аның тимер теленнән дүртләп ат кылыннан үргән, ирләрнең баш бармагы юанлыгы аркан аста утырган бабай янына сузылып төшкән. Авылда ут-мазар чыга калса, шул кыңгырауга сугып, халыкка белдерә торганнар иде «пожарный бабай»лар.

Сүз — Башкортстанда, борынгы Бохара-Болгар кәрван юлында урнашкан, моннан өч йөз илле еллар чамасы барлыкка килгән татар авылы — Эстәрлебашның бер урамы турында.

Урам авылның кыйбла ягында урнашкан. Ырымбурга киткән юл, авыл уртасыннан кыйблага карап, кечкенә үрне менә дә урамның көнбатыш очына житкәч кисәк кенә туксан градуска борылып, Пожарныйны сулда калдырып, авыл базарына карап китә. Ярты чакрым чамасы киткәч, сулга борылып, Ырымбур ягына юнәлә. Тагын ярты чакрым чамасы баргач, юл, челтәрле агач күпер салынган Каенлы елганы чыга да үрләр, чокырлар, таулар, урманнар аша үтеп, Казакъ далаларына таба китеп бара. Юл авылны чыкканда, соңгы тапкыр сулга борылганда, аның уң ягында авыл базары кала. Базар урыны агач рәшәткә белән уратылып алынган. Бер якка йөз илле, икенче якка ике йөз метрлар чамасы булыр базар урыны. Кергән уңайга — он, бәрәңге, яшелчә, иске-москы базары. Унда — кибетләрдән китереп сатар өчен, өсләре ябулы урыннар. Арырак шулай ук өсте ябулы, тик диварсыз ит базары. Аннан алдарак, 40 — 50 метрлар чамасындарак, мал базары урнашкан. Биредә инде аяклы мал саталар.

Эстәрлебаш авылы — салынганнан бирле атаклы авыл. Аны чукынудан качып киткән татарлар салган. Революциядән соң, район үзәге булганлыктан, кешеләре дә күп иде. Сугыш башланганчы, авылдагы вак-төяк колхозларны берләштереп, алты бригадалы «8 март» исемле колхоз төзегәннәр. Кем һәм ни өчен шулай кушкандыр — белеп булмады. Биш бригада — Эстәрлебашның үзендә, алтынчысы — авылдан өч чакрымда, биек тау астында утырган чибәр башкорт авылында. Исеме Мөхәммәтдәмин булса да, ул авылны күбесенчә Урман авылы дип йөртәләр. Бик тә уңган аучылар, игенчеләр яши ул авылда.

Мин туып үскән урамга исем биргән Пожарный — үзем өчен истәлекле һәм бик тә кадерле урын. 1937 елдан 1946 елга кадәр минем малай чагым шушында узды.

Пожарный урамы шуннан башлана һәм озынлыгы ярты чакрымнан артык булып, ул көнбатыштан көнчыгышка сузылган. Көнчыгыш башы Эстәрле елгасына барып туктый. Урамның ике ягында утырган йортларның саны — кырык дүрт. Уң якта — егерме өч, сул якта — егерме бер.

Пожарныйдан соң уң якта, тыкрык аша беренче йорт — Гариф Танау йорты.

## Гариф Танау

Ул бабай — Габдулла Тукай замандашы. Безгә әти ягыннан туган, күрше һәм әтинең дусты да иде. Чыгышы белән төп Эстәрлебаш кешесе булып, Гариф бабай, сөйләшкәндә: «Мин сиңа шухрый-

мухрый түгел, ә Эстәрлебаш егете»,— дип җибәрергә ярата торган иде.

Исеме җисеменә туры килеп, зур, туры кылыч борынлы булганга, авылда ләкаб — исеме Гариф Танау иде. Алдан ук укучымны кисәтеп куям: Җир йөзендә ләкаб исемнәре белән дан тоткан Эстәрлебаш кебек башка авыл юк. Мин элекке Союзны, Башкортстанны, Татарстанны аркылысын буйга йөреп чыккан кешемен һәм аның шулай икәнен кистереп әйтә алам: Эстәрлебашта ләкаб-исемсез бер генә кеше дә юк. Кайберләрендә икешәр-өчәр дә әле.

Гариф Танау урта, чандыр гәүдәле, аркасы аз гына бөкерәйгәнрәк булып торган балта остасы. Хатыны, Фатыйма әби, юанрак кына түгәрәк гәүдәле, һәрчак диярлек маңгаен, башы авыртканнан, кызыл яулык белән бәйләп йөри. Гариф бабай — Фатыйма әбинең икенче ире. Беренчесе Герман сугышыннан кайтмаган. Ә Гариф бабай сугыштан йөреп кайтканчы аның үз хатыны үлгән була. Фатыйма әбинең беренче иреннән калган Маһира исемле кызы бар. Гариф бабайдан туган Зәйнулла 1926 елгы. Фәрит исемле малайлары да бар. Фәрит абый 1930 елда туган.

Гарифулла бабай үзе балта остасы булганлыктан, йорт-курасы төзек. Уртада чоланлы ике яклы йорт. Уң яктагы йорты таш диварлы, сул ягындагы йорты агачтан бурап эшләнгән. Йорт каршында подвал, бакча. Йорт түрендә аркылыга салынган мал абзары. Сулда таш келәт, аннан да арырак, бәрәңге бакчасы эчендә мунчалары бар. Мунчага җитәрәк тал агачы үсеп утыра.

Өенең урамга караган ягында берничә тирәк үсә. Гарифулла бабайның күпмедер төп кара карлыганы да бар. Күпме генә тырышсам да, шул карлыганга төшеп булмады. Урам якка караган рәшәткә — еш, аралырына кул сыймый. Үрелсәң дә буй җитми кара карлыганнарга.

Зәйнулла абый күңеле белән йомшак, кешегә ярдәмчел. Миңа өч яшьләр вакытта, көтү төшкәндә, мине бер үгез бозау сөзде. Чыбык белән суккан идем бугай. Бәхтегани бабайларның читәненә китереп тери бу мине. Үгез миңа кечкенә мөгезле башы белән китереп бирә — читән сыгылып-сыгылып китә. Шунлыктан миңа бик каты эләкми. Иллә дә акырам инде. Тирә-якта үзем кебек ыбыр-чыбыр бала-чага, кайсысы кая таеп бетеп, читтән генә күзәтәләр. Ә үгез бозау укыта миңа сабакны. Азрак артка чигенә дә башы белән китереп төртә, чигенә дә китереп төртә. Шунда мине Зәйни абый коткарды. Аның үзенә дә сигез-тугыз яшьләр чамасы гына булгандыр. Кулындагы таяк белән манчыды берне үгез маңгаена, тегене «гок» диеп бер генә аваз чыгарды да торып чапты. Зәйни абый мине яртылаш ауган читәннән тартып торгызды да көлә:

— Икенче тапкыр үгезгә суксаң, таякның юанрагын ал, таягың булмаса, сугып маташма,— ди. Бу сүзләр минем исемдә мәңгелеккә калдылар. Инде ул күптән юк. Кырыкка да җитә алмыйча дөньядан китте.

Соңгы елларын ул кибеттә эшләде. Сатучы булып. Матур гына йорт салып, яши башлаган иде, үпкә авыруы белән китте дә барды.

Фәрит абый белән без бер чамада үстек. Хәрәкәткә җитез, чандыр гына гәүдәле булса да, бер сугыш чукмары иде анысы. Үсеп килгән чакларында минем абый Мансур белән Фәрит абый бик тә дуслар һәм... көненә бер генә булса да сугышмыйча калмыйлар. Берсе аеруча истә калган... Бу — кырык беренче елның кышы булырга тиеш. Сугыш башланмаган әле. Азрак кар явып торган кышкы көн. Пожарныйдан өстә генә больнис, аңардан өстә мәктәп. Безнеңчә, ышкул. Мәктәп өч бинадан тора. Берсе — Нариман районына сөрелгән кулаклар йортыннан бергә җыйнап лабиринт кебек итеп салынган бина. Мич ягып, идәннәр юып йөрүче апа исеме белән — Хәдичә апа мәктәбе. Без шунда укыйбыз.

Больнис капкасы рәшәткәле. Көздән ачык калган көенә кар басып киткән. Рәшәткә дә, капка да кар көрте астында. Ишек алдына атлы чана

белән керерлек түгел, бураннан капка баганаларының башына кадәр кар өелгән.

Абыйның бала чагыннан ук кеше үрти торган гадәте бар. Нәрсәгәдер Фәрит абый белән үртәшеп киттеләр. Берсе «Танау» ди, икенчесе «Писер» ди. Киттеләр болар төрткәләшеп. Аннан соң Фәрит абый китапларын сала торган фанер тартма белән минем абыйга берне тондырды. Абый — портфеле белән. Шуннан соң сумкалары белән азрак бәрешеп алдылар да, аларны читкә атып бәреп, кул сугышына күчтеләр. Минем абый көчлерәк, Фәрит абый хәрәкәткә тизрәк тә, җитезрәк тә. Абыйдан тоттырмыйча сугыша белә. Китте сугыш. Киттеләр болар кызып, мин сезгә әйти-им! Икесе дә бүрекләрен, туннарын салып очырдылар. Кышкы ачы суыкта күлмәкчән генә чәкәләшәләр. Утыз, кырык метрлар гына Пожарный. Чатан Фәридә титаклый биреп, шунда йөгерә. Хәле-тыны бетеп барып кергән дә безгә сөрән сала икән:

— Мәрҗ-җҗәм әбекәй-йе-ем! Танау Фәрите белән Мансурың сугыша-а! Канга батып бет-ттелә-әр! Бер-берсен үтерәләр бит инде. Әйдә тизрәк!

Мансур абыйның Танау Фәрите белән көн дә сугышып йөргәненнән әни «гарык булып» туйган. Шунлыктан, бер дә исе китми:

— Ярар, балам, ярар! Үтерешсеннәр, суешсыннар әйдә! Тизрәк үлсә, җаным тынар әллә!

Чатан кызның йөрәге тулы изгелек. Бездән чыга да, карлы сукмактан чатанлый-чатанлый, Танауларга (күрше генә бит!) йөгерә. Хәле-тыны бетеп килеп кергән Фәридәне тыңлагач, Гариф бабай «Чапай мыегын» сыпырып, көлә дә хатынына боерык бирә:

— Бар алып кайт инде син ул шайтан баласын! Тегесенә тимә, кеше баласы бит. Монысына биргәлә, тик арт ягына гына сук. Түлке нык сукма, яме!

Фатыйма әби бальнис капкасы төбенә килеп җиткәнче, Чатан Фәридә (Аксак тиз йөгерер!) сугыш мәйданына әллә кайчан кире килеп тә җиткән:

— Әһ-һә, Танау! Хәз-зер әниең килеп җитә. Ну, изә инде изməңне-е!

Чатан Фәриданең шул сүзләреннән сугышкан ике малай, туннарын, китапларын күтәреп, «сугыш мәйданы»ннан тизрәк таярга тиешләр кебек бит инде. Кая ул! Күбрәк сугышып калыйк, килеп аерганчы дип, сугышуны тагын да көчәйтеп җибәрәләр. Инде бер-берсенә тотынышып сугышкан ике малайның куллары, аяклары кайсысыныкы икәнне белмәслек хәлгә килгән. Икесенең дә борыннарыннан маңкалары белән кан ага. Сөртеп-нитеп тору юк — вакыт әрәм узмасын, күбрәк сугышып калырга кирәк!..

Фатыйма әби килеп җиткәндә, хәлдән таеп, егылыр дәрәҗәгә җиткәннәр иде инде икесе дә. Тик малайлар сугышуының бер кануны бар! Кем алдан туктаса сугышудан, шул җиңелгән санала. Шунлыктан, бу икәүнең туктарга уйларында да юк...

Фатыйма әби килеп тә житте, сул кулы белән Мансурны эләктереп алып, капка баганасы артындагы тапталмаган көрткә очырды да. Шуны күреп авызын ера башлаган малаен беләгеннән эләктерде дә, җилтерәтеп алып кайтып та китте:

— Әйдә, кайт, ристан! Анда әтиең күрсәтер күрмәгәнеңне...

Шәп-шәп итеп атлаган әнисе кырыннан Фәрит, төпле пима эзләре калдырып, сукмак читеннән бара. Алар артыннан Чатан Фәридә Фәритнең бүреген, тунын, сумкасын күтәреп, калмаска тырышып чатанлый...

Учлап-учлап кар куеп, Мансур абый борыныннан аккан канны туктата да, аннан соң күлмәк итәге белән битен сөртә. Сугышканда мин тотып торган бүреге белән тунын кия дә, без сугыш мәйданыннан соңгылар булып кайтып китәбез.

— Әнигә әйтмә, ярармы?! — ди абый миңа.

Тик әни барысын да белә бит инде. Шунлыктан, нәрсә әйтмәскә икәнне аңлап бетермәсәм дә, мин баш кагам...

Бер сәгать чамасы да үтми, тышкы яктан, безнең урамга караган тәрәзәне Танау Фәрите кага. Аны иң тәү әни күреп ала, тәрәзә аша йодрыгын күрсәтеп, әрли башлый:

— Каһәр төшкере Танау! Атаңа охшап, сугыш чукмары! Кер генә әле монда, мин синеме-е, мин сине-е...

Фәрит абыйның авызы колагына җитеп ерылган. Ул минем әнинең «болай гына» ачуланганын белә. Туныының ике кесәсе дә бүлтәеп чыккан. Аларның эче туп-тулы чәбәй! Кузна да диләр. Фәрит абый өчен минем әнинең әрләве, йодрык янавы — юк нәрсә!

— Мәрҗә-әм әбе-ей! Мансурга әйт әле, чәбәйле уйнарга чакыра Фәрит, диген. Тиз чыксын дип әйтә, диге-ен...

— Чыкты ди, менә сиңа хәзер, чыкмый ни. Дәресен карыйсы бар...

Әнинең Танауны тәрәзә аша әрләгәнен ишеткән абый, алдындагы парланып торган бәрәңгесен дә ашап бетермичә, тунын гына эләктерә дә өй эченнән юк та була...

Мин ашап-эчеп чыкканда, болар арасында чәбәй уены бара. Әйтерсең лә бер сәгать кенә элек бу икәү яшь әтәчләр кебек сугышмаганнар да инде...

Көн җылырак булса — урамда, көн суык булса — чәбәйле уйнау Пожарный эчендә такта идәндә бара. Көн бик суык булса да, Пожарный эчендә уйнар өчен тагын бер шарт бар: ул көнне дежурда кайсы бабай? Әгәр дә инде Хәйбулла бабай булса, Пожарный эчендә уйнау юк. Ул малайларны яратмаган бердәнбер бабай. Ә инде калганнары — Вагыйзь бабай («Песәй»), Барый абзый («Ташкергән»), Исхак бабай («Айгыр»), Латыйф бабай («Саңгырау»), Гыйльметдин бабай («Озын Муен»), Сәләх абзый («Учак») булсалар, Пожарный эче — малайларныкы!

Абый белән Танау башлап җибәрүгә, башка чәбәйчеләр дә җыела башлыйлар. Алар: Хәзрәт Зөфәр, Ташкергән Мәҗите, Ташкергән Халите, Папай Нигъмәте, Көрпә Гарифы, Бабач Равиле, Мишәр Гаян һәм чәбәй утыртып, аны җыеп торучы безнең кебек ыбыр-чыбыр. Алары инде: Китек Рәшите, Көчти Күте Равил, Капар Рәшите, Ташкергән Талибы, Хаҗи Балак Риф, Көрпә Фәрите, Какыш Гарифы...

Чәбәйле уйнаганда сугышу юк. Чөнки монда, уен белән бергә, акча кәсебе дә бара бер үк вакытта. Сугыш, кычкырыш — чәбәйле уйнап беткәннән соң гына булырга мөмкин.

### Чәбәй уены

Чәбәйле уены кыш көннәрендә генә уйнала. Күп якларда ул уенны кузна уены диләр. Урысларда — «Игра в бабки».

Чәбәй — сыер тоягыннан чыккан сөяк. Ат, сарык чәбәйләре уенга кертелми. Ә чучка чәбәе уен өчен ярый. Аны чучи чәбәе диләр. Үгез, карт сыер чәбәеннән сәк ясала. Чәбәйнең артыннан кыздырган без белән тишеп керәсең эченә. Андагы җелекне кызган без белән яндырып бетерәсең. Аннан соң шул чәбәйнең корсагын тыштан юеш чүпрәк белән урыйсың да, артына ясалган тишектән, эченә сыек кургаш коясың. Чәбәй эче кургаш белән тулгач, шул кургашны артына азрак өебрәк тә куясың. Кургаш каткач, сәк әзер.

Уен болай башлана.

Сөйләшенгән буенча, бер сәк өчен сайланылган урынга, бернича чәбәй утыртасың, яисә яткырып куясың. Ике сәгең булса, икеләтә куясың чәбәйләрне. Өч сәк белән уйнасаң, чәбәйләрне өч тапкыр күбрәк куясың. Кем алдан, кем арттан бәрә — шобага салына. Аннан соң ат юлына аркылы тезелгән чәбәйләрдән 6—7 адым киткләр дә, чират буенча сәк белән теге чәбәйләргә бәрә башлыйлар. Сәк чәбәйгә тиеп, чәбәй, син кигән чабата озынлыгында өч тапкыр очса — синеке. Алып кесәгә

саласың да, сәгең кайда барып төшкән, шуннан тезелеп торып калган чәбәйләргә тагын бәрәсең. Тидерсәң, өч чабата озынлыгы очса, чәбәй тагын синеке. Тидерә алмасаң, яисә чәбәй ерак очмаса, сәгең шул соңгы төшкән урынында ятып кала. Синнән соң бәргәннәрнең берәрсе, чәбәй бәреп алганнан соң, үз чиратын көтеп яткан синең сәкне дә бәреп ала. Әгәр бәреп синең сәкне өч чабата кадәрле тәгәрәтеп-очырып җибәрә алса, синең сәк «үлә». Син уеннан чыгасың. Ә аңарга кадәр алган чәбәйләрең синең сәкне «үтергән»нең кесәсенә күчә.

Сәк белән чәбәйле уйнаганда, бүгенге көнне дә Эстәрлебашта яшәгән, 1931 елда туган Тайгунов Зөфәргә ләкаб-исем тагылды. Зөфәр — кара кашлы, кара күзле, кызларга тартым чибәр малай. Дуслыкка искиткеч тугры. Өстәвенә, бик тә җор сүзле. Чәбәйле уйнаганда, сәк белән бәргәндә Зөфәрнең сул аягы алда. Уң кулы белән кизәнеп чәбәйгә бәргән чакта, бер үк вакытта Зөфәрнең сул аягы алга шуа. Сул аягын шудыртканнан Зөфәр еш тидерә чәбәйгә, малайлар уенча. Ә чәбәй уенының кагыйдәсе буенча, бәргән чакта аяк кузгалмаска тиеш. Шунлыктан Зөфәр бәргәндә малайлар аның сул аягына басып та карадылар, иелеп кул белән тотып та карадылар. Файдасы тимәде. Бәргән чакта Зөфәр барыбер аягын шудыртып бәрде. Әрлиләр тегене:

— Һе-ей Зөфтери-и! Мулла кебек хәйләлисең гелән! Кузгатма аягыңны, хәрамләшмә!

Мулла, хәзрәтләрне бик ныклап сүккән еллар бу.

Зөфәр ап-ак, энҗе кебек тезелеп киткән тешләрен күрсәтеп көлә:

— Мин шудыраммыни аны, үзе шуа бит аяк.

Аңа башта, шулай аягын шудырып уйнаган өчен, «Хәйләкәр мулла» дип кушамат тактылар, аннан соң ул исем кыскартылып «Хәзрәт» кә әйләнде. Инде 63 яшь белән китте Зөфәр, ә барыбер «Хәзрәт Зөфәре» булып дөнья көтә. Акыллы, төптән уйлап, уен-көлке белән дөнья көтә белә торган авыл картына әйләнеп бара Хәзрәт Зөфәре.

Чәбәйле уйнауның икенче ысулы да бар.

Монысы инде Пожарный эчендә, теге су пешкәкләре (насослары) куелган бричкалар артында, такта идәндә. Ул икенче ысул белән чәбәй уйнау өчен ике шартның үтәлүе кирәк. Беренчесе — көн үтә дә суык булса, урамда суыкта, җилдә түзәрлек булмаганнан без Пожарный эченә керергә тиешбез. Икенчесе, мөһиме, ул көнне Хәйбулла бабай дежур булмаска тиеш. Агара башлаган кара сакал-мыеклы ул бабай ни өчендер малайларны яратмый. Әрләп, куып урамга чыгарып җибәрә.

Чәбәйле уйнауның икенче ысулын кулланганда инде сәк бәреп уйнамыйлар. Сәк урынына сыерның туң тизәгеннән махсус ясалган 2 — 3 сантиметр калынлыгындагы, диаметры 25 — 30 сантиметрлар булган түгәрәк диск кулланыла. Сыер тизәгеннән андый түгәрәк диск ясау өчен бик зур осталык кирәк. Беренчедән, аны табарга кирәк. Чөнки сыер ашаган җирдә ул тапталган була. «Уңышлы чагын» туры китерергә зур агач көрәк тотып торган малайлар да булгалый иде сыер артында. Иң ышанычлысы, сыер ашлы су эчкән чакта була. Ашлы су эчендә бәрәңге кабыгы күбрәк булса, тагын да әйбәтрәк — сыер лакан яныннан озаграк китми тора һәм аңардан чыккан җылы тизәк бер генә урынга төшә. Инде андый чакта сыерны тиз генә башка урынга күчереп куярга кирәк. Аның өчен лаканны күчерсәң җитә. Тизәкне башка урынга күчерергә ярамый — түгәрәклеге бозыла! Туңга әйләнгәнче саклыйсың, башкача чараң юк.

Туң сыер тизәген бик әйбәт итеп үткер балта белән (әтинеке инде!) астын, өстен юнасың. Өске ягына баш бармак белән тотар өчен бер кечкенә ям ясыйсың. Аскы өлешен күпме булдыра аласың, шулкадәр балта белән шомартасың. Аннан соң шул шома ас ягын суга тыгып аласың да (иң шәбе су азрак җылымса булса!), түгәрәкнең астын өскә каратып карга куясың. Инде хәзер өскә карап торган юеш ягына кар

сибәсең. Кар йомшак, яңа яуган кар булырга тиеш. Шул юеш карның туңганын бер ая китмичә саклап торасың да, аннан тагын юешлисең, тагын кар сибәсең, тагын юешлисең, тагын кар сибәсең...

Туңып, әзер булган дискны пожарный бабайлар күрмәгәндә Пожарный диварының штукатуркасына ышкып шомартасың. Андый штукатур дивар Эстәрлебашта тик Пожарный диварында гына! Шунлыктан барлык чәбәйле уйнаган малайлар абыйга ялыналар: Мансур, ышкыт әле! Дисклы берничә малай Пожарный эчендәге такта идәндә уен кора. Сөйләшеп килешенгән буенча, такта идәнгә чәбәйләрне утыртып тезәләр. Чәбәйләре күп булса, бер-берсенә терәп, аз булса — сирәгрәк итеп. Кем артыннан кем бәрә, анысына янә шобага салалар. Шуннан соң чәбәйләр утырган урыннан 12 — 15 метрлар чамасы китәләр дә теге түн дискларны идән буйлап шудырып, чәбәйләргә каратып җибәрәләр. Чәбәйләргә тидереп, кем күпме аудара ала, бар да аныкы.

Атна-ун көндә туктамастан барган чәбәйле уенында берәүләр ота, икенчеләре отыла. Чәбәйләре беткәннәре отканнардан акчага чәбәй сатып алалар, тагын оттыралар яисә оталар. Уендагы осталыгын акчага әйләнеп каткан каеры тун кесәсендә атлаган саен чыңгылдап, синең күңелеңне җылытып йөри башлый.

Минем Мансур абый оста уйный торган иде. Шунлыктан бер атна эчендә йөз пар чәбәй сыя торган тартма шыплап тула. Чәбәй санау минем эш. Тартма тулу белән аны күтәреп, чәбәй уйнаган җиргә чыгам. Абый кушуы буенча, ул куйган хакка мин чәбәйләрне сатам. Аннан соң атна буена без кичләрен көн дә киногa йөрибез. Иң истә калган кинолардан «Гайчи», «Без Кронштадттан». Һәм сугыш вакытында чыккан кинобоевиклар. Соңгыларында инде гел генә немецләрне аталар, үтерәләр, плен алалар. Кыскасы, «безнекеләр» җиңә.

Үсә төшкәч Фәрит абый шофер булып китте. Егет булып җиткәч, саратский кыңгыраулы бер гармун алып җибәрде дә, урамның иң кирәкле, иң шәп егетенә әйләнде дә куйды. Иллә дә матур итеп уйный торган иде инде. Аягында ак чүчинкә. Аның өстеннән кара эрзинкә галуш. Тун изүе ачык, аннан өр-яңа күлмәк күренеп тора. Муенында соры мамык шарф, кулларда мамык пирчәткәләр. Башта — колагы һәрчак күтәрелеп бәйләнгән бүрек. Кесә тулы папирус һәм аны алганда папирус кабы белән бергә чыгып коела торган кәгазь акчалар.

Шофер булып киткәч, Фәрит абый искиткеч матур итеп машина кабинасында утыра белде. Башына кечкенә козыреклы, түбәсендә түгәрәк төймәле кепка кия. Сул күз ягына авыштырып, маңгаена чәчен чыгарып сала, изү ачык, авызда папирус. Машина тәрәзәсе ачык булып, Фәрит абыйның сул терсәге ачык тәрәзә аша азрак урамга чыгып тора. Фәрит абый ул терсәге белән пыяласы эчкә кертелеп куелган кабина ишегенә таянган. Кабина эчендә юлда каршы искән җил уйный, машина руле уң кул белән генә әйләндерелә. Тизлекне алмаштыру өчен уң кул кирәк булса, сул кул иренеп кенә рульне тотып торгандай итә дә, кирәге беткәч, тагын ул вазифасын уң кулның үзенә тапшыра. Ә машина сугыш беткәннән соң булган чокырлы-чакырлы юллардан «җиббәртә» генә! Кузовка эләгү бәхетенә ирешкәнсең икән, кырына тотынып нык утыр...

Фәрит абыйның малай чагыннан ук килгән бер сәер ягы бар. Ул әллә нинди тарихлар уйлап чыгарып, безне авызына каратып сөйли торган иде. Шуларның берсеннән берничә җөмлә генә:

— ... Шулай бер мәлне казакъ далаларына барып чыктык. Бөтен тирә як тап-такыр дала. Су юк, агачның үзен түгел, күләгәсен дә тапмассың. Китеп барган җирдән көпә-көндез безне бер көтү бүре уратып алмасынмы! Күзләре чәшке зурлык, үзләренең койрыклары бөтенләй юк. Шак та шок боларның тешләре. Инде ашарга итәләр безне. Шуннан оз-зын гәүдәле бер казакъ абзые килеп чыкты да үзе башлап бүреләргә һөҗүм

итте. Кулында озын, үткер пычак моның. Бүреләр моны күргәч, безне онытып тегене уратып алдылар. Ник бер курыксын. «Тирарай, тирарай, кх»— дип, сикергән берсенең башын бер селтәнүдә чаба да очыра. Тегеләр моның өстенә сикереп торалар, бу боларның башларын бер селтәнүдә чабып, кисеп төшереп тора...

Без ышанырга да, ышанмаска да белмибез. Кемдер кыюсыз гына сорый:

— Ул казакъ ягына кайчан барганыегыз сез, Фәрит абый?

Ә Фәрит абый күзен дә йоммый:

— Әллә тагын, кайчан булды икән? Югары Оч Шөшле Халиулла бабай да бар иде. Ул белә инде кайчан икәнен, аңардан сорагыз, ышанмасагыз.

Шундый дәлилләрдән соң кая барасың инде ышанмыйча!

## Ташчы Фәттах

Гариф Танауларга каршы урам аша Фәттахетдин Дильмөхәммәтов дигән бабай яши. Йорты урам чатында — Вәрисләр урамы белән Пожарный урам кушылган җирдә. Шул ике урам кушылган Фәттах бабай почмагында зур таш утыртылган. Таш көрәнсу-кызыл төстә булып, Фәттах бабайның һөнәрен исбатлап тора. Ул гомере буенча тирә-яктагы таулардан таш чыгарган. Фәттах бабай ташы тирә-як йортларда яшәүче малайларның очрашу урыны иде. Шунда җыйналабыз һәм киңәш итәбез: бүген нинди уеннар уйныйбыз, кая барабыз, ничек көн үткәрәбез? Гомере буена таш чыгарган Фәттах бабай таш һөнәре белән байый алмаган. Уртача гәүдәле, зур куллы, азрак бөкрерәк кеше иде ул. Ках-кох ютәлләп, капка төпләрендә утыра торган иде сугыштан соңгы елларда. Абыйсы Ибрай Мөчтәк тә, Фәттах бабай үзе дә үпкә авыруы белән киттеләр. Шул таш чыгарганда, җир астында эләккән авыру булгандыр инде.

Фәттах бабайның хатыны Васбия әби озын, чандыр гәүдәле карчык иде. Ике малай, дүрт кызлары бар. Зәйнетдин, Шәмсетдин, Кәшифә, Вәсилә, Фәния. Иң зур кызларының исеме онытылган.

Фәттах бабайның йорты һәрчак бала-чага белән тулы. Монда зур кызының өч яшьлек малае Юрискә дә, әтисен НКВД утырткан, әнисе Әминә Урта Азиягә чыгып киткән Римгә дә урын табыла. Ярлылык белән киң күңеллелек хөкем сөрә иде ул йортта.

Сугыш елларында Фәттах бабай колхоз келәтләрендә каравылда торды. Авыр эшкә алынмады, авыру иде.

Икенче малайлары Шәмсетдин әнисенә охшаган, озын, ябык, чандыр егет. Ул 1926 елда туган булырга тиеш. Сугыш барган елларда урамга алма алып чыгып, шуны пәке белән бүлгәләп, безгә ашата торган иде. Ә үзләренең алма агачлары юк. Авылда да алма агачлары берничә генә. Каян алганын мин бик озак еллар үткәч кенә белдем. Бездән өч чакрым Безгин дигән урыс авылы янында Мердер дигән немецның имениесе булган. Гражданнар сугышы вакытында ул имениене, тирә-яктагы татар, башкорт, урыс җыйналып, туздырып ташлаганнар. Шул Мердер боярының урманын каравыллый торган Келлер дигән немец булган. Аның торган йорты авылдан өч чакрымнар урман эчендә Озын Аклан дигән урында иде. Хуҗасын туздырып очыргач, немец Келлер дә качкан. Шул утырган урында алма агачлары торып калган. Фәттах бабай шуннан ташыган алмаларны...

Фәттах бабай сугыш беткәч озак яшәмәде. Шәмсетдин абзый исә сугыштан кайтмады. Зур кызларының дүрт яшьлек улы Юрис тә сугыш елларында үлде. Гаиләләре таркалып, кайсысы кая китеп беттеләр...

«Урләр аша» повестенда аның турысында яздым азрак. Хәмит абый — урамча Мөтәч Хәмите — Гариф Танауның бертуган энесе. Ул 1907 еллар чамасында туган. Аю табанлы, таза, юантык, уртачадан калку гәүдәле, лап-лоп басып атлап йөри торган, кара чәчле юаш кына абзый иде. Хатыны Бикә апа кечкенә гәүдәле, бик житез хәрәкәтле, уң кулы беләзегеннән чыккан, йөгерә-атлый йөри торган хатын иде. Балалары бишәү — дүрт кыз, бер малай. Зур кызлары Мөхтәрәмә 1931 елда туган. Аннан соң минем белән бер елгы Равил, Фәния, Ләйлә, Халидә. Әтисе сугышка киткәндә Халидә ай ярымлык кына сабый бала иде. Хәзер Мөхтәрәмәдән башка берсе дә юк.

Хәмит абый авыл больницасында атлар карый. Бикә апа колхозда эшли. Без Равил белән еш кына бальниска, аның әтисе янына барабыз, шунда уйныйбыз. Бальнис чүплегеннән төрле формалы, төрле зурлыктагы, төрле төстәге шешәле дарулар алып кайтып, үзебезнең өйнең тәрәзә төбенә тезеп куябыз. Һәм... икебез дә әниләрдән үзебезгә «өлеш» алабыз. Безгә кызык — бер кешедә дә булмаган төрле-төрле шешәләр безнең тәрәзә төбендә генә бит!

Бикә апа балаларына каты. Өйдә Хәмит абый булса да, булмаса да, кирәк чагында балаларын тиз-тиз генә «тәпәләп» ала. Ә минем әни исә әти өйдә чакта безгә тими. Шунлыктан, берәр нәрсә «эшләп ташласам», мин өйгә әти кайткач кына кайтырга тырышам.

Равил уйнаганда, көче житсә-житмәсә дә, гелән генә сугыша. Үзенә эләксә, елый-елый кайтып китә. Озак та үтми, күлмәк итәген ыштан бөрмәсенә кыстырган Бикә апа кулына чыбык яисә таяк тотып, Равилне ияртеп, без әле генә сугышкан жиргә килеп тә житә. Кулындагы чыбыгын һавада селки-селки, безне әрли башлый...

Бикә апа безне ээзәрлекләмәгән чагында чарт-чорт китереп, сагыз чәйни, кая гына бармасын, атлаган уңаена мамык шәл бәйли. Кәжә мамыгыннан. Шәлгә ул осталарның остасы. Бикә апа уйлап чыгарган бик күп үрнәкләре бар мамык шәл бизәкләренең. Ул һәрчак ачык күңелле, һәрчак елмаеп тора.

1981 ел. Мин Эстәрледә ялдамын. Докторлык диссертациясе өчен сугышып, көн яктысын күрмәгән еллар. Ялгызым гына үзебезнең урамнан кайтып киләм. Рәйхан апаларның капка төбендә Бикә апа, Зөләйха апа, Кабан Хәйри хатыны Маһикамал апа һәм тагын берничә апа утыралар. Исәнләшәм:

— Исәннәрмесез, апалар! Ходай тыныч тормыш, озын гомер бирсен үзегезгә!

Гөрләшеп җавап бирәләр:

— Амин, шулай булсын! Рәхмәт җылы сүзеңә!

Минем вакыт та, кәеф тә юк, шунлыктан, туктап тормастан атларга иде исәп. Тик көтелмәгән хәл килеп чыкты. Чатан Рәйхан апа урыныннан торып ук миңа эндәште:

— Зәки улым! Кил әле, безнең янда аз гына булса да туктап, утырып кит. Менә минем белән Бикә апаң уртасына утыр! Икебезнең дә сиңа әйтә торган сүзебез бар...

Мин елмаям:

— Сикрит сүзме әллә?

— Түгел дә, шулай да утыр әле, кил.

Майкамал апаны торгызалар. Мин карышам:

— Торма, Майкамал апа, торма! Мин басып та тыңлый алам. — Юк инде, — ди Майкамал апа. — Сиңа тәкмәгә әйтмиләр бит, утыр инде син, ялындырма. — Мин Бикә апа белән Рәйхан апа уртасына кереп утырам. Алар мине ике яктан кочаклыйлар. Рәйхан апа уң кулы белән, Бикә апа сул кулы белән. Аркамнан. Рәйхан апа мине таң калдыра:

— Бүген бит, Зәки улым, синең туган көнең. Кырык сигез яшь сиңа, 10 июль бит бүген, ялгышмыйммы?

— Юу-ук, Рәйхан апа, ялгышмыйсыз. Миңа, чыннан да, бүген кырык сигез яшь тулды. Ә сез каян беләсез аны?

Рәйхан апа моңсу гына елмая, Бикә апа елый башлый.

— И-и — Зәки, Зәки! Белмәскә тагын. Синнән өч кенә көн элгәре минем Миңлегали исемле улым туды. Аннан соң син тудың. Синнән соң дүрт көн үткәч, Бикәнең Равиле туды. Сез, күрше өч малай, бер атна эчендә туган малайлар идегез.

Рәйхан апаның дә күңеле тула, ул да елый башлый. Мин, аптырап, елаган ике апа уртасында утырам. Ә Рәйхан апа күз яше аша дәвам итә:

— Син менә гомереңне читтә уздырдың. Ваянный булып. Ходайның тәкъдире шулайдыр инде, нәстә генә эшләтмәк кирәк. Син кайтып урамнардан үтеп киткән чагында Бикә белән миңа бәйрәм. Атлавыңа, арка, кулларыңа кадәр истә калдырырга тырышып карап калабыз артыңнан. Исән булсалар, безнең улларыбыз да шушы Зәки кебек булырлар иде, дип. Аннан соң елашабыз. Сагынабыз үзебезнең үлгән улларыбызны, исебезгә төшереп...

— Мин синең улың Миңлегалине белмим бит, Рәйхан апа. Исемдә юк.

— Өч яше тулар-тулмас, эче китеп үлеп китте ул. Теге Юдашкин дигән мал фирмасында. Мал арасы, чебен күп, врачлар юк...

Без барыбыз да тавыш-тынсыз утырабыз. Бикә апа, сулкылдап, өстәп куя:

— Равил дустыңны үзең беләсең инде...

Бу сүзләрдән соң тиз генә китеп булмый һәм мин алар белән байтак утырам...

Бикә апаның улы Равил Бабач минем балачак дустым. Аларның әтиләре Хәмит абый 1941 елның декабрендә Мәскәү өчен барган сугышларда башын салды. Бикә апа аяксыз да күтсез биш бала белән торып калды. Равил аның икенче баласы. Кара чәчле, кара шомырт күзле, малай чактан ук озынчарак гәүдәле, йөгерек малай булды ул. Равилнең укуга бик исе китмәде. Сугыш елларында ук укуын ташлап, колхозда эшләде. Өйләре икәү иде. Хәмит абый яңа өен бетереп, искесен сүтәргә өлгерә алмыйча сугышка китеп барды...

1972 елның август башы. Минем бертуган апамның ире башкорт Ибрай җизни вафат. Телеграмма килгәч, мин аны җирләргә кайттым. Уфа зиратына күмгәч, туган авылга да сугылып чыгарга булдым. Кайткан көнне үк абый миңа «яңалык» сөйли:

— Дустың Бабач Равиле хатыны белән аерылды. Өе Бикә апа белән Равилгә тиде. Сыер, калган мал-мөлкәт, кассадагы акчалары хатынга. Өч баласын ияртеп чыгып китте апаларына...

— Сәбәп нәрсәдә?

Абый күзләрен читкә яшерә. Ачыктан-ачык әйтәсе килми. Авыл дипломатиясе шул инде монда.

— Равил үзе салгалады соңгы елларда. Шул да инде сәбәбе. Аннан соң хатынында да бар бугай инде...

Мин, тавыш-тынсыз киенеп, чыгып китәм.

Равил йортын яңарак кына үзе салган. Ул балта эшен белә. Өе зур, киң, иркен итеп элекке иске өй урынына салынган. Ул шабашта йөреп, яхшы гына калым эшли. Мин барып кергәндә Равил чишенмәгән көенә урын өстендә ята иде. Каткан кием, җиткән кап-кара сакал-мыек, тонган кара күзләр. Мин кергәнгә азрак калкына биреп карап торды да... сикереп торып кочаклап, елап та җибәрде.

— И-и-и Зәки дус, и-и-и, Зәки дус...

Минем дә күңелем тула. Кочаклыйм аны. Ите бөтенләй беткән арык гәүдә. Үзе елый, үзе калтырый. Акрын гына аркасыннан сыйпыйм. Еламаска кирәк. Тамактагы зур төенне йотып, телгә киләм:

— Йә, Равил... Тынычлан, зинһар! Ир бул! Тынычлан!

Байтак сөйләшеп утырганнан соң мин аны үзебезгә чакырдым:

— Әйдә киттек безгә, Равил. Мунча керербез. Бала чактагы кебек кем узардан чабынырбыз. Сөйләшеп утырырбыз. Абый да өйдә...

Равилнең таушалган битендә уңайсызланган елмаю чыга:

— Ки-ит, Зәки. Абзаң нәстә әйтер дә, хатыны нәстә әйтер. Кирәкми, бармыйм...

— Әйдә, әйдә, киттек. Ничәмә ничә еллар утырып сөйләшкән юк. Урамда гына исәнләшәбез дә китәбез. Без бит балачактагы дуслар синең белән.

Равил бик теләмичә генә йөрәген ача:

— Анысы шулай ла ул шулайлыкка. Тик минем кая тәгәрәгәнне үзең күреп торасың бит...

— Йә, инде, Бабач, кыйланма! Күп сөйлисең! Киттек әйдә!

Балачакта үзенә Танау Зәйние таккан ләкаб-исемен ишеткәч, Равил миңа карап ала да, малай чагындагы кебек итеп, ап-ак тешләрен күрсәтеп, тамак төбе белән күңелле итеп көлеп җибәрә:

— Киттек әйдә, Писер, киттек! Әллә бар гомер, әллә юк, дигәндәй, бүген кич синең белән үтсен әле. Синеңчә булсын...

Мунча кереп, ашап-эчкәч, ул миңа әйтә:

— Әйдә, азрак мине озатып куй әле. Сөйләшәсе сүз бар. Киңәш белән ярдәм кирәк.

Үзебезнең урам буйлап акрын гына атлыйбыз.

— Хатын өйне алырга итә миннән. Судка биргән. Апасы судта секретарь бит. Судья үзләренеке. Чакыртты мине. Үзең теләп чыгып кит, ди миңа. Йорт урыны бит әтидән калган. Ә өйне хатын алганчы ук салган идем мин. Мин әйтәм, ике баламны миңа бирегез. Зурларын. Әни белән икәү карыйбыз без аларны дим. Судья әйтә, сиңа балалар тиеш түгелләр, аналарының правасы күбрәк, ди. Син миңа бирәр кыягаз язышып бир әле. Минем грамут чамалы бит, үзең беләсең.

Мин, азрак уйлап баргач, аптыравымны яшермичә әйтәм:

— Бик тә четерекле эш бу, әй. Әйдә иртәгә хәтле мин уйлыйм әле. Иртәгә кичке алтылар, җиләләр тирәсендә мин сезгә керермен. Иртәгә эчмә, ярармы!

— Ярар, дус!

Тик икенче көнне кич ул өендә булмады. Аннан соң да мин аны ике көн туры китерә алмадым. Эшендә дә юк, диделәр.

— Ике көн инде килгәне юк. Эчеп йөри. Кабан Хәйбушлары янындагы пивнушкага бар. Шунда алар бар да, авылның алкаш дигән асыл кошлары.

Сугышка кадәр кибет булган, инде татар авылында пивнушка ителгән, кечкенә тузып беткән ямьсез өй янында кешеләр тулгана. Кызу эш вакыты булуга карамастан, бар да таза, сукса үгез үтерә торган ирләр. Равил күренми. Байтак басып торгач, ике кружка тоткан Равилне бер хатын, төрткәли-төрткәли, ирләр арасыннан аерып алып чыга.

— Башыма бүрек киеп, үземне ир диеп йөрмим дә инде мин, шушылай итеп. Хәйванга әйләнеп беттең бит инде...— Равилнең ачуыннан иреннәре кысылып ябылган, күзләре тоныкх. Сакал-мыегы тагын да ныграк үскән, апасы аны әрли-әрли, каядыр китеп юк була. Мин дәшмичә генә аның сыра эчкәнен күзәтәм. Янына минем өчен таныш түгел бер ир килеп баса да нидер әйтә. Равил аңарга сыра тулы кружканы тоттыра да... шулчак мине күреп ала. Беренче омтылышы — кешеләр арасына кереп китеп, күздән югалу. Тик ул үзендә көч таба, ярым бушаган кружканы иптәшенә тоттыра да минем янга килә:

— Нихәл, Зәки, исәнме?

— Әйбәт кенә әле. Үзең ничек?

— Күреп торасың бит инде.

Мин акрын гына, тирә-яктагылар ишетелмәслек итеп сөйлим:

— Әйтә кайтыйк, Равил. Синең исемеңнән райсоветка гариза язарбыз. Атаң нигезе, үзең салган йорт. Судта нык тор һәм ике баланны үзеңә сора. Мин, әни балалар бергә торачакбыз, диген...

Равил, миңа җавап бирмичә, аяк башларына караган килеш байтак басып тора да, аннан соң гына теләр-теләмәс әйтә:

— Хатынга җиткергәннәр синең миңа килгәнне. Нәрсәләр сөйләшкәнне дә белә азрак. Икенче көнне кичкә килеп җиткән. Синнән алдарак. Балалар хакына әйдә яңадан кушылып яши башлыйк, ди...

Мин, нәрсә әйтергә дә белмичә, Равил янында аптырап басып торам. Азрак дәшми торгач, Равил авырлык белән өсти:

— Син мине гафу ит, Зәки. Ярар инде. Бу көннәрне синнән качып йөрдем мин. Дөньяның кызыгы бөтенләй бетте минем өчен. Кайтсын, торсын. Башкача кабатланмас дип сүз бирде. Өч бала бит, Зәки. Аларны хәерче итеп, кешедән кешегә кулларын суздырып йөртәсе килми. Үзем әтисез үскән дә җиткән. Тагын бер түзеп карыйм әле...

Ул, түземсезлеген яшермичә, артына борылып карый:

— Әйдә, берәр кружка җибәрик.

— Юк, Равил, булмый миннән. Мин китим инде. Иртәгә юлга чыгасы бар. Юлга чыкканда эчкәнем юк минем. Әзерләнергә кирәк кайтып.

— Хуш, алайса! Тагын күрешергә язсын!

Күңелсез генә аерылыштык. Кем уйлаган инде — бу безнең соңгы күрешү буласын. Ай үтәр-үтмәстә гарьлегеннән Равил асылынып үлгән...

Рәйхан апа капка төбендә миннән ничек яшәвемне төпченә, ә Бикә апа тавышсыз гына елый да елый. Мин алар сорашканнарга тулы җавап бирергә тырышам. Байтак утыргач, алар мине җибәрәләр.

— Мәриям түти кötәдер, бар, кайт инде. Синең яшәгәнеңә урам белән куанабыз. Үзең зур укымышлысың, үзең безнең урам малае булып кала бирәсең. Кәпәренеп йөри белмисең. Ходай Тәгалә, теге зур укуыңны яклаганда, тел ачкычлары бирсен инде сиңа. Сөйләгәндә каушама. Өч малай өчен яшисең син хәзер, онытма шуны...

Мин үзебезнең урам буйлап кайтып китәм. Күңел тулган, елыйсы килә...

Равилнең әтисе Мөтәч Хәмите сугыштан кайтмады. Рәйхан апаның ире Миңлебай Капар, Учак Сәләхе — өчесе дә сугышта һәлак булганнар. Идел башланган җирдә, Гороховка дигән урыс авылын немецләрдән кире сугышып алганда үлгәннәр өчесе дә.

Бикә апа биш бала белән тол калды. Хәмит абый сугышка киткәч, ул елый иде:

— Ничекләр итеп кенә яшәрбез икән инде-е!? Мин бит бәрәңге дә алалмыйм — кулым гарип би-ит! Бөтен дөньяны Хәмитем алып бара иде би-и-ит...

Бикә апа барлык балаларын да үстерде, үзенчә кеше итте. Кызларын барысын да кияүгә бирде. Равилне ике тапкыр өйләндерде. Соңгы елларын олы кызы Мөхтәрәмәнең зур улы белән дөнья көтте. 1984 елны мине урамда туктатып, өенә алып керде. Ул инде безнең соңгы күрешүебез булды. Хәзрәт Зөфәрнең әтисе — Бикә апаның җизнәсе Вәрис бабай салып биргән кечкенә өйдә мине кунак итте. Өй эче җыйнак, пөхтә. Бикә апа бик нык картайган. Бертуктаусыз елый. Аерылышу күңелсез генә булды:

— Хуш инде, Зәки, башкача күрешмәсәк, бәхил бул. Гаеп итеп китмә инде мине. Сине күргәч, елыйм да елыйм. Бигрәк тә Равилем күз алдымнан китми, сине күрсәм. Бик ярата иде ул сине. Зәки дип, үлепләр китә торган иде. Өзакламам, ахрысы. Бәхил бул. Рәхмәт инде сиңа, керүеңә...

Инде Бикә апа, аның биш баласының дүртесе дөньяда юклар...

1993 елның 10 июлендә Эстәрлебашта минем алтмыш яшьне уздыру тантанасына җыелган халык арасында Мөхтәрәмә апа да бар иде. Ба-

шыннан елый башлаган иде, азагына кадәр яше туктамады. Аңарга карап минем дә күңелем тулып, елыйсыларым килде...

Равилдән калган өч бала дөнья көтәләр: Рауза, Салават, Миләүшә. Алар Равилнең оныкларын үстерә...

## Заһит Таз

Бабач Равилләренә урам аша каршы Заһит Таз дигән бер бабай яшәде. Ап-ак сакал-мыеклы, бөкресе нык кына чыгып торган кыска гәүдә. Халыкка бик күп зыян китергән карт иде, мәрхүм. Аны сугыш елларын белгән авылдашлар әле дә авыр сүз белән искә алалар. Теге дөньядагы урынын Ходай үзе билгеләсен инде. Оҗмахта булсын урыны, дип әйтергә минем дә телем бармый.

Сугыш алдыннан ук ул карт иде инде. Ап-ак сакаллы, башы чыннан да таз иде бабайның. Мин аңарга карап, һәрчак Габдулла Тукайның «Таз»ын искә төшерә торган идем. Үзе ках-кох йөткерә, үзе, авылча әйткәндә, «тәмәке суыра». Ниндидер яшел тәмәкене тел астына сала да, шуны байтак кына суырып утыргач «черт» итеп читкә төкерә торган иде. Ямь-яшел, тавык тизәге төсле нәстә чыга торган иде авызыннан. Без ул карттан җирәнә дә, курка да торган идек... Кичләрен Пожарныйга килеп утыра. Күрәсең, үзе эшчән булгандыр. Урам якка чыккан тәрәзә төбендәге бакчасында кура җиләге үсә. Авылда иң шәп кура җиләге Заһит бабайныкы икәнен мин төгәл беләм. Чөнки без — Түбән Оч малайлары төшмәгән бакчалар авылда юк диярлек иде. Җиләк җитә башласа, безнең исәп ничек кенә булса да кура җиләген кереп ашау. Тик җиләк аз гына саргая-агара башлау белән Таз (Без шулай дип әрлибез бабайны андый чакларда) бакчага Актырнак исемле сарык кадәрле этен кертеп, бакча ишеген бау белән бәйләп куя. Без бакча янында туктый башласак, Актырнак ырылдап, үзенең барлыгын белдереп, безнең кура җиләгенә булган нәфсене тиз юкка чыгара. Инде бик тә кура җиләге ашыйсы килсә, без берничә ташбашлар бергә җыйналып, Югары Оч төпкеленә китәбез. Андагы кура җиләгенең күплеген дә, эрелеген дә сөйләп аңлатырлык түгел!

Заһит бабайның тәүге хатынынннан дүрт баласы булган: Нәсибулла, Сапкамал, Хәйбулла, Миңсылу.

Сапкамал апа ире белән Эстәрлетамакта яши. Аның малайлары җәй Заһит бабайга кунакка кайталар. Барлык кала малайлары кебек, алар да усаллар, сугыш чукмарлары. Безне, юаш авыл малайларын, сәбәп булса да, булмаса да җәберлиләр, кыйныйлар. Бер малайның исеме Гыйбадулла иде. Кыйналу безне дә туйдыра. Малайларның кайтуына ай тирәсе үткәч, Танау Фәрите оештырган сугышта без ул ике малайны, чебенле уйный торган таяклар белән ярып, Заһит Таз ишек алдына куып кертәбез дә, шуннан чыгармыйбыз. Ни өчендер Актырнак та безнең яклы. Күрәсең, усал малайлардан аңарга да көн булмагандыр.

Нәсибулла абый гражданнар сугышыннан соң Ерак Көнчыгышта яшәде. Чөнки ул 1918 — 21 елларда аклар армиясендә булган һәм иң соңгы чиккә кадәр шунда сугышып, Тын океан ярларына барып тергәлгәч кенә кызыллар кулына әсир төшкән.

1918 елны, авыл аша узган Блюхер отрядын куып, аклар килгән. Шул чакта иң беренче булып акларга доброволец итеп, улы Нәспине Заһит Таз яздырган:

— Аллага мең шөкер! Бу Ходай каһәре төшкән влачның беткәнен күрдек бит әле. Аллага шөкер!

Пленга эләккәч, Нәсип абзый тайгага урман эшенә озатыла. Шунда үзе кебек бер бәхетсез бай кызы Нәзирәгә өйләнеп, НКВД күзәтүендә

дөнья көтә башлый. Ун елы тулгач, авылга кайтып, йорт сатып алып яшәп китә. Тик НКВДны яхшы белгәнгә, 1937 елның җәйге бер төнендә ат яллап, авылдан чыгып кача һәм киредән Ерак Көнчыгышка китә.

Сугыш беткәч, 1946 елны ике кызын, бер малаен, Нәзирә апаны ияртеп авылга кайтты. Квартирдан квартирга йөреп, үз йорты булмыйча, үпкә авыруы белән үлеп китте. Нәсип абый үлгәндә Заһит бабай исән иде әле. Карт иде инде. Тик улына мәрхәмәт күрсәтмәде. Мәрхүм Нәсип абзый теге Герман сугышыннан бик оста итеп кәртле уйнарга өйрәнеп кайткан. Ярты авылны акчага кәртле уйнарга өйрәткән.

Заһит бабайның икенче улы Хәйбулла фин сугышына китеп һәлак булды. Ничәнче елны туган булгандыр, әйтә алмыйм. Тик яңа гына өйләнгән иде. Ялгышмасам, колхозда хисапчы булып эшли иде... Сугышка аны бик каты суык көнне озаттылар. Бер ялгызын Бабач Равиле, мин һәм Заһит бабай идек аны озатучылар. Бик шәп «Уфимский» дигән нәсел айгырын җикте Пожарный бабай Гелметдин. Без Бабач белән «Уфимский» җигелгән кашавай чанага утырып, Пожарный ишеге алдыннан колхоз идарәсенә кадәр барабыз. Утыз-кырык метрлар чамасы ара. Аның каравы айгыр җигелгән чанада бит! Тагын нинди малайларга тигән ди мондый дәрәҗә!

Толып кигән Хәйбулла абый, кулбашлары калтырап елаган әтисен кочаклап үпте дә, чанага утырып китеп барды. Хатыны Гөлсем апа ни өчендер юк иде. Без, Бабач Равиле белән икәү, Хәйбулла абыйның «ак финнәр белән сугышка китү бәхетенә ирешүенә» күзебез кызып, салкын урамда басып торып калдык. Атлы чана карлар туздырып Кала юлы белән уңга борылып күздән югалгач, Равил миннән сорады:

— Без үсеп, Хәйбулла абзый кебек сугышка китәрлек булганчы, сугыш бетмәс микән?

Сугыш берничә айдан бетте. Хәйбулла абый кайтмады шул китүеннән...

Заһит Тазны авылда каһәрләп телгә алучылар бүген дә күп.

Авыр сугыш еллары. Ирләрнең күбесе сугышта. Колхозның игенен кырып-себереп алып бетереп торалар: «Икмәк — фронткХна!» Ачлыктан котылыр өчен, зәһәрләнеп килгән суык кышка каршы торыр өчен аз гына булса да азык кирәк. Нинди генә булса да! Бала-чага, карт-коры урылып буш калган иген кырларына башакка йөриләр. 1941 ел азагында Мәскәү сугышында аякларын туңдырып, аяк бармаксыз кайткан Карагыш авылы мишәре Йомадыйлов Зиннәт — безнең «8 март» колхозы рәисе. Буйга ярсаң, ике кеше чыгарлык таза Чолык Зәйнәбе — финагент. Райкомнан безнең колхозга «палнамучын». Шушы ике кеше Заһит Тазны колхоз яланнарын сакларга билгеләделәр. Заһит бабай, карт булуына карамастан, ат иярләп менә, кулында каеш камчы. Көннәр буена ат өстеннән төшмичә, ул ялан-кырларны бер итеп йөреп чыга, аларны «саклый». Башакка чыккан бала-чаганы, әби-сәбине камчылап, әшәке сүзләр белән сүгеп кырдан куа. Башаклы капчыкларны тартып ала һәм аларны күпләп ат ияренә бәйләп, алып кайтып китә. Исендә калганнарын идарәгә чакыртып «җанын алдырта» Заһит Таз. Аның бу «колхоз кырларын сыйныф дошманнарыннан (Чолык Зәйнәп бәясе) саклауга» еш кына Йомадыйлов белән Чолык та кушылалар. Соңгы икесе инде ат менеп, Заһит Таз кебек камчы селтәп кумыйлар халыкны, рессорлы тарантастан төшмичә генә, колхозның нәсел айгырын җигеп кенә куалар. Дилбегә Йомадыйлов кулында. Заһит Таз, ай-һайлап, халыкны өере белән кыр уртасына җыя. Чолык җиргә төшмичә генә «халыкны» куркыта. Халык дигәне — ач бала-чага, таягын тартып алсаң тәгәрәп китә торган әбисәби. Бик истә калмаган, шулай да Чолык Зәйнәбенең «рече» болайрак була торган иде:

— ... Данлы, шанлы Кызыл Әрмиябез ач булганнан гурыт арты гурытларыбызны нимес-фашсит капкорсакларга ысдавайт итеп атступ

ясаганда, сез монда ил корытып, «Гучмуй март» калхозуның иген кырларын талыйсыз...

Шул чакта картаеп бөкресе чыккан, берничә малаена үлем хәбәре алган берәр карчык телгә килә:

— И, Зәйнәп кызым! Ачбыз бит, кышын ничек чыгарбы-ыз! Бала-чага хакы өчен генә рөхсәтләреңне бирсәнә. Барыбер кар астында кала бит...

Тик азык күплектән симергән Чолык аны ишетми дә:

— ... Понимаешь! Барыгыз кайтыгыз! Капчыкларыгызны праулинжыга кертегез. Югыйсә, карагыз аны — өтермә барыгызга да. Иртәгә үк...

Кеше бастырып, 1943 елның җәендә Йомадыйлов белән Чолык колхозның кара нәсел айгырын яндырып үтерделәр...

Чолык Зәйнәбе, Йомадыйлов, Заһит Таз аркасында 1942 — 44 елларда безнең Эстәрлебашта бик күп кеше ачтан үлде. Ябрәй Хәсәне дип йөреткән абзыйның сигез кешелек гаиләсеннән бер генә кызы исән калды. Бүген дә авылда яшәгән Фатыйма апа ул (Кара эшләргә дә шаһитлар кала!).

Заһит бабай (таз диясе килә барыбер!) мәңгелеккә килмәгән икән. Илленче еллар башында китте бугай. Бик йончыды, чак йөрер хәлдә калды. Теге яшел тәмәкене үлгәнче «суырды»...

## Шагали Барый

Равилләрнең ас ягында Шагали (Шаһгали) дигән озын буйлы абый яши. Аны авыл, Шагали Барые дип тә, Озын Барый дип тә йөртә.

Үзебезнең авылныкы булса да, кеше белән бик аралашмыйча, читтән килеп, авылда үзенә урын таба алмаган кешедәй яшәде ул. Сәбәбен мин бик күп еллар узгач кына белдем. Әтисен кеше талап үтерүдә гаепләп, Себергә, каторгага озатканнар икән. Бер гаепсезгә, нахакка. Үсеп килгән малайга «каторжник малае» дип исем такканнар. Шагали бабай кайта алмыйча Себердә үлеп калган. Үлгәндә дә үзенең гаепсез икәнен ант итеп әйтеп үлгән. Атасы катыр киткәч Барый абый кеше белән аралашмас булган.

Ләкаб-исеме көчле булган Эстәрлебашта «Озын»нар өчәү иделәр: Озын Барый, Озын Фәйзери, Озын Хәй.

Озын Фәйзери сугыштан кайтмады. Барый абый кайтып, байтак яшәп дөньядан китте. Озын Хәй әле дә исән. Тик симергән булганлыктан, аны Озын Хәй диючеләр сирәк хәзер авылда.

Озын Барыйның хатыны — Зәйнәп исемле юантык кына, түгәрәк апа. Сугышка кадәр өч балалары булды: Габделхәй, Зәйтүнә, Ринат.

Барый абый кайда эшләп көн күргәндер, тик ул колхозда эшләмәде. Сугыштан исән-имин кайтты. Кече малае, үскәндә, аякка азрак зәгыйфь иде. Озак кына атлап китә алмады. Йөри башлагач та вак-вак кына атлап, ике аягына да титаклап йөри. Уйнарга чыкса, сорыйбыз:

— Ринат, үскәч кем буласың?

Ринат безгә нинди җавап кирәген белә. Шунлыктан һич тә көттермичә җавап бирә:

— Нәби Бүксә булам.

Нәби абзый, аяклары зәгыйфь булганнан, сугышка бармый калган безнең урамның бердәнбер ир кешесе. Тулт-мулт атлап йөри. Ринат үзенең киләчәген шуңардан күреп белгәндер инде. Тик ул үсә төшкәч, Барый абый кебек озын буйлы, чибәр, таза егет булып китте.

Барый абый белән Зәйнәп апа балаларын бик әйбәт, инсафлы итеп үстерделәр. Бар да белемле, сәләтле, эшкә тырышлар.

Инде икесе дә юклар хәзер. Барый абый соңгы елларда салгалый башлады. Шуңа ник бер тавышы чыксын Зәйнәп апаның:

— Аллага мең шөкер! Исән-имин кайтты сугыштан. Ирләрдә аз-маз булгалый инде ул. Заманасы заманамыни. Ай-һай, зәһәр бит еллар. Барыем минем менә дигән ул. Иншалла! Исәнлеген бирсен Ходай үзенә.

## Миңлебай Капар

«Үрләр аша» повестендә Миңлебай абзый белән Рәйхан апа турында байтак язылды. Миңлебай абый, чыннан да, Идел башланган җирдә, Гороховка дигән авылда җирләнгән. Язмыштыр инде. Миңлебай Капар, Мәтәч Хәмите, Учак Сәләхе Уфа янындагы Алкино хәрби лагереннан фотога төшеп җибәргәннәр. Бу — аларның соңгы фотолары. Миңлебай абый уртада, «Привет из Алкина» дип язган такта тоткан. Ике дусты ике ягында. Инде өчесе дә бер кабердә яталар. Туган авылдан читтә, урыс җирендә. Нәрсә калгандыр инде безнең арысландай татар егетләренә ул чит-ят якларда?!

Рәйхан апа да инде дөньяда юк. Икенче уллары Габдрәхим дә үпкә авыруы белән дөньядан китте. «Үрләр аша» повестенда — катыкка буялып беткән, бодай өемендә утырган, ялангач корсаклы кечкенә малай. Иң кечеләре Сәбилә Салават шәһәрендә бугай. Зур уллары Габдрәшит авылда яши, колхозда эшли. Әтисенә охшап, таза гәүдәле, бик чибәр кеше. Малайлары дүртәү бугай: Миңлебай Капарның кызу канлы нәселе, Аллага шөкер үрчеп ята.

Миңлебай абый турында язылмаганнары да байтак. Менә аның турында бер кечкенә тарих.

Утызынчы еллар башында, Эстәрлетамакка әле тимер юл килмәс борын, эстәрлебашлар Раевкага транспорт куганнар. Атлы арбалар, бричкалар белән. Бер башкорт авылында куна туктаганнар. Унлап олау булганнар авылдан. Миңлебай абзый шул авыл башкортлары белән алты литр яңа суырткан бал эчәргә бәхәс тоткан. Эчеп бетергән дә бетерүен, йөрәге тибүдән туктый башлаган. Миңлебай үлә икән инде теге балдан. Бер башкорт бабае кушуы буенча, иптәшләре моны күтәреп, урам коесы янына алып чыкканнар да, ат эчерә торган улакка анадан тума шәрә көенә салганнар. Шуннан соң күп итеп улакка салкын кое суы тутырганнар. Миңлебай абзый аңына килеп, тере калып, улактан чыккан. Иртәгесен юлга чыгар алдыннан атларны теге улак янына эчерергә алып чыкканнар. Атлар суны эчмиләр икән. Тәмләп карасалар, су баллы. Миңлебай абыйның тире белән бергә, бал да чыккан...

Икенче тарих.

1941 елның августында Миңлебай абзый сугышка китте. Раевкага утыз меңнән артык сугышка китүчеләрне җыйганнар. Янәсе, сугышырга өйрәтәләр инде. Халык ач. Ашау юк. Бик каты урлашу бара икән лагерь начальствосы арасында. Җыелган халык ачтан шешенә башлаган. Бер төркем кешеләрне Мәсәй дигән авылга иген җыярга йөртәләр икән. Сафларга тезеп. Шул кешеләр арасында эстәрлебашлар да булганнар. Миңлебай абый да бар икән. Сугыштан исән кайта алган авылдашы сөйли:

— Иртән алтыда уятып, кәбестә суы гына эчерәләр дә, сафларга тезеп, «Әрмия, әзер бул, буржуйлар сузалар кул»ны акыртып җырлатып, алып китәләр безне эшкә. Миңлебай Капар иң артка баса да, аяк очларын эчкә каратып Түбән Оч гарип Камәр бабай булып чатанлый инде. Ике аяк башы эчкә караган — тере гарип инде бу. Инде чатанлый, инде чатанлый. Артта калмас өчен сикереп-сикереп киткән була. Әй, безне карап торган хатын-кыз моны кызгана, инде кызгана: «Бу гарипне нәстә дип алганнар инде, ике аягы тиң гарип бит, юньләп йөри дә алмый». Балаларын йөгертәләр, үзләре йөгерәләр болар. Ипи, бәрәңге, сөт-катык

ташыйлар Миңлебайга. Барган уңайга гына күтәрә дә эчә бу чүлмәктән сөт-катыкны. Ипине, бәрәңгене куенына тутыра. Кырга килгәч, Эстәрле егетләре бүлешеп ашыйбыз теге җыйганны...

Өченче тарих.

Нәрсәдер уйнаганда Миңлебай абзыйның Габдрәшитенә бергәләп алдык бит. Китте бу кайтып. Без аны-моны абайлаганчы, озын юкагач күтәргән, әй йөгерә Миңлебай абзый безгә карап. Урам аша йөгерә, без уйнаган Мәҗитләр йортына. Безгә төртеп күрсәтеп, артыннан әләкче малай да йөгерә. Без озак уйлап тормастан, чаж Мәҗитләрнең абзар башына. Юкагач күтәргән Миңлебай абзый (Бабач Равиленең чыбык кына торткан әнисе Бикә апа түгел ул, Капар Миңлебае диләр аны) юкагачы белән безнең арттан җиппәрә генә. Бездән дә шәп тизлеге, елгырлыгы... Кая качарга Капардан? Без аска сикерешеп төштек тә, Мәҗитләрнең бурап ясаган бәдрәфләренә кереп, эчтән бикләндек. Тартып карады бу ишекне. Безнең кот ботка китте — торабыз тавыш-тынсыз. Кайсыбыздыр еларга булыша, тик куркуыннан аны да булдыра алмый. Тагын тартып карады да, китте бу бәдрәф башына менеп. Түшәм агачлары арасыннан юкагачын тыгып безне төрткәли. Ябыштык барыбыз да теге юкагачка. Төрттермибез тегенәрдән. Аптырагандыр инде, күлә бу үзе. Моны күреп, Мәҗитнең әтисе Барый абзый чыккан өеннән. Шул коткарды безне:

— Күрше, әллә минем бәдрәфне сүтәсең инде?! — ди. Миңлебай абый дәшми-нитми китте чыгып. Юкагачы безгә калды.

Дүртенче тарих.

Узган ел гына 88 яшендә дөнья куйган Миңлеәхмәт бабай сөйли:

— Утыз бишенче ел. Калага транспорт йөрибез. Кемдер котырткан бит Миңлебайны: Миниәхмәт Пәрәү, мин Капар Миңлебаеннан курыкмыйм, шуның нәстәсеннән куркасыздыр инде дип әйдә дип. Мин әйткәнмен, янәсе, Миңлебайны, коры куык кына бит ул, дип. Күлгәннәр тегенәрдән. Конный Хутор дигән урыс авылы янында, Эстәрле елгасы буенда кунарга җыенабыз. Минем пар ат. Тегеләрне тышаулап җибәрдем дә, камыт-дугаларны җыям. Миңлебай килде дә, әйтү-нитү юк, са-алды миңа берне! Киттем мин тәртәләр аркылы тәгәрәп. Сикереп тордым. Син нишлисең, дим. Килә бу өскә менеп. Дуга ятадырые, ал да, кундырдым моның корсагына берне. Ике тәртә арасына бөгелеп утырды бу. Байтак утырды инде. Мин азрак шүрли дә төштем, әллә ныграк тондырдым инде, дип. Торды бу. Күлмәген ачып корсак тирәсен сәрмәде дә миңа карый. Азрак елмайды да әйтә:

— Әл дә дугаң бик юан түгел икән әле, Миниәхмәт абзый! Үтерер идең, — ди. Икәүләшеп көлештек тә, китте бу. Кич буе теге миңа каршы котырткан кешене эзләп йөргән. Табалмаган. Анысы урыслар янына барып кунган. Селезневка авылы урыслары иде. Миңлебай анда баргач, юк дип җибәргәннәр тегене. Көче бик күп, иллә дә беркатлы, капаррак бер җан иде инде, мәрхүм. Кайталмады бит сугыштан. Менә хәзер булсын иде авыл урамнарына ямь биреп, бабай булып йөрер өчен. Мәчеткә йөрер өчен...

Миңлебай абыйның истәлеге булган бу кечкенә тарихлар сугыш үлемнәрен ерып кайта алмаган ир-егетләр истәлеге булсын.

## Сәхи бабай

Шагали Барыеның ас ягындагы йортның хуҗасы Сәхиулла бабай Тайгунов иде. Авылча әйткәндә, Ташкерган Сәхи.

Йортына җилкапканы ачып кергәч, сул якта зур булмаган агач өй. Түбәсе салам белән ябылган. Сәхи бабайның хатыны Мәфтуха

әби — кечкенә гәүдәле, ярым сукыр карчык. Аларның ике кызы, дүрт малае бар: Зәйтүнә, Хәйдәр, Гәүһәр, Халит Талип, Наил. Кечеләре 1940 елгы иде... Сәхиулла бабай үзе 1915 — 18 елларда немецтә әсирлектә булып, Мюнхен каласын күргән кеше. 1981 елны мин авылга ялга дип кайткач, урамыбызда Сәхи бабайны очраттым. 1952 елны Мәфтуха әби бөтенләй сукырайган. Алтмышынчы еллар башында барлык балалары авылдан чыгып киткән. Зәйтүнә апа белән Хәйдәр абый үз дөньялары белән аерым яшиләр. Үз нужалары үзләренә җиткән. Бала-чагалары күп икесенең дә. Халит, Талип, Наил — Урта Азиядә. Гәүһәр апа да шунда. Берсенең дә кайтырга исәбе юк. Шуннан Сәхи бабай балаларының, карчыгы Мәфтуха әбинең ризалыгын алып, икенче тапкыр өйләнә. Каранай дигән авылдан бер балалы, ире сугыштан кайтмаган бер башкорт бичәсен ала. Кырык яшьләр чамасында бу хатын. Чыгуына дүрт ел дигәндә, бу апай Сәхиулла бабайга бер-бер артлы бер малай белән бер кызны тупылдатып табып та бирә. Сәхи бабай малайга теге герман сугышыннан кайта алмаган үзенең дусты Абдулланың исемен куша. Абдулла бабакай — минем әтинең алты яшькә кече бертуган энесе. Ул 1918 елда февраль аенда Псков каласы янында немецләр белән барган сугышларда бер аягын өздереп, Псков госпиталендә үлгән...

— Әхмәт Зәки, исәнме, улым?! — диде Сәхи бабай, мине әллә кайдан ук танып алып.

Исәнлек-саулык сорашкач, ул миңа һич көтмәгәндә сорау бирде:

— Син картәтиең Зәйнетдин бабаңның каберен беләсеңме?

— Юк.

— Әйдә, киттек зиратка. Каберен күрсәтермен, коръән чыгарбыз. Икәүдән икәү генә йөреп кайтыйк әле бер. Әллә бар гомер, әллә юк... Мин сине кайчан күрәм әле тагын...

Авыл урамы буйлап зират ягына атлыйбыз. Сәхи бабай миңа сорау бирә:

— Син, Әхмәт Зәки, мин кигән күзлекне таныйсыңмы?

Карыйм күзлеген. Таныш кебек түгел бер дә. Кара кырлы, матур гына күзлек.

— Юк, Сәхи бабай! Танымыйм бит!

— И-эх, сезне-е! Әтиең Лотфулла абзый күзлеге бит! Бер ун ел бардыр инде, әниең Мәрьямнән сорап алдым: «Бир әле миңа Лотфулла абзыйның күзлеген, төсе итеп киярмен», — дип. Кигәч, бер ел чамасы юньләп бер нәрсә күренмәде. Хәтта көтүдән кайтып килгән үземнең сыерны да танымый идем. Танымасам да, күзлекне салмадым. Аннан соң җайлап-җайлап күзләрем өйрәнеп китте. Иллә дә шәпкә чыкты, мин сиңа әйтим. Вич күрәм хәзер.

Андый чакта күләргә дә елмаерга да ярамый. Җитди төс белән баш кагам, ризалашам.

Зират капкасы бикле. Сәхи бабай, зират ачкычын — каршыда яшәгән Баһау абзыйда, ди. Керәм — өйдә юк. Минем ярдәм белән Сәхи бабай зиратның таш коймасына үрмәли. Сөбханалла, күз тимәсен, аңарга бит инде 89 яшь. Ак кылганнар белән капланган зират эченә төшәбез дә күпсанлы каберләр арасына кереп югалабыз. Монда бар да үзебезнекеләр ята!

— Менә монысы минем улым Хәйдәрнең кабере, — ди Сәхи бабай, бер кабер янына тезләнеп. — Ята, җанкисәгем!

Азрак калтыранган тавыш белән дога сүзләрен укый...

«Карбыз сугышы»нда язылганча, Хәйдәр абый сугыштан бик каты җәрәхәт белән кайтты. 1944 елның җәендә. Аның түбәсеннән алып, җилкәсенә кадәр ярты кул киңлегендә баш сөяге юк иде. Баш түбәсендәге юка гына, чәчсез тиредә кан тибеше күренеп тора. Бер ел чамасы узгач, Сәхи бабай белән минем әнинең чәй янында сөйләшкәннәренә шаһит булдым.

— Мәрьям, мин сиңа кинәшкә кердем. Үтенеч дияргә дә була инде. Син миңа ярдәмче бул инде.

— Сөйләп кара, Сәхиулла абзый, кулдан килсә...

— Теге Ябрәй Хәсәне бар иде бит әле?

— Әй-йе. Бахырлар, кырык өченче елның язында кырылдылар бит бала-чагалары белән, ачлыктан...

— Шулай инде. Хәзер йортында бердәнбер кызы, Фатыймасы гына калды бит. Ялгыз, инсафлы бала...

Әни сүзнең кая таба барганын чамалый, ахрысы, тик дәшми. Сәхи бабай азрак сүзсез утыра да дәвам итә:

— Шул баланы, димләп, Хәйдәремә алыйк әле. Керсен шул Фатыймага йортка. Ул бала да ялгыз, Хәйдәрем бик эшчән минем...

Әни Сәхи бабайга чәй ясый, ул сөйләп бетергәч, акрын гына тавыш белән сорый:

— Мин димләрмен димләвен. Ә бит Хәйдәрнең башы? Кияү булгач та алай-болай булып китсә, Фатыйма миңа нәрсә дияр?

Сәхиулла бабай көрсенә, тик тавышы күнелсез түгел.

— Син димлә аны. Сүзләрен үзең табарсың. Мин өйрәтә торган хатын түгелсең. Үзең уйлап, кирәген сөйли беләсең...

Икенче көнне әни мине Фатыйма апаны алырга җибәрде.

Фатыйма апа, әни сине тиз генә килеп җитсен әле, сөйләшәсе сүз бар, дигәнгә миңа сынап карады да өенә чакырды. Мин Көчти Күтә Равиле белән идем. Кердек өенә. Фатыйма апа икебезгә дә берәр кипкән корт бирде. Аркамнан сөеп сорый:

— Акыллым! Белмисеңме, нәрсәгә чакыра икән әниең?

Минем кулга корт эләккән булса да, серне ачмадым. Тиз килергә кушты, дидем дә чыгып ычкыну ягын карадым. Кайткач, Равил белән икәү Пожарный бабайлар йоклый торган бүлмәдә кармак сүтәбез. Ә фанер диварның теге ягында әни белән Фатыйма апа сөйләшәләр. Әнинең үгетләгәнен Фатыйма апа сүзсез генә тыңлады да, оялчан тавыш белән кыяр-кыймас кына сорады:

— Вакытым җиткән инде, анысы шулай, Мәрҗәм әби. Тик ул Хәйдәрнең башы ярык, анда сөяге бөтенләй юк диләр бит. Үлеп-нитеп китсә, мин тол булып калсам? Бала да булса?

Минем әнинең тавышы күңеллеләнә. Ул Фатыйма апага әйбәт итеп кыска гына аңлата:

— Иркәм, үзең күреп торасың, авыл тулы кияүсез кыз-кыркын. Ә егетләр сугыштан кайтмыйлар. Ул бетәр инде бу ел җәйгә, бетми булмас. Тик кайтырга бит тереләре юклар. Хәйдәрне үләр дисең син. Ходай кушса, үлмәс. Инде үлә икән, ир тәмен белеп калырсың да, аннан балаң булыр. Башы имгәнгән икән, йөри бит әле үз аяклары белән. Менә дигән итеп эшли өстәвенә. Сөйләшә. Ә башка җире (әни кыска гына итеп көлеп ала), сиңа кирәге исән. Үзең чибәрлек белән башка кызлар белән ярыша алмыйсың (Фатыйма апа — эре шадра). Ходайга тапшыр да, тәвәккәллик...

Фатыйма апа чыкты Хәйдәр абыйга. Бик күңелле, тигез итеп яшәделәр. Бергәләшеп утыз елдан артык гомер кичерделәр. Инде төп йортында, Ябрәй Хәсән нигезендә Фатыйма апа улы Мансур карамагында картлыгын каршылый. Юан, таза, шадралары шомарган җитмешне куган әбидә элекке нечкә талчыбыктай гәүдәле оялчан Фатыйма апаны тануы авыр. Тик ул үзе мине тиз танып ала, әллә каян, үз итеп, килеп күрешә...

Сәхиулла бабай зират уртасындагы бер матур таш куелган каберне миңа күрсәтә:

— Менә бу синең картәтиең Зәйнетдин абзыйның кабере була инде. Егерме өченче елны тамагы шешеп үлде. Алтмыш ике яшендә иде. Ташын Хәйрулла бабакаең утыртты.

Мин картәтинең каберен беренче тапкыр күрәм. Таш матур итеп эшләнгән. Тик урта бер җире, кырыйданрак арттан ку учыкадәр булып кителеп төшкән. Утыруы туры, башка ташларга караганда язуы да матуррак кебек. Мин таш янына чүгәләп көзге кояшта җылынган таш өстен сыйпыйм. Гарәп хәрефләрен бармак очы белән барлап чыгам да, шулар арасыннан «Зәйнетдин Нәгимулла углы» дигән сүзләрне эзләп табам, аларны Сәхи бабайга укып күрсәтәм. Сәхи бабай соклануын яшереп тормый:

— Ай-һай, шәпкә чыктың син, Әхмәт Зәки! Үзебезчә дә укыйсың бит. Ходайның рәхмәте төшкере!

Ул кабаланмый гына өстендә ак кылганнар җилфердәп торган картәти кабере янына тезләнә дә миңа кулы белән ишарә ясый. Мин дә аның артына җиргә тезләнәм. Зиратта тыңлаганда дога сүзләре моңлы булып яңгырый...

Бала чактан ук мәкам белән дога укыганны ишетү минем тынычлыкны алып, әллә нинди серле, моңлы, күңелгә азрак курку салып уйландыра торган иде. Әле дә шулай булды. Өстәвенә мин картәти каберендәмен...

Язмыш миңа карата каты булды һәм әти ягыннан да, әни ягыннан да бер генә картәтине дә, картәнине дә күрергә насыйп булмады. Дога укылып беткәч, мин Сәхиулла бабайга хәер бирәм. Ул битен сыпырып, сакалын сыйпый да миннән сорый:

— Нинди дога укыдым, беләсеңме?

— Каян белим инде мин аны, Сәхиулла бабай.

Ул елмая.

— Укуыгыз ифрат та зур, ә үзегез надансыз. Алладан аерып алып бик нык гарипләндерделәр сезне бу хуҗалар. Без китеп беткәч, сезне юып, догалар укып ләхеткә куярга да кеше калмас әле... Салават догасы бу.

Зираттан чыккач, Сәхи бабай мине җибәрмичә, өенә алып кайтты.

— Әйдә, кайтыйк әле безгә. Мин дә сине азрак күргәндәй булыйм. Нәселегез белән авыл күрке булдыгыз бит сез. Синең бабакаең Абдулла минем малай чактагы ук дус иде. Көне буена бер сүз дәшмичә яши белә торган иде... Псковта күмелгәнен беләсеңдер...

— Син дә анда сугышкансыңдыр инде?

— Юк, мин бер ай чамасы гына йөредем дә аннан соң нимес ягына чыгып киттек. Без дүрт татар, бер башкорт идек рутада. Барыбыз да бергә атступление вакытында урман эчендә качтык та калдык...

Өенә кайтып җиткәч, ул миңа бик кызыклы тарих сөйләде.

— Нимеснең Мюнхен дигән каласы янында булдым мин плиндә. Син менә мин сөйләгәнне исеңдә калдыр әле, кирәк булуы бар. Шул плиндә мин 1918 елның азагына хәтле булдым...

— Бик кыен булгандыр инде, Сәхи бабай, анда?

Бабай кыска гына итеп көлә:

— Юләр син, Әхмәт Зәки. Инде менә туксанга җитеп барам. Шул плиндәге яшәгән өч ел — иң шәп яшәгән вакытым.

Минем ышанмаганны сизә, сәкедә аякларын бөкләп утырган җиреннән күңелле итеп көлә.

— Ышанмыйсың! Син плин турында юк-бар укып нык бозылгансың. Менә, тыңлале минем сөйләгәнне...

Һәм Сәхиулла бабай Тайгунов мин моңа кадәр беркайда да ишетмәгән татар тарихын сөйләде.

— Без торган урынны нимесләр лагерпункт дип йөретәләр иде. Кызыл кирпечтән салынган бер генә катлы йортлар. Эче тулы бүлмәләр. Һәр бүлмәдә дүртәү ята торган аерым-аерым урын. Дүрт тумбочка, дүрт комган, дүрт намазлык. Ә яткан урын нәстә-ә! — ап-ак җәймәләр. Икешәр — һәр урынга. Калын, җон адыял, ике мендәр. Бүлмәгә кергәч кия торган матур чүәкләр. Кием-салым искиткеч шәп...

— Әкият кебек бит бу. Шундый плин буламыни?

— Була икән шул! Сиңа алдап сөйләргә, инде минем вакытым житкән Аллам алдына барырга...

Ул елмая:

— Бүлдермәле мине, Әхмәт Зәки. Абдулла бабакаең кебек сабыр бул. Тыңла.

— Иртән алтыда торгызалар:— Шнель, шнель!— дип. Немесчә «Тиз бул»— дигәнне аңлата. Һәр бүлмәдән йөгерешеп чыгабыз да, йортлар алдына тезеләбез. Без 132 кеше. Бар да татарлар. Физзарядкә ясаталар бездән, йөгертәләр, сикертәләр. Көн яңгырлы, томанлы булса — чыгу юк. Безнең тамакны саклый болар...

— Өч ел буена шулай яшәдегезме? Ничек алай?

— Ие-еме менә-ә! Нимес галимнәре ул лагерпунктны татар жырларын өйрәнү өчен төзегән булганнар. Өч ел буена без шунда жырлап яшәдек.

— Ышаныйммы икән, юкмы икән дигәндәй!

— Анысы синең эш. Менә мин сиңа жырлап күрсәтим әле. Нибуч ышанырсың.

Сәхи бабайның башкорт бичәсе телгә килә:

— Кит инде, картлас, тагын кузгалаһың ахрыһы?!

— Син, бичә, тик кенә утыр...

Агач өй эчендә, бүлмәләр эченә ямь биреп, борынгы татар көйләре яңгырый. Сәхи бабай үзенә генә хас моң белән «Ком бураны»н һәм «Сәгать чылбыры»н башкара. Тавышы бик көчле түгел, картларча азрак «утырган» тавыш булса да, ул бик моңлы итеп, көйне белеп, тоеп жырлый. Мин жыр моңына бирелеп, кайда икәнемне дә онытып утырам.

Бабай тына. Алдындагы чынаяктан сөтле чәен уртлый да, миңа күзләрен төби:

— Ошыймы, Әхмәт Зәки?!

— Рәхмәт сиңа, Сәхиулла бабай. Зур рәхмәт.

— Шулай диген, улым! Үзеңә рәхмәт. Син бит безнең авылның зур горурлыгысың. Галимсең син. Әле менә хикәятләр дә яза башлагансың икән. Ходай Тәгалә күп итеп илһамыңны бирсен... Ярар, мин тегене сөйләп бетерим инде... Иртәнге аштан соң без ерлый торган идек. Миттелраух дигән прафисыр минем жырлаганны язып алды. Бер әйләнә торган нәмәстәсе бар иде. Миннән көлә торган иде, үзең киткәч тә жырларың нимесләргә торып кала дип... Шул лагерпунктка килеп йөргән нимес прафисырлары әйттеләр: татар жырлары дөньяда иң моңлы, иң матур һәм жыр авазына иң бай, диеп. Нилектән алай икәнен белмиләр. Безнең жырларны шул галимнәр урыс, хахул, хәтта итальян жырларыннан да өстен куялар иде. Һәм ул шулай да, Әхмәт Зәки...

Мин Сәхи бабайдан ишеткәннәргә исем-акылым китеп утырам. Сорыйм:

— Нилектән икән ул, Сәхи бабай?

Бабай азрак кына уйланып тора да жавап бирә. Төпле итеп:

— Сәбәбе икәүдер дип уйлыйм мин. Беренчесе — бик эшчән халык бит без. Искиткеч эшчән. Эшләгән кеше жырлый да белә ул. Икенче сәбәбе — фажига, улым. Без бит дүрт йөз елдан артык урыс астында ирек даулап яшәгән халыкбыз. Күпме нужа-михнәт, хәсрәт, ачлык күрдек без урыс кулы астында. Акыртып талыйлар, хәерчелектә яшәтәләр бит. Бердәнбер күңел юанычы жыр кала. Күңелле такмак жырлар бик аз бит бездә. Алары да Советлар чыккач көчләп такканнары гына...

Чәй эчелеп беткәндә генә уллары Абдулла кайтып керде. Мине күрүгә, матур итеп килеп исәнләште:

— Исәнмесез, Зәки абый! Рәхмәт безгә килүегезгә...

Соңгы сугышта Сәхиулла бабай трудармиягә эләкте. Чиләбедә снарядлар, бомбалар ясаганнар. 1944 елның май тирәләрендә кайтты. Ике аягы гөбе кебек булып шешенгән. Чак атлап йөри. Сөйләгәннәреннән истә калганы:

— ...Шул бомба эченә шартлый торган тол куялар. Әмирикә җибәрә икән. Зур-зур кисәкле алар. Төсе сарымай кебегрәк. Өстенә менеп лом белән ватабыз. Аякта чабата, табаны ашала теге «сарымай»дан. Бер кием чабата — ике күнлек. Шунда китте шешенеп минем аяклар...

Мин китәргә җыйналам. Кайту ягына. Сәхи бабай озата чыга.

— Берүзем калдым яшьтәшләрдән. Күбесе теге сугышны үтә алмады. Ул трудәрмиядә кырылдылар. Кислата иснәп трудәрмиядән качып калганнары да бар иде. Алары, сугыш беткәч, биш ел эчендә үпкә белән китеп беттеләр. Миңа да иснә дип караганнаар иде, мин иснәмәдем. Ходай кушканны күрермен дидем.

Без хушлашабыз.

— Хуш, Әхмәт Зәки улым! Мин озакламам, китәрмен инде. Картәтиенә, әтиеңә, Абдулла бабакаеңа, Хәйрулла бабакаеңа сәламеңне җиткерермен. Онытма мине, исеңә алгала. Мин бит сине иртүк эзләп таптым. Хушлашуыбыз шушы булыр.

Сәхиулла бабай шул кышны дөнья куйды.

Авылда өч малае яши — Халит, Талип, Абдулла, Зәйтүнә апа, Хәйдәр абый, төпчекләре Наил — гүр ияләре.

Менә шундый бабай иде Сәхиулла Тайгунов дигән кеше.

### Вагыйзь Песәй

Мин белгәндә Вагыйзь бабай бик карт иде инде. Шулай да сугыш алдыннан Пожарный бабай булып эшләде. Кече кызы Мәһинур 1922 елда туган. Шуннан чамаларга була Вагыйзь бабайның яшен.

Мәһинур апа сабыр холыклы, аз сүзле, бик тә мөлаем апа. Әлеге чибәр төпчек кызын Вагыйзь бабай аеруча нык ярата торган иде.

Вагыйзь бабай Пожарныйда каравылда утыра. Кече кызы аны ашарга чакырырга килә. Өйләре ягыннан бина почмагына килә дә туктап кала. Бабайлар янына барып, әтисен чакырырга ояла. Күкрәктән чыккан моңлы тавыш белән әтисен чакырырга тотына:

— Әт-ти-и-и! Әни сине ашарга алып кайтырга кушты-ы! – Вагыйзь бабай ишетмәмешкә салышып утыра бирә. Тавыш-тынсыз утыруын белә. Мәһинур апа азрак көтә дә тагын сузып кына дәшә:

— Әт-ти-и дим-им. Әйдә инде, ашарга ка-айт!

Вагыйзь бабай янында утырган берәрсе түзми:

— Карале, Вагыйзь абзый! Кызың килгән бит, сине чакыра, кайт бар!

— Чү-чү! Шаулама, тик кенә утыр! Тагын эндәшсен әле, «әти» дип. Тавышы — сандугач тавышы минем кызымның...

— Әт-ти, дим би-ит...

Мәһинур апа 1942 елны сугышка китте. Ул кайтканда Вагыйзь бабай юк иде инде. Авырлыклы, ачлыклы сугыш елларын үтеп тере кала алмады бичара бабай. Ә Хәдичә әби сугыштан соң да байтак яшәде. Мәһинур апа 1945 елны өр-яңа гимнастерка-юбка, хром итекләр киеп, орден-медальләр тагып, җиңүче булып кайтты. Германиядән, «немкалардан отып алып кайткан» чәч прическалары белән авыл карчыкларын аптыраткан иде... Ул хәзер Уфада яши. Бу ел Эстәрледә Хәсбия апаларда бергә ашта булдык. Бертуктаусыз елмаеп торган матур әбигә әйләнеп бара. Ходай гомерен озын итсен!

## Ташкергән Барый

Капар Миңлебае каршында, Сәхи бабайларның аскы ягында — НКВД тарафыннан 1938 елда Уфа төрмәсендә атылган Галимулла бай йорты. Әтисен алып киткәч, йортта ирләрдән иң зуры булып улы Барый абый калды.

Мин аны яхшы беләм. Чөнки ул минем әти белән Пожарныйда эшли иде. Аннан мин аның зур улы Мәҗит һәм үземнән бер яшькә бәләкәй икенче улы Равил белән бергә уйнап, балыкка, балтырганга, җиләккә, чикләвеккә йөреп үстем. Бергә таш белән «акча суктык», «ачуклы» уйнадык үзебез ясаган кәрт белән, чебенле, чәбәйле, шаралы, качышлы, унике чыбыклы, лапталы, клүкле, чокыр туплы, туп яшерешле, кыршау куышлы, диварга бәреп акчалы, «шкиндерле», һәм тагын әллә нинди уеннар уйный торган идек.

Мәҗит — арабызда иң шәп балыкчы. Равил — нечкә генә гәүдәле, холкы белән кызларга тартым. Күңеле нечкә, ул җырга, биюгә оста. 13—14 яшьләрендә үзенең иң әйбәт дусты Хәсән белән кызларча киенеп, караңгыда кызларга барып кушылып, аларны көлдерергә яраталар. Хәсән әле дә авылда яши, ялгызы. Авылда аны, шул яшьлегеннән калган шуклыклары өчен, Хәсби дип йөртәләр.

Барый абыйның хатыны Гөлҗамал апа — алда язып үткән Вагыйзь бабайның кызы. Кечкенә гәүдәле. Бу йомры апа үтә дә эшчән, үтә дә тормышчан кеше булды. Иреннән биш бала белән торып калды...

Сугыш башлангач, Барый абый:

— Миндә бит ак билит. Алмыйлар мине. Йөрәк бик каты сугучан минем. Минем кебекне алып, сугышта нәстә эшләтмәк кирәк ди. Алмыйлар... — диде.

Тәүге каралуда ук алып киттеләр Барый абыйны ак билете белән бергә. Немец китереп кыскач, йөрәк сугуын тыңлап торырга вакытлары да, теләкләре дә булмады, ахрысы. Авылдан пар атлар җиккән бричкаларга төяп озаттылар ирләрне. Аякларын салындырып, бричканың бер ягында алтау, икенче ягына тагын алты ир утырдылар. Уртада дүртәү, бер бричкада төп-төгәл уналты әзмәвердәй ир. Киттеләр дә кайтмадылар...

Зиратны узгач, авылны чыгып, Кәҗә тавына җитәрәк, азрак салып алган Барый абый бричкадан сикереп төште дә сул якта яткан тау башына карап менеп китте.

— Бармыйм мин сугышка. Үтерәләр анда. Биш балам бар минем. Биш! Кем ашата аларны? Бармыйм. Кая минем улым, Равилем кая?

Равил иртән казлар куарга дип Күлгә киткән дә, шунда ук, җәяләр ясап уйнап, әтисенең сугышка китәсен оныткан. Аны алырга Сәхи бабайның Халитен йөгерткәннәр. Барый абыйны ирләр юата. Тик ул үзенекен сукалый:

— Улым Равилне күрмичә бармыйм сугышыгызга. Анда үтерәләр. Бармыйм!

Эстәрле елгасы аша кичеп чыгып, Равил белән Халит бакчалар аша турыга йөгерәләр. Равилнең кулында кисеп алган таллар. Ул вакытта Равилгә җиде яшь тә тулмаган иде әле. Барый абый аны кочаклап елый. Ирләр аны күтәреп дигәндәй бричкага утырталар да, кисеп тоткан талларын кочаклап, үксеп елаган Равилне юл читенә бастырып калдырып, атларын юыртып китеп баралар. Ә олы улы Мәҗит бричкага арттан менеп утырган да, аның читенә ике куллап чытырдап ябышып каткан. Аның кулын кубарып та ала алмадылар, үзен төшерә дә алмадылар. Китте Мәҗит әтисе белән. Кайткан саен сөйли Мәҗит миңа әтисе белән «сугышка киткәнен»:

— Башкорт авыллары Мәксет, Ибракай, ике Калкашны үткәнче бардым, әй. Әтисез каласы килми бит. Зурлар булсалар да, шул гап-гади

нәстәне аңламыйлар, әй. Төшмим дә бричкадан, сөйләшмим да, әй, тегеләр белән. Сугышка киткән абзыйлар берсе дә әйтми, төшеп кал, дип. Әти әйтеп карый, бар кайт инде, улым, еракка китәсең бит, кайтуы кыен булыр, дип. Мин дәшмим, әй. Башны идем дә тик барам. Шуннан Урта Калкашны үтеп Дуңгыз Борыны дигән тау янына килеп җиттек. Шунда очрады, Каладан плтаратунка дигән йөк машинасы белән Мәнәх Абдулласы кайтып килә. Туктатты машинасын, сигнал биреп. Төште хушлашырга авылдашлары. Әти әйтә тегеңәргә: «Абдулла, минем малайны алып кайтып кит инде син, әй»,— ди. Теге риза. Әти мине күтәреп алып барып, машина кабинасына утыртты. Күзеннән бертуктаусыз яше ага, сөртеп тормый үзе шуны. Миңа әйтте шунда:

— Мин, улым, бик нык итеп кайтырга тырышырмын ул сугышларыннан. Әгәр кайта алмасам, энеңне, сеңелләреңне, әниеңне, картәниләреңне карарга сиңа кала инде. Галимулла бабаң да юк. Син каласың ирләрдән иң олысы булып. Син хуҗа буласың.

Шулай күзләреннән яшьләре аккан көенә китте әти бричкага утырып. Кайтмады шул киткәннән. Кырык дүртенче елны хахулларның Львов дигән каласын алганда һәлак булган. Автоматчик булган... Абдулла абыйның да күзе тулы яшь. Миңа ике шүшки бирде капчыгыннан алып. Елама, улым, ди миңа. Мин еламыйм. Шулай да күңел бик тулган иде. Үз гомеремдә әтинең әнисе Зөбәйдә әби үлгәч бер еладым. Шул булды. Илле бишенче елны...

Мәҗит авылда яши. Матур, бай яши. Үтә дә эшчәннәрнең берсе. Үзе укый алмады. Ата урнына калгач, энесен дә, өч сеңлесен дә карады, укытты, кеше итте аларны. Равилне өйләндерде, сеңелләрен кияүгә бирде. Әтисенең әйткәнен үтәде Мәҗит. Үзе гомере буенча колхозның кара эшеннән чыкмады, тик туганнарын издермәде колхоз каторгасында.

Гөлҗамал апа урамдагы иң уңган хатыннарның берсе булды. Урман да кисте, печән дә чапты, колхозда да күп эшләде. Иң авыр елларда да бала-чагасын ач итмәде. Биеме Зөбәйдә әбине дә, аның биеме Хәнифә әбине дә тавыш-тын чыгармыйча, савыт-саба шалтыратмыйча карады.

Барый абый сугышка Пожарныйдан киткәнгәме, әллә әтинең кешегә ярдәмчел булганын белепме икән, Гөлҗамал апа сугыш елларында әтигә еш кына килә иде.

— Лотфулла абзый! Утын бетеп килә, ат белән берәр төрле ярдәм итмәссеңме икән?

Әти атны җигеп бирә. Гөлҗамал апа Мәҗите, Равиле белән атка утырып чыгып китәләр. Эшлиләр, булдыралар. Утынын да, печәнен дә төяп алып кайталар.

Мәҗит белән мин 5—6 сыйныфларда бергә укыдым. Ул 1946 елны 15 яшендә укуын ташлап, колхозга тракторга прицепка чыгып китте. Шуннан бирле туктамастан колхозда эшли. Прицептан тракторга күчте. Аннан соң шофер булды.

1993 ел, январь ае. Авылны күрергә кайткан идем. Яңа урам аша үтеп барганда Мәҗитнең йортын сорадым берәүдән. Күрсәтте.

Йорт-кура сандык кебек итеп эшләнгән. Бөтен җиргә тәртип, уңганлык, пөхтәлек, ныклык, муллык, байлык. Мин килеп кергәндә Мәҗит яңа гына эштән кайткан икән. Ашап утыра. Кочаклашып күрештек. Хатыны Мәрьям — Югары оч кызы. Бик уңган, ачык кеше.

— Инде менә, дус, алтмышны уздым, әй. Эшлим һаман да. Бер җирем авыртмый. Кул-аяк менә дигән. Көчем — элекке кебек.

— Нинди эштәсең үзең?

— Калхузга сыек ягулык ташыйм, үземнең хуҗалыгымда бар нәрсә дә бар. Икешәр-өчәр башмак суям ел да. Итсез аш ашаганым юк. Ике сеңел, энем Равил Ташкентталар бит. Бу ел өөчесенә өч йөз кила ит җибәрдем. Әле яңа гына бер КамАЗ китте Ташкентка. Ниндидер запчастьлар алырга. Белеп кенә калдым да тутырдым тегене ит белән, бәрәңге

белән. Миндә бит алар дачурта. Әни генә юк, әй, күрәлми безнең шушылай шәп яшәгәнне. Өч малай, бер кыз үстердем. Бар да башлы-күзле булдылар. Авылда яшиләр барысы да. Һәммәсеннән дә мал асратам. Йөрмәсеннәр соранып кешедән. Әл-ләлә, ул кешедән соранулар, чит бусагага барып. Бәләкәй чакта үземә туры килде минем, балаларым соранмасыннар...

Минем тормышны сораша да, азрак уйланып утыргач, йомгаклый:

— Кайт авылга үзебезгә. Йөрмә читтә. Кадерең юк синең анда барыбер. Чит жир чит инде ул. Үзебезгә кирәк син монда. Син кайтып күренгәндә авыл урамнары ямьләнеп китә. Шул көнне үк...

Мәжит матур итеп көлә дә дәвам итә:

— Кайт, йөремә читтә. Бака — күлендә кадерле, ди. Яшәрбез бергә-бергә. Никадәр шәп яшәсәң дә, үз урамыңда, үз йортың белән яшәгәнгә житми ул. Кайт, дус!

Фәния исемле сеңлесе күрше Бакый авылында яши. Үз йорты белән. Гөлжамал апа 1985 елны китеп барды. Мәжит йортында яшәде.

Барый абыйны 1941 елның октябрендә Алкиннан сугышка озаткан-нар. Атасы Галимулла бабай чын игенче, нык итеп мул яшәгән кеше иде. Галимулла бабайның бурап төзегән коймалары, ишек алдында подвалы, бураган келәте, сарае бар. Сарай кыегы астында төрле төстәге күгәрчен-нәре гөрли. Аның оныгы Мәжит, картәтисе Галимулла бабай төсе итеп, күгәрченнәрне әле дә асрый икән. Хатыны Мәрьям көлә:

— Хужалыктагы ярты бодайны шуларга ашатып бетерә инде, Зәки абый. Минем әйткән әллә бар аңарга, әллә юк. Картәтинең күгәрченнәре бит алар, ашасыннар әйдә. Ходай кошлары бит, ди.

## Тимеркәй

Вагыйзь бабайларның ас ягында кечкенә, урамга буйлап салынган бер йорт бар иде. Сугышка кадәр кем яшәгәндер — истә калмаган. Күрәсең, малайлары булмагандыр инде, югыйсә белер идем. 1942 елның февраль урталарында ул йортта Хафизов Тимергали, безнең урамча әйтсәк, Тимеркәй яши башлады. Ул — «Үрләр аша»дагы Кытыйканың бер туган абыйсы. Тимеркәй сугыштан 1942 елның февралендә кайтты. Уң кулы каты жәрәхәтләнеп, госпитальдә сөяге кыек ялганган булган. Аягында кыска киң кунычлы, калын табанлы, тимер дагалы немец солдатының итекләре. Немец солдатлары буа торган бил каешын һәм немецләрнең тимер акчаларын да алып кайткан Тимергали абзый. Трофей, үзе әйтмешли. Каешның пряжкасы ак тимердән эшләнгән. Пряжкада ике аягы белән свастика тоткан бөркет эшләнгән. Свастиканы уратып «Мит унс Гот»[1] дип язылган. Тимергали абый артыннан без көне буе, берәр нәрсә сөйләсә ярар иде, дип ияртеп йөрибез. Ул бит тере фашистларны үз күзләре белән күргән, алар белән штык сугышларында да капма-каршы сугышкан.

Сугыш еллары. Тимергали абыйны, кайткач та, дүртенче бригадка бригадир итеп куйдылар. Үзе бик эшчән, кешегә ярдәмчел. 1943 елда Сәхи бабайның зур кызы Зәйтүнә апаны үзенә хатынлыкка алды да, алар матур гына итеп яшәп киттеләр.

Тик Тимергали абый тынгысыз. 1946 елны, азрак салган баштан, сугыштан соң беренче мәртәбә булган сабан туенда көрәшкә чыга. Аны туктатып карыйлар — кая ди ул! Аңардан да көчле кеше юк! Алып ыргытканнар Тимеркәйне. Теге гарип кулы бөтенләй сынып, эштән чыкты. Терсәктән бөгелмәс булып, бармаклары хәер сораган кебек, һәрчак

---

[1] «Алла безнең белән».

тырпаеп тора торган булып калдылар. Аннан соң инде житмешенче елларда япа-ялгызы атлы чана белән буранда күрше авылдан кайтып килгәндә, эчкән баштан (һаман шул аракы, каһәр суккан!) чанасыннан төшеп калган. Ике кулының да бармаклары туңып төшкән. Больницадан ике кулына бер бармаксыз чыккан. Соңгы көннәренәчә бармаксыз яшәде, тик барыбер эчүен ташламады.

Сугыш беткәч, йортын алмашып, күрше урамга, Кәкре Тыкрык янына күчте. Аның урынына Имат Күчән дигән абзый күченеп кайтты Эстәрлетамактан. Ул озак тормады, йортны Хәбир Ялман сатып алды, нысыды шул йортта. Бәләкәй генә гәүдәле, бер күзе пыяла, эшчән, хуҗалыклы кеше булды анысы. Гәүдәгә үзеннән дә бәләкәй, үзеннән дә тырыш, минем белән бер елгы улы Әхсән бар. Хуҗалыкларын нык итеп карап, йортларын бик матурладылар алар.

Хәбир Ялман — Эстәрлебашта заманында мәдрәсә корып җибәргән атаклы Монасыйп мулла нәселеннән. Сугыш вакытында Польшаның «Армия Людова»сендә «поляк» булып сугышкан. 1943—45 елларда. Польша орденнары, медальләре бик күп иде. Сугыштан кайткач, берничә ай, «тере калганына» куанып, эчеп йөргәне истә калган. Төп йортта хәзер үзеннән дә тырыш улы Әхсән яши.

## Хәйрулла бабакай

Вагыйзь Песәйгә урам каршы, Галимулла бабай эргәсендә, минем әтинең ике яшькә олы бертуган абыйсы Хәйрулла бабай яши. Ул миңа — бабакай. Олы гәүдәле, җирән сакал-мыеклы, сырган эшләпәле, зур куллы, гайрәтле, көчле һәм оста балта остасы кеше ул. Тууы белән 1883 елгы булып, минем картәти Зәйнетдин белән картәни Мәрфуганың алты малае арасында иң зурысы, беренчесе булган. Әниемнең әйтүенә караганда: Хәйрулла абзый — тач биатай инде!

Хәйрулла бабай Герман сугышыннан җәрәхәтләнеп кайткан. 1912 елны, яучылап, Хәдичә исемле кызга өйләндергәннәр. 1913 елда туган Фәйза исемле кызлары бар. 1923 елгы Габделхәй исемле уллары, аннан соң Зөләйха, Гайшә, Наилә. Хәйрулла бабай төп йортта калган. Җил капканы кергәч, сул якта йорт. Урам якта, тәрәзә төбендә ике өянке. Аларны картәти — Зәйнетдин утырткан. Өйгә кергәндә таш өйалды. Аннан соң кечкенә агач йорт. Салам түбә. Ишек алдында арырак читән абзар. Абзар артында мунча. Абзары читәннән булса да, Хәйрулла бабай урам яктагы ихатасын бервакытта да читәннән үрмәде. Күбесенчә юанрак юкагачтан кадаклап ясалган рәшәткә була торган иде аның ихатасы.

Картәти белән картәни Хәйрулла бабайда яшәгәннәр. Зур кызлары Фәйза апа Галимулла бабайның чатан улы Һади абыйга яучылап бирелгән. Шулай итеп, алар кара-каршы өч кода яшиләр иде: Галимулла бабай, Вәгыйзь бабай, Хәйрулла бабай. Һади абый үлгәч, Фәйза апа сугыш елларында өч бала белән тол калды. Зурысы Рәшит. Тагын ике кыз: Сәвия, Венера. Рәшитнең бала чакта өске ирене китегрәк иде. Шунлыктан ул — безнең малайлар арасында Китек Рәшит. Үскәндә үк картәтисе Хәйрулла бабай янында эшләп үсеп, куллары бик оста иде Рәшитнең. Үсеп җитәрәк, 12—13 яшьләре чамасында, Уфага барып, «китеген яматып» кайтып, үтә дә матур малайга әйләнде дә китте Рәшит.

Дүрт кыз арасында үскән Хәйрулла бабайның бердәнбер улы Габделхәй абый сугыш башланганчы колхозда ат җигеп эшләп йөрде. 1942 елны ул сугышка китте һәм кырык өчтә Курск дугасында һәлак булды. Хәйрулла бабай шул 1943 елга кадәр колхозда балта эшендә булды. 1943 елның сентябрендә базар көнне, фалиҗ сугып, уң кулы хәрәкәт итүдән туктады. Уң аягын өстерәп йөри, уң колагы ишетми, уң күзе

күрми. Таза, имәндәй гәүдәле, зур куллы бабакай ярты кеше булды да куйды. Өтәвенә, теле көрмәлеп сөйләшә торган булып, аның нәрсә сөйләгәнен аңлавы бик авыр иде. Бик каты гарипләнсә дә, хәрәкәттән, эшләүдән туктамады...

Инде хәзер, картая башлагач кына, элек аңламаган нәрсәләр аңлашыла башлады кебек.

Без Хәйрулла бабакайлардан урамның түбән ягында яшибез. Мәктәпкә барганда-кайтканда, мин читән, койма, рәшәткәләр яныннан атлап, Вагыйзь Песәйләр ягыннан йөрим. Безнең өй шул якта. Иртән укырга барганда, Вагыйзь бабайларның өенә житәргә ике-өч йорт кала, мин Хәйрулла бабакайның йорты ягына күз салам. Көн яңгырлы булмаса, анда, такта рәшәткә өстендә Хәйрулла бабайның сырган иске эшләпәсе, жирән сакал-мыеклы йөзе күренә. Ул урамга карап, рәшәткәсенең эчке ягына баскан да, шуннан бернинди дә хәрәкәт күрсәтмичә тора. Исән сул кулын рәшәткә өстенә салган, кыска жирән сакаллы ияген шул кул терсәгенә терәп куйган. Хәйрулла бабакай урам якка караган көенчә байтак басып тора, ахрысы. Мин аның белән урам аша:

— Хәйрулла бабакай, исәнме-е?! — дип кычкырып исәнләшәм. Жирән сакал-мыеклы йөз кузгала, хәрәкәткә килә, көләчләнә, елмая. Еш кына исәнләшкән аваз да ишетелеп куя. Унынчы сыйныфта укып йөргән чакта, сынаулар вакыты иде бугай, исәнләшеп узып киткәч, ни өчендер борылып карадым. Хәйрулла бабакай, башып борып, минем китеп барганны карап тора иде. Йөрәгем ни өчендер тынгысызланды, сыкрап куйды. Ул шул чакта нәрсәдер әйтергә теләде бугай. Тик булдыра алмады — бик яшь идем шул әле мин. Шуннан соң үтеп киткәч борылып карый башладым. Мин күмелгәнче Хәйрулла бабакай минем атлаганны карап кала. Кай вакытларда ул, мин үтеп киткәч, жайлап кына аксый-аксый уң аягын өстерәп атлап, өенә кереп китә. Инде мин ничәмә дистә еллар узгач кына аңладым: Хәйрулла бабакай минем үтеп киткәнне карап калыр өчен чыккан икән! Бу аның өчен кирәк булган! Бердәнбер улы сугышта ятып калгач, бабакай бертуган энесенең төпчеген күреп булса да күңелен басарга тырышкан! Энесенең улы үз нәселе, үз каны бит! Балта Зәйнетдин нәселе!

Мин азрак үсә башлаганнан ук Хәйрулла бабакай мине, оныгы Рәшитне жибәртеп, чакыртып алдырта. Ишек алдында без Рәшит белән икәү күсәкләр, баулар ярдәмендә бүрәнә күчерәбез. Күбесен аркылы пычкы белән кисәбез, ярабыз. Хәйрулла бабай аларны үзе өя. Жиргә бау сузып сала да ярылган агачларны шуңа салып бәйли. Сыңар кул белән, сул аягы ярдәмендә бәйли дә күтәреп алып китә.

Бабакай бик оста иде. Сугыш беткән еллар... Рәшит миңа әйтә:

— Зәки абый! Кичә картәти тәлинкә текте. Чуаш жебе белән.

— Кит, китек! Тәлинкәне тегәләрмени. Ул сиңа бишмәтме. Чынаякны тишеп булмый бит!

— Икмәктер менә, текте! Без белән тиште башта, аннан соң чуаш жебе белән тегеп куйды.

Минем ышанмаганны күреп, Рәшит өйләренә алып кереп, миңа «чуаш жебе белән тегелгән» тәлинкәне күрсәтә. Чыннан да, икегә ярылып ватылган фарфор тәлинкә кисәкләре без белән тишелгән, чуаш киндер жебе белән нык итеп тарттырып тегеп куелган. Менә дигән бөтен тәлинкә булган да куйган! Тәлинкә фарфорын тишәр өчен Хәйрулла бабакай безен дә махсус очлаган. Ике телле итеп.

Хәйрулла бабакайның икенче кызы Зөләйхә апа 1925 елгы. Сугыш вакытларында тимер тешле тәгәрмәчле ХТЗ тракторында, «Сталинец», «Коммунар» комбайннарында күп эшләде ул апа. Кияүгә соң гына чыкты. Бер малае Габделхәй, икенчесе Наил исемле. Курск дугасында һәлак булган Габделхәй абый һәм суга батып үлгән Наилә апа исемен йөртәләр ул егетләр.

Хәйрулла бабакай 1953 елны март аенда вафат булды. Мин курсант булып җәй кайтканда, ул юк иде инде. Хәдичә әби аңардан соң байтак яшәде әле. Тыныч кына, кабаланмый сөйли торган, әмма әчетеллерәк әби иде.

Хәйрулла бабакай белән минем әти Лотфулла, Герман сугышы һәм Гражданнар сугышы тәмам булганда, картәти Зәйнетдиннең алты малаеннан икәү генә исән калганнар.

Таш коймалы зират эчендә безнең нәселнең үз урыны бар. Анда — зират уртасында әти ягыннан минем картәни, Хәйрулла бабакай, аның хатыны Хәдичә әби, кызлары Фәйза апа белән Наилә апа күмелгәннәр. Шунда ук минем әти Лотфулла белән әнием Мәрьям каберләре. Бергә дөнья көткәннәр иде, ходай кушып, каберләре дә бер тирәгә туры килде...

### Һади Чалыш

Һади абый Ибатуллин, ялгышмасам, 1912 елда туган. Мин үземне белгәннән бирле районнагы колхозларда рәис булып эшләде. Бер күзе тумыштан кылый булганлыктан, авылда аны Һади Чалыш дип йөртәләр иде. Ул әле дә исән-сау, авылда яши. Картайды инде.

Һади абыйга уку эләккән. Авыл өчен шул заманда ул белемле кеше санала. Хатыны — Югары Очтан Зөләйхә апа. Балалары — Риф, Рим, Нәҗия.

Һади абый, күзе ярамаганнан, сугышка бармады. Сугыш башлангач, безнең «8 март» колхозы рәисе Габсаттар абыйны сугышка алып киттеләр. Ул кешене авылның өлкән буыны әле дә сагынып сөйли. Кеше буларак та, рәис буларак та ул бик әйбәт иде. Аның заманында бурап салынган агач келәтләр әле дә исән «Эстәрле» колхозында. Габдрәхим абый сугышка киткәч, аның урынына Һади абый калды. Елдан артык эшләгәч, «палнамучын» Чолык Зәйнәбе белән нәрсә өчендер низагка кергән. Аны, бик тиз урыныннан алып ташлап, авылдан унбиш чакрымдагы мишәр авылы Карагышка күчерделәр. Анда ике ел эшләгәннән соң, Калкаш дигән башкорт авылында рәис булып китте. Сугыш беткәч, яңадан үзебезгә кайтты. Калкаштан бик чибәр Әминә исемле бер башкорт бичәсен алып кайткан. Башкорт андый чибәрләрне «һылу» ди. Зөләйхә апа белән аерылыштылар. Зур кызы Нәҗия белән кече малайлары Рим мал-туар, йорт белән Зөләйхә апада калды, ә Риф әтисенә китте.

Һади абыйның Миңсылу исемле апасы һәм Габделхәй исемле энесе бар иде. Сугышка кадәр унынчы сыйныф укучылары (1941 елның март тирәләре) колхоз клубында «Галиябану»ны куйдылар. Ягъфәр Баймуратов дигән башкорт егете — Хәлил. Хәтимә Фәйзуллина дигән бик чибәр апа — Галиябану ролендә. Габделхәй абый — Исмәгыйль. Мин, җиде яшьлек малай, шул пьесаны карагач, байтак вакытлар Габделхәй-Исмәгыйльдән куркып та йөрегән идем әле. Бай малае, өстәвенә «ата» торганы да бар!

Һади абыйның бертуган апасы Миңсылу әбекәй миңа җиңги тиешле. Әтидән ике генә яшькә кече энесе Гатаулла бабакай аны 1918 елда алган. Ул 1915 елның башында немецкә әсирлеккә эләккән. Шул әсирлектән биш мәртәбә качкан. Тик бишенчесе генә уңышлы булып, котыла алган. Әсирлектән кайткач, Миңсылуны ябыштырып алып чыккан. 1920 елда туган Абдулла исемле уллары булган. Тик Гатаулла бабакай 1921 елны Эстәрлетамак каласында тифтән үлеп киткән. Шунда Кызыл зиратта күмелгән. Бер ел узар-узмас уллары Абдулла да үлеп киткән.

Миңсылу әбекәй, ире белән улы үлгәннән соң 7—8 ел вакыт үткәч, бездән унике чакрым ераклыктагы Йомагуҗа дигән башкорт авылына

Исәнбәтов фамилияле бер башкортка кияүгә чыга. 1952 елда мин аларның Марат дигән бик шаян малайларын бишенче сыйныфта арифметикадан укыттым. Шаярганы өчен бастырып әрли башласаң, авызын ера да көлебрәк әйтә:

— Агай! Һез мине әрләмәгез. Мин бит һезгә туган тиешле кустыгыз. Инәем әйтте шулай тип...

Мин аның «инәем» дигәненә әһәмият итмичә үткәреп җибәрәм. Тик юкка икән...

Шулай бер көнне яшәгән фатирыма кайтып кердем. Васфия исемле бик әйбәт, бик сөйкемле әбидә тора идем. Әби мине малаеннан да артык итеп кадерләп карый. Кайтып керсәм, бездә бик чибәр бер бишкорт әбие чәй эчеп утыра. Бәләкәй генә гәүдәле, почтык кына борынлы, түгәрәк йөзле әби бу. Бик матур итеп башкортча киенгән. Васфия әби миңа нәрсәдер әйтергә тели, тик булдыра алмый кебек. Мин дә утырдым чәй эчәргә. Теге әби миннән сорый:

— Минем улым нисегрәк укый?

— Кем ул?

— Кем булһын инде, Исәмбитеф Марат дигән егет.

Мин тиз генә әбигә карап алам.

— Малаең бик шәп укый. Иллә дә шаян инде.

Әби кет-кет кelә.

— Булһын. Шаян булһын. Мене һез нәселегез менән үк шаянһыз, кыюһыгыз. Алдынгылыкты бер касан да бер кемгә лә бирмәйһез...

Мин сагая биреп сорыйм:

— Нигә, син безнең нәселне каян беләсең?

Әбинең йөзе яктыра. Ул үрелеп минем аркамнан сөя дә саф татар теленә күчә:

— И бала, бала. Мин бит синең әбекәең Миңсылу булам.

Гатаулла бабакаеңның хатыны идем бит мин.

Мин каушап төштем:

— Әтинең энесе Гатаулла бабакайныңмы?..

Ул көнне без бик озак сөйләшеп утырдык. Миңсылу әби бездә кунып, икенче көнне генә китте. Мин шуннан соң Марат Исәнбәтов дигән укучыга, чыннан да, үз туганым кебек итеп карый башладым. Ул да шаяруын киметте...

Миңсылу әби белән без тагын берничә тапкыр очраштык. Соңгы бу очрашу 1981 елны булды. Авылда ялда идем. Каяндыр кайтып киләм. Әни янында капка төбендә тагын ике әби утыралар. Мин килеп житү белән әни сүзгә килде:

— Менә, кайтты көткәнегез. Тукта, үзе таныр микән, тик кенә утырыгыз әле.

Мин каршыларына баскан көемә җентекләп карыйм да, берсен утырган җиреннән кочаклап алам:

— Миңсылу-у әби-и!

Әби күңеле булып көлә. Икенче әби, мине дә таны инде дигәндәй, көтеп утыра. Бик озак карап торганнан соң гына телгә киләм:

— Хафиз бабайның карчыгы дисәм инде...

Өчәүләшеп куанышып көлеп җибәрәләр. Өйгә кереп, дүртәүләшеп озак-озак итеп чәй эчәбез. Гәпләшәбез. Мин соңыннан Миңсылу әбекәйне Һади абыйларга кадәр озата барам.

— Һадига әйтеп куйдым үткән ел ук. Лотфулланың төпчеге кайтса, мине килеп ал, диеп. Алланың мең рәхмәтләре төшсен, малаен җибәргән машинасы белән. Кичә алып килделәр. Инде вакытым житте китәргә, сине күреп калыйм дидем. Син бит тач Гатаулласың. Тик аның чәче генә бакыр төсендә иде. Ул гәүдәң, ул торышың инде. Бигрәк тә тавышың охшаган. Бик ярата идем мин аны. Гомерем буена сагынып, юксынып яшәдем. Хуш, улым. Бәхетле бул!..

Хәйрулла бабайларның ас ягында Чатан Һади абыйда кияүдәге Фәйза апа яшәде. Алар яшәгән йорт башта Заһит Таз улы Нәсип абзыйныкы иде. Ул кире Ерак Кәнчыгышка чыгып киткәч, йортны Галимулла бабай малаена сатып алды.

Һади абый ике култык таягы белән йөри. Бар нәрсәне дә тик үзенчә генә эшләп өйрәнгән тискәре кеше. Шунлыктан Фәйза апа ул исән чагында барлык нәрсәне дә аныңча гына эшләргә күнеккән.

Һади абый колхозда хисапчы булып эшли. Аяклары гарип булса да, аның мылтыгы бар һәм ул колхоздан ат алып җигә дә кышын... куянга йөри. Бакый Баткан урыны бездән чакрым ярым гына. Һади абый без ыбыр-чыбырларны чанага төйи дә, алга үзе менеп утыра. Без, барып җиткәч, алдына печән салып атны берәр тал куагына бәйлибез дә ауга тотынабыз. Һади абый, арада иң зурыбыз булган Мәҗит белән «нумирга» китәләр. Без ай-һайлап куян куабыз Һади абый ягына. Ул култык таякларына таяна да, мылтык көбәгеn Мәҗитнең җилкәсенә салып, куян көтә. Бер чыкканда тәки бер куянны «алдык» бит. Ул безнең шатлыклар, куян атып алгач! Мәҗит белән очрашсак, әле дә искә алабыз. Чөнки кайткач, Фәйза апаларда куянны тунап, урталай бүлдек. Тунадык дигәч тә, без катнашмадык инде, Мәҗит кенә Һади абый янында буталанып, куян аяклары тотып торды. Шул ярты куян безнең барыбызга да «куян куган өчен» бирелде. Гөлҗамал апа икенче көнне бәлеш пешереп ашатты үзебезгә.

Аннан соң Һади абый мылтыгын тикшердеме икән? Мәҗитләр келәтенең диварына аткан иде. Дивар вак ядрәдән чуарланды да куйды. Сугыштан соңгы елларда да, балык кармагына кургаш кирәк булса, пәке очы белән келәт агачыннан шул ядрәнең берсен яисә берничәсен чокып аласың. Сөйли торган идек: «Их, Һади абый булса, тагын атыр иде дә, без тагын чокып алыр идек». Күрәсең, чокып алып беткән булганбыздыр инде.

Сугыш елларында Һади абый үлгәч, Фәйзи апа өч бала белән тол калды. Балаларның иң зурысы Рәшиткә алты яшь тә тулмаган иде. Ире фронтта үлмәгәч, Чолык Зәйнәбе күрсәтте инде Фәйза апага Сәвит влачын! Иң зур заемнар, иң авыр налоглар аңарга төште.

Рәшит белән мин бик дус үстек. Ул мине абый итә, ә мин үзем бар җирдә бер малайдан да аңарга тидермим, аны яклыйм һәм кулдан килгәнчә ярдәм итәм. Без бергә җиләккә, балтырганга, балыкка, урманга утынга йөрибез. Мин инде унике-унөч яшемдә, үгез җигеп йөрим. Рәшит миңа иптәшкә утырып бара. Мин төягән йөк өстенә аңарга да бәйләп утын алып кайтабыз. Фәйза апаның шул утын өчен куанганнары әле дә истә.

Рәшит Уфада яши. Куллары белмәгән эше юк. Хәйрулла бабакайга охшап, нык итеп гомер сөрә.

Фәйза апаны мин 1991 елны, әнине күмгән көнне — 21 августта күрдем. Елмаеп, матур итеп исәнләште. Авыруын әйтте. Нык йончыганы күренеп тора иде. Тик, күмү мәшәкатьләре белән, озак сөйләшеп торырга вакыт булмады. Ярты ел үтүгә, үлеп китте. Фәйза апаның теләгеn үтәп, Рәшит әнисен Уфадан авыл зиратына алып кайтып, Хәйрулла бабакай белән Хәдичә әби янәшәсенә куйды...

## Фазулла бабай

Фәйза апалардан соң тыкрык. Ул безнең авылның иң атаклы тыкрыгы иде. Чөнки ул Кәкре тыкрык дигән исем белән бөтен авылга билгеле. Ул, чыннан да, кәкре. Яртылаш сузылып бар-

ганнан соң, сулга борылып ясый да, тагын тураеп, икенче урамга барып чыга. Аннан соң шул соңгы урамны чыккач, Каенлы елгага барып төртелә торган икенче соңгы тыкрык. Ул — авылның иң кыска тыкрыгы. Озынлыгы 15 метрдан артмас. Тыкрык тирән ярга барып терәлә. Елга аша чыга торган иске күпере бар иде. Сугыш елларында җимерелеп юкка чыкты. Исән чагында, язгы сулар киткәч, ул күперне Тимергали абый берүзе төзәтә торган иде.

Фазулла бабай тәбәнәк гәүдәле, азрак камыт аяклы, йомшак кына итеп сөйләүче, юаш кына бабай. Карчыгының исеме онытылган. Гатиятулла исемле акылга зәгыйфь малайлары бар. Аңардан башка — ике кызлары. Зур кызларының исеме Латыйфа, кечесенеке Хафизә. Фазулла бабайларда кече кызларының Тәлгать исемле улы да яши. Апа үзе Кала Утарында икенчедә кияүдә.

Фазулла бабайның зур кызы Латыйфа — авылда кияүдә. Ире Әмәт исемле. «Карбыз сугышы» дигән хикәядәге бакча каравылчысы. Әмәт бабай авылның ике урнында яшәгән ике хатын белән алмашлап гомер итә. Бер җырының азагы гына истә калган:

Латыйфада тавыш купса,
Миңнисага күчәбез.

Әмәт бабайга кагылышлы минем дә бер истәлегем бар. 1939 елның язы. Минем абый, Танау Фәрите, Хәзрәт Зөфәр, Ташкергәннәрнең Мәҗите, Халите, мин һәм тагын берничә ыбыр-чыбыр киттек башкорт авылы Мәксет ягына балыкка. Танау Фәрите зур, кызыл бакыр чәйнек алган. Тоткан балыкны тутырырга. Зурракларда кармак. Бездә — кечерәкләрдә юк. Танау Фәрите теге зур бакыр чәйнекне миңа күтәртә:

— Күтәреп йөрсәң, азактан өч ташбаш бирәм.

Кармак юк, ә балыклы буласы килә бит! Мин теге үтә дә авыр бакыр чәйнекне көнозын өстерәп дигәндәй, күтәреп йөрим. Көнозын йөри торгач, чәйнек эчендәге суда бер ташбаш белән бер маймыч балыгы йөзеп йөри башлады. Үлмәсеннәр дип, еш кына суны да алмаштырып торам. Миңа маймыч та ярый инде, тик тагын бер ташбаш кына эләксен! Көн үтеп бара. Су суыктан, көн суыктан ул көнне балык эләкмәде. Киттек кайтып тугай аша турыга. Зуррак малайларның берсе котырта:

— Әйдәгез калхуз бакчасы аша үтик. Суган булса да йолкырбыз!

Кемдер карыша, килешми:

— Иртә бит әле. Берни дә юктыр анда.

Тик, аны тыңламыйча, өеребез белән бакчага кереп китәбез һәм кемгә нәрсә туры килә, шуны йолкырга, ашап карарга тотынабыз. Шалкан, торма, кишер — җеп юанлыкта гына. Тәмнәре дә сизелми. Шулчак яр башыннан, калкулыктан Әмәт бабай кычкырып җибәрде:

— Ах, сез, бакча кортлары! Каяле, мин хәзер сезне-е...

Тотынды бу безне куарга. Кулында таяк моның. Зуррак малайлар иң алдан, алар артыннан без тотындык качарга. Ул бастыра, без качабыз. Кот ботка төште, җиппәрәбез генә. Тик Әмәт бабай, карт булса да, шәп йөгерә икән, иманы качкан нәрсә. Мин әллә араларында иң бәләкәе булганга, әллә тиз йөгерә алмаганга, артта кала башладым бит. Өстәвенә, кулда теге зур, бакыр чәйнек. Капкачы сүс бау белән тоткасына бәйләнгән иде. Йөгерә башлагач, шул капкач бер чәйнеккә, бер минем ботка сугып, йөгерергә комачау итә башлады. Куркудан сөрән салып акырам үзем. Ә Әмәт бабай, артта кала башлаганымны күреп, инде мине генә эзәрлекләп йөгерә. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела башлады. Таягын һавада болгый-болгый йөгереп, мине куып житәргә 5—6 адым гына калды. Эләгәсе килми бит, малай, тегенең кулларына! Зур, бакыр, капкачы ботка суга торган, теге чәйнекне ташладым да, тизлекне шәбәйтеп, җиппәрдем генә башка малайлар артыннан. Авыр чәйнектән котылгач йөгерүе дә ансатрак икән ул! Әмәт бабай теге бакыр чәйнекне җирдән

иелеп алды да, безне куудан туктап калды. Миннән алда йөгергән малайларны куып җитәргә байтак ара бар икән. Мин килеп җиткәч, инде Танау Фәрите мине кыйнарга итә.

— Әтинең Герман сугышыннан алып кайткан солдат чәйнеге иде. Аршау каласында биргән булганнар. Писер! Ник ташладың, ә? Бирәм бит хәзер кирәгеңне!

Абый кыйнатмады.

— Танау, тиеп кенә кара! Иң алдан үзең качтың бит, аны ташлап чәйнегең белән бергә. Бар, үзең барып ал!

Фәрит абый, чәйнекне күтәреп үргә табан куышына карап атлаган Әмәт бабайга күз карашын ташлап ала да кулын селти:

— Әй, ярар инде! Өйгә кайткач мин ул чәйнек турында әйтеп тә тормыйм. Югалтканны белмәсләр әле, бәлки...

Кырыгынчы елларның уртасы һәм азакларында, колхозда эшләгәндә, мин ул таныш бакыр чәйнекне еш күрәм. Аңарда Әмәт бабайның кызы Хөрәйдә апа яланда чәй кайната...

Фазулла бабай мин үскәндә кайда эшләгәндер — белмим. Тик бик ярлы яшиләр иде. Тимеркәй (Тимергали) Хафизов сөйләгәннән, мин Фазулла бабайның үзебезнең татар өчен җаны әрнеп, егерменче еллар башында атаклы Эстәрлебаш мәдрәсәсе ябылгач, сәбәп итеп, укытуны булдырырга тырышканын язмый калдыра алмыйм:

1921 елгы ачлыктан соң, 1690 еллар чамасында ук ачылган, шуннан бирле эшләп килгән атаклы Эстәрлебаш мәдрәсәсен ябалар. Аны мәдрәсәнең соңгы мөдәррисе, Дәрдемәнднең, Риза Фәхретдиновнең дусты булган Мөхәммәт Шакир Тукаев яптырмаска бик тә тырышып карый. Тик уңышсызлыкка очрый. Ябалар мәдрәсәне. Барлык хәлфәләрне, мулла-мәзиннәрне ГПУга чакыртып, башкача укытмаска сүз бирдереп имза алалар.

Гомерендә хәлфәлек итмичә, игенче булып яшәгән Фазулла бабайның авылда мәдрәсә беткәнгә, аның ябылуына бик тә эче пошкан һәм йөрәге янган. Үзенең өендә ун яшьләр чамасындагы малайларны җыеп, ул аларга хәреф танытып, догалар өйрәтә башлаган. Малайларга хәрефне мәдрәсәдә шакмакка төшереп өйрәтә торган булганнар. Шул гарәп хәрефләре төшкән шакмакларны тезеп, сүзләр китереп чыгарганнар.

Фазулла бабайда укыган шул заманның ике малаен мин, инде алар зур абзыйлар булгач, белә идем. Берсе — алда язып узган Тимеркәй — Тимергали Хафизов, икенче — Сәббахетдин Рафиков. Урамча әйтсәк, Капар Сәппәхе. Икесе дә Ватан сугышыннан исән кайтты. Тимеркәй абый сөйли:

— Капар Сәппәхе хәреф таный алмыйча этләнә бит, әй. Мин инде «әлеп»не «ләм»нән аера башладым. Чамалыйм азрак. Фазулла бабай бахыр үзе дә этләнә, безне дә ярыйсы гына этли инде. Ярар. «Әлпи» төшкән ягын күрсәтә Фазулла бабай Сәппәхкә шакмакның. Сорый, нинди хәреф бу, дип. Сәппәх таш булган да каткан. Фазулла бабай:

— Ташбаш! Нәстә дигән хәреф бу, ә? — дип тегенең җилеген каезлый. Төштең Капарның җилегенә, төшмини? Сөппәхнең күзе теге шакмакта. Тик утыра үзе һаман. Мин Сәппәх артында утырганмын тезләнеп, пышылдыйм тегеңәргә:

— «Фыр» дип әйт! «Фыр» хәрефе диген.

Сәппәх куана:

— «Фыр» хәрефе,— ди.

Фазулла бабай сала Сәббәхетдиннең маңгаена теге шакмак белән:

— Хайва-ан! «Фыр» дигән хәреф буламыни?! Тач атаң Шәйхел икәнсең, мокыт. Ул шулай «әлеп»не таяктан аера алмады, ничә еллар мәдрәсәдә ятып...

Урамга чыккач, әй китәбез сугышып Капар белән. Теге бәйләнә миңа, ния яңгылыш әйтәсең, юри әйтәсең, дип. Мин әйтәм, белгәнне әйтем бит

инде. Биргәләшәбез тегенең белән, берәребезнең борынынннан кан киткәнче... Язгылыкка знай сукалый башладык теге хәрефләрне. Шакмаклар тезеп сүзләр ясыйбыз. Тик... Тамчылар тама башлаган чак җиткәч, иртән Фазулла бабайга барсак, бабай юк. Карчыгы елап шешенеп беткән. Хәлфәгезне, төнлә килеп, алып киттеләр атарга, ди бу. «Гыпывы» ди. Бишләп малай киттек милиция йортына. Үзебез куркабыз, тик үзебез Гапкадыйр мәгъзүмнең малайлар өе алдында карда таптанабыз. Шул малайлар йортыннан өтермә ясадылар. Иң беренче өтермә булды бу авылда. Сугыштан соң гына зурайтып чын өтермә салып куйдылар. Зу-ур итеп... Ярар, тапануын тапанабыз. Бабайны күреп булмый. Чыкты Антипов дигән милиция. Карамалка урысы иде. Яңа гына килгән. Япь-яшь иде әле ул вакытта. Урысчалап куа бу безне. Без азрак читкә йөгерәбез, ләкин кайтып китмибез. Өч көн йөредек тегендә бабайны күрергә дип. Ашарга да кайтмыйбыз, көнозын шунда буталабыз. Өйгә кайтсаң, әти әрли:

— Йөремә анда, йә утыртып куярлар үзеңне. Иманнары юк аларның.

— Утыртмыйлар. Бәләкәй бит әле без.

— Синең өчен мине утыртсалар?

Мин дәшмим, йөрүем йөрү. Өч көн узгач, чыгардылар безнең бабайны. Бәләкәй генә булып калган, ансыз да бәләкәй гәүдәле кеше. Укытмаска кушып, куркытып чыгарганнар моны. Тирәләп уратып алып кайтып киттек хәлфәбезне. Туктады, укытмады башкача, нык куркыттылар, ахры.

Ясаклы урамында, көзгә, бер йортта совит мәктәбе ачтылар. Бер ай чамасы укыгач, Фазулла бабай килгән безнең мәптеккә. Теге гарәп хәрефле шакмакларны китергән. Бер кечкенә киндер капчык белән. Үзе елмая. Җайлап кына карап чыкты без укыган ике бүлмәне. Парталарны тотып-тотып карады. Шуннан соң гына, чыгып киткәндә әйтә:

— Мәдрәсәгә җитми инде мәптегегез. Әллә урысчарак инде. Шулай булса да тырышыгыз, балалар. Без татар, гыйлемсез татарлыгыбызны җуябыз, югыйсә...

Шушылар менә Тимергали абый сөйләгәннәр.

Фазулла карт сугыш елларында үлде. Ачлыктан. Кияве Әмәт бабай да шул елларда вафат булды. Фазулла бабайның улы Гатиятулла да 1943 елгы язгы ачлыкта, әнисе белән бергә, агуланган башактан пешергән ботка ашап үлделәр.

Фазулла бабай йортына кызы Хөршидәне ияртеп олы кызы Латыйфа апа кайтты да үлгәнче шул йортта яшәде.

Файзулла бабай оныгы Хөршидәгә урам «Әмәт малае» дип исем такты. Чөнки ул кызның бөтен торышы, балта-сәнәк тотышы, таш бәрүе, чебенле, шаралы уйнавы — бар да малайларча булды. Үзе бар нәрсәгә дә малайларча оста, тәвәккәл, мунча бурый, келәт сала. Атны да ирләрчә оста итеп җигә белә. Чын-чыннан «Әмәт малае» иде ул. Әлеге көндә дә шул урында яши. Тик япа-ялгызы. Бердәнбер малае авариягә юлыгып үлеп киткән. Килененә малаеннан калган ике баланы тәрбияләргә ярдәм итә. Фазулла бабай нәселе, кызы ягыннан булса да, бар әле.

Хөршидә апа — безнең урам комитеты рәисе. Урамны карый белә. Бар җирдә тәртип, урамда чүп-чар тузылып ятмый. Эчкәнен, эчмәгәнен урам файдасына эшләтә белә ул. Урам кешеләре, аңарга азрак көлебрәк караган кебек булсалар да, аны хөрмәт итәләр һәм... аңардан азрак шүрлиләр дә.

Фазулла бабай йорты салам башлы, юкагач чоланлы, сирень агачлы йорт иде. Сирене әле дә бар...

Урамдагы иң бай булган ул кешене мин күреп түгел, ишетеп кенә беләм. Һади Чалышлардан соң — тыкрык. Исеме Күлик тыкрыгы.

Шәңгәрәй бабайниндирәк булгандыр — белмим. Аны авылдан 1937 елны алып киткәннәр. Ничек итеп, ни сәбәп тапкандыр, тик шуңа кадәр аңарга тимәгәннәр. Йорты исә менә мондыйрак иде.

Зур, такта урыс капка. Тау ташыннан салынган койма. Биеклеге метр ярым чамасы булып, киңлеге метр тирәсе. Койма салганда таш арасына кара туфрак тутырганнар. Өе — урам буйлап сузылып салынган ике яклы зур йорт. Өй белән таш койма арасында бердәнбер өянке үсеп утыра. Өе капкадан керүгә уң якта. Сул якта бер-берсенә терәлеп салынган таш келәтләр, сарайлар, мал абзарлары. Барсының да ишекләре калын имән тактадан ясалган. 1938—40 елларда Шәңгәрәй бай йорты — «8 март» колхозының бишенче бригадасында атлар тота торган урын. 1941 елны сугыш алдыннан гына бишенче бригада атларын Каенлы елга буена салынган таш сарайга, авылдан читкә чыгардылар. Шәңгәрәй бай йортында сабан, тырмалар, атларга солы тота башладылар. Ә 1943—44 елларда Шәңгәрәй бай йортына Миңлегали дигән абзыйны дүрт баласы белән урнаштырдылар. Ул кап-кара сакал-мыеклы, үпкә авырулы кеше. Хатыны үлгәч, йорт-курасын сатып ашагач, шунда күчерде авыл советы. Миңлегали абый 1944 елны үлде. Ул үлгәч, дүрт баласын да энесенең хатыны — фермада эшләгән Рәйхан апа үзенә алып кайтып китте. Үзенең ике баласы белән бергә, тагын дүрт ятим бала карады ул апа. Ире Басыйр абзый сугышта ятып калды.

1945 елда Шәңгәрәй бай йортын икенче урамда яшәгән Хәйрулла Кәримов дигән абый сатып алды. Урамча әйтсәк, Хәйри Кабан. Әтисе, авылча Гапкадыйр Кабан Югары Очта яшь хатыны һәм өч малае белән яши. Хәйри Кабан сугышка кадәр үк колхозда тракторист булып эшли башлаган кеше. Сугыш елларында бронь белән калып, колхозда ЧТЗ тракторында эшләде. Колхоздан ул йортны сатып алган кебек кенә итте. Алган уңайга ук өен сатып җибәрде дә, күрше Мәксет авылыннан Локман мулладан калган зур, карагай йортны алды. Шул зур йортны 1946 елда күчереп салып куйды. Хатыны Маһикамал (Майкамал) — күрше урамдагы Шүрәле Лотфулла кызы. Ул бабай безнең авылга Миякә ягыннан килеп йортка кергән кеше. Колхозга кермичә калган берничә бабайның берсе. Кызы Майкамал апаның кул-аягы гарип. Ул кулы белән чиләк тә тота алмый, суны ташыганда чиләк келәсен беләгенә киеп алып кайта. Безнең урамга күченгәндә аларның дүрт малайлары бар иде: Хәлим, Хәлил, Хәйдәр, Халит. Безнең урамга күчкәч, кызлары туды. Халидә исеме куштылар.

Хәйри абзый бик унган. Җәен, кышын ЧТЗ тракторыннан төшмичә эшли. Чагыштырмача тормышлары тук. Алар сугыш елларында да ипидән өзелмәделәр. Әниләре гарип булганлыктан, малайлар яшьли үк бик эшләп үстеләр. Алар белән зур малайлары Хәлим җитәкчелек итә. Тыңламасалар, аз-маз биргәләп тә ала тегеләргә. Ә малайлар абыйларын нык яраталар. Чөнки ул «тәккә генә тими». Хәйдәрләре сөйли:

— Берүзем генә өйдә идем. Бер христара (урыс теләнчесен безнең якларда шулай атыйлар, «Ради Христа» дип соранган өчен) килеп керде. Капчыгы да бар зур гына. Мин курка калдым, әниләр әйтмешли, капчыгына салып алып китсә. «Христара бит!» Кереп, ишек төбенә басты да: «Христара?» — ди. Дай хлиб пжалыста?» — ди бу. Әни яңа гына мичтән ипиләр чыгарып тезеп сәкегә, өсләренә ашъяулыгы ябып куйган иде. Берсен алдым да тоттырдым теге Христарага. Ипине алды да елый әй теге урыс. Миңа: «Спачиба, сынук», — ди. Китте чыгып...

Хәйри абый әле дә исән-сау. Майкамал апа инде күптән юк. Халитләре, төпчек малайлары, юлда авария белән һәлакбулы. Хәлим — полковник, Таллинда яши. Хәлилләре, Халидәләре — авылда.

## Көрпәләр

Фазулла бабай белән янәшә, аның ас ягында, бертуган абыйсы Көрпә Гобәйдулла йорты. Озын чандыр гәүдәле, озын муенлы, зур колаклы, озын куллы бабай ул. Аның турында мин «Үрләр аша» повестенда азрак язган идем инде. Битенең бер ягын нindидер экзема каплаган. Шуннан аның бите көрпә каплаган кебек булып тора: авыл өчен ул Көрпә Гобәй. Нәселләре белән игенчеләр, малчылар булып, Гобәйдулла бабай да авылның иң тырыш игенчеләренең берсе. Абзаркуралары зур, бөтен. Улы Зөбәйдулла абзый 1903 елда туган. Ике яклы йорт тотып, әтисе белән бергә яшәде. Зөбәй абыйның хатыны Гайшә апа 1904 елда туган. Күрше урамда яшәүче Әфисәр Абдулла бабай кызы. Зөбәйдулла абзый белән Гайшә апаның өч баласы бар: Гарифулла, Кәшифә, Фәрит. Гарифулла абый белән минем Мансур абый дуслар. Фәрит белән мин дус. Гобәйдулла бабайның бәләкәй генә йомры гәүдәле Өмәһани исемле әбисе бар. Ул — минем кендек әбисе. Очраган саен минем аркамнан сөеп китә торган иде ул әби.

Мин 1933 елның 10 июлендә, арыш урагында Гөбазы дигән яланда басуда туганмын. Шунда Өмәһани әби минем кендекне урагы белән кискән һәм капчыктан суырып алган киндер җеп белән бәйләп тә куйган. Кояш сүрелә башлаганны көткәннәр дә киндер капчыкка төреп, тотып алып кайтып киткәннәр. Өмәһани әбинең кендек әбисе буларак тәҗрибәсе бөтенләй булмаган ахрысы — минем кендекне озын итеп калдырып кискән. Су кергәндә малайлар мине «ике почтиле» дип үрти торганнар иде. Бер-икесенә бергәләп алгач кына туктадылар. 1974 елда Рига госпиталендә сукыр эчәккә операция вакытында, көлеп-шаяртып, хирург ул кендекнең артыгын кисеп ташлады. (Шунлыктан су кергән чакларда мин хәзер тыныч кешемен).

Зөбәйдулла абый 1942 елны сугышка китте дә шуннан кайтмады. Ни өчендер мин аның турында сугышта ул бер генә тапкыр да атмагандыр да дип уйлыйм. Бигрәк тә гади җирче, бигрәк тә юаш иде ул, мәрхүм. Өмәһани әби сугыш башлангач үлде. Гобәйдулла бабай Ибрай дигән авылдан бер әбине алып кайтты. Үзе, сукыраеп, 1944 елда үлеп китте. Ул үлгәч, шул әби ярты йортны сүтеп сатты да, кире кайтып китте.

Гарифулла абый, әтисе сугышка киткәч, 1942 елны колхозда эшли башлап, үлгәнче (1984 елга кадәр) шунда эшләде. Белеме аз булуга карамастан (биш сыйныф иде бугай), бик тә китап укырга ярата торган иде. Мин ялга кайткан саен аңарга бер китап алып кайтам. Ул, кайтканның икенче көнендә, зур авызын ерып килеп җитә. Китапны алып, матур итеп җайлап кына сыйпый да, гәзит сорап алып шуңа төреп куя. Минем абый аны үрти:

— Кая, Көрпухин, миңа да күрсәт инде?!

Еллар буена бер үк җавап:

— Мин укыгач карарсың, сиңа дип апкайткан китап түгел!

Гарифулла абыйның бәхете бик тә чамалы булды. Бер-бер артлы туган өч малае да гарип булдылар. Үз-үзләрен белмиләр, сөйләшмиләр. Тәүге икесе йөри дә алмадылар бугай. Икесен гариплар йортына илттеләр. Иң соңыннан туган дүртенче малайлары белән төпчек кызлары исән-тазалар.

Гарифулла абый зур, иркен итеп йорт салды. Тик йортына кергәч озак яши алмады, 56 яшендә үлеп китте.

Гайшә апа, улы үлгәч Ташкентка Кәшифәсенә китәргә мәҗбүр булды. Килене кырыс холыклы булып чыкты. Гайшә апа соңгы елларда авылны, урамны бик нык сагынган. Килененнән кайтырга рөхсәт сорап хатлар яздырган. Килен рөхсәт итми. Гайшә апа туксан яшенә җитә язып, Ташкентта үлде, шунда күмелде. Теләге — кайтып, улы Гарифулласы янына күмелергә иде. Тик язмышлар белән хәзерге заманда комсызлык идарә итә.

Урам якка караган тәрәзә төпләрендә бер өянкеләре бар. Урамда, Көрпәләр каршында сиртмәле кое. Аның бавында агач чиләк, ул чиләк өч тимер кыршау белән уратылган. Кое янәшәсендә генә 4—5 метр озынлыкта, чокып эшләнгән улак. Анысы мал эчерер өчен. Кое — урамда бердәнбер сиртмәле, улаклы кое. Бишенче бригадада Гобәйдулла бабай алып килгән aклы-кызыллы Ала бия бар. Шул биядән үзе кебек aклы-кызыллы колын туды. 1948 елда мин, колхозда атлы печән чапкычында Нигъмәт Папай белән эшләгәндә, шул тайга менеп, авылга ашарга алырга кайта торган идек.

Кәшифә сөйләгәннән:

«Картәти мине үзләренә алып кереп (чолан аша!) кундырды да иртән ураза тотарга дип сәхәргә уятты. Картәни тәмле-тәмле коймаклар пешергән, күп итеп каймак, корт, бал куйган. Ашап-эчеп, тагын ятып йокладык. Инде яктыргач, йокыдан торгач, ашыйсы килә-ә. Ә ураза тоткан-да ашарга ярамый икән, караңгы төшкәнчегә кадәр. Картәти әйтә, иртәгә ураза бетә, гает бәйрәме була. Түз кичкә хәтле генә, ди. Кич була башлагач, картәти белән сәкегә менеп утырдык та, тәрәзәдән кояшның тау артына төшеп киткәнен көтеп карап утырабыз. Инде ашыйсы килә — түзәр әмәл калмады. Минем исәп — үзебезнең як өйгә чыгып таю. Су булса да эчсәм, дип торырга иткән идем, күлмәк итәгем арттан шытырдап җыртылды да китте. Картәти мине, торып китмәсен дип, арттан күлмәк итәгемне кулы белән басып утырган икән. Мин тотындым еларга. Ике көн узгач, картәти миңа, картәнигә, әнигә күп итеп күлмәклек алып кайткан кибеттән. Барыбыз да бертөрле ситсыдан күлмәкләр тектергән идек!»..

Кәшифә 1931 елда туган. Бик күп нужа, бик күп михнәтләр күреп үсте. Беренче мәртәбә иргә чыгып, тиз генә аерылды. Шуннан бер кыз баласы булды. Исеме Нурия. Гарифулла абый өйләнгәч, Кәшифә шул кызын алып (килен командалык итә башлый!), Урта Азиягә, әтисе белән бертуган апасы Миңсылуны эзләп чыгып китә. Зур авырлыклар белән Ырымбурга барып җитә. Сиксәненче елларда табынга бергә туры килдек, авылга кунакка кайткач. Сөйли:

— Ташкинга китәргә дип утырабыз Ырымбур вакзалында. Пуез көтеп. Барлы-юклы акча билиткә кереп бетте. Билит кесәдә. Ташкинның үзенә хәтлек. Башкача бер тиен акча юк. Бетте. Нуриям бише белән бара. Инде елый сабый — ашарга сорый. Ике көн авызга юньле ризык капкан юк. Аңарга кушылып үзем дә елыйм. Сатып ашарга да бер нәстә юк өстә. Азакны куфтыны сатып, билиткә өстәдем. Пуез кузгалырга ун сәгатьтән артык вакыт бар... Ап-ак сакаллы бер бабай килеп утырды яныбызга. Тирәк төбендә җирдә утырадырыек. Күләгәдә. Утырган җиремнән үзем уйлыйм: «Әтием Зөбәйдулла, балалары шушылай ачтан яфа чиксеннәр дип нимес фашистлары белән сугышып юкка чыктымыни инде?» — дип. Утырды бу бабай безнең янга. Догасын укып, битен сыпырды. Аңа ияреп, кызым белән без дә бит сыпырдык. Сабый бит, бисмилланы кычкырып укый. Безгә карап байтак утырды бу бабай. Нуриям башын минем алдыма салган, шыңшый бичара. Еларга хәле бетте эсседә. Бабай сорады:

— Кызым, сез мөселманнармы?

— Мөселман, бабай.

— Бу сабый баланы, елата-елата, кая китеп барасың?

— Ташкинга барабыз, бабай. Әтиемнең бертуган сеңелесе анда яши. Авылда форсат калмады яшәргә.

— Үзең каян?

— Ерактан, бабай. Башкортстанның Эстәрлебаш дигән авылыннан.

— Ерактан икәнсең шул,— ди бу бабай. Шуннан капчыгын чиште дә, Нурия белән икебезгә зу-ур бер түгәрәк арыш әпәе бирде. Алдым теге әпәйне, бисмилламны әйтә-әйтә, куана-куна. Ис-се теге ипекәйнен — баш әйләнә. Йөгереп барып, вокзал янынннан кайнаган су алып килдем дә, кызым белән утырдык ашарга. Бабайның үзенә дә бирдем кисеп. Алды рәхмәтен әйтеп. Күрәсең, азаккысын биргән булгандыр. Кружкадан өрә-өрә кайнар су эчеп, шул бер телем ипине ашады да тагын дога укып битен сыпырды. Зур авырлык белән торды да, буш капчыгын сул кулына тотып, уң кулына шомарып беткән таягын алып, безгә изге юл теләп, китеп барды бабаебыз...

Инде минә Нуриямнең ике баласы бар. Үземнекеләр Нурия белән алтаулар. Бик әйбәт бер үзбәккә кияүгә бирде Миңсылу апа мине. Аллага биргәненә мең шөкер. Нуриям теге бабайны һаман да исенә ала. «И-и, әни,— ди. Ул бабай Алла бабай үзе булгандыр,— ди. Шул хәтлек тә миһырбанлы кешеләр булалармы икән дөньяда? Әгәр ул бабайны хәзер таба алсам, үзебезгә алып кайтып, үзем карар идем, нык итеп тәрбияләп»,— ди балам.

Ялан кебек зур йортта Гайшә апаның килене бер ялгызы яши хәзер. Малае да башка, кызы да башка. Иркендә калды ялгызы...

## Мәчет йорты

Урамнан Көрпәләр йортына карасаң, сул якта мәчет йорты. Эстәрлебаш авылы зур авыл булса да, атаклы Тукаевлардан чыккан ишаннар авылда бер генә мәчет тотарга тырышканнар. Максаты, күрәсең инде, авыл халкын тик Тукаевлар йогынтысында гына тоту.

Түбән Очта мәчет узган гасырның туксанынчы елларында гына салынган. Мин үскәндә, утызынчы еллар азагында, бар җире дә тәзек, кызылга буялган тимер башлы бина иде. Тик манарасы гына юк. Мәчетнең манарасын 1934 елда кискәннәр.

Мәчет йорты — сугыш елларында безнең җыйнала торган урын. Йорт эчендә арырак мулла өе. Мулла бабай үзе өтермәдә. Ул 1945 елның көзендә генә кайту бәхетенә ирешкән. Тик йортын кире бирмәделәр.

Мәчет ишек алдында без кәртле, акчалы, качышлы, чокыр-туплы уйныйбыз. Истә калганнардан берничәсе.

1937 ел. Без Пожарныйга күченеп киттек. Шул көзне Түбән Оч мәчетендә урыс школасы ачтылар. Әни зарлана:

— Аллаһы Тәгаләнең каһәре төшсен инде, мәчетебездә урыс ышкулы ачканнарга! Каһәр суксын! Ходай үзе сакласын — бала-чаганың әллә нәрсәләр күрәсе бардыр әле. Мәчет хәтлек мәчетне шулай кыйландырсыннар әле?! И-и Алла-а, үзең беләсеңдер нишләргә...

Без, вак-төяк малайлар, зуррак малайларга ияреп, «мәчет өчен урыслардан үч алабыз». Дәресләре башланса, мәчетнең биек нигезенә менеп басабыз да, туңа башлаган тәрәзә пыялалары аша кычкырабыз: «Урыс, урыс!» Аннан соң кем кая өлгерә, торып йөгерәбез. Тагын киләбез, тагын кычкырабыз, тагын йөгерәбез. Берничә көн шулай җәфаладык теге урысларны. Шуннан бер дә беркөнне берничә зур урыс малае мәчет артындагы бина чоланына качып торып, безне — вак-төяк малайларны тотып, баштан бүрекләрне җыеп киттеләр. Колаклар өши башлагач, таралыштык. Әнидән дә өлеш чыкты. Өстәвенә, иртән әнидән миңа «ультиматум»:

— Бүрексез, өйгә кайтып керәсе булма!

Икенче көнне бүрекләре алынган малайлар җыйналып бардык мәчет йортына. Бер урыс малае чыгып чакырды эчкә. Кердек. Чибәр генә бер марҗа апа урысча безгә байтак кына нәрсәдер сөйләде. Тавыш-тынсыз тыңлап, бүрекләрне алып чыгып киттек. Урыс теле белән танышу шуннан башланды бугай минем өчен. 1942 елны ул урыс мәктәбен татар мәктәбенең бер зур бинасына күчерделәр. Бүгенге көнне татар авылында татар мәктәбе бетерелеп, урысча гына укыту алып барыла...

Сугыш елларында шул Түбән Оч мәчетенең идән-түшәмен, ишек-тәрәзәләрен куптарып алып ягып бетерделәр. Суык, ачлык...

Мәчет йорты безнең кебек ташбаш малайларга уйный торган, бергә җыйнала торган урынга әйләнде. 10—13 яшьлек малайлар идәнсез мәчет эченә кереп «ачуклы» уйный. Акча булса, без вак-төяк тә шулар арасында буталабыз. Тик безнең өчен иң куркынычы — Тәмеч дигән кеше. Ул — милиционер һәм аның чын исеме Сәлимгәрәй. Фамилиясе Гайсин. Аның Вачута исемле хахул хатыны бар һәм бөтен авылга берәү генә булган чучкасы бар. Балалары юк, икәү генә яшиләр... Тәмеч мәчет йорты аша салган сукмак белән эшеннән өенә кайтып йөри. Безнең кәртле уйнагандагы шау-шуны ишетеп, мәчет эченә тавыш-тынсыз гына керә дә безне «эләктереп ала». Үзебез агач пичәтләр сугып ясаган кәртне, безнең акчаларны «конфискацияли». Безнең берәм-берәм колакларны бора. Чигәләргә дә «җиппәргәли» кайчак. Зәңгәр төстәге милиция киеме, салынып торган кара шнурлы кабура эченә тыккан «ливарвиры», күн итекләре, йолдызлы фуражкасы, кечкенә кәкре аяклы гәүдәсе безгә шом һәм курку сала. Бик озак безне шулай эзәрлекләгәннән соң, без дә «чара күрә» башлыйбыз. Мәчет тәрәзәсе төбенә берничә малайны утыртып куябыз. Кем Тәмечне беренче булып күрә, шуңарга егерме тиен акча. Сакчы: «Тәмеч килә», — диюгә, ишек-тәрәзәләрдән чыгып сызып, юк булабыз. Ә Тәмеч абзый, сезнең кайгы юк әле монда дигәндәй, вак-вак адымнар белән титаклый биреп, Вачутасы янына ашыккан була...

Сугыш бетәсе елны язын Мәчет йортында сукырлар җәмгыяте төзеделәр. Төрле яктан җыелган ирләр, хатыннар яңа идән-түшәмнәр ясалган мәчет эчендә кыеш башлы пималар баса башладылар, чыпта суктылар. Хатын-кызлары уйнаштан бала таба башлады. Аларның яшәгән урыны элекке мулла бабай йорты булды. Сукырлар, ятимнәр, ярлылар, йортсызлар иделәр бичаралар.

## Минамал әби

Мәчет каршында гына Миңлеямал әби яши. Минем хәтердә аз гына калганы — ире Бәхтигани бабай иде. Балта эшенә бик оста куллы. Күрше-тирәгә нык ярдәмчел. Һәрчак балта-пычкысын күтәреп кереп җитә торган иде. Тик 1938 елны капылт кына үлде дә китте. Минамал әби өч кечкенә бала белән ятим калды. Фәридә апага ун яшь. Бер аягы тумыштан чатан булып, урам өчен әле дә Чатан Фәридә. Аннан соң 1931 елда туган Флүрә һәм 1935 елгы төпчекләре Тимербулат.

Нәрсә эшләп көн күргәннәрдер, әйтүе кыен. Бик ярлы, бик фәкыйрь яшәделәр. Бердәнбер сыер тоталар иде. Фәридә апа белән Флүрә шәл бәйләделәр. Тимербулат 1948 елда ук колхозда үгез җигеп эшли башлады.

Флүрә, үсеп җитәр-җитмәстән, Эстәрлетамак каласына нindидер бер заводка барып урнашты. Аның анда эшли башлавы ул ярлы гаилә өчен иң зур шатлыкларның берсе булды. Аллага шөкер, үзен-үзе карый, дип сөенде нужадан бәләкәй генә булып калган Минамал әби. Фәридә апа

районның мал карый торган больницасына идәннәр себереп, юучы булып эшкә урнашкач, Минамал әбиең гәүдәсе зураеп та киткәндәй булды. Тимербулат өйләнгәч, Фәридә апа шуннан үзенә фатир алып, алар Минамал әби белән «башка чыктылар».

Тимербулат бик үткер, унган хатын алып, шуның белән алты бала үстерделәр. Матур итеп, мул тормыш белән шул урыннарында яшиләр. Тимербулат бик күп еллар колхозда «Беларусь» тракторында эшләде. Инде ике малае да трактористлар булып, хәзер алар җир алып, фермер булырга тырышып эшләп яталар. Өчесе дә сунарчылар.

Тимербулат күрше Фәйзеригә, миңа ияреп, малай чагында бик зур ихласлык белән балыкка йөрде. Фәйзер янында сунарчылыкка өйрәнде. Тимербулат төптән юан чыккан, кечкенә гәүдәле, әнисенә охшап үтә дә җор сүзле, телгә беткән бер кеше. Сөйли:

— Уидүрт яна гына тулган чак. Кыш көннәрендә ышкулга утын ташыйбыз. Миңа бригадир Сәвәләй Бакыйры Сапкамал дигән иң шәп үгезне бирде. Кызгана Бакыйр абзый мине. Мин бригадта эшләгән малайлар арасында гәүдәгә дә, яшькә дә иң бәләкәе. Гомере буена авыл көтүен ялланып көткән мукшы бабайның Вәчилие — урман каравылчысы. Ясаклы урамында яши бу авылның. Бердәнбер мукшы бездә. Татарча сиңнән-миннән шәп сукалый инде. Бер атна ташыдык. Үгез дә ач, үзем дә ач — көненә бер юллыйбыз инде.

Утын төягән җир — Вәчилефке дигән урыс авылын узып, текә тау башында. Бу мукшы Вәчиле миннән көлергә булаша бит, әй. Буй бәләкәй бит инде минем. Көч юк. Парта арасыннан чыкмый торган бер маңка малай гына инде. Юан дүрт каен агач ята теге утыннар ташыган җирдә. Ач халык тегеләргә тотынырга базнат итми. Бик юаннар, авырлар болар. Мукшы әйтә миңа:

— Төяп ал шул каеннарны. Барыбер төягән кеше юк. Миннән рөхсәт сиңа. Үзеңә генә.

Мин нәрсә инде, ризалашып баш селкегән булдым, елмайган булдым моның мукшыча шуткасына. Бер тәүлек йөрдем, әй, уйланып ничек итеп төяп алып кайтырга теге юан каеннарны?

Иртәгә базар көн дигән көнне киттем Сәвәләй Бакыйр абзыйга. Шулай-шулай, Бакыйр абзый, утын бетте. Иртәгә Сапкамалны бир инде син миңа. Мукшы Вәчили белән сөйләшкән сүз бар, утынга барырга иде үземә. Бирде, әй, берсүзсез. Бригадта эшлим бит. Киттем иртән, Кабан Хәлимен утыртып, урманга. Мәҗит бабай күп итеп сарут печән чалды чанага. Яртысын сыерга калдырдым да, куенга ике кисәк ипи тыгып, киттек Хәлим белән. Иптәш кирәк бит. Урман диләр аны...

Уйлап таптым әй, ничек төяргә тегеләрне. Үгез муенына капчыктан камыт кебек нәстә әтмәлләп кидердем. Ике яктан аркан очын теге камытка нығытып бәйләдем. Арканнарның икенче очын төйи торган агач, чана астыннан чыгарып кире китереп бер юан агачка бәйләдем. Чананың үрәчәсен төшердем дә, үзен тартып китереп агач буена тигезләп куйдым. Ялт иттереп минут эчендә үгез белән тарттырдым да меңгердем теге агачның икесен чана эченә. Хәлим үгез җитәкләп тарттыра, мин бүрәнә янында күсәк белән теге тәгәрәгән бүрәнәне тигезләп кенә барам. Хәлим әйтә:

— Ну, баш синдә, әй, Тимербулат. Укымыйча әрәм буласың бит, әй син,— ди. Хәлимнеке кебек әти булса, мин дә укыр идем дә бит. Юк әти! Ике агач бер йөк булды да куйды. Сапкамалга үземә дигән ипине ашаттым да киттек кайтып. Авылга кергәндә теге мукшы өе янынннан чаптырып үтеп киттек. Икенчегә барырга булгач, Сапкамалга бер чиләк бәрәңгене турап, аз гына солы оны сибеп ашаттык та киттек чыгып. Аллага тапшырып. Заматта әйләнеп кайттык әй икенче йөкне төяп... Ике көн узгач теге мукшы килгән безнең йортка. Әй йөреде, әй йөреде мин алып кайткан бүрәнәләр янында бу. Шуннан соң сорый:

— Тимерпулат! Мин урманда синең төягән эзләрне карап, бер нәстә дә аңламадым. Ничек итеп төядең син бу юан бүрәнәләрне?

— Сикрит,— мин әйтәм.— Хәйләсе бар.

— Ярар инде,— ди мукшы.— Угавур даруже дингә, ди. Синеке булсыннар болар,— ди.

Соң баш бар диген инде, минем ишек алдында яталар бит инде. Азрак әчеткән бал бар иде, алып кердем теге мукшыны. Ул әнинең куанганын күрсәң! Улы ирләр төйи алмаган агачлар алып кайткан бит тә, өстәвенә, урман каравылчысы бал эчәргә кергән бит безгә. Шуннан соң утын кытлыгын бетердем үзебез өчен. Иң юан бүрәнәләрне барам да, төйим ышкул диләнкәсеннән. Башка кешеләрнең көче житмәгәнен... Бакыйр абзый ат бирергә булгач та Сапкамалдан аерыла алмыйча тагын бер кыш йөрдем әле. Иллә дә шәп хайванкай иде инде. Колхозда машиналар күренә башлагач, Эстәрлетамакка иткә сдавайть иттеләр үгезне...

## Әфисәр Сибгате

Сибгатулла абзый — күрше урамда яшәгән Әфисәр Абдулла малае. Көрпә Гайшәсе аның бер туган апасы. Хатыны Өмегөлсем апа — Эстәрлебашның атаклы тегермәнчеләр нәселеннән. Аның бертуган энеләре, абыйлары — Фәррәх, Гимай, Кәррәм, Сәләх — бар да тирә-як елгаларда су тегермәннәре төзеп, шунда тегермәнче булган кешеләр. Абзасы Гимай егерменче ел азакларында, колхозлар чыкмас борын, тирә-яктагы сабан туйларында дан тоткан Кызыл биясенә көмеш белән бизәлгән йөгән, эшлияләр кидереп, дугасына көмеш кыңгыраулар тагып йөри торган булган. Колхозлар чыккач, башкорт авылы Мортазадагы тегермәннең буасына батырган барысын да. Кызыл биясен юк иткәнен берәү дә белми. Имеш-мимешләргә караганда, суеп җиргә күмгән, диләр. Ул тегермәнчеләр тирә-якта осталарның осталары иделәр. Иң кечеләре Кәррәм бабай минем әтинең дусты иде. 1981 елны гына үлде. Үзе үлгәнче Урман авылында Кәррәм бабай салган соңгы су тегермәне эшләде. Ул районда да соңгы су тегермәне булгандыр әле.

Әфисәр бабай — Абдулла Гатауллин Япун сугышыннан унтер-офицер булып, погонына өч лычка, түшенә бер Георгий хачы белән ике медаль тагып кайткан. Тәреләрен әтисе Хәсән бабай башкача тактырмаган. Мөселман син дип. Погоннарындагы лычкасына, унтер-офицер булганына карап, авыл халкы аңарга «Әфисәр» дип исем такканнар. Без үскәндә ап-ак сакал-мыеклы Әфисәр бабай иде инде ул безнең өчен. Сугыш елларында һәм сугыш беткәч, улларының, кызларының балаларын үз янына җыйнап, ашатып яшәде ул карт бабай. Бик асыл кеше иде. Җәй көннәрендә Әфисәр тыкрыгыннан үтәргә туры килсә, күрәсең: Әфисәр бабай тезләнеп бәрәңге буразнасы арасына кереп утырган. Бәрәңге утый, аны көрәк белән күмә. Ул көннәр буе бәрәңге бакчасыннан чыкмый торган иде. Авылда иң эре, иң тәмле бәрәңге аныкы. Ел саен яз башында аның бәрәңге утыртканын көтә Түбән Оч кешеләре. Абдулла бабайга карап бәрәңге утырталар, аңарга карап ала торган идек без дә.

Шул Әфисәр Абдулла бабайның улы Сибгат абзый Хөснә апаларның каршысында яши. Өмегөлсем апа белән икесенә дүрт кызлары бар: Рауза, Оркыя, Асия, Мөнәвәрә. Рауза 1930 елда туган, Мөнәвәрә — 1942 елда. Сибгат абзый колхозда бригадир булып та, гади колхозчы булып та эшләде. Ябык кына, чандыр гәүдәле, сүзләренең азагын йотып сөйли торган кеше иде. Нык кына эчеп ташлаган вакытлары да истә калган.

Сибгат абый сугышта ятып калды. Өмегөлсем апа белән кызы Оркыя 1943 елны язгы ачлыкта үлделәр. Үләренә ике-өч көн кала Өмегөлсем апа әни янына Пожарныйга килгән иде. Аягындагы чабаталары тузып,

киярлеге калмаган. Әни белән Өмегөлсем апа Пожарныйдагы иске чабаталар арасыннан «киярлекләрен» сайлыйлар. Юньлерәкләре Өмегөлсем апа аякларына кияргә тырыша, үзе сөйләнә:

— Инде ачмын, Мәрьям түти. Бер ходаем гына белә. Өемдә дүрт кызым ачлар. Шунлыктан йөрәгем өзгәләнә, үзем генә беләм инде. Менә аякларымны карале, ачлыктан шешенә башладылар...

Ул, бичара, бармаклары белән шешенгән аяк йөзен басып күрсәтә. Бармак баскан җирдә, аяк йөзендә чокырлар хасыйл була да, алар озак бетмичә торалар. Минем әни — унберенче, егерме беренче, утыз өченче елгы ачлыкларны күргән кеше — аны юатырга тырыша:

— И-и Өмегөлсем иркәм! Сабыр ит! Ходай бирәр юнен бирер әле, бирми булмас. Менә сиңа катык, азрак бәрәңге. Кызларыңа ашат. Үзең дә аша, юкса өзлегерсең. Аша, аз булса да. Тик үзең күп ашый күрмә, киселә башлагансың ачтан. Азлап кына аша...

Өмегөлсем апа әни белән утырып чәй эчә дә әни биргән җәймәне чемертеп кенә каба. Күбесен түшенә яшерә:

— Кызларым куанырлар инде, сабыйларым. Ходай Тагалә сиңа бетмәс ризыклар бирсен инде, Мәрҗәм түтекәем. Тизрәк кайт күченеп үз йортыңа. Бергәләшеп яшәрбез, Алла боерса, күршеләр булып. Син барда күңелле иде. Күршелеккә бик әйбәт идең син...

Атна үтүгә алар — кызы Оркыя белән икесе үлделәр. Әни белән бергәләп, ятим калган өч кызга ашарга илтергә бардык. Урам як нигездә унике яшьлек Рауза нигез тырнап елап, шешенеп беткән. Аның янында куркынган алты яшьлек Асия бөрешеп җирдә утыра. Өй эчендә, как сәкедә, ялангач такта өстендә сабый бала — ялангач Мөнәвәрә ята. Кемдер калдырып киткән бөрттерелгән кабыклы солы бөртекләрен берәмләп чүпләп ашап ята сабый. Яшәргә тырыша адәм баласы, әни үлде дип тормый. Әни алып килгән бәрәңгеләрен ашатып булышканда, өйгә Абдулла бабай белән карчыгы килеп керделәр. Тере калган балаларны Абдулла бабай алып кайтып китте үзләренә. Сибгат абыйның озакламыйча сугыштан үле хәбәре килде: «... смертью храбрых». Кем өчен? Сугышып йөргәндә гаиләсен ачтан үтергән «Родиhа Россия» өченме?

1980 ел. Мин Ригада ракета училищесендә лекцияләр укыйм. Картәтисе Сибгатулла абзыйга охшаган Раузаның кече малае Ильяс училищегә укырга керде. Торышы, төсе белән тач Сибгат абзый. Хәтта сөйләшкәндә дә аның кебек сүз азакларын йотып сөйләшә. Охшаса да охшар икән кеше! Математиканы, физиканы су кебек эчә. Бик сәләтле малай. Рауза Эстәрлебашта телефон станциясендә телефонистка булып эшли. Көн аралаш миңа шалтырата өйгә. Сөйләшүе тулы зар, елый һәрчак:

— Әй, Зәки! Нигә генә җибәрдем икән ул баламны-ы! Бигрәкләр дә сагынам инде. Кайтарасыңмы әллә, сагынып үләм бит инде. Бигрәк тә әтиемә ошаган би-ит ул малаем минем...

Раузаның авылында тагын ике малае бар. Ильяс — төпчеге. Әниләр һәрчак шулай инде алар. Рауза белән 8—9 сыйныфларда без бергә укыдык. Тик ул уны бетерә алмады. Ә укыйсы бик тә килә иде. Картаеп аяктан егылып барган Абдулла бабай белән әбисен, ике бәләкәй сеңлесен карыйсы бар иде шул Раузаның. Телефонистка булып эшкә керергә мәҗбүр булды.

Ноябрь аенда Эстәрлебаштан Ильяска телеграмма килеп төште: «Кайт, әниең авыр хәлдә!»

Кичен мин аны озатам, вәгазь укыйм:

— Уфага, Мөнәвәрәләргә кереп торма. Аэродромнан Эстәрлетамакка туры кит. Аэропорттан автобуслар ярты сәгать саен йөреп тора. Туктамастан кайт та кайт. Бер дә булмаса, юлга чыгып кул күтәр. Йөк машиналарына булса да утыр. Юкка курсант формасын кимәгәнсең...

Туры кайтмаган. Уфада тукталган. Кайтып җиткәндә әнисе инде үлгән булган. Хәзер кайдадыр Чита якларында офицер-ракетчик булып хезмәт итә. Әфисәр бабай нәселен дәвам итә — ике малае бар...

Сибгатулла абзый йортында Магнитогорск каласы янындагы ябык поселениегә әти-әнисе белән бергә раскулачиваниегә эләккән, сугыштан соң гына аннан котыла алган, 1928 елгы Әхәт абый яши. Бик әйбәт кеше ул Әхәт абый!

## Папайлар

Хөснә апа белән янәшә Папайлар йорты. Заманында йорт башлыгы булган Гобәйдулла бабай — Эстәрлебаш авылындагы атаклы, кулы тик тормас бәндәләрнең берсе. Хөснә апаның ире Әбеч Сәхиенең әтисе белән алар бертуганнар һәм атаклы ат карагы Габсаттар нәселеннән киләләр. Гобәйдулла Папай — минем әни ягыннан картәти Гиниятулланың җан дусты... Пожарныйга күчмәс борын, яз була башлау белән Гобәйдулла бабай әтигә керә:

— Лотфулла! Мин сиңа тагын Карабайны сорарга кердем инде. Минем гозеремне кире какма, бир инде минем дусны?!

Карабай — безнең этебез. Ул бик тә ис сизүчән шәп эт. Ә Гобәйдулла бабай авыл көтүе көтә. Карабай аңарга җәен куян тоту өчен кирәк. Гәүдәгә ул зур түгел. Шунлыктан куянны бастырып тотмый, ә көндез яткан җиреннән исе белән барып басып ала. Гобәйдулла бабай җәй буена көн дә куян ите ашый... Әти көлә:

— Ул хайван мин бирмәсәм дә сиңа ияреп китә инде. Алырсың!

Карабайның эш хакы итеп, Гобәйдулла бабай безнең сыерны бушка көтә. Аның өч улы бар, бер кызы: Гиниятулла, Рәхмәтулла, Нигъмәтулла, Нәфига. Хатыны — юашларның да юашы Нәфисә әби. Куганакбаш авылыннан. Зур улы Гиниятуллага 1907 елда үтерелгән минем картәтинең исемен кушкан. Ә Нигъмәтулласына 1921 елда ачлыктан үлгән шул картәтинең улының исемен. Бик дус булганнан алар. Гобәйдулла бабай әтигә сөйли:

— Көндез берәр нәстә чәлдерә алмасам, мин, Лотфулла, ул төнне йоклый алмыйм. Ятам, ятам да пошлыгып, шуннан торып, киенеп чыгып китәм. Йоклап булмый барыбер. Барып берәрсенең читәненнән казыгын булса да суырып алып кайтып, үземнең утынлыкка ташлыйм. Шуннан соң кереп тә ятам, йоклап та китәм. Рәхәтләнеп йоклыйм инде калган вакытын төннең. Ходай шулай итеп яраткан инде мине, нәстә эшләтмәк кирәк...

Гобәйдулла бабайны, Совет хөкүмәтен сүккән өчен, «тройка» белән «суд ясап», Уфа төрмәсендә аттылар. Гиниятулла абзый Мәскәү сугышларында башын салды. Нигъмәтулла абыйны 1950 елда, егерме яшендә Бакый Баткан үрендә яшен сугып үтерде. Уртанчы улы Рәхмәтулла абзый әле дә исән. Тик 1942 елда немец бомбежкасына эләгеп, каты җәрәхәт алып, ярты кеше булып яши. Ишембайга күчеп китте кызы янына. Хатыны Фәридә апа белән. Аларның башкача карар кешеләре юк. Төп йорт урынын урталай бүлеп, Гобәйдулла бабай олы улы Гиният абзыйны йорт салып чыгарган иде. Ул урында хәзер кызы Нәфига апа яши. Гиният абыйның хатыны Зәйнәп апа, дүрт баласын алып, 1943 елда Казакъ якларына чыгып китте, ачлыктан качып. Ә Нәфига апа бүген дә исән-сау, шул урында яңа йорт салып, бер ялгызы яшәп ята. Кызы Василә авылда кияүдә. Очрашкан саен, хөкүмәткә ярарга тырышыптыр инде, Нәфига апа миңа бер үк җөмләне сөйли:

— Әй, шәп яшибез бит, Зәки иркәм! Ипи бар, бәрәңге вуле. Аллага мең шөкер! Шәп яшибез!

Минем читкә чыгып киткәнгә кырык елдан артты. Ә Нәфига апа һаман шул сүзләрне кабатлый. Папайлардан авылда калган бердәнбер

зат шул Нәфига апа, мин бәләкәй чакта миннән Гобәйдулла бабайның бер җырын җырлаталар иде:

Агач башы шартлады,
Куян вак-вак атлады.
Бар дусларым дошман булды,
Әл дә Ходай саклады.
Ай ли-и-и!

Нәфисәм дә бар минем,
Нәфигам да бар минем.
Нәфиганың пар имчәге
Пот та биш кадак килә.
Ай ли-й!

«Зират күперен чыккач» дигән повестьтә шушы җырның соңгы ике юлын тормышта булганча язарга йөрәк җитмәде. Инде тәвәккәлләдем менә: Нәфига апа үзебезнеке, «әллә нәстә эшләтмәс» әле...

## Писерлар

Авыл өчен без — Писер. Ул ләкаб әтиебез Лотфуллага 1918—33 елларда авыл советында секретарь булып эшләгән өчен тагылган. Аңа кадәр картәти Зәйнетдин бабайны — Балта Зәйнетдин дип йөреткәннәр. 1918 елда, бай малайларын санамаганда, әти авылда бердәнбер урысча укый-яза белә торган кеше булган. Таза гәүдәле, азрак җирәнрәк сары чәчле, зәңгәр күзле, бик көчле һәм чибәр кеше иде мәрхүм.

Әнием Мәрьям әтидән тугыз яшькә кече. Кара күзле, кара чәчле, урта гәүдәле, житез хәрәкәтле, эшчән хатын. Без унбер баладан бишәү үстек. Зур апа Мәрхәбә 1914 елда туган, мин — төпчек — 1933 елда. Гарифулла абый — 1919, Рәшидә апа — 1927, Мансур абый — 1929 елгы.

Гарифулла абыйны бөтен гаилә, күрше-күлән белән нык ярата идек. Киң күңелле, шат йөзле, белемле, җиңел сөякле иде абый. 1941 елның көзендә Ленинградны яклап һәлак булды. Лейтенант-артиллерист иде...

Мин туган йорт Эстәрлебашта әле дә бар. Чишмә урамында. Әти ул йортны 1936 елда Мастеренко дигән хохолга сатты. Ул шунда күчереп салды аны. Ә мин үскән йортның фотосы бар. Абый яңа йорт салганда аны икегә бүлеп сатты бугай. Барановка дигән авылда яшәгән урыс йорты булган. Әти аны дусты Мәҗит Хирахаудан сатып алган. Йорт әлеге абый яшәгән өй урынында иде. Әтидән элек ул йортның хуҗасы Бамбыр Гобәйдулла бабайның абыйсы Миңлеәхмәт дигән кеше булган. Мин үскәндә безнең бакчада шул Миңләхмәт бабайдан калган ике юан тирәк (тополь) бар иде. Ул ике тирәк авылда иң юан, иң биек тирәкләр һәм мин, малай кеше, ул тирәкләр белән горурланам үземчә. Аралары күп булса метр ярым булгандыр. Гарифулла абый шул тирәкләргә кадаклар кагып, шунда бер тимер көпшә ныгытып, үзенә турник ясады. Шул кадакларга эләктереп, тиктормас Мансур абый үзенең Ходай биргән янчыгын ерттырган иде. Бу 1936 елда булган.

1937—46 елларда без, гаилә белән күченеп барып, Пожарныйда яшәдек.

Мин үсә башлаганда әти, картаеп, көчен югалтып килә. Өстәвенә Гражданнар сугышы елларында аны Дутов казаклары кыйнап, нык кына имгәткәннәр икән. Эстәрлетамак белән Эстәрлебаш арасы 55 чакрым. Шул арадан ике көн эчендә казаклар әтине һәм тагын ике кешене, аяктан егылганчы, камчылар белән кыйный-кыйный куганнар. Бу 1919 елның июнь башларында булган. Әти сигез яшеннән байга ялланып эшли башлап, егерме ел буенча ялчылыктан башы чыкмаган... Картәтинең җире булмаган һәм ул гомерен балта эшендә үткәреп, шуның белән көн күргән. Картәни Мәрфуга исемле. Ул күрше Янгырча авылы мәзиненең кызы булган. Китап гыйлемен яхшы белгән, им-том итә торган булган. Төп кәсебе бүрек, кәләпүш, түбәтәй тегүдән торган. Картәти белән алар

алты малай үстергәннәр. Герман сугышы, Гражданнар сугышы беткәч, алты малайның икесе генә исән калган. Хәйрулла бабакай белән минем әти Лотфулла. Картәтинең алты сеңлесе булган. Ул аларны күрше-тирә авылларга кияүгә биргән. Шунлыктан әти ягыннан безнең Тәтер Арслан, Ибрай, Хәлекәй, Каен Үзәк, Йомагуҗа авылларында агай-эне байтак иде. 1938 елны әти белән әни чаналы кунак булып Каен Үзәк дигән авылга бардылар. Биш яшьлек малайны — мине дә алдылар үзләре белән. Ул авылда картәти Зәйнетдиннең сеңлесенең өч малае яшиләр: Нурислам, Гәйнислам, Динислам. Берсенең хатыны Кәшифә апа. Нәрсәгәдер көйсезләнгән өчен, әни юкта, Кәшифә апа кулы белән минем арт якка бер-икене бирепл тә алган иде. Кая ул аннан соң көйсезләнү! Ислам исеме йөрткән өч абыйның берсе дә сугыштан кайтмадылар. Балалары таралды. Рәшидә апа Яңгырчы авылында, Әсма апа Өршәкбаш Карамалыда, Сәлимәләре Эстәрлебашта. Малайлары да бар иде бугай, тик кайдалыгын белмим. Өзелә туганлык җепләре — йөрешеп яшәмәгәч.

Мин үскән йорт шул заманның авылдагы иң зур йортларының берсе булды. Тик ул йортның бер җитешмәгән ягы бар иде. Аны саткан чакта түбә тимерен аерым сатканнар. Ә йортның кыегы тимер өчен сөзәк итеп эшләнгән. Без аны салам белән яптык. Җәй эссе килеп, берәр ай чамасы яңгыр булмаса, кыек саламы кибә дә яңгыр китереп бәргәч, су үткәрә. Тотына өй эченә шабыр-шобыр төрле урыннардан яңгыр үтәргә. Аннан инде салам юешләнеп бүртенгәч, кыек су үткәрүен туктата. Чолан өй алды тактадан ясалган, бик зур. Чоланнан ике якка ике ишек чыга. Мин бигрәк тә бакчага, кояш чыккан якка чыккан ишекне яратам. Аның аша кеше йөрми. Иртән көтү куып кайткач, шул ишекне ачам да бусагасына утырып, бөтен дөньямны онытып, хыял дөньясына чумам. Бездән ерак та түгел Тал Борыны дигән җирдән тугайлык башлана. Аннан соң Ялгыз Каен яланнары. Ә ул якларда кәккүкләр сагышлана. Берничәсе берьюлы. Андый кәккүк тавышларын мин башка җирләрдә ишетә алмадым. Моны җитенкерәми чит җирләрдәге кәккүкләрнең. Ялгыз Каен ягындагы кәккүк тавышларының үзенә генә хас булган сагышы көчле аның...

Сугыштан соңгы еллар бик авырга туры килә, Мансур абый тугыздан соң укуын ташлап, колхозда эшли башлый. Тик икмәк бирмиләр. Өстәвенә, Уфа пединститутында Рәшидә апа укый. Стипендия аңарга сирәк эләгә. Безнең тапкан-табылган Уфага китеп тора. Ярый әле сыер бар. Аклыкаралы ул сыерны безгә әлеге шул әтинең дусты, маклерлык итүче Хирахау бабай сатты. Сыер зур, ябык, иллә дә сөтне күп итеп бирә. Безне шул сыер коткара да инде ачлыктан. Көн аралаш әни бер кадак маен сата «сукырларга». Шуның акчасын апага җибәрә. Безгә сепарат сөтеннән оеткан катык кала. Хөкүмәт безне налог белән талый. Финагентка әтинең картлыгы да, кызыл партизанлыгы да, абыйның лейтенант булып кырык бердә сугышып үлгәне дә — берсе дә әһәмияткә ия түгел. Түлә! Сыерың бар, өч сарыгың бар, унбиш сутый җирең бар. Түлә! Хөкүмәтебезгә сугыш яраларын ямарга кирәк, немецләр җимергән авыл-калаларыбызны аякка бастырырга кирәк!

Без, әти белән, яшәү юлын табабыз. Бер яшьлек үгез бозау сатып алабыз да, шуны печтереп, җигәргә өйрәтәбез. Өч яшькә кадәр ул үгез, бозау гына булып санала һәм хөкүмәт аңарга налог салмый. Әти тимерче дусты Мөхетдин Чәүкәдән миңа фурман дигән кечкенә арба ясатып алып кайтты. Үрәчәле арба ул. Мин моның эченә иске паласларны кадак белән кагам да кәсепкә керешәм. Безнең якларда, кышкылыкка җылырак булсын дип, тыштан өйнең бүрәнә араларын сылыйлар. Аның өчен кызыл балчык һәм ат тизәге кирәк. Миннән кешеләр өй сыларга дип кызыл балчык китертәләр, тизәк сатып алалар. Тугай тулы ат йөри. Тизәге — күпме телисең. Шул чактагы акча белән кызыл балчыкның йөге 15 тәңкә, ә ат тизәге — 25 иде.

Үгез җигә башлаганнан алып, утын ташу җайлап-җайлап минем вазыйфага күчә башлады. Әтинең кыйшайган, картайган гәүдәсенә мин

тыныч карый алмыйм. Шунлыктан урманга ялгызым гына йөртырышам. Урманнан корыган агачларны кисеп ташыйм, закон бозам. Урман каравылчысына эләксәң, ул балтаны алып кала, үгез камытын (агачтан ясаган ярмо) буйга яра, тәжеләрне чапкалый...

1949 елны Мансур абый солдатка китте. Тормыш тагын да авырлашты. Картайган әти белән әни, көч утырта алмыйча, үсә алмыйча тормыш белән тартышкан кечкенә буйлы мин — дөнья күтәргә калдык.

1952 елның җәендә офицер булу уе белән мин авылдан чыгып киттем. Еракка, Иркутскига. Башта әллә ни романтика юк. Исәп — укып кеше булу. Ничек кенә булса да колхоз эшеннән котылу. Шуннан бирле мин читтә йөрим...

Зур апабыз Мәрхәбә авылда улы Марат карамагында яши. Ире Хәмит жизни Кубаньда 1943 елның ноябрьләрендә һәлак булды. Апа өч бала һәм гарип биеме белән калды. Үстерде балаларын, кеше итте. Биеме аны икенчегә кияүгә бирергә тырышса да, бармады.

Рәшидә апа пединститутны тәмамлады. Ул булачак зур шагыйрәбез Сажидә Сөләйманова белән бер группада укыган. Үзенең сөйләвенә караганда, укыган чорда, дүрт ел буена дус булганнар. Апаның ире Дим буеннан бер башкорт иде. Бергә укыганнар. Плен җәфалары үткән, бик йончыган кеше. Озак яшәмәде, 52 яшендә дөнья куйды. Апа ике бала белән калды. Озак еллар Уфада мәктәп директоры булып яхшы гына эшләде.

Абыем Мансур төп йортта яши. Озак еллар хуҗалык оешмалары белән житәкчелек итте. Бик тә тырыш кеше. Өч кыз үстерделәр. Хәзер инде хатыны Кәримә белән йортта икәү генә яшиләр.

Әти 1965 елны 79 яшендә, әни 1991 елны 96 яшендә дөньядан киттеләр. Каберләре, рухлары — янәшә...

## Дүлдин Гайнулла

Папайлардан ас якта, тыкрык аша, 1903 елда туган Гайнулла Даутов дигән абзый яшәде. Урамча ләкабе Дүлдин. Җәен, кышын бүрегенең колакларын артка бәйләп, азрак кырынрак итеп, уң кашына китереп киеп йөри. Гайнулла абзый — Бамбыр Гобәйдулланың бертуган энесе. Ә Даутов Гобәйдулла бабай — әтинең иң якын дусларының берсе. Ул 1918—19 елларда Бояр урамында акларга каршы оештырылган партизан отряды командиры Дюльдин Федот Гавриловичның ярдәмчесе. 1922—29 елларда Эстәрлебаш авыл советы рәисе. Янача укый-яза белми.

Әти белән әни сөйләгәннәрдән:

— Гайнулланы 1924 елны гыйнварда өйләндерде абзасы Гобәйдулла. Кызны Куганактан алдык. Без дә кода булып бардык егет ягыннан. Килен буласы кыз Мәхфия исемле. Васфиямал дигән хатынның тәүге иреннән калган кызы бу. Йомшак кына холыклы, әкрен генә итеп сөйли торган бала. Бик тә инсафлы, үзе бик укымышлы. Ә Гайнулла, ай-һай, үткер иде. 15 яшьлек малай чагыннан аны олауга дип аклар алып чыгып киткәннәр иде. Шулар белән чыгып киткәннән соң, ике елдан артык йөреп кайтты. Аны онытып та бетә язганнар иде инде, ә ул «тишек бер тиен» кебек, «туп» итеп кайтып та төште. Авылның исләре китте. Гобәйдулла абзыйның бик шәп бер сары биясе бар иде. Шуның белән чыгып киткән ие унсигезенче елның дикәберендә, егерме беренче елның үктәберендә кайтып керде. Шул ук бия белән. Тик үзе генә үзгәргән, үскән нык итеп. Аклар белән Себернең әллә кайдагы Чита дигән каласына хәтлек барып житкән. Җәһәннәмнең читендә икән ул кала. Әллә нинди бүрәт дигән халыклардан да арырак икән... Кайтып төшкәч, исебез-акылыбыз китте. Сары бия елкылдап тора — шул хәтле таза...

Егерме дүртенче елны, гыйнвар аенда Куганакта туйдабыз. Гайнулланы өйләндерәбез. Туй башланып бер генә көн узганые, коточкыч хәбәр килеп төшмәсме: Лилин карт үлгән. Менә сиңа, мә! Инде нишләргә? Куганакбаш силсәвит рәисе, Гобәйдулланың партизан чактагы дусты Мотыйгулла да туйда. Барысы да ике сугыш үтеп, утны-суны кичкән халык болар. Эчеп-җырлашып утырганны кеше күрә бит инде. Барып әйтсәләр, Лилин үлгәнгә куанып эчеп утыралар, дип? Лилин үлгән бит. Шуннан Мотыйгулла әйтә:

— Ни булса да булыр, туйны туктатмыйк. Тәрәзәләрне эчтән палас белән томалыйк. Мин Ивановкага ат җибәреп, Карцев дусны алдыртыйм, алый-болай берәрсе чакса безне, паминка ясадык Ленин үлгәнгә, диярбез. Тик кычкырып җырлаштан булмасын...

Туктамадык, туйладык. Кая ди инде ул җырламау да, кая ди инде ул биемәү!.. Мотыйгулла ике кешедән каравыл куйган булды әле. Алар да кереп, җырлап-биеп йөределәр — шунда буталанып. Атна үтүгә, Мотыйкны вулыска чакырганнар. Калкашта иде ул чакта вулыс. Сорыйлар:

— Лилин үлгән көннәрне туй ясап эчтегезме?

Мотыйгулла:

— Эчтек эчүен. Тик туй түгел, ә паминка уздырдык, бөек юлбашчыбыз истәлегенә.

— Как так? Ленин үлгән, ә сез эчәсез?

Мотыйк:

— Гүредән эчтек. Кайгыдан йөрәкләребез шартламасын, дип. Кызыл партизаннар эчтек, җыелып.

— Кемнәр?

Мотыйк:

— Даутов Гобәйдулла, Карцев Егор, Зәйнуллин Лотфулла, мин...

— Кайсы Карцев?

Мотыйк:

— Унсигезенче елны аклар аткан Михаил Карцевның энесе.

Вулыста урыслар үтеп керә башлаган чак. Мотыйкның «гүредән» дигәнен «аңлаганнар» тегендә. Тик искәртеп куйганнар: «тагын берәр җитәкче үлеп-нитеп китсә, вулыстан рөхсәт кирәк икән «паминкага». Бетте шуның белән.

Гайнулла абзый белән Мәхфия апа бик матур итеп, тату яшәделәр. Мәхфия апа иренә бер вакытта да бер генә дә каршы сүз әйтмәде. Инде алда язып үткән, Шәңгәрәй бай йортында күп бала-чагасы белән яшәгән Миңлегали абзыйның 1930 елда, бәбиләгәч, хатыны үлеп киткән. Яңа туган бала ятим калган. Малай. Шул өч көнлек баланы Гайнулла абзый белән Мәхфия апа үзләренә ул итеп асрамага алалар. Исемен Хәйрулла дип кушалар. Үзләренең балалары булмады. Безнең белән бергә үсте Дүлдин Хәйрүше. Бик кадерләп, иркәләп үстерделәр Хәйрүшне. Ул — чиккән күлмәкләр киеп үскән бердәнбер малай. Яланаяк та ул әтисе, әнисе күрмәгәндә генә йөреп ала иде. Кесәсендә һәр чак кәнфит, вак акча булды.

1945 елның җәендә Гайнулла абзыйның сугыштан кайтканы истә калган. Хәбәре үзеннән алда килеп җитте: Дүлдин кайтып килә икән. Иртәгә кайтып җитә икән!

Иртән иртүк ике урам кешеләре Мәхфия апаның капкасы төбенә җыйналдык. Көтәбез. Менә берзаман Пожарный ягыннан кечкенә бер «плтаратунка» машинасы күренде. Капка төбендә матур итеп киенгән (кызыл-алсу битле иде ул) Мәхфия апа да бар. Машина пырхылдап тузан, төтен туздырып килеп туктауга, яшел гимнастерка, чалбар, башына пилоткасын кырынрак салып кигән, гвардейский мыек җибәргән, орден-медальләр таккан Гайнулла абзый кабинадан сикереп төште. Аны күрүгә, Мәхфия апа яшь кыр кәҗәсе кебек йөгереп, өенә керде дә китте. Гайнулла абзый аның артыннан. Халык шау-гөр!..

Гайнулла абзый сугыштан трофейлар алып кайтты. Аның холкы трофейларында да күренеп тора иде. Алып кайткан әйберләре — немец солдатының соры төстәге мундир һәм чалбарлары. Эчке күлмәк-ыштаннары.

— Кешенеке нимес булса да кирәкми миңа. Мин тик үзем җиңгән нимес солдатыныкын гына алдым. Анысын да өстеннән түгел — складларыннан гына. Безгә калхузда эшләгәндә ярый ул...

Гайнулла абзый кайтканда Хәйрүш «калюсный» тракторда эшли иде инде. Әтисе кайткан чакта Хәйрүшнең чибәрләнеп үсеп барган чагы. Хәйрүш әтисе алып кайткан мундирларның берәрсен кия дә аулакка килә. Зур кесәле, соры, моңарчы без күрмәгән шома әйбердән тегелгән мундир башкаларның ямаулы чалбарлары, куфайкаларыннан нык аерылып тора. Өстәвенә, озын муен белән баш тоташкан җирдә, ияк тирәсен Хәйрүш «автол» белән буяп җибәрә. Янәсе, тракторист егетнең юса да «автолы бетми». Башка малайлар кебек ул прастуй калхузник түгел — тракторист! Папай Нигмәте, Көрпә Гарифы, Мәхми Гәрәе кебек атлы эштә түгел абзагыз, ә тракторда! Белегез аны! Бигрәк тә чыркылдык кызлар белсен! Өстәвенә, Мәхфия апа Хәйрулла улына соры кәҗә мамыгыннан озын итеп шарф, биш бармаклы перчаткалар бәйләп кидергән. Озын муенга берничә катлап озын шарф уралган, очлары немец мундиры өстенә төшерелгән. Аякта ап-ак чүчинкәләр. Аларга өр-яңа, кап-кара ялтырап торган эрзинкә галушлар киелгән. Ак чүчинкәнең кунычы тездән түбән итеп кайтарылып төшерелгәннәр. Шул кайтарылган чүчинкә кунычы өстенә нимес солдаты кияргә тиешле булган соры чалбарның балагы кунычтан байтак чыгарылып, чүчинкә өстеннән кайтарылып төшерелгән. Кесәдә берничә башланган «Норд» папирусы һәм шуларга эләгеп кәгазь акчалар да килеп чыгалар...

Нимес мундирының изүе ачык. Шарф астыннан кара сатин күлмәкнең изүенә берсенә берсе терәп тезеп таккан ак сәдәфләр. Кара күлмәк кызыл ефәк җеп белән матур итеп чигелгән. Шту сез, егетләр!..

Хәйрүш абый үскәндә безнең урамның иң ыспай, иң чибәр егете булып үсте. Аны шулай дип бүген дә ныклы итеп әйтеп була. Чөнки безнең урамда шул еллада Дүлдин Хәйрулласын үзләренә каратырга тырышкан кызлар бүген дә исән-сау, әбиләр булып яшәп яталар... Шул чибәрлеге артыграк булгангадыр инде, Хәйрүш абый унсигез тулартулмас борын ук күрше урамның иң чибәр, тал чыбыктай бөгелепсыгылып торган, зифа буйлы, сиртмә сыйраклы Тәүилә апаны туйлап алып та куйды. Үзе солдатка китқәнче Оркыя исемле кызлары да туды. Алар өйләнешеп, икәү бергә урамнан үтә башласалар, каршы очраган кешеләр, туктап, читкә чыгып юл бирәләр дә, озак итеп артларыннан сокланып карап калалар. Берсеннән берсе чибәрләр!..

Гайнулла абзый колхозда эшләде. Җәен, көзен яланда тракторлар янында каравылда булды. Кышын колхоз келәтләрен саклады. Алтмыш яше чамасында китте дөньядан. Үпкә белән.

Ни өчен аны Дүлдин дигәннәр соң?

Гобәйдулла бабайның күрше Ивановка авылыннан урыс дусты бар иде. Федот Гаврилович Дюльдин. 1918 елның ноябрь башларында ул Эстәрлебашка Гобәйдулла бабайга кайтып төшә. Төнлә килеп кергән Федотны Гобәйдулла бабай яшереп асрый. Чөнки ул август аенда авыл аша узган Блюхер белән киткән була. Берничә көн торгач, Дюльдин белән Гобәйдулла бабай Гайнулланы чакырып кертәләр. Гайнулла абзыйдан үз колагым белән ишеткәнне язам.

— Аулакка чыгып китәргә дип киенеп беткән идем инде. Абый чакыра, кер әле дип, олы якка. Кердем. Дюльдин кул биреп күреште минем белән. Бик зур үтенече бар моның миңа. Эстәрлетамактан уң якта Покровка дигән авыл бар. Шуннан барып, төнендә урап, бер карчыкны алып кайтырга кирәк икән. Эстәрлетамак юлы белән китсәң

ерак, турыдан утыз биш чакрым чамасы. Ярар, мин әйтәм, дилайт будем. Сары бияне җиктем, бер толыпны кидем, икенчесен печән өстенә төреп салдым да киттем аллага тапшырып. Бакыр Чагылны менгәнче Сары бияне кумадым. Юыртып, азрак үз җаена барып, җылыттым тегене. Бакыр Чагыл тавын менгәч киттем моның белән! Теге утыз чакрымны бер сәгатьтә, күп булса сәгать ярымда узганбыздыр. Ат тоягы астыннан кар гына оча, мин сиңа әйтим. Ул ат шәп, дирбия нәрсә. Үзем дә төшеп калганнардан түгел бит инде. Барып кердем Покровкага төн уртасында. Ярар. Атны атланып кына урамнарыннан узып, таптым кирәк йортны. Шакыдым Дюльдин әйткән тәрәзәне. Пәрдә ачып карадылар тиз генә. Мин бер генә сүз әйттем: «Дюльдин». Бер биш минут тирәсе узгач, чыкты бер карчык. Кәкерәйгән бу, чак атлый. Чана янына килгәч, ярдәм итәргә дип булашкан идем үзе, менеп утырды бу. Карадан киенгән, калын шәл белән битен томалаган, бер дә күренми. Толыпны кидердем дә, чаж мин кайту ягына!

Сары бия, хайван, әллә җирдән чаба, әллә инде җир өстеннән оча. Теге карчык та дәшми. Утырган кечкенә төенен тотып, толыпка төренеп. Мин куам. Башта — юл кайгысы да, аннан бүреләр генә очрамасын. Кирегә барганнан да тизрәк кайттык. Гомбазы үрен менгәндә Сары биянең корсагы астыннан бүрек-бүрек күбек оча башлады. Кайтып кердем, малай, йортка. Атым туктагач, тыпырдап тора. Абый туннарын киенгән, абзарда көтеп тора. Алып кереп киттем теге карчыкны, өйнең ишекләрен ачып. Абый барысын да майлап куйган ишекләрнең. Берсе бер шыгырдамый. Бу карчык килеп тә керде һәм толыпны, өстендәге кара тунын салып та очырды. Мин авызымны ачтым да, шаккаттым. И-эх, чибәр бер яшь кенә сылу марҗа, әй. Ушлар китәрлек. «Федотушка мой!» — дип Дюльдиннең муенына сарылып, кочагына керде дә китте. Шуннан соң Дюльдин минем кулларымнан кысты да нык итеп кочаклап, әйтте:

— Спасибо, Гайнулла! Смелый ты парень! Дюльдиным будешь! — диде...

Советлар урнашып киткәч, Гайнулла абзый ул тарихны сөйләргә ярата торган булган. Авыл кешеләре берничә тапкыр тыңлаганнар да, озакка сузмыйча Гайнулла абзыйга исемне тагып та куйганнар: «Дүлдин Гайнулла».

Гайнулла абзый алып кайткан яшь марҗаның исеме Евдокия. Чын Фамилиясе Маркелова. Ул атаклы Башкортостан язучысы Недолинның бертуган сеңлесе. Недолин, сеңлесе Евдокия һәм Дюльдин Федот Гаврилович булачак маршал Блюхер Василий Константинович белән Белорецк каласыннан алып Көнгергә кадәр, 1918 елда, аклар тылы аша Кызыл Армияне эзләп китеп, берничә мең чакрымлык поход ясаганнар. Шул поход өчен Блюхер иң беренче Хәрби Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнде. Дюльдин шул походта бер полк командиры булган. 1918 елның ноябрендә Эстәрлебаш урманнарына партизан отряды оештырырга Блюхер тарафыннан кире кайтарылган. Гайнулла абзый сөйләгән вакыйга — шул партизан отрядын оештыра башлаган вакыттан.

Дюльдин Федот Гавриловичның да, хатыны Евдокиянең дә язмышлары аяныч. Дюльдин Гражданнар сугышыннан исән-имин чыгып, утызынчы елларда фаҗигале рәвештә һәлак була. Евдокиянең язмышы да аныкыннан җиңел түгел. Алар турысында аерым әсәр булачак. Шунлыктан Дюльдиннар турында язуымны шушы урында туктатам...

Гайнулла абзый урынында «Дүлдин» Хәйрулла белән хатыны Тәүилә апа дөнья көтәләр. Яңа дүлдиннәрне үстереп, инде оныклар карыйлар.

# Мөчтәкләр

Мөчтәкләр бездән тыкрык аша яшәделәр. Гаилә башлыгы Ибраһим бабай безнең әтидән биш-алты яшькә олы. Ул бабай бик тә эшчән иде. Мин аның эшсез капка төбендә утырганын хәтерләмим. Хатыны Хәсбия әби безнең авылдан 15 чакрымдагы Куганакбаш авылыннан төшкән килен. Сугышка кадәр аларның өч малайлары бар иде — Габдрәхим, Габдрахман, Фәйзрахман.

Габдрәхим абый күрше урамда үз йорты белән яшәде. Хатыны Минзифа, кызлары Фәния белән Суфия. Сугыштан кайта алмады. Минзифа апа Иҗәләй Миңлеәхмәтенә икенчегә иргә чыгып, Октябрьск шәһәренә күченеп киттеләр... Габдрахман абый 1918 елгы. Аның турында һәм энесе Файзер турында мин «Сугыш алды малайлары»нда язган идем инде.

Капкалары тәбәнәк кенә, иске-москы такталардан әтмәлләп ясалган. Такта капканың ике ягы да читән. Тыкрык мөешендә (бездә «почмак»ны шулай сөйлиләр) зур кызгылт таш басып тора. Арба күчәрләре тыкрыкка кергән чакта читәнне ватмасыннар өчен. Капканың сул ягындагы читән эчендә кечкенә бакча. Анда юан гына, матур шомырт агачы үсеп утыра. Шомырт төбендә бер төп балтырган үсә. Көпшәсен үсеп җиткәч, Габдрахман абый аны чалгы пәке белән кисеп ала. Бакчада кайчандыр «баздуш» өй булган. Без үскәндә ул келәт булып хезмәт итә иде. «Баздуш» дип безнең якларда салам катыштырып басып кызыл балчыктан ясалган, яндырылмаган кирпечләрдән салынган өйне әйтәләр. Ул кирпечләр яртышар метр озынлыкта булып, андый өйнең эче, тышы сыланып, акбалчык белән агартыла. Матча куяр өчен имән баганалар утыртыла.

Хәсбия әби, сөйләшкәндә, «Эй, илаһым» дип сүз башлап алып китә. «Мөчтәк»тән башка аларның урамда икенче исемнәре дә бар: «Хуадарлар». Мин аның нәрсә икәнен белмим. Тормышлары ярлы булса да, гаилә белән алар бик тату яшәделәр. Минем исемдә юк аларның кычкырышкан чаклары. Гаиләдә Габдрахман абый башлык. Ул бик акыллы, төптән уйлаучан, үз сүзен ныклап уйлап сөйли һәм аны бер кайчан да икенче кешегә бирми. Тик сәламәтлеге шәп түгел — аягы агач һәм йөрәге суга. Шунлыктан тиешле белем ала алмаган... Габдрахман абый минем өчен шәхсән бик кадерле һәм якын кеше. Минем сугыштан кайтмаган бертуган абыем Гарифның дусты ул. Алар бергә укыганнар, бергә үскәннәр, дус булганнар. Габдрахман абый миңа Гарифулла абыем турында бик күп истәлекләр җиткерде. Менә берсе:

— Көз җитеп килә шулай. Гариф белән миңа, күп булса, шул биш тирәләредер инде. Әниләр икебезгә дә пардан ап-ак күлмәкләр текте. Теге күлмәкләрне киеп, сезнең агай-энегә дә, безнең агай-энегә дә барып, берничә көн котлатып йөредек. Күршеләрне дә вич йөреп чыктык. Минамал әбигә кергән идек, ул әйтә: «Әй, әгәренки! Авызымдагы сагыздан башка бернәстәм дә юк бит әле, күлмәкләрегезне котларга!» — ди. Гариф әйтә: «Ярый, ярый! Сагыз булса да ярый безгә»,— ди. Гариф тererәк иде миннән. Теге сагызны бүлешеп чәйнәдек көне буена. Шул көннең икенчесендә читән буеннан бер ватык, ак фарфор чәйник янында тегенең борынын да табып алдык бит. Шунда ук күп итеп тилебәрән орлыгы үскән. Тегене җыеп, чәйник борны эченә тутырабыз. Бу безнең өчен, янәмәсе, мәк була инде. Тутырабыз да теге чәйник борынын шул тилебәрән орлыгы — «мәк» белән, алмашлап ашыйбыз тегене. Ничәшәрне ашаганбыздыр инде — анысы истә юк. Шуннан бервакыт тотынды баш авыртырга, шуннан тотындык косарга. Аяклар тотмый, берәм-берәм тәгәрибез дә китәбез. Әниләр елаша, нәрсә эшләргә дә белмиләр. Йөгертеп алып килделәр күрше урамнан Зәбир бабай әбисен. Мәгрифә исемле иде мәрхүм. Теге әби белде эшнең нәрсәдә икәнен. Гарифның авызын гына

ачып карады да белде. Теш арасы тулы теге «мәк» орлыгы. Кара кәҗә сөте кайнатып эчерделәр. Күзләр акая башлаган иде малай...

Габдрахман абый үзе скрипка ясый, үзе шуңарда уйный. Умарта ясый, бакчасында алма, чия үстерә. Авылда иң шәп бакча аңарда. Тегү машиналарын төзәтә, радиоалгыч ясый. Белмәгән эше юк. Искиткеч оста кеше ул. Безнең Башкортстан якларында йөзем үсми. Кыш бик каты суыклар булганга, йөзем агачлары туңып һәлак була. Бер елны кайткач, Габдрахман абый әйтә:

— Әйдәле, сиңа йөзем агачларымны күрсәтим.

Өй артында, кояшта, чыннан да, йөзем агачлары үсеп утыра. Өй кыегына тарткан бау буйлап өскә үрмәләгәннәр.

— Менә күрәсеңме, ничек матур булып үстеләр...

Җәйнең бик матур көннәре. Ямь-яшел, зур яфраклы йөзем агачларын борчак зурлыгында гына йөзем җимешләре каплап алган. Сыргак кебекләр.

— Ничек туңмыйлар алар кышын?

Хуҗа канәгатьлелек белән елмая:

— Шул-шул менә! Туңдырмауның сере бар!

— Нәрсәдә соң ул сер?

Габдрахман абыйның шадрарак битенә кызыллык йөгерә:

— Кыш якынлашып, суыклар башланыр алдыннан мин ул йөзем куакларының төбенә салам җәям. Калын гына итеп. Шул саламга яткырам йөзем агачларын. Өсләреннән тагын салам белән ябам. Тик ябар алдыннан шул салам астына күп итеп тигәнәк башларын тутырам. Тигәнәк тутырмасаң, саламга ияләшеп, агачның кабыгын тычкан кимерә. Кар яугач, инде шул салам өстенә күп итеп кар өям. Шул кар, салам астында кышлый йөзем агачлары. Өшемиләр. Яз булып, көннәр җылыткач, саламын алып ташлап, агачларны күтәреп куям. Җәен тагын үсәләр, уңыш бирәләр.

Фәйзер капкыннар белән куян, төлке, бүре аулый. Фәйзернең аудан кайтуы урам өчен тамаша. Ул капкынга эләккән төлкеләрне... тере көенә, агач авызлык кидереп, муеннарына бау салып, җитәкләп алып кайта. Кулбашына кыска, киң чаңгыларын күтәргән Фәйзер авыл урамы буйлап атлый, ә кырыннан муенына бау салып җитәкләгән уттай тунлы, чибәр төлке юырта...

Без аның белән байтак еллар бергә балыкка йөредек.

Башкорт авыллары Мәксет белән Ибракай арасында Эстәрле елгасының һәр ташын, һәр борылышын, һәр чоңгылын, һәр шарламасын белә идек без. Соңгы тапкыр 1952 елның җәендә икәү генә балыкка бардык. Чикерткәгә байтак кына чабаклар тоттык. Мин армиягә киттем, ә Фәйзер авылда калды...

1959 елның юеш, карлы көзендә әнисенең туган авылыннан кемдер туганнарыннан Фәйзерине үзләренә кунакка чакырган. Фәйзеригә 29 яшь. Куганакбашта бер генә балалы 29 яшьлек бер хатын бар икән. Шуны Фәйзергә димләргә булганнар һәм аңа шул хатынны күрсәтергә чакырганнар. Фәйзери киткән теге хатынны «күрергә». Барган, сөйләшкән, килешкән Куганакбашка килеп йортка керергә. Икене кунгач, җәяүләп кайтып киткән. Җәяүләп көннәр буена ауда йөри ала торган иде. Тик бу юлысы өсте юкарак булган шул. Куганакны чыккан көенә юеш кар катыш яңгыр ява башлаган. Ә ике авыл арасы 15 чакрым. Көзге карлыяңгырлы пычрак юлдан атлый-атлый нык юешләнгән, арыган Фәйзери. Һәм Безгин дигән урыс авылын чыккач, юеш бер калкуырак урында утырып ял иткән. Шул бетергән дә инде аны. Шунда бик каты суык тидергән.

Мин 1960 елның февралендә бер яшь тә биш айлык улымны, торырга урын булмаганлыктан, авылга кайтарган идем. Кайтканның икенче көнендә абый әйтә:

— Фәйзеринең хәле шәптән түгел. Дөнья хәлен белеп булмый, кереп чык...

Авыр һавалы, тынчу өй эче. Түрдә, сәкедәге урын өстендә гәүдәсе бик тә кечерәеп калган Фәйзер утыра. Мине күргәч бик куанды. Озак итеп сөйләшеп, малай чакларны искә төшереп утырдык. Зур өметләр белән сөйли:

— Яңгыл бабайның энесе Кинҗә абзый ярты түшкә бурсык ите китергән. Шуның итен ашап, маен эретеп эчә башлагач, азрак хәл керә башлады. Иншалла, җәйгә аякка басармын, Ходай кушса.

Бик матур итеп елмая Фәйзери:

— Син җәйгә кайт, Зәки. Мәксет белән Ибракай арасында мин чабаклы урыннар беләм. Яңаларны. Су төбе үзгәреп тора бит. Балыкка төшәрбез икәү генә. Малай чактагы кебек учаклар ягып, уха пешереп кунарбыз. Коры тал да күп анда. Бездән соң балыкчылар бетте Эстәрле буйларында...

Фәйзеринең арык, ябык кулларына, аның кечерәеп калган, элек тә зурдан булмаган гәүдәсенә карап, күңелем тулыша. Ул Габдулла Тукайның соңгы фотосындагы сурәткә бик нык охшаган. Бернәрсә дә сиздермәскә тырышам:

— Ярар, Фәйзер, ярар. Син җәйгә терелеп тор, яме!

Ә ул һаман елмая:

— Соң, терелмичә тагын. Әле бит минем утызым да тулмаган. Син Ригадан чебен кармаклары алып кайт. Күп итеп. Шул кармаклар иң шәбе инде чабак тотарга...

Чебен кармаклары дип без иң вак кармакларны йөртәбез.

Апрель азакларында ул үлгән. Габделхәй Таракан, ягъни Фәйзер белән соңгы елларда бергә ауга йөргән абый сөйли:

— Бик көткән иде җәйләрне. Сине көн дә сөйләп ала торган иде, җәйгә кайта минем дус Зәки дип. Үлә алмыйча атна ятты әй. Аңы юк иде. Тәне дерелдәп кенә ята. Үзе жылы. Үпкә беткән инде, гыжлап кына тын ала. Көчкә-көчкә. Ә йөрәк шәп тегенең. Бирешми. Үләсе килми. Бик әйбәт кеше иде мәрхүм...

Габдрахман абыйны мин соңгы тапкыр 1981 елның сентябрь башларында күрдем. Бер генә атнага авылга тиеп китим дип, Кавказдан кайтып төшкән идем. Хәл белергә дип керсәм, Габдрахман абзый ишек алдындагы чирәмгә җәйгән йон паласка (безнең авылда аны асалы палас диләр) азрак кырын төшебрәк яткан. Минем белән ике куллап жылы итеп күреште:

— Әйдүк, әйдүк, Зәки! Утыр азрак, аннан өйгә керербез.

Безнең тавышны ишетеп өеннән чыккан Мәгүзә җиңгигә «боерык» бирә:

— Чәй куй! Тегене дә чыгар! Соры чүлмәктәгесен ал! Анысы бит бала корт балыннан.

Мәгүзә җиңги минем белән ике куллап күрешә дә кире кереп китә.

Габдрахман абзыйга 63 яшь. Ул бирешә башлаган. Йөзе ябыккан. Тик күңеле һаман көр.

— Элекке кебек итеп эшләп булмый хәзер, Зәки. Тын кысыла. Астма дигән авыру икән. Йортта гына инде хәзер. Кышларын җиңгәнә шәл бәйләшәм. Мамыктан. Шапалыйм тегене. Аннан соң катарга да өйрәндем. Башкача бик килгән җир юк бит. Ә җан асрарга кирәк...

Чәй янына утыргач, берәр стакан ачы бал эчәбез. Елмаюлы күзләре белән миңа карый:

— Шәпме?

— Шәп.

— Син кайтырсың дип калдырган идем. Белдем мин синең кайтасыңны.

— Мин бит хәбәр итмәгән идем.

— Итмәсәң ни! Узган ел кайта алмадың. Мансурдан сорашып торам мин сине. Күргән саен. Синең эш авыр. Шунлыктан авылга кайтып, урман-тауларда, Эстәрле елгасы ярларында йөрергә кирәк сиңа. Иң киме дигәндә дә ике елга бер. Сиңа азрак та әле ул. Рухыңны гелән генә кабаттан ныгытып торырга кирәк сиңа. Шулай бит?

Мин сүзсез генә баш кагам.

— Әйдә, тагын берне җиппәрик әле. Минем дус Гариф өчен, синең дус Фәйзер өчен. Әллә бар гомер, әллә юк гомер дигәндәй...

Бик башлы, акыллы, төптән уйлый белә торган абзый иде. Китәсен шул вакытта ук сизендеме икән әллә? Шул елны ноябрь урталарында киткән. Ясинны Мәхфия апа укыган аңарга...

Габдрахман абый авылның иң сәләтле шәхесләренең берсе иде. Тумыштан, табигать тарафыннан бирелгән инженерлык, музыкантлык рухы бик көчле иде аңарда. Алтын куллы, җор телле иде өстәвенә.

1961 елның август ае. Миңем абый яңа йорт бетерә. Күрше 43 яшьлек Габдрахман абзый аның яңа өе тәрәзәләренә пыяла кисә. Абыйның хатыны Кәримә авыл хуҗалыгы институты тәмамлаган. Агроном. Үзе укытучы булып эшли. Тәрәзәләре каршындагы бакчада икешәр метр озынлыкта булыр, помидор сабаклары. Үзләре ямь-яшел, тик ни өчендер бер генә чәчәкләре дә юк. Помидорлары да юк, җәй бетеп баруга карамастан. Буйга гына үскән дә үскән болар. Мансур абый сараеннан пыяла ташый, Габдрахман абый кискәндә мин тотып торам. Габдрахман абзый алмазы белән пыяла кисә, үзе абыйга карамаска тырышып, кет-кет көлә:

— И-и-иэх, Мансу-ур! Синең хатын, әй, агранум булгач, ничек итеп үстерә белгән памидурларны-ы! Әлләлә-лә! Үлчәп карасаң, өчәр метр бардыр боларның озынлыклары? Бола-ар памидур бирә башласала-ар, ни тумышты саты-ып, авылга бушка таратып бетерә алмассың, әй! Укыган кеше, укыган кеше инде ул, диюем...

Хәзер ул гаиләдән йортта берәү дә юк. Хәсбия әби, улы Габдрахманны җирләгәннән соң тагын берничә ел яшәп, йөзгә житә язып үлде. Аның тегәл генә яшен белгән кеше булмады да. Узган ел килене Мәгүзә апа да, һич көтмәгәндә, җир куенына кереп китте.

Кызлары Нурия, уллары Наил башка авылларда дөнья көтәләр. Мөчтәкләр йортында хәзер чит кеше яши...

Ә шомырт агачы исән. Тик төбендә балтырганы гына юк. 1993 елның июль аенда рәшәткә аша үрелеп карадым. Юк балтырган.

### Галия апа

«Дүлдин»нәрнең ас ягында сугышка киткән ире Абдулла Кабаннан торып калып, ике баласы белән Галия апа яшәде. Әле дә исән.

Галия апа — авылыбызның бае булган Мөслим дигән кеше кызы. Йорт-җирләрен тартып алып, Мөслим байны улы Барый белән Нуриман районына сөргәннәр. Барый абый сугыштан соң кайтты авылга, гаиләсе белән. Тик Мөслим бабай кайта алмады, чит җирләрдә ятып калды.

Галия апаның ире Абдулла абый — Шәңгәрәй бай йортында тәрбияләнгән Хәйри Кабанның бер туган абыйсы. Алар агалы-энеле, сугыш башланганда икесе бер ЧТЗ тракторында эшләделәр. Икесе дә сугышка бронь белән бармады һәм 1942 елның декабренә кадәр шул ЧТЗда эшләделәр. Декабрьдә икесен дә военкоматка чакырткannar. Военком азрак камыт аяклы майор Сиденко иде. Әйткән:

— Менә нәрсә, Кәримовлар. Икегезнең берегез сугышка китәргә тиеш. Барыгыз, кайтыгыз, киңәшегез. Кайсыгыз китә, кайсыгыз кала — иртәгә иртән әйтерсез!

Ишеккә юнәлә башлаган энесе Хәйрулланы туктата Абдулла. Әйтә военкомга:

— Мин — абый кеше. Мин китәм, нигә аңарга кинәшеп вакыт үткәрергә. Яз мине!

Нәрсәдер әйтергә булашкан энесенең авызын да ачтырмый:

— Тик кенә тор! Абзаңа каршы сөйләмә! Бар, чыга тор...

Абдулла абый сугышка китте дә шуннан кайтмады. Тракторист булганга, танкка утырткан нар моны. Курск дугасында, немец танклары белән алышканда һәлак булды ул. Абзый була белгән ул. Чөнки энесенең өч баласы бар, хатыны Майкамал апа дүртенчегә авырлы. Аяк-кулы да авырта...

Бай кызы булса да, Галия апага колхозлашкан елларда тимәгәннәр. Чөнки аны Абдулла абый үзенә хатынлыкка алган. Авылның иң беренче трактористларыннан булган ул Абдулла Кәримов...

Хәзер инде төп йортта Галия апа кече улы Фәрит, шуның уңган хатыны белән дөнья көтә. Фәритнең дүрт малае бар. Абдулла Кабан нәселе үрчи, күбәя. Килене белән Галия апа бик тату яши. Галия апаны бөтен урамга үрнәк итеп күрсәтәләр: «Менә ичмаса яши белә Галия апа килен белән. Урамга бер тавышлары чыкмый. Фәрите дә әйбәт». Урам Фәритне иң соңыннан исенә алып сөйләсә дә, иң беренче чиратта Абдулла Кабан малае Фәрит шәп. Фәрит әйбәткә күрә гаилә дә әйбәт. Атасыз үсте үзе. Малайлар үстерә хәзер. Ходай ярдәменнән ташламасын!

## Шәрифә әби белән улы Сабур

Мөчтәкләрнең аскы ягында Шәрифә әби яши. Үз гомерендә ике ир белән яшәгән хатын ул. Беренчесе Шәмсетдин исемле. Аңардан алда язылган Өмөгөлсем апа, Тимеркәй белән Сабур туганнар. Икенчесе Абдулла исемле булган. Анысыннан өч кыз: Мәрьям апа, Чуар Галия, Халидә.

Тимеркәй белән Сабур — бакыр җирәннәр. Галияләре чәүкә күкәе кебек сипкелле. Шунлыктан, мәктәпкә барганчы ук, урамда исеме — Чуар Галия. Өмөгөлсем, Мәрьям, Халидәнең аерым исемнәре юк.

Сабур абый 1920 елда туган. Ул «Сугыш алды малайлары»ндагы Сабир инде. Авылда әле дә яши, исеме әле дә Кытыйка. Ул сугыш башланганның башында ук Днепр янында әсир төшеп, тик 1945 елның март аенда гына кача алган. Кып-кызыл битле, бакыр төсендәге чәчле, җитез хәрәкәтле, ачык күңелле, үтә дә эшчән һәм... бик мактап җибәрдем шикелле,— Сабур абыйның холкының нигезе булып, аның теле тора. Ул бик күп итеп, ике сүзнең берсенә урысча да, татарча да сүгенү кушып сөйләргә ярата. Сүгенүеннән туктатырга теләп кемнәр генә тырышмадылар инде: Габдрахман мулла бабай, укытучылар, авыл картлары, әбиләр, милиция, авыл советы, хәтта, райкомның беренче секретаре дә булашып карады. Файдасы чыкмады. Сабур — Сабур булып, сүгенү сүгенү булып калды. Язып карыйм әле.

Сабур абыйга 73 яшь тулган. Ул әле дә район үзәгендәге ветлечебницада конюх булып эшли. Атлар, куяннар, кош-корт, чучкалар карый. Сабур абый авыл халкының иң яраткан кешеләрнең берсе. Әсирлектә булган, берничә тапкыр үлем белән йөзгә-йөз очрашып тере калган. «Плендә булган өчен» гомере буена хөкүмәт һәм кара күңелле кешеләр тарафыннан кимсетелеп яшәде ул.

Кырыгынчы еллар азагында, илленче еллар башында авылдан унике чакрым җирдә колхозның Матюшкин яланы бар иде. Кайчандыр, Столыпин заманында башкорт җирен бер Карамалка урысы Матюшкинга бүлеп биргәннәр. Тегесе шунда хутор салган. Гражданнар сугышыннан

соң каядыр юкка чыккан. Колхозлар төзелгәндә л җирләрне Эстәрлебашта төзелгән «Шәфыйк» колхозына биргәннәр. Сугыш елларында ул яланнарны сөреп-чәчәрлек ат көче дә, трактор да булмады. Үлән басты аларны. Шунлыктан сугыштан соңгы елларда да без ике бригада кешеләре шунда куна ятып, куышлар корып, печән чаба торган идек. Һәрберсенә өч ат җигелгән печән чапкычы (косилка), ике печән җыйгыч һәм йөзгә якын кибән салучылар эшлибез. Шулар арасында Сабур абзый да бар. Ул печән чапкычта эшли. Аңарга ярдәмче булып Меж-меж Зәки йөри. Сабур абый Зәкине печән чапкычка утырта да үзе кибән салучылар янында эшли. Иң авыр эштә. Озын, өч япле агач сәнәк белән кибәнгә печән ыргыта. Янсә еш кына кибән башына менә. Шундый кызып эшләгән көннәрнең берсендә, очланып килгән кибән башыннан Сабур абыйның күңелле тавышы ишетелә:

— Э, се-з! Нимескә сатылганна-ар! Җыйналыгы-з! Безне алырга киләлә-әр!

Кибән башыннан ике чакрымнар чамасында Даут урманы яшәреп күренеп тора. Шул урманнан чыккан юл белән, ел саен шушы вакытта милицияләрнең күк биясен җигеп, Антипов фамилияле урыс милиционер килеп чыга. Ул «плиннейләрне» авылга алып кайтырга килә. Сабур абый аны атының төсеннән, юыртуыннан ук танып ала. Һәм кибән башыннан «куанып» сөрән сала. Сәбәбе: Антипов пленда булып кайткан «сатлык жаннарны» район милиция бүлегенә печән чабарга, кибән коерга алып китә. Милициягә печән әзерләргә эләгү өчен «танышлык» кирәк. Чөнки анда эшләгән көннәрне, «сатлык жаннарны», милиция исәбеннән ашаталар. Бушка, Сабур абый әйтмешли. Ә колхозда ашау яклары бик начар. Чапкычта, җыйгычта йөргәннәргә аванс итеп, 400 грамм — нинди бар, шул онны бирәләр. Сәнәк, тырма күтәреп печән җыйганнарга 200 грамм он. Ә милициядә печән эшләгәндә кичен итле аш та бирәләр икән әле. Ул елларда, пленда булып кайтканнарны җыйнап, милиция атларына да, үзләренең сыер-сарыкларына да бушлауга печән әзерләтә торганнар иде...

Немец әсирлегендә булып кайткан Иләкәй Биктимере, Кыстыбый Латыйф, Кытыйка Сабур һәм тагын берничә кеше, сәнәкләрен күтәреп, таборга төшеп китәләр. Ун көннәр чамасы узуга, кире әйләнеп кайталар. Шатлыкларын яшереп тә тормыйлар.

— Тиз кайттыгыз, әй! Акрынрак эшләп, озаграк ит ашап яшәр идегез шунда. Тамагыгыз тук! — ди аларга «бармаска хәйләсен тапкан», шулай ук плен үткән Меж-меж Закиры. Аңарга җавап бирүче юк. Тик Сабур абый гына «өзеп чәпи» тегеңәргә:

— Качып ятып калдың монда, Меж-меж! Бар, туйдыр тамагыңны! Анда сиңа да эш табылыр. Хәйван!

«Плиннейләр» кайткан көнне учак янында уен-көлке юк. Без Сабур абзыйның «плиндә күргәннәрен» тыңлыйбыз:

— ...Украинада аэродром карыйбыз. Бомба төшкән чокырларны күмәбез. Кышын кар көрибез. Шул карны ат кебек чаналарга җигелеп тартып, әллә кайларга, еракка итеп түгәбез. Ашау начар, өстә юка, көн-төн кыйнау, сүгү. Бер нимес солдаты бар иде. Сиздермичә арттан китереп лепкәгә тибәргә ярата бу. Ятасың инде 10—15 минут тора алмыйча, ушыңны җуеп. Әгәр инде тиз торсаң, тагын китереп тибә бу. Димәк, алдагы типкәне тиешле нәтиҗә бирмәгән булып чыга...

«Пленда булганнарын» хөкүмәт «гафу иткәч», Сабур абыйга больницада ятарга туры килгән. 1985 елның Җиңү көннәренә туры килгән моның ятуы. Өч фронтовик аерым бүлмәдә, шунда боларга тәрбия дә әйбәтрәк икән. Өченең берсе Сабур абзый. Бүлмә зур, иркен, юылган, каралган. Бар нәрсә дә урнында. Шул чакта Уфадан Исәнлек саклау министрының урынбасары булып эшләгән чибәр бер ханым Эстәрлебаш больницасын тикшерергә килгән икән. Шуннан бер көн кала гына больница мөдире Сабур абый янына кергән.

— Сабур абый, мин сиңа дип кердем бит әле.

— Әйдүк, әйдүк, энем. Татар әйтмешли, түрдән үт. Ни йомыш?

— Иртәгә Уфадан тикшерү килә...

— Килмәгәк, килә бирсен әйдә. Бер дә исең китмәсен. Нинди юлдан килсә, шул юлдан китә ул.

Врач елмая:

— Туктале, Сабур абый! Сүз бөтән турыда бара...

— Нәстә тагын, әйт!

— Комиссия башлыгы бик чибәр бер хатын врач. Син ул хатын барда сөйләшмәскә тырыш инде, яме.

— Ния тагын?

— Соң... ни бит, ...син бит, ...

— Инәңнен[1] (.!.) Андижан. Ния, минем кешедән кайсы җирем ким! Ния син миңа сөйләшмәскә кушасың?! Ә?..

— Ай, сөйләшсәң, сөйләш! Тыймыйм мин сине. Тик сүгенү сүзләрен кыстырмыйча сөйләш, яме!..

Иртәгесен Сабур абый яткан бүлмәдә булган хәлне Эстәрлебаш кешеләре бүген дә күзләрен елтыратып сөйлиләр. Авыз суларын корытып... Икенче көнне, Сабур абый яткан бүлмәгә, үзе белән алып килгән өч ир врачны ияртеп, министр урынбасары, бик тә чибәр ханым килеп кергән. Якты, матур итеп җыештырылган бүлмәне күздән кичереп чыга. Баш врач аңарга мәгълүмат бирә:

— Өчесе дә фронтовиклар. Без аларны аерым салдык, тыныч булсын дип.

Чибәр хатын врач одеал астыннан чал башы гына күренеп торган олы яшьтәге берсенә мөрәҗәгать итә:

— Нәрсә белән авырыйсыз, абзый?

— Сукыр эчәкне кистеләр. Инде төзәлеп бетеп бара. Берничә көннән чыгармын дигән өмет бар. Хәлем әйбәт. Рәхмәт врачларга.

Чибәр ханым Сабур абзый янына килә:

— Исәнмесез, абый!

— Әйбәт, сеңлем, әйбәт! Өтерге кебек!

Сабур абый, үзенең сүгенмәгәнлеген белдертергә теләгәндәй, тиз генә баш врачка карап ала: янәсе, күрдеңме Сабур абыйны!

— Сез дә фронтовикмы?

— Фронтовик, сеңлем, фронтовик. Бик күп яфалар күргән фронтовик мин, туганым. Башкалар ише генә түгел!

— Кайсы җирегез авырта?

Сабур одеялын өстеннән ачып ташлый да, күлмәген күтәреп, ябык корсагын ача:

— Менә, сеңлем, иң тәүдә корсакның шушы җире ката башлый...

Сабур уң кулы белән корсагының өске уң ягын төртеп күрсәтә...

— ...катканнан ката инде. Башта имән бармак хәтле генә, бер нәстә калкып чыга. Шуннан китә (!) кебек катып, зураеп... Ирләрнеке кебек менә. Һич алдау түгел. Менә мондый...

Беләге белән нинди зурлыкта икәнен дә күрсәтә.

Кызарып бүртенә башлаган чибәр хатын врач урыннан кузгала алмыйча исе китеп, Сабурга карап каткан. Бүлмәдә чебен очкан тавыш та юк. Тик Сабур гына үзенекен сөйләпме сөйли:

— Индесе монысы үсеп, бетүгә, эчнең икенче ягында, шушысы кебек тагын бер (!) үсә башлый... Шуннан ятасың инде ике-өч сәгать буена өч каткан нәрсә белән. Нишләргә дә белгән юк, туганым. Врачларга сөйлисең, күрсәтәсең — авызларын ералар инде. Көлке аларга. Нәстә эшләргә инде, сеңелкәш, аптыраган.

Кырт борылып чыгып йөгергән хатын артыннан Сабур кычкырып ятып кала:

---

[1] Сабур абыйның сүгенгән сүзләрен кәгазьгә язып булмый инде. Кем нинди сүгенү сүзләрен белсә, (.!.) урынына шуларны куеп укысын... *(Автор искәрмәсе.)*

— Тукта инде, кая йөгерәсең?! Мин бит әле сөйләп тә күрсәтеп тә бетермәдем...

Икенче көнне баш врач Сабур абый яткан бүлмәгә керә. Көлгән күзләрен Сабурдан читкә яшереп, «корыч» тавыш белән аңарга вәгазь укый башлый:

— Әй Сабур абый, Сабур абый! Әйттем бит мин сиңа, бер генә көнгә туктап тор дип. Шул хәтле затлы, шул хәтле чибәр хатынга шулай итеп, әшәке итеп, сүгенеп сөйләмәсәң! Син бит сүгенмәскә сүз биргән идең. Бигрәкләр дә оятлы иттең инде бөтен Эстәрлебашны...

Сабур абый күзен дә йоммый:

— Сүгенмәдем мин, ин... ! Сүгенмәдем. Авыруның исеме белән генә әйттем. Үземә үзем диагноз куйдым мин. Шуны гына сөйләдем. Тизрәк аңласын дип. Әллә ул хатынның ирләр күргәне юк дип беләсеңме син?! Һе! Ничекләр күргәндер әле. Мин сөйләгәндә күзләреннән очкыннар очып очып китте — көлтәсе белән. Ярар. Моннан чыккач нәрсә эшлидерие? Сиңа нәстә ди, минем авыру турында? Йәле, әйт! Әрләдеме әллә?

— Юу-ук! Нинди әрләү ди ул. Диванга тәгәрәгән. Үлә язып көлде. Каян алдыгыз бу хәтлек асыл абзыйны, ди. Әллә ди, мин килүгә махсус яткырып кына тордыгызмы, ди...

Сабур шат, Сабур елмая:

— Ту-ты-ы, менә, ин... (!). Ә син (!) дигәнне гаепләргә булашасың. Акыллы, күпне күргән хатын икән. Күзеннән үк күренеп тора иде, дөрес икән...

Баш врач ерылган авызын җыеп ала алмыйча, кул селтәп чыгып китә башлый. Артыннан Сабур кычкыра:

— Сабур абзаңа рәхмәт әйтеп, берәр йөз грамм шунда эспирт керттер, Андижан (!)...

Мәскәүдә диссидентлар хәрәкәте башланды бер чак. Ул хәрәкәт Мәскәүдә башланганчы ук, безнең Эстәрлебашта беренче диссидент дип Сабур абыйны әйтергә була. Җитмешенче еллар башында кергән бу кибеткә. Ә кибеткә ниндидер әйбер китергәннәр дә, хатын-кыз чиратта кырылышалар икән. Шул төрткәләшкән хатын-кызлар арасында беренче секретарьнең хатыны да бар икән. Сабур абый чират өчен «көрәш» алып барган хатыннарга карап торган-торган да, секретарь хатынына ычкындырган:

— Хет син этешмә инде шушылар белән. Ирең белән төннә... (!) көчең бетә бит. Кич яткач нәстә эшләрсең, ирең сораса. Чиратта (!) кайттым диярсеңме?! Әй, акыл юк та инде хатын-кызда...

Кибет эче шаркылдап көлгән хатыннар тавышыннан шартлаган. Берничә көн узгач, Сабур абыйны өеннән килеп алып киткәннәр.

— Кая алып барасыз? — ди икән бу.

— Райкомга. Бюрога. Беренче кушты.

— Китегез (!) Ул партиягез белән минем алганым да, сатканым да юк. Куних мин витличибнисада. Куних. Биспартийный мин, Сабур...

— Атла, атла, Кытыйка! Боерык бирелгән безгә, сине китертергә. Анда беләләр синең большевиклыгыңны. Атлавыңны бел...

Райком бюросында соңгы мәсьәлә итеп, беренче секретарь Сабур Хафизовның авыл урамнарында, кибетләрендә булган тәртибен куйдырткан. Сабурның тәртибе хакында информацияне үзе биргән. Хатынының Сабурга бик нык ачуы килгән булган, ахрысы. Алып кереп, Сабур абыйны кабинет уртасына бастырып куйганнар.

— Иптәшләр! Хафизов Сабур постоянно эчә, авыл урамнарында, магазиннарда бер туктамастан сүгенеп йөри, хатын-кызларны сүз белән мәсхәрәли. Сүгенүе аты-юлы белән булып, халыкның тәртибен бозуга сәбәп булып тора. Минем тәкъдимем бер генә: авылдан куарга Сабур Хафизовны!

Бюрода утырганнар берсе дә дәшми. Беренче барысына да күз йөретеп карап чыга да Сабурга мөрәҗәгать итә:

— Иптәш Хафизов!
— Ә?!
— Менә бюрода сүз бирегез, эчүне ташлыйм...
— Ташлыйм, энем, ташлыйм...
— ... башкача сүгенмим, диген. Бүгеннән башлап. Шулай дип сүз бирсәң генә авылда каласың.
— Шулаймы?
— Шулай тора вопрос.
— Ә-ә, алай ук торамыни? Бетте, энем, бетте. Эчү дә юк, сүгенү дә юк бүгеннән соң. Бетте. Сабур Эстәрлебашсыз яшәми, авыл да минсез була алмый. Бетте, энем. Бетте...
Беренче тантаналы күзләре белән бюро әгъзаларен карап чыга: күрдегезме атаклы Сабурыгызны ничек итеп акылга утыртырга кирәк икәнен.
— Ярар, Хафизов, бар. Кайт. Тәртипле итеп яшә моннан соң.
Сабур абый ишек төбенә кадәр җитә. Ишек тоткасына кулы белән ябыша да борыла:
— Кумакчымы син, килмешәк, мине авылдан, тот (!). Мин синең кебек иртәдән алып кичкә хәтлек, гомере буе (!) чәйнәп, бер эш эшләмичә, үзең белмәгәнне кешегә өйрәтеп утырмыйм. Мин эчсәм, ат тизәге тазартып эчәм. Үземнең көчемне, тиремне түгеп. Синең кебек партвзнос дип, кеше эшләгәнне талап эчеп йөргәнем юк минем (!). Ах, инәңнең (!). Син монда, безнең Эстәрлебашка ничек килгәнсең, шулай китәрсең дә (!).
Райком бюросы беренче тапкыр, Беренченең кушуына буйсынмыйча, Сабур Хафизовны авылдан куарга дигән тәкъдимгә тавыш бирмәгән. Икенче елны яңа бюрога инде аларның яртысыннан күбесе кертелмәгән, әлбәттә...
Сабур абый, пленнан кайткач, өйләнде. Фәүзия исемле апаны алды. Алты бала үстерделәр.
Хәзер инде Мөчтәкләр ягындагы төп йортта сеңлесе Мәрьям апа ялгызы яши. Инде картая башлагач, йортны Сабур абыйның үсеп килгән бер малаена яздырып куйган. Сабур абый, шуны ишеткәч, килгән сеңлесе Мәрьям апага.
— Мә, Мәрьям тот! Сиңа бу!
— Нәрсә ул, абый!
— Тот (!) Нәрсә, нәрсә! Акча сиңа биш мең (сиксәненче еллар башы!). Әйтмәсеннәр Сабур ялгыз сеңлесе Мәрьямнең өен малаена бушлай эләктергән дип. Киен әйбәт итеп.
Мәрьям апа елый башлагач, Сабур абый аның аркасыннан сөя.
— Рәхмәт, сеңлем! Минем сеңел икәнсең, чын-чынлап.
«Сугыш алды малайлары» басылып чыккан «Казан утлары» журналын Сабур абыйга җибәрдем. Укып чыккач, Фәүзия апа әйтә ди:
— Бигрәк әйбәт итеп язган сине Зәки. Мин дә белеп бетермәгәнмен икән әле сине. Сүгенмисең дә бит, китапта...
Сабур абыйның башы тиз эшли:
— Кайтсын гына әле Писер! Мин аның атасын, әнкәсен искә алып сүкмәсәммме! Үземнең шушылай әйбәт икәнемне белсәм, әллә мин сиңа өйләнгән булырыеммы? Ни за что!
Үзе рәхәтләнеп көлә икән.
«Урам» язылып беткәч, быел июльдә авылга кайттым. Тугайдан көтү китмәс борын кайтып киләм. Капка төбендә мине Сабур абый көтеп тора. Байтак утырдык сөйләшеп. Шунда йөрәгенең бер почмагын ачты ул миңа:
— ... бик шәп укый идем мин. Синең абыең Гарифка җитә алмасам да, бик артта да калмый идем. Ул миннән ике генә сыйныфка алда иде. Кудылар мине сигезенчедә мәктәптән. Бөтенләйгә. Клүкле уйнаганда яңгылыш, Һәдия апаның аягына таяк белән тидердем. Китте

бу акырып: — Хулиган! Жулик! Сәлимгәрәев абый директор. Күп сөйләшеп тормый иде. Кудылар әй, мәктәптән. Киттем чыгып. Каюмов абый бер айдан килгән иде кире алырга, бармадым. Бик нык гарьләнгән идем. Инде менә җитмешне уздым, ә мәктәпне сагынам. Бик укыйсы килгән иде минем. Шәп укый идем мин. Нигә ул апа миңа каныккандыр инде.

Моңсу гына елмая Сабур абый:

— Ул чакта мин сүгенүнең нәрсә икәнен дә белми идем.

Сабур абый да, мин дә дәшми утырабыз бераз. Ул сагыш белән өстәп куя:

— Үтте гомерлә-әр!!!

## Нәби абый

Нәби абыйның кызлары, малайлары миңа ачуланмасыннар. Хатыны Газимә җиңги дә. Нәби абый турында, аның ләкабен биреп язмасам, аны тулысынча аңлатып, язып булмый. Авылда аны Нәби Бүксә дип йөртәләр иде. Безнең урамга ул сугышка кадәр Югары Очтан күченеп килде. Әмир авылыннан алган Газимә исемле мишәр апа аның хатыны. Мин ул апаның бер вакытта бер кеше белән дә кычкырышканын хәтерләмим. Шул ук вакытта ярарга тырышып, күтәкәйләнеп тә сөйләшми. Урам кешеләре аны яраталар, хөрмәт итәләр. Чөнки ул гарип ир белән дөнья алып барды, уңган, эшчән, кешелекле балалар үстерә алды. Газимә ала безнең авылда берничә ел яшәүгә, аның теле дә Эстәрлебаш кешесенекенә әйләнеп бетте. Мишәрлек бөтенләй сизелми дә.

Нәбидулла абзый 1906—07 елгылар булыр. Кечкенә гәүдәле, ике аягы да зәгыйфь иде. Ул үз аяклыры белән бернинди таяксыз йөри. Тиз итеп яисә йөгереп йөри алмый. Бик ыспай итеп киенә белә. Ямаулы «куфайка» да аның өстендә матур, ятышлы, затлы кием кебек булып тора. Башында кырынрак салып киелгән бүрек яисә кепка. Бүрек колаклары өскә яисә артка каратып бәйләнгәннәр. Кышын, көзен өстенә нәрсә киюенә карамастан, аны өстеннән билбау белән буган. Билбавы озын булып, очлары матур итеп салындырып куелган. Атлаган уңайга матур итеп селкенеп баралар. Билбау буган соңгы кеше безнең авылда Нәбиулла абый булгандыр инде. Аякларында төпле пима яисә галушлы чүчинкә. Ул, никадәр ярлы булса да, чабата кимәде. Чабата киюне үзе өчен түбәнлек саный иде, ахры. «Урыс кидерде безгә чабатаны»,— дип карый иде.Телгә оста һәм тәмле итеп, «иркәм» дип сөйләшә белә. Урам буйлап килгән чагында эндәшмичә, сөйләшмичә бер генә кеше янынннан да үтеп китми. Үзе вак-вак кына итеп атлый, үзе ниндидер кошка охшатып, башын кисәк-кисәк боргалап, аяк басасы юлын карап ала, аннан баш тагын тиз-тиз генә уңга, сулга борылып карап ала. Шуннан соң тиз генә алга карап ала да, аннан соң тагын аяк астына. Үзе түлт-түлт итеп кенә атлый, ә ике кулы бер үк такт белән атлаган уңайга икесе бергә, бер алга, бер артка селкенә. Көзен, җәен киндер белән тышланган ике бияләе билбавына кыстырылган була.

Сугыш елларында Нәби абый бишенче бригаданы җитәкләде. Көйләп, чөйләп, карт-коры, хатын-кыз, үсеп җитә алмаган малай-шалайдан торган бригаданы эшләтә белде ул. Азрак белеме дә бар иде. Гаиләсен шул колхоздан эләккән аз-маз азык белән һәм Газимә апаның кул һөнәре белән алып бардылар. Нәби абыйның үзенең дә куллары оста иде. Газимә апа шәл бәйли, ә Нәби абый пималар төпли, итек тегә. Нәби абый төпләгән пималар кеше аягында матурлыгы белән аерылып, әллә каян күренеп торалар. Әтисе Лотфулла бабай заманында авыл мәд-

рәсәсенең соңгы мөдәррисе булган Мөхәммәт Шакир Тукаевта, аның ишек алдын караучы булып, ялланып эшләгән. Житеп килгән өч малайга — Нәбиуллага, Ибраһимга һәм Вәлиәхмәткә, кичен бер пар пима төпләмәсәләр, аулакка чыгу юк икән. Аяклары гарип Нәбигә кызларның бик исе китми һәм ул аулакка барудан әллә ни тәм тапмый. Шунлыктан өйдә пима төпләп торып кала. Ибрай белән Вәли кичләрен чыгып сызалар аулакка, ә абыйлары Нәби өчесе өчен дә пима төпли. Абый кеше абый кеше инде ул!

Сугыш еллары авыр. Алар ачлык, михнәт, югалту кайгылары белән узды. Шул елларда Нәби абзый бишенче бригада хатыннары өчен ашарга табарга, аларга утын өчен ат бирергә, печәнен кайгыртырга тиеш. Һәм ул һәрчак ярдәмчел булды... Атына утырып кырга килә. Атын тугарып жибәрә дә, бер нәрсә дә эшли алмаса да, шунда кеше арасында эштә катнашкан булып маташа.

Кичен авылга кайтырга булса, ат жигү — ул башкара ала торган эш түгел. Чөнки... камыт чөелдереген тартып кыса алмый. Аякларының да, кулларының да көче житәрлек түгел. Тирә-ягына карана да, аның чөелдерәк кыса алмый аптыраганын күрмәмешкә салынган хатыннарга кычкыра:

— Йәгез әле, чыркылдыклар, килегез бирегә! Чөелдерекне генә кысып бирегез дә, мин китим инде.

Сугыш елларында Пожарныйда Абдулла Таз дигән бик кызык бабай эшли иде. Бертуган абыйсы Таһир мулла аклар белән качып чыгып киткән. Халык телендә, Чиләбедә башка кеше исеме белән качып ята икән, дигән сүзләр йөри. Абдулла бабайның Барый һәм Әкрәм исемле ике малае сугышта. Нәби абзый шул Абдулла бабайдан, бер йөк утын бирергә вәгъдә итеп, бишенче бригадага бер дугасын алган. Тик ни сәбәпледер шул бер йөк утынны бирмәгән. Абдулла бабай байтак соранып караган. Тик утынны китертә алмаган. Шуннан әйткән:

— Син, Нәбиулла энем, яхшылык белән теге утынны китертеп котыл. Бер атна срук сиңа. Шул арада китермәсәң, мин сине бөтен авылга адәм мәсхәрәсе итәм. Үпкәләштән булмасын.

Нәби абый нәрсә әйткәндер, анысы билгесез. Тик утынны китермәгән. Шуннан соң Абдулла бабай Нәби абыйдан үч алырга тотына. Пожарныйның эчендә, озын эскәмиядә «пожар саклап утырган» Абдулла бабай, урамнан килгән Нәби абыйны күрү белән урыныннан торып, урамга чыга да аңарга каршы китә. Урам уртасында юк корсагын азрак алгарак чыгара, ике кулын да терсәгеннән азрак өскә каратып бөгә дә, аяк очларын азрак читкә карата да, Нәбиулла абзыйга охшатып, вак-вак кына атлап, түлт-мүлт итеп йөреп китә...

Ә Нәби абыйның исе дә китми. Үз йөреше белән йөреп, көннәрен эшләр үткәреп, яшәвен дәвам итте. Абдулла бабай да килеште Нәбиулла абзый белән. Китерткәндер утынны Нәби абый. Кешенекенә тими иде ул мәрхүм. Абдулла бабай да күптән мәрхүм инде. Ул диндар, укымышлы һәм бик моңлы тавышлы кеше иде. Шул Пожарныйда утырган жиреннән сузып-сузып «Карурман»ны, «Салкын чишмә»не һәм тагын байтак кына борынгы жырларны саф, көмеш кебек чылтырап чыккан тавыш белән жырлый. Узган хатын-кыз туктап, яшьләрен сөртә-сөртә тыңлый торган иде. Сугыштагы малайларын сагынып сөйләр иде дә, күз яшьләрен киндер алъяпкычына сөртә-сөртә елар иде...

Нәбиулла абзыйның балалары күп булды. Бар да сары чәчле, жингигә тартым зәңгәр күзлеләр. Уңган аның балалары. Барысы да матур һәм тигез итеп дөнья көтәләр. Кызлары — ирләрен тыңлаучан, балаларын карый белә торган хатыннар. Тик хәзер безнең урам гына ятим. Аңарга ямь биреп, түлт-мүлт итеп атлап йөрүче, киң күңелле Нәбиулла абзый Хисмәтуллин гына юк...

Мәҗит бабай — зур романга лаек кеше. Олы гәүдәле, лап-лоп атлап йөрде, әтинең иң якын дусларының берсе иде. Ләкабе дә үзенә үзе чыгарган исем. Эше шәптән булмаса яисә акчасы бетсә: «Эшләр хирахау бит әле. Тәмәкелек тә акча юк». Шуннан китте инде: «Хирахау Мәҗите».

Мәҗит бабай базар көнне өеннән бер тиенсез чыгып китеп, сыер, һич югында тана җитәкләп кайта торган кеше иде. Хатыны Миникамал — Сәмүсә Биктимеренең бер туган апасы. Уен-көлке сөйли белә торган бик җор хатын.

Безнең урамда яшәгән йортлары баздуш. Мин уллары Халит янына уйнарга төшәм. Ишекләре — туза башлаган чыпта белән җылытылган. Ишек авыр һәм аны ачарга минем көчем җитми. Нәкъ бәләкәй Габдулла Тукай кебек, мин дә ишек ача алмыйча, суыкта басып торам. Тик минем аякта Рәшидә ападан Мансур абыйга, аннан соң миңа «мирас», куныч-лары теткәләнеп кыскарган киез итекләр. Төпләнгән булсалар да, алар җылы. Өстемдә шулай ук мин өченче хуҗасы булган «песи якалы» (аны Мансур абый шулай ди), күп төстәге ямаулар салынган, кыска гына, яшел төстәге бишмәт. Башта — әтинең иске бүреге. Миңа дип алынган яңа «кибет бүреген» Мансур абый кия. Чөнки мин, «тумыштан ике башлы булганлыктан», кибет бүрекләренә «сыймыйм». Шунлыктан Мансур абыйның бүрекләре икәү һәм икесе дә яңалар. Әти бүрекләрен мин үзеннән соң киеп туздырып бетерәм. Әтидән калган бүрекләр миңа бик тә охшыйлар. Чөнки аларның эчен иснәсәң, аннан әти исе килә. Ә дөньяда иң яраткан кеше — ул минем әтием иде.

Хирахау бабайның туңган кышкы ишеген ачарга минем көч җитми. Тик мин көтеп кенә тавышсыз басып тормыйм. Төпле пиманың үкчәсе белән бер туктаусыз ишеккә тибә башлыйм: «Тук-тук, тук-тук!» Берничә минут шулай тукран кебек тукылдатып торгач, ишек ачыла:

— Кер, Ходайның рәхмәт төшкере нәстәсе. Халитең әле торуны уйлап та бирми. Кай арада торып өлгерәсең син, таң әтәче?

Халитнең әнисе һәр көн диярлек мине шулай итеп каршы ала.

— Мин әтиләр белән бәрәңге пирәмәче ашап, ике шәшке чәй дә эчтем инде. Аннан ярты чүмеч су. Мин Халиткә бер кәнфит тә алып килдем әле.

Сәкедәге иске тун астыннан минем дус Халитнең ялтырап торган башы, зур колаклары, калын иреннәре күренә.

— Кәнфитеңнең эчендә вәринҗәсе бармы?

— Юк, лампачи дигән кәнфит.

— И-и, алай булгач йоклыйм әле мин. Уянгач, аннан соң бирерсең,— Халитнең туны аның башын бөтенләй каплый. Хырылдый башлый тун астыннан. Миникамал әби миңа ымлый да уң кулының бармакларын селкетеп күрсәтә: кытыкла! Тик мин риза түгел.

— Ярар, йокласын. Аның торганын көтә-көтә үзем суырам да бетерәм кәнфитне.

Аяклар белән тибеп очырганнан тун сәкедән идәнгә үк барып төшә.

— Ы-ы! Суырткаңнар ди синнән, суыртмыйчани! Бир минем кәнфитне. Миңа дип алып килгәнсең икән, димәк, кәнфит минеке.

Халит минем кулдан кәнфитне тартып ала, ул аның калын иренле зур авызына кереп юк була.

— Бит юмыйча ашыйлар димени, кил, битеңне ю!

Халит кәнфитне чыгарып сәке йөзлегенә куя да, сәке астыннан тартып чыгарылган җиз тас өстендә, әнисе салган су белән битен, кулларын юа башлый. Битен юып бетерми, сәке йөзлегендәге кәнфитне идәннән үрелеп иснәп булашкан ата зур песигә ялан аягы белән тибә:

— Кара син аны, кәнфит ашыйсы килгән. Ашамый тор әле, мин абзаң бар чакта монда!

Мин Халит белән бергә утырып чәй эчәм, эссе кабартма ашыйм. Аннан соң без уйнарга чыгып китәбез. Халит уйнаган, йөргән җирендә һәрчак баш, барлык малайлар аңа буйсына. Авыл карты кебек, Хирахау Халитенең белмәгәне юк.

Мәҗит бабай мин белгәндә генә берничә өй сатып, бик күп сыер малын алмаштырды. Сугыш елларында трудармиягә эләкте һәм аны Эстәрлетамакта уздырды. Үзе янына гаиләсен дә алдырды. Безнең Халит китте «градский» булып. Авылга кайткан чакларында урысчалан кына җибәрә бу. Тик урысчасы, безнең авылча әйткәндә, нагузим билла иде инде. Кайттылар 1945 елның көзендә авылга, бөтенләйгә. Чөнки Хирахау Мәҗитенең йөрәген кала урамнарына сыйдырып кара! Кайтканнан алып, ун елга якын Мәҗит бабай атлар карап, «дбур йортында» яшәде. Халит үсеп җиткәч, күрше Мәксет авылының «иң һылу кызын» урлап алып кайтты. (Кызның ризасызлыгына карамастан.) Тугыз бала үстерделәр. Өстәвенә Халит хатынының әнисен дә үзләренә алып кайтты һәм үзе карады. Минем дус Хирахау Халите бүген дә авылда Хирахау булып яшәп ята. Ә Мәҗит бабай кече улы Габделхәй белән яшәде. Халиткә дә, Габделхәйгә дә бик матур һәм зур итеп ике йорт бетерделәр. Халитне соңгы тапкыр Гөмбазы фермасында малларга силос салган җирендә күрдем.

1991 елның августы. Мәскәүдә ГКЧП фетнәсе шаулый. Ә авыл, тырыша-тырыша, көзгелеккә малга азык әзерли. Салкын чишмә якларыннан бер ялгызым кайтып киләм. Авариядән соң сул кул гипста. Ачлыктан чыкканнан соң да ике ай гына чамасы вакыт узган. Йончыткан. Җәяүләп килгән җирдән берәү эндәште:

— Зәки, син нәстә эшләп йөрисең монда?

Карасам, озын саплы тимер сәнәк тоткан Халит дус силос чокырына китергән үләнне тигезләп таратып йөри. Бөтен халәте — минe күргәнгә шат. Сәнәк сабы белән арбасы астына төртә:

— Выхади, капитан, полковник пришел, тебя правирайт будет!

Чып-чын капитан... арба астыннан арты белән мүкәйләп чыгып килә. Өстәвенә, минем яшь чактагы кебек авиатор. Хирахау көлә:

— Күрдеңме Халит дустыңны. Мин дә сиңа килде-киттедән түгел. Миңа капитаннар гына падчинайтса итәләр.

Колхозга печәнгә ярдәм итәргә дип җибәрелгән машиналарны, шоферларны карап, тикшереп эшләтүче капитан икән. Халит тегенең белән чын-чынлап командалык итә. Әгәр армиягә барып эләккән булса, Халит полковник кына булып калмас иде. Генерал булыр иде, һичшиксез. Әгәр инде марҗа алган булса, кем белә, бәлки маршаллыкка да үрмәләр иде. Халит элеккечә калган:

— Утыр әйдә минем белән азрак. Казан мәйданында ач утырып киселгәнсеңдер. Сыйлыйм әле үзеңне.— Ул мине каймак яккан помидор белән сыйлый. Минем тормышны сораша. Аллага шөкер, минем узган тормышка бертөрле дә бәя бирми. Сәяси ачлыкта утырып, Россия президентына безнең каршы чыкканга үз бәясен бирә:

— Мин, Зәки дус, синең дәрәҗәдә уйлап эш итә белмим инде. Безгә — сәнәк, көрәк күтәреп эшләп көн күргән кара кешегә — нәрсә кирәк? Түләсеннәр без эшләгәнгә. Яшәргә ирек бирсеннәр. Артыгы безгә кирәкми. Алмагайлары ирек, теләсә нәстә эшләтсеннәр...

Мин сорау бирәм:

— Читтә балаларың күпме?

— Дүртәү әй.

— Оныкларың читтән кайтканда нинди телдә сөйләшәләр?

Халитнең көләч йөзе караңгылана.

— Ничек дип, теге тишек башлар телендә инде. Урысча. Үзем сукалыйм инде. Ә әни менә булдыра алмый. Аз-маз белә ул. Тибашын

белмәмешкә салып, тик тора тегеләр кайтса. Ну би анда Себердә ничек итеп татар мәктәбе ачып, татарча укытасың ди инде?

— Безнең татар авылында урысча укыткан кебек итеп.

Халит миңа карап азрак утыра да, кыска гына итеп көлә:

— Аңладым, әй, синең нәрсә өчен анда ач утырганыңны. Чыннан да, унике көн буена ашамадыңмы?

— Юк, ашамадым. Су гына эчтем.

— Мин китәм инде Халит. Эшеңне бүлдем.

— Бүлмәдең! Калхуз эше бүленми дә, бетми дә ул. Бөтен кешегә дә житә. Тукта, мин сине министрлар кебек иттереп машина белән генә кайтартыйм әле авылга. Давай путюфку. Капитанның биргән кәгазенә кул куя да, өсти:

— Боларның көне буе эшләгәннәре мин кул куйсам гына дөрес. Кич кил миңа, сөйләшеп утырырбыз. Әтиләрне искә алырбыз. Бик дуслар иде бит алар...

## Ятим Фәтхия

Фәтхия әби Сәмүсә Биктимереннән соң тыкрык аша яши. Мин өч-дүрт яшьлек чакта, аның баздуш өенә тыкрык эченнән кереп йөриләр иде. Урамда аны Габит Фәтхиясе, ә күбесенчә Ятим Фәтхия дип йөртәләр. Ире Габидулла теге Герман сугышыннан кайтмаган. Аңардан бер генә улы калган. Гәүдәгә Фәтхия әби — ябык кына, озын чандыр карчык. Ике кәжәсе, кызыл тукал сыеры, берничә тавыгы бар. Сугыш алдыннан улы урамга каратып, зур агач өй салдыртты. Сугыш елларында Фәтхия әби шул йортта яшәде. Мин 1952 елны армиягә киткәндә Фәтхия әби исән иде әле. Тик колакка катыланган иде инде. Улы урыс авылларында су тегермәнендә эшли һәм Фәтхия әби янына кайтып-китеп кенә йөри.

Фәтхия әби каршысында гына Хирахау Мәжите яши. Мәжит бабай сыер малының жиленен тотып карап, аның кайчан бозауларга тиешлеген әйтеп бирә белә. Ялгышса да 4—5 көннән артмый ялгышы. Мәжит бабай солдаттан хәмергә өйрәнеп кайткан. Герман сугышыннан ук. Андый чакта ике урамны тоташтырган «Ятим Фәтхия» тыкрыгыннан туп-туры үз йортына килеп чыга ул. Тыкрыкка килеп керүе була Хирахау бабайның, жыр сузып жибәрә. Күп түзә Фәтхия әби Хирахауның «килде-китте» жырларын тыңлап. Һәм бердәнбер көнне Хирахауның тыкрык буйлап карлыккан тавыш белән жырлап кайтканын сәкесендә «йөрәген бозып» тыңлап ятканнан соң, керә боларга иртән иртүк.

— Син, Мәжит күрше, теге нәстәңне эчеп, күңелләнеп кайткан чакларыңда, минем тыкрыгымнан кайтма моннан болай. Синең килде-киттеле жырларыңны тыңлап, Ходаем алдында гөнаһлы булып, тәмугъ утларында янасым килми минем.

— Тыкрыгыңнан тагын жырлап кайтсам, нәстә эшләрсең? — ди Хирахау Мәжите, аңарга табан башын да бормыйча.

— Тавык тизәге катыштырып көл әзерләп куям бүген үк. Сибәм өстеңә!

— И-и күрше, күрше,— ди Хирахау Мәжите.— Көл сибешүгә барып житмик инде без. Без бит синең белән, яхшымы, яманмы, күршеләр!

— Оятың да юк, иең дә юк, Мәжит синең! Алладан да курку юк. Тагын эчсәң, олы урамнан кайт әнә. Рөхсәт сиңа! Үзе киң, аннан сине анда тыңларга капка төбе саен кеше. Тар тыкрыкта кем ишетә сине! Бер мин генә...

Мәжит Хирахау хатыннар белән озак тел чарлаган кеше түгел, сөйләшү беткәнгә ризалаша:

— Ярар алайса, күрше, шулай, үпкәләштән булмасын. Үзең әйтмичә башкача синең тыкрыкта җырлаулар бетте...

Икенче көнне кичләтеп, Хирахау Мәҗите тагын азрак салган баштан өенә кайтып барганда, җан күршесе Ятим Фәтхия әйткәнне исендә тотып, аның тыкрыгыннан түгел, ә үзләренең олы урамы буйлап атлый. Ни өчендер җыры да берәү генә. Хирахау аны җырлап бетерүгә, тагын башлый. Тавышы азрак карлыккан, ләкин көчле һәм үзенә күрә моңлы:

> Карабодай ярмасын,
> Он итәргә язмасын.
> Фәтхиянең артын күрдем,
> Күп күрергә язмасын.

Икенче көнне бөтен Эстәрле авылы малайлары урамнар буйлап шул җырны гына җырлап йөриләр. Ә кичен, караңгы төшкәч, Ятим Фәтхия, кара шәле белән йөзен күренмәслек итеп каплап ябынып, Хирахау Мәҗите Миникамалын үзенә чәйгә чакырырга керә. Шул чәйләгәннән соң Хирахау Мәҗите хәмер җибәргән күңелле кичләрендә олы урамнан кайтмыйча, «Ятим Фәтхия» тыкрыгыннан гына җырлап кайта торган булып кала. Шулай йөрергә аңарга Ятим Фәтхия рөхсәт биргән икән дә, тик бер генә нәстәне шарт итеп куйган ди: «Карабодай көен» башкача олы урамда да, үзебезнең тыкрыкта да җырламаска. Күрше хакы!..

## Җомайлар

Мин аларны яхшы беләм. Чөнки кеше улы Габдрахман минем кечкенә чактагы дус һәм без аның белән урамдагы малайлардан икәү һәм Пүликәр Касыймы өченче сыйныфка кадәр бергә укыдык. Ул миннән бер яшькә зуррак булса да гәүдәгә миннән дә кечерәк. Бу да безнең дуслыкның бер нигез ташы булып тора. Чөнки бәләкәй чакта синең белән бер яшьлек малай синнән аз гына булса да буйга озынрак булса, андый малай белән булган дуслыкның бер җире барыбер китек була.

Җомайларда казакъ каны нык катыш булганнан, алар торганы белән казакъка охшаганнар. Киң, азрак карарак бит, почык танау, кысыграк күз, камыт аяк. Габдрахман дуслык өчен бик ныклы, әйбәт малай иде. «Сугыш алды малайлары»ндагы бәләчәк Габдрахман әнә шул Җомай Габдрахманы инде ул.

Әтиләре Мәҗит абзый азрак сакау. «Егетләрнең асылы, Йосыповлар нәселе» (Фамилияләре Йосыпов боларның) дигәнне ул:

— Жегетләнең ашылы, Жошопофлар нәшеле,— ди торган иде. Берәрсеннән тел ягыннан көлергә уйласалар, авылда шул «Жошопофларны» әле дә искә төшерәләр.

Өйләре кечкенә, нечкә генә бүрәнәләрдән салынган. Ул йорт әле дә шул урынында утыра. Тик башын гына шифрлап япканнар. Бу ел кайткач, бик озак басып тордым мин ул йорт каршында. Анда Күлик Бакыйрының сеңлесе Маһира апаның бердәнбер улы Кылый Ринат яшәп ята. Япа-ялгыз, берүзе. Ә Җомайларның берсе дә авылда юклар. Шул чактагы өйнең чоланы юкагачтан кысма итеп эшләнеп, балчык белән сыланган. Өйләреннән 15—20 метрлар гына Төрек күле җәелеп ята. Ул күл әле дә шул урынында. Яз көннәрендә ул җәелеп китә һәм Габдрахманнарның өенә кадәр килеп җитә. Чоланнары су белән тула, базларына керә. Идән тактасы сыгылганнан, чупылдап су чыккан чаклар да истә.

Габдрахманнарның кечкенә бер ана үрдәкләре бар. Яз көннәрендә ул үрдәк Төрек күленнән кермичә, шунда йөзә. Бакылдап, кыр үрдәкләрен үзе янына чакыра. Ә тегеләре — гомерләре беткәннәре бу үрдәк янына шапылдап килеп төшәләр. Мәхәббәт уены башлыйлар. Ашарга

кайтканда шул ана үрдәккә ияреп, ата кыр үрдәге дә кайта һәм аның гомере Җомайлар өенең чоланында тәмам була, шунда өзелә. Мәҗит бабай казыган канау белән алдан ана үрдәк йөзеп кайта, аның артыннан мәхәббәттән күзе тонган егет үрдәк. Шул чоланда байтак мәхәббәт эзләп килгән үрдәк асыллары башларын салдылар. Мәҗит абзыйның чалгы пычагы астына. Ел саен яз буена Габдрахманнар кыр үрдәге ите ашыйлар.

1942 елның язында Габдрахманның әнисе үлде. Озак ятты ул урын өстендә. Исеме Мәгузә иде бугай. Тормышлары ярлы, сыерлары юк. Җомай Мәҗите Хирахау бабай кебек мал таба торганнардан түгел. Аларның хәтта кәҗәләре дә юк. Мәҗит абзый лап-лоп итеп авыр атлап йөри. Аның гәүдәсе дә юан, зур. Киеме сәләмә, аякларында юан итеп ыштыр урап киелгән чабаталар. Балалары Габдрәхим, Хәбибә, Габдрахман. Авыру әнисен күбесенчә Габдрахман карый. Ашата-эчертә, урынын алмаштыра, чәчен тарый, күлмәкләрен юа. Габдрахман бик миһербанлы, инсафлы, кешеләр өчен ярдәмчел малай.

Әниләре үлгәч, Мәҗит абзый озак та тормый чит авылдан (Әнәчтән иде бугай) зур гәүдәле (безнең авылда андый хатыннарны, Күшкүл аты кебек, диләр. Кушкүлдә хахуллар яши, атлары олы гәүдәле), шадра битле «яңа әни» алып кайтты. Ул хатын балаларга бик әйбәт булып, аларның тормышлары күңеллеләнеп китте. Минем истә шулай калган. Өйләренә яга башласалар, төтен чыга. Шул апа пычак белән мичне тыштан кырып, төтен юлын ачып тазарта торган кирпечләрне эзли. Габдрахман аңарга ярдәм итәргә тырышып, аның янында буталана. Теге апа аңардан сорый:

— Габдрахман улы-ым! Әниең кайсы җирдән ачып тазарта торган иде пичегезне?

Минем исем китеп карап торам. Габдрахман шул кирпечләрнең кайсысын ачарга икәнне белә! Күрсәтә «яңа әнисенә». Теге апа кирпечләрне ачып, шул тишекләргә кулын тыгып, корым тазарта. Шадра битенә корым буяла. Габдрахман аңардан көлә башлагач, ул Габдрахманның битенә күп итеп корым буйый да көлә:

— Менә син дә кара кеше булдың!

Ул апа көлеп, шаярып кына Мәҗит бабайдан кайдандыр кызыл балчык белән тау комы кайтарта. Көне буена мич көйлибез. Кичен «яшь әни» кыстыбыйлар пешерә, безне сыйлый. Өй эчендә кечкенә, янчелеп беткән, ләкин ялтырап торган самавыр җырлый. Ә без кыстыбый ашыйбыз. Мае аз кебек булса да, бик тәмле иде ул...

1943 елның җәендә Габдрәхим абыйны сугышка алдылар. Ул, ахрысы, 1925 елда туган булгандыр. Ә Мәҗит абзыйны шул елның февраль тирәләрендә үк трудармиягә алып киттеләр. Теге апа аны озаткач, озак та тормады, кайтып китте. Сәбәбе: Габдрәхим абый өйләрен сатарга булаша, теге апа саттырмый. Әтиеңнең кайтканын көтик, ди икән. Габдрахман белән Хәбибәне, абыйлары сугышка киткәч, Эстәрлебашның үзендә яңа гына оештырылган балалар йортына бирделәр. Габдрахман аннан качып, безнең урамга кайткалый. Өстендә ап-ак яңа эчке күлмәк белән эчке ыштан. Балак очлары ак баулар белән бәйләнгән. Бер атна узуга күлмәк белән ыштан кап-карага әйләнә... Сугыш бетәр алдыннан Габдрахманны да, Хәбибәне дә каядыр читкә озаттылар. Габдрәхим абый сугыштан кайтмады...

1948 елны Габдрахман, туу турында таныклык алырга дип кайтып, бездә берне кунып киткән иде.

— Мин ничек, Зәки, үскәнменме? — дип, миннән берничә тапкыр сораганы истә. Ул да, минем кебек, үсә алмам ахрысы, дип шүрли иде бугай. Шуннан бирле аның авылга кайтканы юк. Әтисенең энесе хатыны Нәфисә ападан алар турында сораганым булды. Аның җавабы:

— Әдрисләре бар. Хәбибәнеке дә, Габдрахманныкы да. Бирермен тапсам. Тик бик күптәннән күргәнем юк. Кая куйдым икән — иллә дә хәтерем начарланды...

Таба алмады Нәфисә апа аларның адресларын. Соңгы елларда күргәнем дә юк инде. Кызыл Урдада кызы Рәйсә яши. Шунда кунакка бара да, бик озакламыйча кайтып житә.

— Ашау әйбәт. Кода белән кодагый да бик тә әйбәтләр. Кызым үлеп тора минем өчен. Оныкларым үлеп торалар. Тик үзебездәге кебек кара туфрагы, челтерәп аккан чишмәләре юклыктан, түзәрлегем калмады. Бик сагынам үзебезнең туган якларны. Ялгыз булсам булам, тик үземнең туган ягымда яшим. Кирәге юк ит-майлары да, куй тулы далалары да. Үз жиремдә, үзебезнең кара туфрагымда буласым килә. Кайттым менә...

Балачак Жомай Габдрахманы белән бергә сагындыра. Вакытлар узгач, бер күрешербез кебек...

## Мәсәл Фәткиясе

Олы гәүдәле, аскы калын ирене алгарак чыгып торган, җәен-кышын иске, ямаулы куфайка киеп, башына ак яулык ябынып, шәл дә бөркәнеп йөри торган әби иде. Пожарныйдан кире күченеп кайткач, әнинең иң якын ахирәтләренең берсе. Күрше дүрт йорт аша булса да йөрешәләр, чөкердәшеп сөйләшәләр, кайсы чакта «эләгешеп» тә китәләр. Тик, андый чакларында Фәткия әбинең пырылдап, әнине «кара чуен» дип исемләп кайтып киткәненә бер сәгать тә узмый, ул кире килеп тә җитә:

— Җә, куймадыңмыни әле самавырыңны?! Син-«кара чуен» белән кычкырышып тамагым кипкән. Кайтып җиткәч кенә беленде. Өйдә чәй куеп караган ием, бармый. Йотып булмый синнән башка. Юкка гына әйтештек шикелле. Сиңа каршыәйткән мин дүрәк. Сине әйткән дә юк инде. Гомерең буена акылга туймадың. Лотфулланы әйтер идем, нәстә дип тотадыр инде сине...

— Утыр, утыр. Самавыр кайнаган, бәрәңге пешкән.

— Ыы, шулай булсын. Рәхмәтләр төшкере нәмәстәкәй...

Ире — Мәсәл исемле бабай. Озын буйлы, үрә каткан, урамнан узганда дөя кебек башын югары тотып атлый. Җиргә карап йөри белми. Фәткия әбинең зур улы Әхәт абый — тәүге иреннән. Ул 1918 елгы. Әнвәр, Ямал, Хәсбиямал, Иншар — Мәсәл бабай балалары. Әнвәр абый сугыштан кайтмады. Ул 1925 елгы иде. Ә Иншар бертуктамастан эчеп, үзен-үзе бетерде.

1941 ел. Июнь ае. Сугыш башланырга берничә генә көн калган. Безнең абый-апалар (аларга 12—13 яшьләр) Сәхәп яланында бодай утыйлар. Хирахау Халите җитәкчелегендә (атаманыбыз!) без шул 5—6 чакрымдагы Сәхәп яланына күтәреп өйдән ипиләр илтәбез. Чөнки яланда утауда ятучы безнең апалар, абыйлар шунда «калхуз ипиен ашасалар, көзен трудка иген азрак тия». Тотып алып калалар икән шул җәйлектә ашаганга. Ул «авыныс ипие» дип атала икән. Халит кичә генә бригадир Сәвәләй Бакыйр абзый белән ул Сәхәп яланына барган инде. Кичен кире утырып кайткан. Ул бүген безне «алып бара». Юлны яхшы итеп исендә калдырган. Тик барганда безне «әнә теге тау башында»гы, «әнә теге миләшлектә»ге җен-пәриләр белән бертуктаусыз куркыта. Шунлыктан, авылдан чыкканнан бирле, без аңарга елышабыз, берсүзсез аңарга буйсынабыз. Халиттә баш шәп. Ул юл буена адашып торып калган малайлар турында, аларның башын җеннәр кимергәне турында сөйли. Калын иреннәре безне куркытып, шапылдап-шапылдап, бер туктамастан сөйлиләр дә сөйлиләр.

Байтак араны тузанлы ялан юлы белән барганнан соң, бер кечкенә елгачыкны чыккач, Локман Атрубын сулга калдырып, үләнле басуга борылабыз. Юлдан читкә. Үләндә, арба үткәннән, тәгәрмәч эзләре ярылып ята. Халит безгә аңлата:

— Болар Сәвәләй Бакыйры абзыйның крандасының тәгәрмәч эзләре. Ике тәгәрмәч эзе уртасыннан гына барыгыз. Читкә чыксагыз, адашып торып калуыгыз бар. Аннан мин әниләрегезгә нәстә диярмен? Сезне эзләп торырга минем вакытым юк. Белегез аны!

Без «белергә тырышабыз». Шунлыктан ике тәгәрмәч эзе арасыннан чыкмыйча атлыйбыз. Һәрберебезнең кулында түгәрәк зур күмәчләр. Букча кебек нәрсәләр беребездә дә юк. Шул көенә кулларга күтәргәнбез дә атлый бирәбез...

Табор янына барып җитүгә, безне Мәсәл Фәткия әби каршы ала:

— И-и-и, Ходайның рәхмәте төшкән җаннар! Сез үсмичә кем үссен инде.

— Ыы, үсте ди болар, үсми ни. Мин алып килмәсәм, адашып бетәрләр иде юл буйларында. Баш имгәкләре...

«Баш имгәкләре» ул без инде. Ипиләрне куыш авызына куябыз да, шул куыш авызы янына тезелешеп утырабыз. Фәткия әби әйтерсең лә безнең килгәнне генә көтеп торган. Зур агач табак белән (тагарак диләр иде) безнең уртага китереп, аш куя. Аш — бодай умачы. Аңарга күп итеп катык ката да, безнең барыбызга да агач кашыклар тарата. Халит безнең кулдагы кашыкларны тиз генә карап чыга да, минем кулдагы кашыкка үрелә:

— Кичә мин ашаган кашык ул. Минеке, димәк. Бир!

Әнинең әхирәте Фәткия әби янына килгәч, минем «килә белмәү» куркуым бетте. «Баш күтәрәм» һәм кашыкны Халиткә бирмичә тартышам. Халитнең урыныннан торганын күреп, мин дә торам. Көч ягыннан мин аңарга бирешмим. Без бер-беребезне төрткәли үк башлыйбыз. Шулчак Фәткия әби Халиткә өр-яңа кашык суза:

— Йә, йә! Аш янында ипләп кыланыгыз. Кайткач урамда төрткәләшерсез. И-и, ташбашлар...— Ашның тәмлелеге — ис китәрлек. Без табын яныннан тәгәрәтеп җибәрерлек булып, корсаклар шар кебек түгәрәкләнгәнче ашыйбыз. Фәткия әби өстәп тора, аш бетә башласа.

Ашап туйгач, Халит озын кызыл телен чыгарып кашыгын ялый, уң кулын күлмәге астына тыгып, түгәрәк корсагын сыйпап карый да, Сәхәп яланнарын яңгыратып кикерә:

— Әлхәмдлиллә-ә, мең шөкер биргәнеңә, Ходай!

Халит артыннан без дә битләрне сыпырып, табын яныннан көчкә кузгалабыз. Шулчак ерак та булмаган бодай басуыннан Дүлдин Хәйрүше кайтып төшә. Кулында таяк һәм баулы тоткалы ярты чиләк сыешлы балчык чүлмәк. Шундый таяк белән алар бодайны узып үскән билчән башларын чабып йөриләр. Шул «бодай утау» дип атала икән. Йолкырга ярамый билчәнне, чөнки билчән белән бергә эргәдәш бодай да йолкынып килеп чыга икән җирдән. Бодайны шулай итеп утауны колхоз рәисе Габсаттар абзый уйлап чыгарган. Ул безнең авылныкы түгел. Читтән килгән. Ул колхоз эшен оста итеп оештыра белә, халыкка ел саен «труд»ка күпләп ипи тараттыра. Алган игеннәр келәтләргә сыймый. Габсаттар «прсидәтел» игенне ишек алларына бушаттыра кешеләрнең: эшләгәне үзенә булсын!

Габсаттар абзый сугышка китте, шунда югалды. И көттеләр инде аны сугышлар беткәч авыл халкы — и көттеләр. Менә Габсаттар прсидәтелебез кайтыр. Алла кушса, аннан китәрбез бөтен колхоз белән баеп. Игеннәр алырбыз «труд»ка, сугышка кадәр алган кебекләр итеп. Ул кайтса, күмә инде калхузны да, безне дә икмәккә...

Кайтмады Габсаттар абзый, баемады «8 март» колхозы. Бетте, таралды...

Фәткия әби, Хәйрүшне күреп, бик куана:

— Менәтрәк, рәхмәт төшкере! Бар, Хәйрүш улым, шушы малайларны каршы тауга алып мен дә юа җыярга өйрәт. Күрсәт балаларга...

Хәйрүш тик йөрми икән шул.

— Әнвәр абый безнең малайлар бригадиры бит. Суны эчеп бетерделәр теге бирәннәр. Ул мине су алып килергә җибәре. Тиз кил, ди. Көрпә Гарифы анда җиргә утырды да, су эчермәсәгез, башкача утамыйм ди бит...

Фәткия әби Халиткә күрсәтә:

— Әнә минем Халит улыма бир чүлмәгәеңне. Ул менә бу малайларның бригадиры, башлыклары икән. Кая итәргә ул гына белә. Ә син юага бар. Алып бар балаларны, күрсеннәр, белсеннәр юа тәмен.

Халитнең дә безнең белән юага барасы килә. Тик ул инде «бригадир» булганлыктан, аның эше безнекенә караганда җаваплырак. Без «башлыктан» котылганга ризабыз, тик сүз белән әле аны әйтә белмибез. Хәйрүшкә ияребез дә каршы тауга үрмәлибез. Фәткия әби безнең арттан кычкырып кала:

— Син, Хәйрүш улым, аларга Читән коедан су эчер. Үссеннәр тизрәк, талчыбыгы кебек.

Без Хәйрүш абый күрсәткәнчә, тезләнеп, юа эзлибез. Тик юаны тиз генә башка үләннәрдән аера белмибез. Хәйруш абый « карап эзләргә» дип, безгә биргән юаларны «тәмләп карап кына» ашарга тотынабыз. Хәйрүш абый безне тирги, юа эзләргә өйрәтә. Юа ул ике төрле була икән. Бер төрлесе кәҗә юасы, икенчесе сарык юасы. Кәҗә юасы суганнан да ачырак, кырлы юа, үзе кара-яшел. Озын кыяклы булып, бер төптән ике-өч кыяк кына чыга. Ә сарык юасы төчерәк, аксыл яшел. Бер төптән бик күп булып, учлап алырлык булып үсә икән. Тапкан юаларны Хәйрүшнең кепкасы эченә тутырабыз. Җомай Габдрахманы үтенә:

— Хәйрүш абзы-ый! Тәмлеме икән, ашап карыйк инде?!

— И-и Җомай! — ди Хәйрүш абый. — Авыз тирәң, туфрак кына, ашагансың бит инде.

Без барыбыз да күлмәк җиңе белән авызларыбызны сөртәбез. Хәйрүш абый безгә юалар тарата. Әрчеп, тазартып тору юк. Тиз генә үләнгә ышкып алабыз да авызга тыгабыз. Тик Габдрахман такмаклый башлый:

— Иске корсак яңа аш, ихахай-михахай!

Габдрахманга без дә, «ихахайлап», ияребез. Сәхәп тауларын шаулатып, гөрләшеп алабыз. Хәйрүш абый безгә Сәхәп буйларын күрсәтеп сөйли:

— Элекке заманнарда менә бу җирләр Мәксет авылының Сәхәп дигән башкортның җирләре булган. Монда аның меңәрләгән сарык һәм елкы маллары йөргән. Ничә баш малы барын ул үзе дә белмәгән. Тик кичкелеккә алып кайтып, малларын киртә эченә япкач кына чамалый торган булганнар барсы да кайтмаганны. Чөнки маллары яланда торып калса, киртә эче тулмый икән. Шул Сәхәп бай бик күп алтын-көмешләрен менә шушы тауларның берсенә күмгән. Тик капылт үлеп китеп, беркеменә дә әйтә алмаган. Ияре өстендә үлгән, диләр. Инде менә шул хәзинәнең кайда икәнен белүче юк. Тик елына бер тапкыр ярты төн уртасында шул хәзинәне саклаучы убырның уты күренә ди...

Без барыбыз да аяк астына карап, хәзинә эзләргә тотынабыз. Хәйрүш абый бездән көлә:

— Тапсагыз, сугыша башларсыз, миңа да миңа дип.

Кайтышлый уңга борылып кереп, куаклар каплый башлаган бер бәләкәй генә ерым кебек җиргә төшәбез. Анда акрын гына чылтыраган чишмә тавышы килә. Чишмә казылып, аның эченә түгәрәк иттереп читән үрелгән. Тешләр чатнаганчы, ятып, чишмә суы эчәбез. «Читән кое» суы үстерә! Габдрахман, өч тапкыр ятып эчкәннән соң, «бисмилласын» әйтеп, кое суын учлап ала да башын чылата:

— Әни Читән кое суы белән башны чылатырга кушты. Тизрәк үсәрсең шуннан соң, диде.

Без этешә-төртешә учлап-учлап су алып башларны чылатабыз. Китә сибеш. Тик Хәйрүш абый безне шаярттырмый, алып кайтып китә.

Кояш баер алдыннан бер өер малайлар, кызлар утаудан кайтып төшәләр. Малайлар өере алдан. Алар арасында Мөхмиләрнең Равиле, Рашаты, Гәрәс, Сәлиме, Җомай Габдрәхиме, Әмин карт Хәбиренең улы

Габдрәхим, Капар Варасы, Сиксән күз Миңлегалие, Төрек Бәдретдине, Папай Нигъмәте, Көрпә Гарифы, Писер Мансуры (минем абый!), Фазулла бабай Тәлгате, Мәсәл Фәткия әбинең Әнвәре белән Иншары. Болар бар да шул замананың безнең урам малайлары!

Әнвәр абый, Җомай Габдрахиме, Төрек Бәдретдине сугышта һәлак булдылар. Алар өчесе дә күрше булып үскән дуслар иде...

Кич ятар вакыт җиткәч, шул малайлар безне озын, тәбәнәк куышка тутыралар. Без шунда йокларга тиешбез. Куыш эче кысрык, һава җитми, борча күп. Өстәвенә, бертуктаусыз шаяралар. Кычкырыш, көлеш, елаш. Байтак изалангач, тыштан Фәткия әбинең тавышы ишетелә:

— Халит, Зәки, Габдрахман, Фәрит — чыгыгыз монда. Үзем белән йокларсыз. Әнвәр абыегыз салган зур куышта...

Без теге тәбәнәк куыштан мүкәйләп чыгып китәбез. Фәткия әби яшәгән куыш — иң зурысы, иң биеге, иң иркене. Аннан соң миңа байтак кына куышлар ясарга туры килде. Мин аларның барысын да, күп уйлап тормастан, шул Әнвәр абый ясаган зур куышка охшатып ясый торган идем. Һәм шулардан да иркен, уңайлы куышлар булмый.

Куыш эчендә Фәткия әбинең уллары Әнвәр, Иншар абый, кызлары Ямал белән Хәсбиямал апалар йокларга әзерләнәләр. Безгә дә урын табыла. Без «ишек төбендәрәк», Фәткия әби янында урнашабыз. Безнең Эстәрлебашның үзенең генә берничә әйтеме бар. Аларның икесен сугыш елларында, ата-бабасы казакъ далаларына тамак туйдыру нияте белән китеп, шуннан кайта алмаган Җомай Сәгыйдәсе чыгарган. Берсе: «Күңелең киң булса, учак өчен бөтен авылга бер шырпы җитә». Икенчесе: «Әмир авылы, Хәлекәй авылы, бар да миңа хәсрәт».

Әнвәр абый сугыштан кайтмады. Кече улы Иншар абый 1930 елгы иде. Эчкегә сабышып китте дә үзен-үзе бетерде.

Ямал апа күрше Куганакбаштан күченеп килгән Синагулов Латыйф абыйга кияүгә чыкты. Ул абый, үлгәнче, безнең «Эстәрле» колхозында бухгалтер булды. Сугыш вакытында, немецләрдән әсирлектән качып, Польшада партизан булган абзый иде.

Икенче кызлары Хәсбиямал апа Ясаклы урамы егете Тити Габделхәйгә кияүгә чыкты. Титинең әтисен — гади, надан колхозчыны 1937 елда, НКВД «Тройкасы» суд ясап, Уфада атканнар. Габделхәй абый гәүдәгә бик зур түгел, иллә дә эшчән кеше иде. Фронтовик. Ул, күрәсең, 1926 елгы булгандыр. Габделхәй абый озак еллар колхозда эшләде. Бригадир булып. Безнең Түбән Очта Тал Борыны дигән урында үзенә зур йорт бетереп керде. Үлгәненә ун еллар чамасы бардыр инде.

Мәсәл бабай сугыш елларында Оренбург якларына япа-ялгызы икмәк эзләп чыгып китте. 1944 елны ул 18 пот бодай алып кайтты һәм Иншарны үзе белән алып китте. Казакъларга ялланып көтү көтәләр икән. Иншарга ияреп Папай Нигъмәте дә китте. Тик икенче елны алар икесе дә авылга кире кайттылар. Өр-яңа яшел куфайка өсләрендә. Аякларында итекләр. Казакъ якларында «чабата юк» икән. Чөнки анда юкә агачы үсми. Мәсәл бабай башкача кайтмады. Казакъ далаларында калды... Фәткия әби урынында Әхәт абыйның улы Мидхәт яшәде. Тик узган ел мотоциклы белән бәрелеп һәлак булды. Ул Эстәрле авылы асылларының берсе иде...

### Төрек Зөбәйдәсе

Җомайлардан аста Төрек Басыйры дигән абзый яши. Хатынын да Төрек Зөбәйдәсе дип йөртәләр.

Зөбәйдә апа гәүдәгә зур, үзе төскә-биткә бик чибәр хатын. Түшләре киң, буе зифа, тавышы моңлы. Эшкә бик уңган. Ире Басыйр абзый дәшмәс, сөйләшмәс, гелән генә эш белән мавыккан бер җан иде. Гаиләләре тату, тормышлары мул бара. Аларның дүрт балалары бар.

Уллары Бәдретдин һәм кызлары Рауза, Фатыйма, Хәлимә. Хәлимәләре сугыш елларында үлде. Бәдретдин абый фронтта һәлак булды, ә Басыйр абзый трудармиядә үлде.

Сугыштан соң Әфисәр Абдулла үлгән килене Өмегөлсем өен (безнең өс яктагы йортны), өстәү биреп, Зөбәйдә апа белән алмаштырып алды да үз йортына шуны күчереп яңартып салды. Зөбәйдә апа безгә күрше булды. Ә алар яшәгән йорт урыннары тузылып, Төрек күле урыны киңәеп китте. Анда каз-үрдәкләр үлән чеметеп йөри башладылар.

Зөбәйдә апа белән минем әни бик тиз дуслашып, тату күршеләр булдылар. Шул чакны Зөбәйдә апа сөйли:

— Силсәвиттә Бөркет Абдулла дигән бабай мич яга, павискалар тарата иде бит. Улыма, Бәдретдинемә сугышка китәргә пависка китерә бу бабай. Бәдретдинем тегене тәрәзәдән күреп кала да сәке астына кереп кача. Шуннан пышылдый миңа: «Өйдә юк дип әйт, әни. Минем сугышка барасым килми, үтерәләр икән анда». «Берничә тапкыр килде бу Бөркет. Улым өйдә юк, бетте-китте шуның белән. Шуннан беркөнне үземне силсәвиткә алып китеп, бер тәүлек шундагы эскәмиядә утырдым. Чыгармыйлар инде мине — кая малаең?

Икенче көнне Бәдретдинем килгән мине эзләп. Эләктереп алдылар да алып та киттеләр бәбкәемне сугышка. Кешегә сугу түгел, күтәрелеп карарга да курка, уңайсызлана торган иде. Атасы кебек бик юаш иде шул. Аны барып җитүгә үк үтергәннәрдер инде. Кешегә ияреп тә сугыша белми иде ул...

Кызы Раузасы урта Азиядә, ә Фатыймасы — Калининградта. Үзебезнең авыл егете, сугышлар беткәч кайтып, алып китте Фатыйма апаны. Майор. Шулай итеп Фатыйма апа офицер бичәсе булды. Әле дә шунда яши.

Зөбәйдә апа, мин армиягә киткәч, Урта Азия якларына күченеп киткән. Хәзер безгә күрше булып, аның бертуган апасының улы Әхәт абый яши. Ул әнисе белән Магнитогорск якларыннан сугыштан соң «выселка»дан кайтты. Әтиләрен, кулаклар дип, шунда алып барып, чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алып авыл төзетеп, Магнитогорск өчен яшелчә үстерткәннәр. Бушка, тамак ялына.

Зөбәйдә апаның нинди эшчән булганын утызынчы елларда колхоз ындырында зур иләк белән ашлык тазарткан бер ир сөйли:

— Пиреч Мәҗите белән иләк әйләндерәбез. Зур иләк. Ул берне, мин икенчене. Күлмәкләрне салып ташлап эшлибез әй. Икебездән дә пар күтәрелә. Ярышабыз тегенең белән — кем күбрәк или. Күбрәк иләгән кешенең исем-фамилиясен Гали Тукай идарә янына тактага язып куя. Бөтен калхузник укый инде тегене. Укый белгәне. Без бала-чага кебек, шуңа кызыгып эшлибез бит инде. Төрек Зөбәйдәсе, Кушкул аты кебек таза әй, безнең иләкләргә иген салып тора. Пудаука дигән тимер тәпән белән. Иләккә икене салырга кирәк. Без янып чыгабыз, аңарга да ник эләгә инде. Күлмәге кап-кара булып чыга тирдән, сыгып алып була. Көнозын бирешми теге, салуы салу. Мәҗит белән күз тимәсә ярар иде мона дип соклана торган идек. Үзе миннән байтакка зур иде Зөбәйдә апа...

Туфрак тарткандыр инде. Читтә, үзбәк якларында күмелгән безнең Төрек Зөбәйдәсе.

## Мөхмиләр

Мәсәл бабайлардан аста Мөхмиләр яши. Аталары Мөхәммәт исемле. Озын буйлы, кара чәчле, кызлар кебек кыйгач кашлы, аз сөйләүче абзый ул. Әниләре Мәрхәбә апа әле дә исән бугай. Аларның балалары бик күп иде. Бар да диярлек малайлар үзләре.

Мәрхәбә апа — Мөхәммәт абзыйның икенче хатыны. Беренчесе үлгән. Анысыннан бер улы, бер кызы булып, ул балалары олылар һәм авылда бик сирәк күренәләр. Эстәрлетамакта яшиләр.

Мәрхәбәападан туганнар: Равил, Рашат, Рәйсә, Мөхәммәтгәрәй, Сәлимгәрәй, Тәлгать, Миңлегөл, Мансур.

Без үскәндә, Төрекләр янында Мөхмиләр өстенлек итәләр. Атаманнары Равил. Ул кырыс, зур авызлы, кеше кызганып тормый, сугыш чукмары. Кәрт уйный, тәмәке тарта. Энесе Рашат, киресенчә, бик тә кешелекле, ярдәмчел, үзе атасына охшап бик тә чибәр иде. Инде картаеп, әбигә әйләнеп барган шул замандагы безнең урам кызлары бар да Рашат абыйга гашыйк иделәр.

Миңа өч яшьләр чамасы. Авыл урамының очында бер буа була торган иде. Аны, зелпе тамыры казып, шуны казанда кайнатып, тамыр кабыгын куптарып алып киптереп, хөкүмәткә тапшыра торган Гомәр бабай Эстәрлене буып ясый. Буа ярында «полкавай катюл» да зелпе тамырларын суда кайната. Көн саен шул ук учакта бер чиләк ботка пешерә. Без шул буада су керәбез, зелпе тамырын тешләр белән кимереп, каерысын аерабыз. Гомәр бабай безнең ул эшне «каз боты кимерү» ди. Каерыны куптарып бетергәч, барыбыз да бергә утырып ботка ашыйбыз. Кашыклар да бабайныкы. Кашык җитмәгәннәр йомычка белән тырыша. Ботка — безнең эш хакы. Шул буа янында минем Мансур абый Мөхми Равиленә нәрсәдер каршы әйтте бит.

— Һәй, Пис — сер! Әле син шулаймыни-и! — диде дә, Мансур абыйның яр буенда яткан күлмәген, майка, чалбарын алды да суга ыргытты. Артыннан ук үзе сикерде дә, барысын да су төбенә батырып чыкты. Минем абый анадан тума яр башында басты да калды. Су болганчык, бернәрсә күренми. Тотындылар малай-шалай чумып эзләргә. Берсе-бер әйбер таба алмый. Шуннан соң Рашат абый төште дә, чумып-чумып эзләп, бөтен әйберләрне табып бирде...

Равил белән Рашат икесе дә сугыштан исән кайттылар. Тик Рашат абыйның сул кулының ике бармагы юк. Хәзер үзе дә юк инде. Эчеп... нык эчеп китте бу дөньядан. Бик йончып.

Сугышка кадәр, сугыш вакытларында, илленче еллар башына кадәр — урамда алардан да ярлы кеше булмагандыр. Кышын кияргә киемнәре дә юк иде. Безнең өй яны — бәләкәй генә калкулыкның түбәсе. Ат юлыннан кыш көннәрендә без шуннан чана шуабыз. Безнең чаналар шуып төшеп, Сәмүсә Биктимерләренә кадәр барып җитәләр. Шау-шу күп. Чыр-чу килеп, без шул «тауда» көннәр буе кайнашабыз. Чаналарга төялеп тә төшәбез, бер-берсенә тагып та шуабыз. Минем Гариф абый кебек зурлар оештыра шунда шууны. Мөхмиләрнең дә бик тә шуасылары килә. Тик киенеп чыгарга барысына да берьюлы кием җиткерерлек түгел. Ә урамда кар, суык җил. Менә шул чакларда алар капкасыннан чана тарткан бер гәүдә күренә. Ул, күбесенчә, Равил була. Тиккә әйтмиләр бит — көчленеке замана! Ул, нәрсә бар шуны киенгән дә, шуарга чыккан. Башта, өстә, аякта — нәрсәләр генә киелмәгән. Бар да бар. Сәләмәдән булса да, суыкка каршы торырлык. Чана өстерәп ярты юлны тауга карап узгач, Мөхмиләр капка төбендә яланаяк, яланбаш берсе пәйда була. Куллары белән үзен-үзе кочаклап, бертуктаусыз яланаяклары белән карда сикергәләп, ул чана өстерәп калкулык башына үрмәләгән абыйсын күзәтә. Чана тартканы, Кытыйка Сабурларның өен үтүгә, шул капка төбендәге яланаяклы малай үзләренең өй тәрәзәсе ягына кул болгый. Шул ук мизгелдә Мөхмиләрнең җил капкасыннан эреле-ваклы мөхмиләр йөгерешеп чыгалар. Барысы да яланаяк, яланбаш, күлмәк-ыштаннан гына. И тотыналар урам буйлап, чана тарткан абыйлары артыннан йөгерергә. Тегесе үр башына менеп чананы боруга, барысы да җанфәрман тупырдашып, йөгерешеп килеп җитәләр чана янына. Килеп җитә баралар, эченә күп итеп салам тутырылган чанга тула да башлыйлар.

Алар бер өер булып, иң кечеләре Мансурны күтәреп, Тәлгатьне житәкләп йөгерәләр. Берсен-берсе ташламыйлар. Күбесенең кулларында кыска гына таяк. Чанага кереп тулалар да, барысы да куанып кычкырып, тау башыннан кузгалып китәләр. Көймәдә ишкән кебек, таяклары белән каты юлдан этенәләр. Шау-шу тагын да көчәя. Мөхмиләр чанасы кебек күңелле һәм еракка шуа торган башкача чана юк урамда. Сәмүсәләрне узып китеп, чана туктауга, таралган борчак бөртекләре кебек сибелешеп төшәләр дә, яланаяк кардан, өйләренә йөгерешеп кереп китәләр. Яланаяк, яланбаш...

Ник шуларның берәрсе авырсын да, ник ятсын температура дип.

Гәрәйнең тулы исеме — Мөхәммәт Гәрәй. Аның исемен мин тулысынча әйткән чагымда ни өчендер Кырым ханнары Гәрәйләрне исемә төшерәм: Сәхиб Гәрәй, Дәүләт Гәрәй...

Гәрәйне урамда Гуркий дип йөретәләр. Укыганда дөрес итеп Горький дип әйтә белмәгән өчен... Гәрәй абый мине балык тотарга өйрәтте. Шуңа нигезләнеп, балалар өчен хикәям язылган. Әзер көенә ята.

Пожарныйга күчкән елны бугай, мин, урам Эстәрле елгасына барып төртелгән җирдә, яр башында кармак салып утырам. Беренче тапкыр үз гомеремдә. Бернәрсә эләкми. Гәрәй абый минем янга килеп утыра.

— Эләгәме?

— Юк.

— Чиртми дәмени? Тәләкәң кая?

Мин чиртүнең, тәләкәнең нәрсә икәнен белмим. Шунлыктан дәшмим. Миңа әле дүрт яшь чамасы гына. Белмәгән әйберләр белгәннән күбрәк.

— Кая бир әле, кармагыңны карыйк.

Минем ризалыкны көтмичә, нечкә талдан үзем кисеп ясаган кармакны минем кулдан ала да судан җебен тартып чыгара. Кармак кечкенә, чуаш җебе белән тал очына бәйләнгән.

— Челәүчәне юк бит моның, шуңа чиртми дә ул.

— Нәрсәгә ул челәүчән?

— Балык су астында челәүне күреп, аны ашарга дип килә дә, челәү белән бергә кармакны да йота. Шуннан китәргә итеп йөзә башлый. Шул чакта тәләкә бата. Тартасың да аласың балыкны...

Челәүгә «лач»итеп төкерә дә, сул кулы белән җептән тотып, челәүчәнле кармакны суга ыргыта.

— Тәләкә балык челәүне ашый башлаганны белер өчен кирәк. Менә карап тор, хәз-зер бата башлый ул. Бат дисә...

Сүзен әйтеп тә бетерә алмый, тәләкә батып, су астына төшеп юк була. Яр башында үземә урын таба алмыйча, мин акырам:

— Тарт, Гуркый, тарт!

Гәрәй абый кармакны тиз генә судан тартып ала. Тик анда бернинди балык та, челәү дә юк. Ул ризасызлыгын белдерә:

— Ния шул хәтлек акырасың син, Писер баласы. Куркыттың бит балыкны, акырып. Әнә түбәтәеңнән челәүчәннәрең кача...

Мин кичен, уннан артык балыкны түбәтәй эченә тутырып, балыктан кайтып барам! Балыкларның тик икесен генә үзем тотсам да, өйгә кайткач, барысын да үзем тоттым, дип сөйлим. Бер көн эчендә «балыкчы» булалар икән ул! Беренче тапкыр балык тоткан көнне үк мин чын балыкчыга әйләнеп кайттым. Ул «авыру» белән гомер буена авырдым. Элекке Союзның кайсы елгаларында гына балык тотарга туры килмәде. Шулай булса да, минем истә һәрчак мине балык тотарга өйрәткән Гәрәй абый саклана.

Гәрәйдән ике яшькә кече энесе Сәлимгәрәй. Без аның белән, мин унны бетергәч, 1950—51 елларда колхозда бергә эшләдек. Ат белән йөреп. Кайбер малайлар минем ун сыйныф белем алып та ат белән йөреп, колхозда алар белән бергә эшләп йөргәннән көләләр. Нигә этләнеп укып йөрергә, безгә барыбер колхоз! Ә Сәлимгәрәй көлми. Без бергә эшкә

китәбез. Яланда бергә печән төйибез. Ул мине ничек итеп эләкмичә урлашырга өйрәтә. Ә шунсыз яшәү мөмкинлеге юк — колхоз «труд»ка бирми. Уртак алып, урман кисәбез. Алып кайткан утынны йорттан гына сатып җибәрәбез. Базарга алып чыксаң, финагент утынга налог сала. Кичләрен кызлар янына аулакка китәбез. Безнең мунча бар. Сәлимнең әнисе Мәрхәбә апа бәләкәй чана белән тартып алып килеп, атна саен мунча яга. Утын күп. Рөхсәт белән алган алты кубометр урынына без Сәлим белән кыш буена Баранcки урманыннан утын ташыйбыз. Әти барып урман караучыны бер тапкыр эчереп кайткан иде, ул безне «күрми». Очраганда исәнләшәп тә китә әле өстәвенә. Дөнья барыбер үзенекен итә ул!

Сәлимнәрнең өй эчендә фәкыйрьлекнең дә аръягындагы фәкыйрьлек. Ябынырга юрган, баш астына мендәр юк. Равил белән Рашат абый һаман армиядә. Гәрәй абый да. 1951 елның апрелендә, куана-куана, Сәлимгәрәй дә армиягә китә. Өстендә иң сәләмә киемнәр. Аякларында юкә бау белән аркылыга бәйләнгән, икесе дә бер аякныкы булган зур эрзинкә галушлар. Сәлимгәрәй армиягә киткәненә бик тә шат. Чөнки ул анда, солдатныкы булса да, беренче тапкыр яңа киемнәр киячәк. Тамак тук, өс бөтен булачак...

Илленче еллар уртасында ялга кайткач, Сәлим мине эзләп безгә керә. Кочаклашып күрешәбез. Минем алда Рашат абыйга тартым, бик чибәр егет басып тора. Аулакка барсак, аның кашларына һәм балкып торган елмаюына кызлар һәрчак кызыгалар иде. Мөхмиләрнең Равил абыйдан башкалары бар да авылда. Армиядән кайткач, берсе дә колхозда эшләми. Аларны авыл советына, прокуратурага чакыртып куркытып та карыйлар. Тик Мөхмиләр, ярлылыктан, куркудан үткәннәр һәм кайсысы кайда конюх, йөк төяүче, складта һәм теләсә нинди эштә йөриләр. Алар бар да «армиядан акыл утыртып кайтканнар», «хуҗалардан куркудан» узганнар. Гәрәй, Сәлим, Тәлгать — паспортсызлар.

Тормыш һәрчак фаҗигале. 1965 елның февраль буранында Сәлимгәрәй, буранда адашып, туңып үлде. Энесе Тәлгать сөйләвенчә, ул болайрак булган.

— Бальниста эшләгән Мәрьям исемле бер врачны Сәлимгәрәй абый Эстәрлетамакка алып киткән. Бальниста конюх иде бит. Атлы чана белән. Үзең беләсең, Николаевканы чыккач, 25 чакрым калага хәтлек бер авыл да юк. Сугышка хәтле иске кала юлы Эстәрле елгасының сул ягы белән барган. Анда өч авыл бар. Николаевканы узгач та дала башлана. Казакъ ягыннан һәрчак көчле бураннар уйный ул тирәләрдә. Шунда каты буранга эләккәннәр өйләдән соң. Адашканнар болар. Байтак буталангач, Сәлим абый әйткән теге врачка:

— Син тавыш биреп тор, шушы урыннан кузгалма. Мин уратып йөреп юл эзлим. Ерак булмаска тиеш ул.

Башта җил уңаена китеп, аннан соң җилгә каршы якка чыгып, юл эзли башлаган. Мәрьям тавыш биреп утыра икән. Берникадәр вакыт узгач, Мәрьям карлы буран аша күреп калган: әле Сәлим бармаган яктан бер атлы юлчы узып бара икән. Мәрьям, атына суккан да, шул атлы артыннан Сәлимгәрәйне ташлап киткән дә барган...

Сәлимгәрәй, япа-ялгызы шул далада йөреп, чана туктап торган җиргә килеп, шунда туңып үлгән. Кәкерәеп, утырып туңган...

Бу ел кыш кайтуда абыйның капка төбендә кар көрәп йөрим. Иртән иртүк. Яңа гына яктырган. Бик шәп ат җигеп, чанага «егетләрчә баскан» Мөхми Гәрәе килеп чыкты. Атын минем янгарак туктатты да чанасыннан төште. Авызы ерык.

— Трр! Кая басарга белми хайванкай! Кая, Зәки, мин бу мәхлүк җанны бәйлим инде, югыйсә тик тора белми ул. Аннан күрешербез.

Атын бәйләп куя да минем белән, аннан соң капкасыннан чыгып килгән абый белән ике куллап исәнләшә. Картаеп баруыма карамастан, минем аркамнан, малайларны сөйгән кебек итеп, шапылдатып ала кулы белән:

— Синең кайтканны улым Мансур күргән. Кызлар янына иянәште, машинник малай. Куна калган, ахрысы. Кайтып килгәндә шул сине күреп кайткан. Көрәк күтәргән, ишек алларында йөри Мансур абыйларның ди. Теге, язучы Зәки абый кайткан, ди. Башкалар килгәләгәнче, йомыш белән килеп життем сиңа...

Сораулы күзләрен миңа текәп басып тора. Сорарга килгәч, сорар — мин, дәшмичә, елмаям: Мөхәммәт Гәрәй абыйның кыяфәте искиткеч эшлекле.

— Син китапларыңны алып кайттыңмы?

— Әйе.

— «Сугыш алды малайлары» бармы?

— Бар.

— Икене сорамыйм, берне генә бир инде син. Анда бит минем энекәш Сәлимгәрәй турында да бар икән.

Куанычтан ялтыраган ике кара күзен миннән алмый.

— Мактыйм әле үзеңне. Бер утыз ел бар инде, бер нәстә укыганым юк иде. Шуны абыеңнан күреп алып, күрше Катык Габделхәй белән бермекләп укып чыктык. Икәүләшәп. Укыйбыз, укыйбыз да, эй, китәбез ыспурлашып. Аңарда да өч класс бит инде, миндә дә өч. Гыйлемягы икебезгә алты класс... Безнең урам малайлары турында бит. Нигъмәт турында укыганда яшь ага күздән — тыеп булмый. Без солдатта чакта аткан бит аны яшен.

Үзе йомшак, матур итеп елмая, үзе сөйли:

— Ул китапта Катык турында да бар. Гызыниса әби аның карт әнисе бит. Теге им-том итә торган әби. Габделхәйгә кергән идем. Кит, Гуркый, ди, Зәкидә синең генә кайгың бармы, ди. Китап яза торган язучының вакытын алып йөремә, ди. Юк, мин әйтәм, барам, сорыйм бер китап, алам. Үзебезнең малай ул, дим. Катык әйтә, бирсә миңа да сора ди. Бирмә аңарга. Өйдә ятып кына китаплы булырга итә. Миннән сорап укысын әле...

Мин китап алып чыгып, исемен язып аңарга истәлеккә тоттырам. Ул, уен сүзләрен туктатып, житдиләнә.

— Син яз күбрәк, Зәки. Үзебезнең авыл турында яз. Безнең нужа, фәкыйрьлек, михнәт күргәннәрне кем дә булса язарга тиеш бит инде. Шулай бит?!

Китапны куенына кыстырып, атын чишә дә, жәһәт кенә чанасына сикереп менеп баса. Аты шунда ук кузгала да жилдәй юкка чыга...

## «Сиксән Күз»ләр

Мөхмиләрдән аста — кечкенә өй. Ул безнең урамдагы иң бәләкәй йортларның берсе. Хужасы Бәхтияр Мәжите урамча — Сиксән Күз Мәжите. Ләкабе — сирәкләрнең сирәге булып, иң кызыклыларның да берседер дип уйлыйм. Балалары: Миңлегали, Равил, Рәфкать, Миңлегөл. Миңлегали, олы малае сугыштан кайтмады. Башкалары исәннәр, авылда яшиләр.

Мәжит абзый авылда оста булып дан тоткан кеше. Сугыш елларында ул Югары Очтан, тыкрык эченнән Латыйф бабайның йортын сатып алды. Шул авыр елларда йортының чоланында он тарта торган кул тегермәне ясады. Ат чапкычының шестерняларын кулланып, бәләкәч кенә ике ташлы, бер кеше әйләндерә торган кул тегермәне. Ап-ак, вак кына он коела мөшкәсеннән. Игенне сала торган жирләре, шомартып, тактадан ясалган. Инде агылды халык шул тегермәнгә. Ә чират бер вакытта да ике-өч кешедән артмады. Минем белән бер елгы Равил шул тегермәнне, мыш-мыш килеп, автол белән майлый, онның эрелеген көй-

ли, гәрнич ала. Анысы — тарткан өчен түләү. Су тегермәннәрендә гәрнич ун кадактан бер кадак алына торган иде, ә кул тегермәнендә, үзең әйләндергәнне исәпкә алып, егерме кадакка бер кадак. Агач түгәрәкләргә ватык казаннан чуен кисәкләре кагып эшләгән ярма яра торган кул тегермәннәре йорт саен. Ә он тарта торган кул тегермәне бөтен авылга берәү генә. Безнең өчен иң кыйммәтлесе — тегермәннең мөшкәсеннән ап-ак, җылы, тәмле исле он ага.

Ярты ел тирәсе эшләгәч, финагент Чолык Зәйнәбе белеп алган кул тегермәне турында. Ярдәмчесе Чуаш Каримовны җибәргән тикшерергә. Теге килгән, караган да Мәҗит абзыйга әйткән:

— Мәҗит абзый! Син ике көн эчендә бу бик тә асыл тегермәнеңне юк ит. Сүтсәң сүт, читкә озатсаң озат. Ике көннән мин керермен акыт төзергә будты өстеңнән. Килештекме?

— Ярар, энем, рәхмәт сиңа кешелеклегең өчен!

Күптән сорап йөргән, калада яшәгән Пәрәү Абдулласының малае Хәйбуллага бер сыер бәрабәренә сата тегермәнне Сиксән Күз Мәҗит.

Озак та тормады, Мәксет авылы очындагы безнең колхозның чын тегермәненә китте Мәҗит абзый. Аның тегермәне иң шәп язгы ташкын вакытларында да туктамый, буасы ерылмый... Без шул тирәдә балыкка барган чакта тегермәнгә керәбез. Равил — безнең урам малае, безгә катык ашата, күп итеп ипи телә. Үзе безгә тальян гармунда уйный. Миниямал әбинең үлгән ире Бәхтегани бабай белән Мәҗит абзый бертуганнар. Ятим өч балага, Миниямал әбигә Мәҗит абзыйның ярдәме зур булды...

Җитмешенче ел урталарында Равил белән бер табында очраштык. Яшь кенә бер егет кисәге тальян гармунны «этли». Тик уйнаган көйләре «барып җитми», тиешенчә моң чыкмый. Ә без үскәндә сабан туйларында Равил уйный башласа, барлык халык аның янына җыйнала торган иде. Табында Равил дәшми-тынмый минем эргәдә утыра. Эчә, ашый, тик бер дә сөйләшми диярлек. Мин өстәл аша гармун тарткан егеткә үреләм:

— Бир әле гармуныңны, энем!

Гармунчы, куанып, каешын сала:

— Яңа гына алган идем, өйрәнчек кенә әле мин. Син, абый, әллә уйный беләсеңме?

— Беләм, беләм. Бир генә гармуныңны.

Гармунны алып Равилгә тоттырам.

— Әйдә, дус! Тарт әле шушыны! Искә төшерик яшь чакларны!

Равилнең хатыны иреннән алда «телгә килә»:

— Юк, юк, уйнамый! Инде яше кырыкны узган. Уйнаган яшь чагында, җиткән!

Равил, гармун каешын җилкәсенә кигәндә, пышылдый:

— Тик кенә утыр!

Хатын елмая да тына. Исеме Фәния. Югары Оч Өтек Вәлинең кызы. Ул абзый Нәби абый белән бертуган. Мин канәгать: өйләрендә чын хуҗа бар икән боларның!

— Бармаклар гел балта тотып катканнар инде. Кая, баскалап карыйм әле азрак. Байтактан бирле уйнаган юк. Эш тә эш...

Азрак баскалап, гармунга көйләнә дә сузып җибәрә.

Осталыгы нәкъ элеккечә икән. Өздереп, өздереп уйный Равил. Табын тына һәм барысы да бу көтелмәгәннән килеп чыккан чын татар көйләренә сихерләнеп тыналар. Равил азрак уйнагач та табындагылар гармунга кушылып җырлап җибәрделәр. Бик күңелле кичә булды.

Табын уртасында, кәефе азрак кырылып, авызын чак кына бөрештереп утырган хатыны Фәния, иренә карап-карап алды да, аннан соң бер ноктага күзләрен текәп, нечкә генә моңлы тавыш белән:

— Җәйләүләргә — ә бардым, биялә — әр саудым...— дип, җырлап җибәрмәсенме! Сезнең чамалаганыгыз бармы? Безнең татар табыннары-

ндагы итагатьле, инсафлы татар хатыннарының бер генә ноктага карап, шуннан күзләрен алмыйча җырлаганнарын? Моңланып җырлаганда, тирә-якка карарга яратмый алар!

Бу ел җәй кайткач, Равил белән тагын очраштык. Ясаклы урамында килеп кочаклап алды:

— Мин сине иртәннән бирле эзлим инде. Бүген кич сигезгә безгә кунакка кил. Тальян да бар минем. Утырырбыз яшь чакларны искә алып, гармун уйнап...

Төнге өчтә генә таралыштык. Ул очрашуны аерым әсәр итәргә кирәктер. Шунлыктан монда язмаска булдым.

## Шәкүрә

«Сиксән Күз» Мәҗитләрдән ас якта Шәкүрә апа яшәде. Ул апа күрше урамда яшәгән Шиһаб бабай белән Мәликә әбинең зур кызлары. Шәкүрә апаның миннән ике генә яшькә кече Әнвәр исемле улы бар. Әнвәр Шиһаб бабайга койрык булып тагылып йөри. Кыш көне Югары Оч төпкелендә урман кисәбез. Кар күп. Агачның төбе озын булып калмасын өчен, казып төшәргә кирәк. Арып-талып, хәл җыярга утырабыз. Ирләрнең күбесе тарта. Шулар арасында тәмәке пыскытып утырган кечкенә гәүдәле Шиһап бабай да бар. Төргән тәмәкесен яртылаш суырып бетерүгә, янында утырган Әнвәр телгә килә:

— Әтк — әй, бетерәсең бит! Миңа калдыр инде — е.

Кордашлары, ир-атлар арасында Шиһап бабайга оныгының «тәртипсезлеге өчен» уңайсыз. Ул дәшми генә уздырып җибәрергә тырыша. Әнвәр тынмый:

— Әткә — әй, ди — им! Калдыр инде — е, әткә — әй!

Ирләр, авызларына тәмәкеләрен капкан булып, елмаюларын яшерәләр. Тәмәкесе, гәҗите, шырпысы булган зур күн янчыгын Әнвәргә тоттыра Шиһап бабай. Әнвәргә 11—12 яшь чамасы.

— Бар, бар! Кит моннан! Күренмә күземә! Бар, әнә үзең чокыган чокырыңа төшеп тарт! Оял кешедән!

Үтә дә миһербанлы, йомшак холыклы иделәр Шиһап бабай белән хатыны Мәликә әби. Алар безнең тыкрыктан Шәкүрә апага еш кына баралар. Тыкрык читәннәре өстеннән Мәликә әбинең зур, чибәр гәүдәсе океан пароходы кебек салмак кына чайкалып бара. Аның янында 14—15 яшьлек малайлар гәүдәсе кебек кенә буйлы Шиһап бабай тиз-тиз итеп атлый. Шулай булуга карамастан, гаиләләрендә аз сөйләүче, эшчән Шиһап бабай баш. Шәкүрә апа чибәр. Ул сугыштан соң ике тапкыр иргә чыгып карады да, булырлык булмагач, Урта Азиягә чыгып китте.

Хәзер ул йортта күрше урамнан күчкән Катык Габделхәй яши. Аның әнисе Гайникамал апа — Танау Гарифның бертуган сеңлесе.

## Галләм абзый

Галләм абзый дөньядан киткәнгә дә ике ел тулып узды инде. Ул дүртенче елгы иде бугай. Әтисен мин белмим. Аны 1928 елда ГПУ алып киткән. Әнисе — бик нык юан әби. Авылда ләкаб-исеме Фәкыйрь Түшәге. Галләм абыйның акылга саерак апасы да бар. Исеме Гобәйдә. Галләм абый сугыштан соң, «картая башлагач кына» өйләнде. Ул пенсиягә киткәнче, клубта эшләде — билет тикшерде. Әнисе белән апасы юрган сырдылар, бишмәт текteләр. Шулай өчәү дөнья көтте алар.

Галләм абый авыл артистларының берсе һәм зурысы иде. Ул сугышка кадәр клуб мөдире булып эшләгән, колхозның беренче трактористы,

авылның беренче комсомолы, беренче режиссеры, беренче рәссаме, беренче артисты булган Зариф мәгъзүмнең улы Гали Тукайның дусты, көрәштәше. (Әти мәрхүм сөйләгәннән)... Авыл байлары, ишаннары, мәдрәсә мөдәррисләре, сәүдәгәрләр булган Тукаевлар ярлы-ябагай һәм сәләтле балаларны җыйнап, бер йортта асраганнар. Шунда аларны ашатып, киендереп, мәдрәсәдә урысча да укыта торган булганнар. Галләм абый шул укуларны узган шәкертләрнең иң соңгысыдыр... Галләм абыйның дусты Гали Тукай чыгышы белән мәшһүр Тукай бабай нәселеннән. Тукай бабай, Риза Фәхретдиневнең язмаларына караганда, XVII гасыр азагында хәзергә Татарстанның Балтач районындагы Салавыч авылыннан чукындырудан качып чыгып киткән. Тулы исеме Тукай Әл-мәшһүр Биктә хәзрәт. Эстәрлебашка килеп төпләнгән.

Эстәрлебаштагы нәселенең бер генә чыбыгы: Тукай — Биктимер — Нигъмәтулла — Харис, Харрас — Мөхәммәт Шакир. Болар бар да Эстәрлебаш авылы мәчете имамнары һәм мәдрәсәсенең мөдәррисләре.

Гали Тукай Зариф мәгъзүм улы шушы аталы Тукай бабай нәселеннән. Мин үскәндә, сугыштан соң да әле, Гали абыйның авылда әнисе, сеңлесе Гөлсем апа исәннәр иде. Бүгенге көнне Гөлсем апаның улы Марат Эстәрлебашта яши.

Гали абый — авылның иң зур талантларының берсе. Авылда, ул мөдир булган колхоз клубыннан башка, элекке зур мәчет бинасында урнашкан Сталин исемендәге район клубы да бар. Тик сугышка кадәр барлык куелган пьесалар колхоз клубында уйнала. Артистлар бар да авылныкылар. Гали абый бермәкләп җыйган талантлар. Минем истә калганнары: Галләм Мостафин, Абдулла Рафиков (Пөштәри), Мәрхәбә Насырова (Гали абый хатыны), Сәйфулла Музагитов, Зәкия Саттарова, Мөршидә һәм ике Сәрвәр апалар, Факия Харисова, Бану Вәлиева, Шиһап бабай Әхмәте, Әптә Минниәхмәте һ. б.

Эстәрлебаштан Башкортстанда киң танылган өч халык артисты чыкты: Хәй Фәхриев, Шамил Рәхмәтуллин, Риф Музагитов. Соңгысы — алда язылган Сәйфи Музагитовның бертуган энесе. Куелган пьесалар: «Чик буенда», «Көнлекче Әхмәт һәм аның чибәр хатыны», «Шәүрә», «Чаткылар», «Банкрот», «Галиябану», «Беренче театр», «Серле казна». Шуның өстенә җырлар, биюләр һәм Абдулла Рафиковның сәхнәдәге клоунлыгы. Боларның барысын да сугышка кадәр Гали абый оештыра, ә сугыштан соң — Галләм абый белән Абдулла Пөштәри. Рафиков Абдулланың клоун исеме ул Пөштәри.

Гали абыйның һәлак булуын безнең авыл Самат абый сөйли:

— Воронеж каласында биш катлы йортның иң югары катында алты кеше бер бүлмәдә яшибез. Гали Тукай да безнең белән. 1942 ел. Донның теге ягында немецләр, бу ягында без. Ашарга утырганда, Гали Тукай гелән генә бер урынга — мөешкә утыра. Бер көнне соңга калып кайтты бу. Мин ул юкта аның урынына утырам. Янәсе, үртим инде тегене. Кайтты да минем колактан өстерәгән кебек итә. Тор, ди. Син әле ди, Гали Тукай урынына утыра торган кеше түгел. Тәһарәтеңне тиешенчә итеп ала белмисең, ди. Үзе көлә. Авызының аскы ирене чыгып тора иде азрак алга. Утыртты бит тәки күчереп. Сизми дә калдык — немец самолеты шул чакта бомба ташлаган булган. Гали абый утырган мөешне китте дә алды теге бомба. Гали абый белән бергә мөеш китеп бара, китеп бара, безнең күз алдында... Талпынды бахыр торырга, булдыра алмады. Төшеп киткәндә, хушыгыз, егетләр, дип кычкырды. Төшеп карадык, эзләргә дип. Кая ди ул табу — кирпеч ватыгы икенче катка хәтле ята өелеп...

Сугыштан соң Сталин клубында үзешчән түгәрәк оешты. Аны, әйткәнемчә, Галләм абый белән Абдулла Пөштәри алып бардылар. Пөштәри плен узган кеше. Аңарга, үзе әйтмешли, «худ юк».

Галләм абзый безне киноларга кертмичә иллә дә этли торган иде. Ямаулы бишмәтләр, чабаталар, төпле пималар кигән бер көтү малай

клуб ишеге төбендә таптанабыз. Беребездә дә акча юк. Ә киногa керәсе килә. Безнең сорануга Галләм абыйның сүзе кыска:

— Барыгыз, бар кайтыгыз өегезгә! Әниләрегез ыштаннарыгызны юсын. Барыгыз, югалыгыз күземнән...

Әгәр инде кәефе әйбәт чак булгач, кино башлангач, безне өеребез белән кертеп җибәрә. Без, тавыш чыгармыйча гына алга узып, идәнгә тезелеп утырабыз.

Галләм абый кырыкны узып өйләнде. Хатынны Куганакбаштан алды. Балалары дүртәү бугай. Малны аз тотты. Мин аның печән чапканын, курмы ташыганын хәтерләмим.

Галләм абзыйның яраткан рольләре — татар байлары. Сугыш алдыннан, Гали Тукай белән парлашып, кызыл төрек фәсе киеп йөргәннәре исемдә. Фәс киеп төшкән фотолары да бар миндә.

Галләм абзый Мөршидә апа белән еш кына «Җизнәкәй»не башкаралар. Галләм абзый калын бас тавыш белән, ә Мөршидә апа нечкә генә моңлы тавыш белән ул шаян җырны үтә дә зур тырышлык һәм осталык белән җырлыйлар. Халыкка аларның шул җыры бик тә ошый. Галләм абый белән Мөршидә апа сәхнәгә чыга башласа, залда утырган халык үзеннән-үзе елмая башлап, шунда ук кул чабарга тотына торган иде. Яраталар иде ул «артист»ларның икесен дә.

Галләм абый холкының тагын бер ягы бар. Ул, азрак колакка каты булганнан, күрәсең, суфлерның сүзләрен ишетеп бетерми иде. Шунлыктан, рольләрен ятлап ала һәм беркайчан да суфлер нәрсә әйтер икән дип пошаманга бирелми торган иде.

Сугыштан ул ике култык таягы белән кайтты. Сугыш беткәнче аны янә алып киттеләр. Тик ул, ай узар-узмастан, кире кайтты. Соңгы елларында тагын шул таякларын кулына алды...

Галләм абый — Эстәрлебаш авылының егерменче гасыры өчен иң затлы артисты һәм авылның иң зур шәхесләренең берсе. Акча өчен түгел, авыл күңеле өчен көчен аямаган кеше булган ул.

Кайткан саен өе яныннан баш иеп узам...

## Шәйхелләр

Йорт хуҗасы Шәйхелислам исемле иде. Авылда аны, кыска гына итеп, Шәйхел Капар дип йөреттеләр. Малайлары: Сәббәхетдин, Вара, Хәйбрахман, Сәфәретдин. Шәйхелислам бабай да, улы Сәфәр дә 1943 елгы ачлыкта үлделәр. Сәббәх абый сугыштан соң берничә ел бригадир булып эшләде, аннан Эстерлетамак совхозына күченеп китте. Шунда җирләнгән. Шәйхел бабай һәм Вара абый үзләре сөйләгәннәрме, юкмы белеп булмады — тик авылда алар сүзе булып ике көлке йөри. Язмыйча түзеп булмый. Вара абый әрләмәс әле. Имеш, Шәйхел бабай сөйли:

— Салдатта чакта бер вакыт камандир рут чакыра. Сорый: «Син, рәдәвәй Рафикыф, мунчада бик каты чабынасың икән!?» Чабынам, мин әйтәм, нык чабынам. Бер себерке җитми, икәү белән йөрим. Тыңлады да, алып китте бу мине икенче көнне фаютун белән. Әйтә миңа: «Николай патшаны чабып, себерке белән инде, бер кеше үткәрә алмый. Давай, син чабып кара.» Ярар, мин әйтәм, була ул. Мин авылда чакта Дөя Хәсәнне чабып та үткәрә торган идем, дим. Кердек Николай патша белән мунчага. Башына бүрек кигән бу, кулында йон бияләйләр. Калганы ялангач, анадан тума. Чаптым тек чаптым инде патшаны. Сөйләшү-нитү юк, бу күрсәтә генә кайсы җирен чабарга икәнен. Шул. Өчерәт хәл җыя-җыя чаптырды бу, әй. Хәл бетәргә итә итүен, тик туктамыйм, чабам тегене. Төшеп чүмечләп салкын су эчә дә тагын менеп ята. Миңа маладис, ди,

рәхмәтен кызганмый. Шуннан, мин чабып беткәч, моның аркасын ышкып, коенып, киенергә чыктык. Атка утырып, фаютун белән тәүдә мине казармага китереп куйдылар, аннан соң патша хәзрәтләре китте кайтып. Кич йокларга ятарга дип чишенә башлаган идем, бөтен казармадагы салдатның күзе миндә. Ни өчен дисәгез, Никалай патша белән кальсуннарны алмашып кигәнбез ялгышып. Миндә менә дигән ефәк кальсун. Ә минекен салдат кульсунын Николай патша кигән. Икенче көнне бер зур гиниралы килеп, алмаштырып алып китте»...

Малае Вара исә болайрак сөйли:

— Бик соңлатып, иптәш Сталинны алып кайтып киләм лигкавай машина белән. Кайтып җитәргә байтак ара бар. Бер сәгать кирәк булыр. Кууын куам инде машинаны, тик Кримелгә хәтлек ерак бит. Шуннан Мәскәү каласының бер урамыннан икенчесенә борылып бара идем, юл читендә берәү кул күтәрә. Карасам, иптәш Варашилов. Шлемын кигән, озын шинил моның өстендә. Кылычын да таккан. Туктадым. Сталинны күрде дә, дәшә: «Иптәш Сталин, Кримелгә хәтле алып кайтыгыз әле?!» — ди. Сталин бик текәлеп карады да тегеңәргә, кабаланмый гына әйтте:

— Если таварищ Вара вазмет, только тогда садис!»..

Вара абый сугыштан исән-имин кайтты. Зират күперен чыккач, сул якта ялгыз утырган йорт — аныкы...

## Пүликәр Касыйм

Шәйхелләрнең ас ягында Пуликәр Касыймы яши. Өченче сыйныфка кадәр бергә укыдык. Без урамнан өч малай бергә идек: мин, Җомай Габдрахманы һәм Пүликәр Касыймы. Касыйм әле дә шул урында яши. Гомере буена колхозда ат белән йөреп эшләде. Ат белән килгән җиреннән каршы очраса, үзең исәнләшсәң исәнләшә, үзең исәнләшмәсәң — юк. Йорты төзек, дөньясы бөтен. Әтисе сугышта ятып калды. Авылда бердәнбер энесе Зөфәр яши. Картәтисе Гапкадыйр Пүликәр нигезендә ул.

## Урыслар

Касыймнардан аста урамдагы бердәнбер урыс гаиләсе яшәде. Башта алар Бүре Сабурының кечкенә таш өендә тордылар. Сугыш алдыннан, әтиләре үлгәч, Касыймнар ягына күченеп утырдылар. Балалары: Мишка, Маруся, Генка. Соңгысы безгә яшьтәш иде. Татарча шәп итеп сөйләшә белә, җырлый, иптәшлеккә дә бик әйбәт иде.

Урысларның өй эчендәге шакшылыгын мин беренче тапкыр шул Генкаларның өенә кергәч күрдем.

Илленче еллар башында Маруся аларны Эстәрлетамакка күчендереп алып китте. Ул анда йөк машинасында шофер булып эшли иде...

## Гомәр бабай

Ул бабай бик аз истә калган. Бүгенге көндә аны авыл да онытып бетерде диярлек. Гомәр бабайның улы Сафа абый 1920 елда Перекопны алганда күрсәткән батырлыгы өчен сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән кеше. Районның паспортлар бирә торган

жирендә эшләде. Соңгы елларда капитан дәрәҗәсендә йөрде. Бик юаш кына, күп сөйләшмәс абый иде. Кызыл бант өстнән ныгытып куйган Кызыл Байрак орденын зәңгәр милиция гимнастеркасы тагып йөри. Балалары бик күп булып, сугыштан соңгы авыр елларда гаиләсе белән Ташкент якларына чыгып китте.

Бертуган энесе Ибәт абый Гомәров озак еллар «Эстәрле» колхозында комбайнчы булып эшләде.

Минем хәтеремдә калганы: Гомәр бабай зелпе тамыры кабыгын һәм тал каерысын әзерләп, хөкүмәткә сата торган иде. Аның ул шөгыле турында Мөхмиләр турындагы бүлектә яздым инде...

## Мәфрүзә апа

Укучы минe кыска бүлекләр өчен гафу итсен. Урамның бу түбән очында сирәк булдым, чөнки минем бу тирәдә дусларым юк диярлек иде.

Урамның уң ягындагы иң соңгы йортта яшәгән Мәфрүзә апа әле дә исән. Әнисе һәм ике малае белән яшәде. Малайлары Рәфкать һәм Рәис... Рәфкать Эстәрлетамак тирәсендәге Кала Утары дигән урында совхозда яши. Ул урын — безнең авылның элекке байлары Тукаевларның утары. Кече улы Рәис, бәләкәйдән үк күрше Ибәт абый белән бергә эшләп, бик шәп комбайнчы булып китте.

Мәфрүзә апаның ире Батыргәрәй абый безнең авыл аша 1918 елның җәендә узган Блюхер отряды белән киткән. 1920 ел азагында авылга исән-имин кайткан.

1938 елны, Блюхер һәлак булгач, Батыргәрәй абыйны да төрмәгә утырттылар. Ул аннан тик 1946 елны гына кайтты...

Мәфрүзә апаның йорты Эстәрле елгасына килеп терәлә. Аннан соң Күл башлана. Эстәрле халкы елга белән таллык арасында яткан ямьяшел аланлыкны шул исем белән йөртә. Күрәсең, анда кайчандыр зур күл булгандыр һәм Төрек күле шул күлнең калдыгы гынадыр. Күл — авылның Түбән Очындагы өч урамның бозау, казлар йөри торган урыны.

Без бәләкәй чакта, сугыштан соңгы елларда, Эстәрле елгасын Мәфрүзә апа өе янында буып, үзебезгә су керү урыны ясыйбыз. Күрәсең, безнең көне буе шаулаганнан туептыр инде, Мәфрүзә апа аны төнен казып ера. Иртән без тагын буабыз. Ул тагын ера...

Мәфрүзә апага урам аша Җиһанша бабай йорты урнашкан. Ул инде урамның сул ягындагы соңгы йорт.

## Җиһанша бабай

Җиһанша бабай азрак җирәнрәк сакал-мыеклы, эшләпәле бабай булып истә калган. Колхозда атлар карый иде. Хатыны яшь чагында бик чибәр һәм үткен булган. Шунлыктан авылда ул әбине Айгыр Хәдичә дип йөртәләр иде. Аларның Зифа исемле бердәнбер кызлары бар... Йортларының капкасы урамга түгел, ә тыкрыкка чыга. Зифа апаның ире Мөхәммәдияров Басыйр абый Югары Очныкы. Алар әле дә исәннәр. Инде ярыйсы гына карт әби белән бабай булып, шул йортта яшәп яталар.

Утыз җиденче еллар чамасында Җиһанша бабай күрше Олы урамда, Эстәрле елгасының сул як ярында япа-ялгыз утырган йортта яши. Без, дүрт яшь чамасындагы берничә малай, Хирахау Халите җитәкчелегендә каядыр китеп барабыз. Шул замананың ялан аяклы, бер нәрсәгә дә кай-

гыра белми торган ташбашлары без. Авылдан чыкканда, Зират күперенә житмәс борын Эстәрле елгасының уртасында кырчын ташлардан гына торган кечкенә утраучык. Шул утрауда чиләк юанлыгындагы бер өянке үсеп утыра. Өянкенең урта бер жирендә, ботаклар арасында Жиһанша бабай утыра. Ул анда баскыч куеп менгән. Шул ботаклар арасында аркылы пычкы белән теге өянкенең урта бер жирен кисеп маташа. Берүзе. Башында сырган эшләпә, күлмәк өстеннән кигән камзул, буйлы ыштан, оек-чабата. Без, ыбыр-чыбыр, яр башына басып, Жиһанша бабайның әллә нәрсә эшләгәненә карап басып торабыз. Бабай кеше агач башында утыра! Байтак телсез торгач, Халит телгә килә:

— Жиһан-ша-а бабай-ай!

Агач башыннан жавап авызы ишетелә:

— Әү, улы-ым!

— Ния кисәсең аны-ы!

Жиһанша бабайдан «улым» дигән сүз ишетеп, без сай гына суны кичеп, аның янына «утрау»га керәбез. Бабай кисүен туктата да, елмайган, матур йөзе белән безгә карап иелә. Кабаланмый гына, без аңларлык итеп сөйли:

— Агачның башын киссәң, ул күп итеп, шул кискән жирдән яңа ботаклар чыгарып, матур итеп үсеп алып китә. Ә менә бу агач гелән генә өскә үсә дә үсә. Киңәеп үскән ботаклары аз. Ә мин аның күп ботаклы булып үскәнен телим. Шуңа күрә башын кисүем...

— Ы-ы! — ди Халит, бер урында таптанып. Үссә ни була да, үсмәсә ни була?

— Менә исегездә кала инде хәзер, шушы агачның башын Жиһанша бабай кискәние дип. Үсәп житәрсез, солдатка китәрсез. Авылга сагынып кайтканда, авылга килеп кергән ыңгайга шушы өянке каршы алыр үзегезне, ботакларын жәеп, жилгә селкетеп. Иң тәүдә сез шушы өянкене сәламләрсез. Аңа карагач, мине дә исегезгә алырсыз. Онытмагыз мине, ул вакытта мин үлгән булсам да. Яме?!

— Ярар! — ди Халит, киң күңеллелек күрсәтеп. — Алырбыз искә, нәстәсе бар аның. Әнә бит утырасың агач башында...

Жиһанша бабай, кеткелдәп, чын күңеленнән көлә. Күзенә килгән яшьләрен жиң очы белән сөртеп ала да тагын пычкысы белән кисәргә тотына. Бераздан безгә яр ягына чыгып китәргә куша. Аннан соң тагын азрак кискәч, өянкенең башы шаулап елганың аргы ягына табан ава. Жиһанша бабай кабаланмый гына баскычтан төшә дә, агач төбендәге тимер чиләкне алып, кире менеп китә. Чиләктән кечкенә калай кисәге белән нәрсәдер алып, агачның киселгән жиренә сылый.

Сылап бетерә дә, куеныннан чәчәкләр төшкән иске бер чүпрәк алып, агачның сыланган жирен бәйләп куя. Чалма кебек уратып бәйли. Халитнең белмәгәне юк. Ул безгә чәчкәле чүпрәкнең нәрсә икәнен аңлата:

— Айгыр Хәдичә әбинең иске күлмәге ул.

Халитнең тагын да беләсе килә:

— Ния бәйлисең аны, Жиһанша бабай?

— Яңгыр яуса, юып төшермәсен, дип бәйлим, улым Халит.

Жиһанша бабай кабаланмый гына төшә дә, балта, пычкы ярдәмендә жирдә яткан агач башын туракларга тотына. Безгә кызык бетте. Халит безне каядыр алып китә...

Ни хикмәттер, шул көннән соң, кайда гына барып авылга кайтсам да, мин Жиһанша бабай өянкесе яныннан һәрчак аны искә алып уза торган булып калдым. Башын кисеп, бәйләгәннән соң ул агач ис китмәле булып, күп ботаклар чыгарып, үсеп китте. Авылда аңардан да матур өянке башкача юк иде.

Еллар үтте. Мин утыз алты елдан артыкка сузылган «солдат хезмәтенә» барып эләктем. Гомернең яртысыннан күбесе урыс армиясендә узды. СССРның «бөеклеге» өчен. Чит якларда, заяга!

Авылга кайткан чакларда, Зират күперен үтеп, килеп кердисәм, юлның уң ягында, Эстәрле елгасының уртасындагы, кечкенә, кырчын ташлардан торган утраучыкта ямь-яшел булып үсеп утырган өянке тора. Ул һәрвакыт мине сәламли: «Исәнме, Зәки! Кайттыңмы авылга?» Мин өянкене кайткан саен барлыйм һәм аның исәнлегенә сөенә торган идем... Тик, еллар уза-уза, өянке картайды. Башта яфраклары азайган кебек була башлады. Аннан соң кайбер ботаклары корыды. Бер кайтуымда... өянкене кемдер кисеп ташлаган! Утрау эчендә юан кәүсәсе генә ята. Ботарлап, кискәләп алып бетергәннәр. Урынында диаметры метрдан артык төбе генә сәрәеп утыра: Ходай Тәгаләдән бу дөньяда сезгә дә китәргә җыйнала башларга вакыт инде дигән берәр хәбәрдер инде безгә дә, кайчандыр яланаяклы малайларга...

Китәр алдыннан шул өянке урынына яңа өянке утыртырга хыялым бар минем. Мин дә Җиһанша бабай кебек бәхетле булып, минем өянке утыртканны вак кына малайлар карап торсыннар иде. Яланаяклы булмасалар да ярый...

Менә, мин үскән урам хикәяте язылды кебек. Түземлек күрсәтеп укыганыгызга зур Рәхмәт! Ходай сезгә саулыклар бирсен...

# ШИГЪРИЯТ



**Фәрит Габдрәхим**

## УРДА

Вакыт ага, дәрья булып ага,
Мәңгелекнең ярларына кага.
Әле алга дулкын, әле артка...
Кабатлана бу хәл әлмисактан.
Бер тарая Галәм, бер киңәя.
Буйсынадыр шуңа ук вә җәя,
Буйсынадыр шуңа ошбу дәрья.
Заманында дәрья бәргән ярга
Бабамнарның хакын хаклап куптым.
Күкрәк каккан өч йөз еллык дулкын,
Татар дулкыны ул — Алтын Урда,
Хәсрәт чәчеп, имеш, ялкын урган.
Ялган! Анда чиркәү тончыкмаган,
Кяфер булган өчен җан чыкмаган.
Йотмаган да Дулкын урыс илен,
Чоңгылларга атмаган ла телен.
Оятсызлар, мәшһүр Алтын Урда,
Гайбәт сата һаман синең турда.
Бер ел — бүдәнә, ди, бер ел — тартай
Симерә. Хак! Дулкын алга... артка...
Мең дә биш йөз... Алтын Дулкын чиккән,
Урыс дулкынына чират җиткән.
Җилкәненә җәллади җил җиккән,
Зольмәт-вәхшилеге ашкан чиктән.
Ярымайлар баткан, тәре арткан,

---

Фәрит ГАБДРӘХИМ (1933) — *Уфада яшәүче татар шагыйре, башкорт телендә басылган китаплар авторы. Татарстан матбугатында даими басылып килә.*

Татарларның кан вә яше аккан.
Тора-бара сусыз калган дәрья,
Кан-яшь кенә көн-төн бәргән ярга.
Илләр баскан гел-гел Урыс Урда,
Чын исеме булган Орыш Урда.
Дәрья тора гел хәмердән хәзер,
Сәрхуш Урда кемгә казый кабер?
Үзенәдер: дулкын чигә бугай,
Арчыладыр, әнә, безнең тугай.
Киңәя дә, тарая да Галәм,
Нинди Урда килер, нинди Әләм?

## «Дөрес юлдан барасыз, иптәшләр!»

Даһи һәйкәл — биектән дә биек,
Сузган кулын — бөектән дә бөек.

Инкыйлаби мәхшәр купканнан соң,
Ул — атасын суйды, ата — улын.
Тере даһи тәхетендә
шуны
хуплап торды, алга сузып кулын:
«Дөрес юлдан барасыз, иптәшләр!»

Без ашкынып бардык! Бер үк булган
Коммунизм белән ГУЛАГ юлы.
Даһи һәйкәл дәртләндереп торды,
Мәйданнардан сузып бөек кулын:
«Дөрес юлдан барасыз, иптәшләр!»

Коммунизм — офык. «Базар кирәк!» —
Күңелебез өмет белән тулы.
Раслап тора, хуплап тора таш сын,
Һаман тала белми икән кулы:
«Дөрес юлдан барасыз, иптәшләр!»

## Тот капчыгыңны!

Әҗәткә акча алалар,
Килеп алалар: кирәк!
Ләкин бурычын китереп
Бирүче генә сирәк...

Барганны тормыйлар көтеп,
Кулга алалар килеп.
Килеп алалар... Котылгач,
Өйгә куймыйлар илтеп.

Илне дә килеп алалар,
Илтеп бирүче сирәк.

Иленне, шәт, китерерләр,
Көтеп торырга кирәк.
Тот капчыгынны!..

## Оныкларга калдырабыз.

Уйлап тормый, кисеп-төпләп
Инеш-елга тирәкләрен,
Вәхшиләрчә җимердек без
Киләчәкнең терәкләрен.

Нефть-газны алыштырдык
Калҗа-икмәк кисәгенә.
Бардык «якты киләчәк»кә —
Оныкларның исәбенә.

Елышабыз Сталинга
(Көлемсери канлы явыз...)
Күңелдәге богауларны
Оныкларга калдырабыз.

Үткәндәге афәтләрне
Салышабыз онытканга.
«Әллүки»не коткаруны
Калдырабыз оныкларга...

## Ишетелә аваз

Казан ауган. Аскан-суйган катыйль,
Беркемне дә тормаган җәлләп.
Мәскәвендә, ерткычлыгын данлап,
Блаженный храмын салган җәллад.
Ишетелә аваз: «Кемнәр ватар,
Син ватмасаң аны, гаярь татар?!»

Һәйкәл тора Казан-су буенда,
Урысларның батырлыгын зурлап.
Үз җирендә кол хәлендә калган
Татарларны мәсхәрәләп-хурлап.
Ишетелә аваз: «Кемнәр ватар,
Син ватмасаң аны, гаярь татар?!»

Блаженныйлар, вәхши ул һәйкәлләр —
Яралары татар бәгыренең.
Җуйсаң, халкым, кадер-хәтереңне,
Шул ук көрәк казыр каберенне.
Ишетелә аваз: «Ватма, татар!
Хәтерсезлек киләчәгең таптар...»

## Килде заман

Жилли дөнья:
Жилләр инде
Исәргәме-юкмы, дими.
Бәреп чыккан чишмә: ташны
Тишәргәме-юкмы, дими.
Көннәр буе балкый: нурын
Чәчәр-чәчмәс тормый Кояш.
Эчтән генә көйләү житәр,
Жырлыйк әле, жырлыйк, кордаш.
Килде заман: хәлсез — ялган.
Чын фикерләр житте пешеп.
Өшиселәр бетәр өшеп,
Төшәселәр бетәр төшеп.
Әверелде сукмак юлга,
Аерылды биттән битлек.
«Явызлык» исемен алды —
Үз исемен — барча «этлек».
Туйганчы бер елыйк, кордаш,
Әйләнде ич яшькә сыкрау.
Шатланыйк без:
Халыкныкы
Булып чыкты безнең сорау.
Сихәтлерәк була бара
Кешеләрнең рәхмәтләре.
Елмаю гел эчтән житәр,
Көлик әле рәхәтләнеп!

*
* *

Бер ялгызы кайткан сыерчыгым;
Алыштырган чишмә ана телен;
Бик тарайды дөньям: бәхетемнең
Чикләгәнсең икән буен-иңен —
Һәркем тартеп ега ала мине...

Туган жирдә шатлык тора көтеп;
Шытып чыга чәчкән һәрбер бөртек;
Халкым тарихыннан агу ясап,
Безне чаккан кортлар качты өркеп.—
Мине беркем ега алмый төртеп.

*
* *

Киләчәккә китеп барам,
Ә юлым түгел такыр.
Очрап тора төпсез сазлык,
Текә тау, чокыр-чакыр.

Очрап тора упкыннарның
Күперсез җирләре дә,
Малны түгел,
Җан сораган
Сират күперләре дә.

Янәшәдә ифрат такыр
Кемнәрнеңдер юллары.
Юл читендә уйлаган бар
Озыннарын уйларның.

Әллә алмашырга микән?
Хикмәт соң юлдамыни?!
Юлны мөмкиндер,
Язмышны
Алышып буламыни?!

## Яшәп буладыр ла...

Әйтче, яшәп булыр иде микән
Чырай сытып,
                дөнья көлгәндә;
Авыз ерып,
                хата хыяллардан
Кемдер мантымаслык бөлгәндә.

Әйтче, яшәп булыр иде микән,
Тарихыңны сатып икмәккә;
Тамагы туйгач, ашка таш белән
Атучыны тагын җитәкләп...

Әйтче, яшәп булыр иде микән,
Кайгыртып гел шәхси бураңны;
Соңгы көнеңәчә хаклык белән
Ялган арасында тулганып.

Яшәп буладыр да...
Ләкин моны
Чын яшәү дип әйтеп буламы?!


* * *

*Я не буду больше молодым.*
С. ЕСЕНИН.

Үткән көннәр урап кайтмас кабат,
Түксәң-түкмәсәң дә яшьләрең.
Булмый калып яшьлек илләрендә,
Юк булмый шул кире яшәреп.

Агачларым коя яфракларын,
Ярсып чапмый инде аткаем.
Гүзәл яшьлегемне сагына-сагына,
Булса иде ныграк картаеп.

# ШИГЪРИЯТ



## Кави Латыйп

### ТУРАГАЧТА КОШ ОЯСЫ

* * *

Турагачта кош сайрый,
моң артыннан моң сайлый.
Идел-йортта оясы,
Идел-йортта кояшы,
Идел-йортта дөньясы.
Җырын Тур тыңлап тора:
олылап, зурлап тора.

Сайрый-сайрый,
турагачлар сайлый-сайлый,
тургайлар оя кора.

Идел-йорт дөньясына әле
тере җан сыя тора,
ырысын тоя тора...

* * *

Ташлап киткән үземә — мин
кире әйләнеп кайттым:
ятлар теләсә нишләсен,
үземне мин... яраттым.

---

Кави ЛАТЫЙП (1927) — *шагыйрь, «Вакыт канатлары», «Хәтер йомгагы», «Иркен сулыш» һ. б. китаплар авторы. Чәчмә әсәрләре дә («Мизгел», «Йолдыз тапкан егет» һ. б.) бар. Казанда яши.*

---

Турагач — кош кундыра торган агач. Тур — чуашларда Тәңре дигән мәгънәне аңлата. Ырыс — бәхет.

Күкләргә чөйдерә икән
үзең булып яшәвең.
Үземне үзем иткәчтен,
йөз елга мин яшәрдем.

Үзеңдәме чәчкә-гөлең? —
сулмас мәңге күңелең...
Чигенү, җиңелү белән мин
үз кадеремне белдем.

Үзем булып, кылдан нечкә
сират күперен кичәм...
Дөньядан китә калсам да,
үземнән мин, юк, китмәм...

* * *

*\Рөстәм Яхин ядкяре*

Өзелде лә Яхин гомере,
өзелде лә даһи гомере.
Юк, ул түгел гүрнеке.
ул — безнең күңел гөле.

Яхин үлгән! Яхин үлгән!
Даһи үлгән! Даһи үлгән!

Күңелләр тетрәнә.
Яхинның моңлы көенә,
даһинең моңлы көенә,
Җир-бишек тирбәлә гүя,
Җир-бишек тирбәлә...

* * *

Мин-минлек!
Өстенлек!
Хакимлек! —
аның кыйбласы, иманы.
Шул өч «кит»та
тотарга ниятли фани дөньяны.

Кече яшьтән өстенлек алырга өйрәнгән.
Инде бабайга әверелгән.
Әмма ваз кичми бәндәне
үзенә буйсындыру әмереннән.
Гүргә кергәч тә,
әмер бирердер ул исәннәргә —
өч көн тоташ! —
кабереннән...

* * *

*Туган авылым мөәзиненә*

Әйт син азан,
кыл син дога,
күңелләрне уятып.
Яшәү вә үлем хакында
көннәр-төннәр уйлатып.
Уяныргa,
уйланырга бик вакыт!
Агайлар да, малайлар да
ишетсен азаннарны,
тыңласын догаларны...
Без сүнгәч тә,
без үлгәч тә,
милли көйгә
яшь аналар җырлармы?

...Бисмилласыз,
кыйбласыз юл бармы?..

* * *

Яралганмын синең хакка.
Син имин-аман булганда —
Илһамым таша.

Яшә, туган туфрагым,
синдә шыта җырларым...

* * *

Туган җир — язың, көзеңдер.
Җуелмас эзеңдер.
Туган җир — изгедер.
Туган җир — нәселең, үзеңдер.
Йөзеңдер!..

* * *

Җан бирермендер,
кара гүргә керермендер.
И Хода, сабыр булыймчы, —
һава сулыймчы...

Соңгы сулышка кадәр
каләмле булыймчы, —
уйлыймчы...

* * *

Бушлык — мәңгелек,
мин — мәңгелек түгелмен.

Бер көн бушка үткән көнем,—
бер көн алдан гүргә керүем,
бер көн алдан үлемем...

* * *

Үземне мин богаулы дип хис итәм,
яшимен сыман зинданда.
Тоткынлык минем җанда,
тоткынлык әллә канда?

Ничек кенә котылырга?
Ничек кенә онтылырга?
Өметем — язылмаган шигырьдә,
җырланмаган җырда.

Алар, бәлки, коткарырлар,
богауны салдырырлар,
мине саклап калырлар,
ташлар ярып,
иреккә чыгарырлар?

Язылыгыз, язылмаган шигырьләр,
җырланыгыз, җырланмаган җырлар!...

* * *

*Оныгым Русланга*

Кынында
чын кылыч түгел,
төсле кәгазьдән ясалган
кылычның сыны гына.
Күпме изаланма,
сынмый гына...

Син – бәләкәй пәһлеванны
сыный гына...



**Локман Бадыйкшан**

# МӨРТӘТ

РОМАН

*Әй син, дус, кызганма мине,*
*Без — үлми торган халык!*
*Булмагач булмый икән ул,*
*Халыкның җанын алып!*

Рәшит ӘХМӘТҖАН

## Беренче бүлек

Владивосток шәһәре Алтын Мөгез култыгы ярына җәелеп утырган. Әлеге култык һаман саен киңәя барып, Япон диңгезенә чыга. Аның башланган урыны — Черек почмак дип аталган җирдә. Ул тирәләрдә балыкчы алачыклары, кораблар төзелә торган ачык кярханәләр урнашкан. Еллар буе диңгезләр, океаннар кичкән корабларны төпләренә ябышкан әкәм-төкәмнәрдән чистарту, яңартулар шунда башкарыла.

Сигез елга якын сузылган хәрби хезмәтемне миңа шушы якларда үткәрергә туры килде. Ниһаять, туган Татарстаныма кайтып китәчәкмен! Бүген — 1947 елның 10 марты. Инде хәрби билет тутырылган. Япон, Охот, Беринг бугазы, Тын океан, Сары диңгезләр аша узылган сугышчан походлар артта калды. Бүген-иртәгә демобилизация көтәм...

Япон белән сугыш беткәнгә ике ел була. Әле һаман Ерак Көнчыгышта тынычлык урнашып бетмәгән. Көньяк белән Төньяк Корея тарткалаша. Шуңа күрә Тын океан хәрби флоты һәрчак сугышчан әзерлектә тора. Демобилизацияне кичектереп торулары да шул сәбәпле бугай. Шулай да, күп еллар хезмәт иткән өлкән диңгезчеләрне шәһәргә чыгаргалыйлар.

Владивосток укытучылар институтында миңа читтән торып укырга мөмкинлек биргәннәр иде. Соңгы имтиханнарымны тапшырып кайтып киләм.

Корыч арканнар белән ярга тарттырылып беркетелгән крейсерның койрыгына киң такталардан эшләнгән трап сузылган. Шуннан күтәрелеп,

---

Локман БАДЫЙКШАН (1919) — *прозаик. «Атау кызы», «Атау егете» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

вахтадагы офицерга жетонымны[1] тапшырып, яшәгән кубригыма таба атладым.

Егетләр инде кичке ашка да утырганнар. Кизү торучы миңа:

— Сине кайтып җитмәс дип белдем, өлешеңне алмадым. Үзең барып алырсың,— диде. Минем өчен кайгыртучанлыгы өчен рәхмәтемне әйтеп, өс-киемнәремне алыштыра башладым. Шулвакыт, кораб кизүе кубрикка төшеп, муенына аскан җиз чылбырлы муенсага беркетелгән сыбызгысын сызгыртты. Барыбыз да шул якка борылдык. Кемне булса да эзли ул. Бик кирәк булганда гына кизү кубрикка төшә торган иде.

— Өлкән матрос Бадыйкшанов, Сезне командирның беренче ярдәмчесе көтә, ашыгыгыз! — диде дә кизү, ничек тиз күренгән булса, шулай юк та булды.

Өс-башымны тәртипкә китереп, һич нәрсә уйламастан чакырган җиргә чыгып киттем. Чисталыгы белән ялт итеп торган югары палуба аша офицерлар яшәгән шкафут коридорына килеп кердем. Кораб командирының беренче ярдәмчесе каютасы янында ике кеше күренде. Болар да чакырылганнардыр, күрәсең,— дип уйларга өлгермәдем, тегеләрнең берсе миңа таба атлады.

— Бадыйкшанов, Сезне мин чакырдым, әйдәгез минем каютама,— диде ул. Ирексездән аның артыннан иярдем. Янәшәсендәгесе дә бездән калышмады. Миңа дәшүче офицерны яхшы беләм, ул безнең корабның оперуполномоченный булып эшләүче вәкиле. Моннан бер генә ай элек мине үзенең каютасына чакырып сөйләшкәне булды аның. Нинди китаплар укуым белән кызыксынды. Мин аңа бер кызыклы китап та биреп торган идем әле.

Укырга теләге булгач, укысын. Китабымны кайтарып бирергә чакыргандыр. Ә менә аның белән янәшә атлаган майорны беренче генә күрүем.

Каютага килеп кердек. Майор уртачадан калкурак, озынча яңаклы, тар маңгайлы, кысыграк күзле. Татар икәнлеген шундук абайладым. Сүзне беренче булып ул башлады.

— Шушы буламы безгә кирәкле кеше? Бадыйкшанов фамилияле башка дингезче юктыр бит корабыгызда?

— Юк, берәү генә андый фамилияле.

Мин шөбһәгә төштем. Аңламыйм. Нәрсә булды бу? Ни өчен кирәк булдым әле мин боларга? Аптырашта калдым. Икесе дә миңа текәлеп, сөзеп карыйлар. Майор куен кесәсеннән озынча кәгазь чыгарды да:

— Сез кулга алынасыз, менә ордер, кулыгызны куегыз,— дип кулындагы кәгазен миңа сузды. Аптырап киттем. Беравык югалып калдым. Нәрсә дип әйтергә дә белми тордым. Аннары гына:

— Ни өчен? — дип сорадым.

— Белмисезме?

— Башыма да китерә алмыйм!

— Шулаймы? Баргач белерсез...

— Кая баргач? Һич тә аңламыйм.

— Әйберләрен китерегез,— дип, майор янәшәсендә торучыга дәште. Тегесе шундук кулына телефон трубкасын алды.

Озак та үтмәде, минем старшинам белән ике матрос барлык мөлкәтемне каюта идәненә кертеп аудардылар.

— Башка әйберләре юкмы? — дип, майор старшинамнан сорады.

— Барлык әйберләре шушында,— урын-җирен китереп тормадык, аларын сорамадыгыз,— диде кыю гына.

— Ярый алайса, барыгыз, башка сезнең кирәгегез юк,— дип, аларга чыгарга кушты.

Каютада без өчәү генә калдык. Мине тоткарлап торучылар дингез капчыгымны чишеп, анда булган әйберләремне актара башладылар.

---

[1] Хәрбиләргә шәһәрдә вакытлыча йөреп кайту өчен бирелә торган рөхсәт билгесе.

Каюта бик кечкенә, һавасы бөркү, сулыш алуы вакыт үткән саен авырлаша. Моны капчык актарган майор беренче булып тойды бугай. Йөзенә, авыр эш башкарган кешенеке кебек, бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты. Бер генә кешелек тар каютада нибары ике генә иллюминатор бар. Аның берсе тышкы якка, диңгез култыгына, икенчесе коридор ягына караган. Җитмәсә алар ябылып, боргычлап куелганнар. Ишек ябык. Өстәвенә пар торбасы идәне читеннән үтә. Мин бер генә адым читтә басып торсам да, бик тә кайнар икәнлеген тоям. Кораб оперуполномоченные, һава җитмәвен сизеп, диңгез култыгына караган иллюминаторны ачарга керешге. Аны бу эшеннән майор шундук туктатты.

— Анысын ачма, коридор ягындагысын ачсаң дә җитә,— диде ул, бер кочак кульязмамны диңгез чемоданымнан өстәлгә чыгарып куйды.

Кораб уполномоченные, кабаланып, коридорга караган иллюминаторны ачарга керешге.

* * *

Әдәбият минем аерылгысыз юлдашыма әверелгән иде инде. Буш вакытым булдисә, кулыма каләм алып кәгазьгә ябышам. Һич югында, көндәлек язарга керешәм. Бу минем каныма сеңгән. Шуннан ләззәт табам. Миңа моны хәрби хезмәткә китәр алдыннан Гадел Кутуй әйтеп калдырды. «Язучы буласың килсә, энем, көндәлек алып бар, киләчәктә алар сиңа кирәк булачаклар»,— дигән иде ул.

Менә хәзер тар каютада ят бәндәләр, еллар буена язып барган көндәлекләремне, кульязмаларымны зур дикъкать белән актаралар, нәрсәдер эзлиләр. Беләм, язмаларымда бернинди документ та яки хәрби серне ача торган, шуңа бәйләнешле нәрсәләрнең эзе дә юк. Кирәкмәгәнгә вакыт әрәм итәләр. Шулай да, минем йөрәгем әрни, ачуым килә. Талчыгып басып торганда, коридорга караган ачык иллюминаторга күзем төште. Таныш диңгезченең башы күренә анда. Ул күзләре белән миңа нәрсәдер әйтмәкче була. Аннары аның кулы күренде. Шундук таныдым. Кораб пешекчесе икән. Кулында урталай киселгән ак икмәк, өстендә калын итеп ябылган ак май да бар. Миңа суза бу. Тикшерүчеләр барлык игътибарларын өстәлдәге кульязмаларыма биргәннәр. Уйланып торырга вакыт юк, тиз генә бер атлап, миңа сузылган икмәкне алдым. Коридордан чабып киткән аяк тавышлары гына ишетелеп калды. Тикшерүчеләр шундук минем кулымдагы икмәкне күреп алдылар. Майор шап итеп кулымдагы икмәккә ябышты.

— Бирмим, мин кичке ашны ашамаган. Миңа биргәннәр икән, димәк, ул минеке. Кеше өлешен алырга хакыгыз юк,— дидем кыюланып.

Шулвакыт икенче тикшерүче тиз генә ишекне ачып чыгып китте. Шундук әйләнеп тә керде. Миңа икмәк бирүчене тота алмаган. Күңелемнән сөенеп куйдым. Тикшерүчеләр мине стенага терәп куйдылар. Коралфәләм бирмәделәр микән дип булса кирәк, өстемдәге киемнәремне баштан-аяк капшап тентеп алдылар. Шулай да, кулымдагы икмәкне тартып алып, аны икегә аерып, анда берәр нәрсә куелмаганмы икән дип, бармаклары белән төрткәләп карадылар. Икмәк эчендә өч-дүрт калын гына ак май кисәгеннән башка бер нәрсә дә таба алмадылар.

— Кем тапшырды? Әйт, әйтмәсәң, үзеңә үпкәлә. Барыбер әйтерсең,— дип татарча әйтеп ташлады майор, тавышын күтәрә төшеп. (Аны татар дип уйлаган идем, ялгышмаганмын икән.)

— Йөзен күрми калдым, әйткән булыр идем,— дидем, тыныч кына.

Минем кулга алынуымны диңгезче дусларым белеп алганнар. Чын күңелләреннән теләктәшлек белдереп соңгы бүләкләрен: икмәк белән май китергәннәр. Ничәмә еллар бергә хезмәт итеп, тормышның ачысын-төчесен бергә кичереп, ерак походларда булдык, хәтәр операцияләрдә

катнаштык. Болар, әлбәттә эзсез генә калмагандыр. Крейсерда дусларым күп минем. Алар белән фикерләремне уртаклаштым, аралаштым, киңәшеп яшәдем...

Бер сүз дә ала алмауларына ачулары килеп, зәһәрләнеп миңа бераз карап тордылар да язмаларымның битләрен бер-бер артлы барлый башладылар. Майор кәгазьне катырак тартып бармагы белән «Кара шайтаннар» дип аталган зур күләмле повестемның бер битен яртылаш ертты. Минем бик тә ачуым килде. Түзмәдем:

— Нишлисез сез, иплəбрәк булмый мени,— дип әйтеп ташладым. Минем сүземә исе дә китмәстән майор:

— Язмаларың бүтән сиңа һичкайчан да кирәк булмаячак,— диде дә, кабат битләрне актарырга керешге. Язмаларымның берсендәге сүзләргә үтә игътибарын биргән майор,— табышын бүлешергә теләп булса кирәк, иптәшенә карап:

— Коллега, монда кара әле,— дип килбәтсез симез бармагы белән үзе укыган юлларга төртеп күрсәтте. Өстәлгә якын басып торганлыктан шунда мин дә күз салдым. «Хризантема чәчәгеннән дә гүзәл чәчәк юктыр, япон солдатыннан да батыр сугышчы булмас»,— дигән юлларны күрдем. Менә нәрсәгә игътибар иткән икән ул. Бу җөмләне язучы Степановның «Порт-Артур» китабыннан күчереп алуым исемә төште. Япон самураеның нинди икәнлеген укучыма киңрәк аңлатып бирү өчен, үземә ошаган җөмләне алган идем. Әйдә, казынсыннар, мине барыбер моның белән генә гаепли алмаслар. Ватаныма сигез елга якын тугры хезмәт иттем, һәм, насыйп булса, калган гомеремә дә тап төшермәм...

Бик озак актарындылар алар. Көндәлекләремне җентекләп карап чыкты майор. Үзләре белән алып китәргә дипме, аларны өстәлнең бер читенә өеп куйдылар. Капчыгымда башка әйберләр дә бар иде. Кечкенә күләмле «Моника» исемле язу машинкам майорны аеруча гаҗәпкә калдырды.

Ардылар, күрәсең, берсе сәгатенә карап алды. Аннары күкрәк кесәмнән партбилетымны тартып алмакчы булдылар. Мин:

— Сез бирмәдегез, алырга да хакыгыз юк,— дидем. Икесе дә җилкәләрен җыерып, бер-берсенә караштылар. Бераз киңәшеп тордылар да, мине политбүлек башлыгы Яков Гурьевич Почупайло яши торган каютага алып менеп киттеләр. Төнге уникеләр җитеп килә инде. Башта югары чинлы начальникны йокысыннан уятып, өлкән хуҗага керергә батырчылыклары җитми торды. Нишләргә? Мин партбилетны бирми торам. «Элек гаебемне ачып, җыелышта тикшерсеннәр, аннары алып китәрсез»,— дип карышам.

— Иртәгәгә калдырыйк,— диде кораб вәкиле.

— Юк, тикшерүче көтә,— дип каршы төште майор.

Каютага кергәч, политбүлек башлыгы башта аңламый торды. Майор хәрби прокурорның мине кулга алырга санкциясе барлыгын әйткәч, Яков Гурьевич йомшак ягымлы тавышы белән:

— Билетыңны миңа бир, ачыклангач, үзеңә кайтарырмын,— диде.

Буйсынырга туры килде. Саубуллашып чыгып киттем. Яңадан кулъязмаларым калган теге тар каютага төштек. Майор миңа җыенырга кушты. Кубрикка кайтып килим дисәм, кая ул, якын да җибәрмәделәр. Шинелем, бүрегемне дә старшинамнан китерттеләр. Язмаларымны җыеп бәйләделәр дә, аннары каютадан чыктык.

Корабта отбой булган, диңгезчеләр ял итә. Бары тик вахтада торучылар гына үз постларында. Минем дә бүген вахтага басасым бар иде. Көтелмәгән тоткарлык — кулга алынуым, әлбәттә, хезмәттәшләремә дә уңайсызлык китерми калмагандыр...

Палубадан атлыйбыз, алдан майор бара, аның артыннан мин, сизәм, оперуполномоченныйның бер кулы кесәсендә, күрәсең ул пистолет тоткан. Моны мин борт буеннан үткәндә сиздем. Янәсе, суга сикермәгәем.

Корабтан төштек. Беркадәр читтә бетонланган ярда җиңел кара машина тора иде. Шофер руленә башын куеп йокымсыраган. Без ишек ачуга, ул бик тиз уянды. Шул кадәрле гомер безне көтеп, талчыгып беткән, күрәсең. Әйтергә генә ансат, минем чамам буенча дүрт-биш сәгать узгандыр. Машинага кереп утыргач та, шофер хәтсез генә моторны кабыза алмый азапланды. Ниһаять, кузгалдык.

Ниндидер караңгы урамнарны үтеп, машина зур гына дүрт этажлы соры йорт алдына килеп туктады. Бездән пропуск-фәлән сорап тормастан кертеп тә җибәрделәр. Паркет идәннән шактый атлагач, бер этаж өскә күтәрелдек. Аннан янадан түбәнгә төштек. Тар коридорны үтеп, кечкенә тәрәзәле куе кызылга буялган тимер ишек янына җитеп туктадык. Шундук ишек ачылып, аннан дежур офицер килеп чыкты.

— Китердек!

— Яхшы. Сезгә погоннар инде кирәк булмаячак,— диде каршылаучы офицер. Аларны тиз генә умырып йолкырга да керешге. Бу эшен ул шундый тиз башкарды, мин сүз әйтергә дә өлгерә алмадым. Китерүчеләр аңа нидер әйтеп китеп тә бардылар. Офицер мине коридорга алып керде. Бик үк якты булмаса да, ул иркен иде. Уң якта тагын берничә ишек күземә чалынды. Ходаем, коридор эчендә ничә бүлмә? Дежур офицер бер ишекне ачты.

— Керегез!

Ирексездән ул күрсәткән бүлмәгә таба атладым. Борылып сүз әйтергә дә өлгермәдем, ишекне ябып, бикләп тә куйдылар. Камера икән бу. Бер генә тәрәзәсе дә юк. Нибары ишек өстенә амбразура сыман уелып ясалган тишектән тонык кына яктылык төшә. Урындык та, өстәл дә, караватта юк. Озынлыгы биш, киңлеге өч адым чамасы гына үзенең.

Гомеремдә беренче мәртәбә бик астына эләгүемә аптырап, берникадәр зиһенемне җыя алмый тордым.

Коридорда аяк тавышы тынды. Күрәсең, дежур офицер ишек янындагы мин бая күргән өстәл янына барып утырган. Башымда бер генә уй: ниндидер зур ялгышлык килеп чыккан, тикшерерләр дә, гафу үтенеп корабка кайтарып җибәрерләр. Анда иптәшләрем!

...Нинди гаебем бар соң? Хезмәтем крейсерда гына үтте. Озак елларга сузылган хәрби хезмәтем дәверендә, шәһәргә увольнениега, барысын җыйсаң, бер ай чамасы чыкканмындыр. Сугыш башлангач, ялга чыгулар бөтенләй туктатылган иде. Ни өчен соң мине демобилизация алдыннан кулга алдылар? Йөрәгемне чәнчеп торган мең сораулы уйлар акылымны чуалтты. Тар, һавасы бөркү, караңгы камерада кулымны артка куеп арлы-бирле атлыйм да атлыйм...

Коридорда аяк тавышлары ишетелде. Шыгырдап камерам ишеге ачылып китте. Анда ике солдат ияртеп офицер күренде.

— Әйдәгез, сорау алырга чакыралар,— диде ул.

Шул ук йортның мәрмәр баскычларыннан күтәрелеп, киң, якты коридорга килеп чыктык. Уң яктагы зур тәрәзәләр урам якка карыйлар. Әле тышта караңгы икән. Шәһәрнең йокыда икәнлеген абайлап алдым. Коридор бик озын, түшәмнең бер башыннан икенче очына кадәр ай сыман якты калпаклар асылган. Алардан төшкән яктылык күзләрне кисә, кайда икәнлегемне чамаларга, хәтта уйларга да комачаулый. Алдымнан штыклы винтовкасын тотып сакчы атлый, аның алдыннан офицер бара. Ә иң артта икенче солдат. Офицер туктады. Биек ак ишекне ачып башта үзе керде. Аннары: «Керегез»,— дип, мине чакырды.

Алга таба уздым. Идән уртасында баскан, уртадан калкурак буйлы, кара чәчле, ябык чырайлы нурсыз күзләре белән миңа сөзеп карап торган офицер киемнәрендәге берәү:

— Утырыгыз,— дип миңа зур өстәл янына урын күрсәтте.

— Исәнмесез, иптәш өлкән лейтенант,— дидем дә аның белән аңлашырга фикерләремне туплый башладым.

— Миңа бүтән иптәш диясе булмагыз, сезнең иптәшләрегез Брянск урманнарында, аңлашылдымы?

— Һич тә аңламыйм, иптәш өлкән лейтенант.

— Кабатлап әйтәм, мин сиңа иптәш түгел. Гражданин өлкән лейтенант булам, аңлашылдымы?

— Төшенә башладым, гражданин өлкән лейтенант...

— Менә шулай, синең җинаять эшеңне тикшерергә билгеләнгән тикшерүче булам. Фамилиям Шумихин. Аңладыңмы?

— Бераз төшенә башладым, ләкин бернәрсәне аңлап җиткермим әле?

— Нәрсәне?

— Көнбатышта, шул исәптән партизанлыкта да йөрмәдем. Шулай булгач, сез әйткән Брянск урманнарында иптәшләрем юк минем...

— Бөтенләй шыр тиле булып кыланма! Җитәр, эшкә керешик.

— Мин әзер, сорый башлагыз?

— Тартасыңмы?— дип, өлкән лейтенант өстәлдә яткан «Казбек» папиросы тартмасын миңа таба этәреп куйды.

— Рәхмәт, тартмыйм,— дидем, аның тәкъдимен кире кагып.

Тынычлык хөкем сөрде. Тикшерүче өстәл тартмасыннан ак кәгазьләр чыгарды.

— Йә, Бадыйкшанов, минем сорауларыма җавап биргәнче, үзең нәрсәләр беләсең, кемнәр белән аралаштың, ул кешеләр белән элемтәләрегез ничек башланды, ниләр эшләдең, барысын да тәртибе белән ашыкмыйча гына сөйли башла? Без ничек тизрәк аңлашсак, шулкадәр үзеңә дә җиңелрәк булыр. Йә, мин көтәм, башла!

Өлкән лейтенант Шумихин каләмен кулына алды, аны кара савытына тыгып күтәрде дә язарга ук хәзерләнде.

Аптырап калдым. Нәрсәдән башларга? Ниләр сөйләргә? Нәрсә, нинди ярамаган җинаять эшләп ташладым соң әле?! Башымны стенага таба бордым. Күзләрем сәгатькә төште. Төнге өченче ярты булып килә. Ике тәрәзәле зур бүлмәдә тикшерүче белән без икәү генә. Сакчылар коридорда. Моны мин күңелем белән тоям. Чөнки вакыт-вакыт итекләрнең паркет идәнгә бәрелүләрен ишеткәлим.

— Йә, мине көттермә. Кабатлап әйтәм, сөйлә?

— Гафу итегез, аңламый торам, нәрсә сөйләргә?

— Белмисеңме?

— Бернәрсә дә белмим.

Тикшерүче кызып китеп, тавышын күтәребрәк кычкырды.

— Кызмагыз, гражданин өлкән лейтенант, мин Аллага шөкер, саңгырау түгел, шулай ук карак-угры да булмадым. Диңгезче мин, әйе, хәрби диңгезче! Япон самурайлары белән булган сугышта үземә йөкләнгән хәрби бурычымны намус белән үтәгән өчен медаль белән бүләкләнгән кеше булам.

— Әле син, Бадыйкшанов, минем белән шулай сөйләшәсеңмени?

— Сез тавышыгызны күтәреп миңа җикерендегез!

— Сөйләргә өйрәтәчәкмен әле мин сине. Синнән акыллырак кошчыкларны да сөйләргә мәҗбүр иткәнем бар!

Тикшерүче кызып китте, йөзе тагын да агара төште. Ул шунда кулын өстәл читенә куйды. Хәбәр итә торган кнопкасы бар күрәсең. Атылып бүлмәгә кораллы солдат килеп керде.

— Камерасына озатыгыз!

Яңадан йортның аскы катындагы баягы камерага алып бардылар да шартлатып ябып куйдылар.

Нәрсә бу? Мин берни белмәгән хәлләр турында сөйләтмәкче булалар? Нинди җинаять эшләдем соң мин? Бары хәрби диңгезчеләр турында гына, батырлыклары, намуслы хезмәтләре, сугышчан походлар, эчке дөньялары, мәхәббәтләре — менә нәрсәләр турында яздым мин. «Кара шайтаннар» повестеннан башка, чистага күчерелгән унҗиде хикәям дә

бар. Аларның берсен «Совет әдәбияты» журналына җибәргән идем. Аны 1944 елгы бер санда басып та чыгардылар. Иптәшләремә дә ошаган иде хикәям.

Йөрәгемнең әрнүен басар өчен, тикшерүче өлкән лейтенант Шумихинны вакытлы гына булса да онытып торырга телим. Уйларга бирелəм. Яшьлегемне, флотка киткәнче булган тормышымны күз алдына китерергә тырышып күзләремне йомам. Бәхет кичергән матур еллар! Бик үк ерак та түгел әле алар. Кул гына сузасы ул елларга. Менә шушы мизгелдә йолдыз булып атылып яшьлегемә кайтырмын сыман...

Камерада озак уйланып йөрергә ирек бирмәделәр. Яңадан ишек ачылды.

— Әйдәгез! — диде дежур офицер.

Өлкән лейтенант Шумихин өстәл артында үз урынында утыра. Аның йөзе сүлпәнләнгән, күзләре тоныкь. Миңа игътибар итмәгәндәй, ниндидер кәгазьләр актара. Язмаларымны тикшергәндер, аңлый алмавына ачуы килгәндер инде. Каршысына килеп утырганчы баштa стенадагы сәгатькә карап алдым. Иртәнге бишенче ярты икән. Шулай булуга карамастан, йокым килми. Тикшерүче арган, бик тә арган, ахры. Йөзе көзге каен яфрагы төсле аның. Миндә нишләптер, бу кеше туберкулез белән интегә, дигән фикер туды. Утырам, ул дәшми, әйтерсең, каршысында беркем дә юк. Күп тартканлыгы беленеп тора. Бүлмәдә тәмәке исе, югарыда куе төтен зәңгәрләнеп җәелгән, урыслар әйтмешли — «балта эләрлек». Укшып алдым. Шунда гына тикшерүче тоныкь күзләрен күтәреп миңа текәде.

— Уйладыгызмы?

— Нәрсәне?

— Мин бит сине уйларга, тиешле нәтиҗәгә килергә җибәрдем, — дип куйды ул, тавышын күтәрә төшеп.

— Юк инде, иптәш... гафу итегез, гражданин өлкән лейтенант. Уйларлык, башымны ватарлык эшем булганын исемә төшерә алмыйм.

— Алмыйсызмы?

— Андый эшләрнең минем белән булганы юк!

— Бик астыртын кеше син!

— Моны ничек дип аңларга инде?

— Вакыты җиткәч аңлатырга да туры килмәгәе...

Сүз көрәштереп торуның мәгънәсез икәнлеген аңлый башладым. Акрынлап үземнең КГБга килеп капканымны сиздем.

Тикшерүче өстәленең бер башында, «Казбек» папиросы белән янәшәдә генә, кечкенә хатын-кыз пистолеты ята. Мин аны килеп утыргач та күреп алган идем. Яңадан күзем шунда төште. Тикшерүче бик тә арган кыяфәттә, күрәсең, мин камерада вакытта ул башка тоткын белән шөгыльләнгән. Аңар пистолет белән янагандыр, куркыткандыр, ә менә хәзер аның каршында мин утырам...

Сүзләребез ябышмый. Тикшерүче дә тавышын күтәреп бер сүз әйтми. Тынлык хөкем сөрә. Тукта әле, Локман, пистолет синең өчен куелмады микән? Маҗаралы китаплар күп укыдым. Куркыныч җинаятьчеләрне шулай өстәлгә патронсыз корал куеп, үзләре игътибар итмәгәнгә сабышып, торып киткәлиләр. Шулчак тоткын пистолетка ябыша. Тегеңәргә шул гына кирәк, кесәсендәге икенче корал белән һөҗүм итүчене атып үтерә. «Үзе ташланды», — дип соңыннан үзен аклый. Мондый алымнар безнең көннәрдә кулланыла микән? Юк, иптәш өлкән лейтенант, синең бу номерың барып чыкмас, дип әйтәсем килеп китте. Тыелып калдым. Сабырлыгымны миңа һич тә югалтырга ярамый. Әле моннан биш-алты ай гына элек үзем белән булган бер вакыйга исемә төште.

...Владивостокның хәрби портында инде күптәннән бирле хезмәт итүче Сафар исемле таныш кешем бар минем. Ул җәмагате белән үзәк урамның кечкенә бер тыкрыгында, ике катлы йортның бер бүлмәсендә

яши. Флотка миннән берничә елга алданрак килгән. Еш кына очраша идек аның белән. Беркөнне эшеннән соң ул корабка килгән. Мине чакырып чыгардылар. Сафар мине сөендерерлек яңалык алып килгән. Миңа калын журнал суза бу. Карыйм — «Совет әдәбияты». Шатланырлык урын да бар шул. Журналда хикәям басылган. Бу очрашудан соң дуслыгыбыз тагын да ныграк кабынып китте. Менә шуларны искә төшереп, уйлар диңгезендә йөзгәндә, тикшерүче:

— Нишлибез, сөйлисеңме, юкмы? — дип куйды.

— Әллә чынлап та сез, гражданин өлкән лейтенант, мине җинаятьче итеп китергәннәренә ышандыгызмы?

— Безгә гаепсез кешеләрне китермиләр. Озак вакытлар артыгыздан күзәткәннәр, тәмам ышангач кына кулга алырга мәҗбүр булганнар.

— Алай икән...

— Кабатлап әйтәм, җинаять эшләрегезне ача башлагыз, югыйсә, тагын да начаррак булыр.

— Гаебем юк минем. Дөрес аңлагыз, гражданин өлкән лейтенант, борчылмагыз,— дидем кыюланып.

Тикшерүче нервалана, авызыннан папиросын төшерми.

Шулай кара-каршы тарткалашып утырабыз. Бервакыт аның түземлеге бетте. Җикеренә башлады. Ә мин салкын канлылык белән тыныч кына утырам. Кинәт өлкән лейтенант аягына басты. Башта әйтәсе сүзен әйтә алмый, миңа туп-туры күзләрен акайтып карап алды. Аннары зәһәр тавыш белән:

— Начар ысуллар белән сөйләтергә теләмим. Үзең сөйләп бирерсең дип өметләнгән идем. Син андый булып чыкмадың.

— Гражданин өлкән лейтенант, сез менә бу минутта, минем урында булсагыз, нишләр идегез?

— Сорауларны бу йортта мин бирәм,— дип, тагын да тавышын күтәрә төште тикшерүче.

Күрәм, ул соңгы сүзләренә аеруча басым ясап, миңа каш астыннан гына нурсыз акайган күзләрен текәгән. Сөйли башлар, дип өметләнә. Тизрәк минем белән эшен тәмамлап, хуҗалары кушканны җиренә җиткереп, миннән котыласы килә аның.

— Сораулар бирегез, бәлкем, чыннан да гаепләрем бардыр...

— Гыйффәтле кыз булып кыланма, бу сиңа бик тә кыйммәткә төшәчәк.

— Аңламыйм, һич кенә дә аңламыйм.

— Аңларсың. Сөйләргә теләмисеңме?!

— Телим дә бит, нәрсә сөйләргә кирәклеген белмим.

Тикшерүче миңа текәлеп карап алды да, иң кадерле нәрсәсен югалткандай, өстәл тартмасын тиз генә ачып, нииндидер кәгазьгә күз төшерде, аннары:

— Кабатлап әйтәм, дәшмәвең сиңа бернинди дә файда бирмәс. Тагын вакыт бирәм, уйла, барыбер сөйләтәчәкбез! — дип кулын өстәле астына сузып кнопкага басты.

Солдат килеп керде.

— Камерасына!..

Күп уйланудан башым тубал булган, йөрәгем әрни, берничек тә тынычлык таба алмыйм. Борчулы төнне үткәрсәм дә, йокы миннән качкан. Шулай стенага карап торганда, көтмәстән камера ишеге ачылды. Анда кулына алюмин кружка тоткан солдат күренде.

— Килегез, иртәнге чәй китердем,— диде ул. Солдат кулыннан чәй, икмәк алдым да, аны камераның бер почмагына илтеп куйдым. Бер генә дә кабасым килми. Кичә төштән бирле авызыма ризык алганым юк. Ашыйсым килми. Кайнап торган диңгез тормышымнан аерып, ябып куюларына йөрәгем яна. Үземне һич кенә дә тынычландыра алмыйм. Тагын шыгырдап ишек ачылды. Офицерның колгадай буе күренде. Алы-

шынганнар икән. Кичәгесе калын гәүдәле, урта буйлы лейтенант иде. Бусы тегенең капма-каршысы.

— Җыеныгыз, тикшерүчегә!

Өлкән лейтенант Шумихин үз урынында утыра иде. Аның белән янәшә тәрәзәгә якын гына урта яшьләрдәге билгесез майор басып тора. Ул әледән-әле миңа карап ала, күрәм, өйрәнә бу мине. Шумихин, бер сүз дә әйтмәстән, каядыр чыгып китте. Миңа утырырга урын тәкъдим итмәүләренә ачуым килеп басып торам.

— Синмени әле ул, җинаять эшләреңне сөйләргә теләмәүче, тикшерүчебезне җәфалаучы диңгезче?

— Нәрсә сөйлим, сөйләрлек җинаять эшләрем юк минем.

— Алай ярамый, бездә кешеләр белән гадел эш итәләр. Никадәрле тартышсаң, шулкадәр үзеңә явызлык кына өстисең.

Дәшмим. Күрәсең бу юлы икәүләп сөйләтергә уйлаганнар. Башта дивардагы сәгатькә карап алдым: тугызынчы яртылар чамасы. Тышкы тәрәзәгә күз салдым. Көн болытлы. Язгы һава форточкадан бүлмәгә керә. Мартның унбере генә бит әле. Шулай да тыштагы җылылыкны күңелем тойды. Майор миңа билгеләнгән тикшерүченең башлыгы булырга охшый. Ул арада өлкән лейтенант Шумихин керде. Башта минем әле һаман басып торуыма игътибар итте. Аннары, утырырга рөхсәт бирде. Үзе дә урынына барып утырды, алдына кәгазь чыгарып куеп ручкасын карага төртеп, язарга әзерләнде.

— Йә, сөйли башла?

— Нәрсәдән башларга?

Тикшерүче минем җавабымнан зәһәрләнеп:

— Сөйләрсең! — диде дә, кнопкага басты. Солдат килеп керде.

— Алып чыгып китегез!

* * *

Нәрсә генә уйласам да, очына чыга алмыйм. Яңадан портта эшләгән Сафар күз алдыма килә. Аның демобилизацияләнеп киткәненә алты айдан артык вакыт үтте. Соңгы очрашуыбыз искә төште. Шулай бервакыт, аның бүлмәсендә икәү генә утырабыз. Җәмәгате белән кызы каядыр чыгып киттеләр. Өстәлдә ризык мул. Башта берәр рюмка спирт эчеп алдык. Ашау-эчү яклары әйбәт булгач, мин исермәдем. Сафар мине сыйлый да сыйлый. Сөйләшеп сүзләребез бетми. Ул әңгәмәне күбрәк Татарстанга, тиздән минем өйгә кайтып китүемә бора.

— Күп калмагандыр инде,— дидем.

— Син аңлап бетермисең, хезмәтеңнең кайчан бетәсе билгесез. Көньяк һәм Төньяк Кореяда тынычлык урнаштырылмыйча, сезнең буынны тиз генә кайтармаячаклар,— ди Сафар.

Бу сүзләрен ул йомшабрак киткән вакытымны туры китереп әйтте. Шулвакыт, игътибарымны юнәлтеп, тәрәзә янындагы язу өстәленең астагы шүрлеген ачты. Аның ымлавын аңлап мин дә утырган урындыгымнан күтәрелеп янына килеп бастым. Ни күрим: өстәлнең шүрлеге эчендә пистолет, патроннар, өр-яңа тутырылмаган хәрби билетләр ята.

— Нишләп бу нәрсәләр синдә,— дип сорадым аңардан. Ул болай да зур авызын ача төшеп елмайды да:

— Портта тентү вакытында берәүдән килеп чыкты. Аларны органнарга тапшырасым бар әле, күрсәтүемнең максаты — сиңа кирәк булмасмы диюем иде. Телисең икән ал, пистолетын да, хәрби билетны да. Дүрт ягың кыйбла, китәсең дә барасың...

— Әллә мине ахмак дип белдеңме? — дидем аңарга. Ул:

— Мин болай гына, җүри әйттем. Иртәгә үк тапшырам үзләрен,— дип куйды Сафар, өстәле тартмасын ябып.

Хәтсез вакыт үткәрдем мин аның квартирасында. Менә хәзер, шул соңгы күрешүебез күз алдыма килгәч, башыма да төрле-төрле уйлар килә башлады. Миңа беренче тозакның салынуы — Сафар белән шул соңгы очрашуыбыздан башланмады микән? Нигә әле миңа бу хакта органнарга әйтми калырга булган?

Уйларга вакытым күп. Акрынлап искә төшерәм. Кайда нинди ялгышлык җибәрүемнең очына чыгарга тырышам...

Хәрби хезмәтемнең беренче елында миңа нindидер журналда инглиз матросының язмаларын укырга туры килде. Ун ел хезмәт итә ул диңгездә. Дөньяның бик күп материкларын, атауларын күрә. Офицерлар белән дорфа сөйләшкәне, хәрби тормыш тәртипләрен бозганы өчен флоттан сәяси яктан гаепләнеп куылуы турында язылган иде ул журналда. Мин дә аның кебек яшьлек елларымны флотка бирдем. Гомеремнең бер өлешен аңа багышладым. Кайтыр вакытым җиткәч кенә, нindидер аңлашылмаучылык килеп чыгып, көтмәстән кулга алындым...

Шулай мыңгерәүләнеп утырганда, камера ишеге ачылды, яшь кенә бер диңгезче килеп керде. Ишек ябылгач, башта ул ишек төбендә басып торды. Ярым караңгы камераның бар ягына да күзен йөртеп чыкты. Аннары:

— Биредә кеше бар икән әле,— дип куйды.

— Әйе, күгәрченкәй, кайсы яклардан очып килдең?

— Әле генә флот экипажыннан китерделәр.

— Мин хәрби корабтан, монда икенче тәүлегем. Иптәш булырсың, якынрак кил?

Яшь диңгезче белән танышуыбыз әнә шулай башланды.

Яшь матросның күңеле бик тә төшенке. Ябылуына ышанып бетә алмый. Егетнең хәрби диңгез флотына килүенә нибары алтынчы гына ай икән әле. Уку отрядына эләкмәгән, эшче командага билгеләгәннәр. Үзе Себердән. Кичләрен экипажның койма тактасын шудырып шәһәргә чыккалаган. Шунда яшь-яшь кенә бер кыз белән танышкан. Бер-берсен яратышып та өлгергәннәр.

— Фәрештә диярсең ул кызны. Зур зәңгәр күзләр, нечкә сын, биленә җиткән куе калын чәчләр, төз аяклар...— Егет дәртләнеп сөйли, ә минем үз кайгым, тыңламыйм. Аның сөйләгәннәре бер колагыма керә, икенчесеннән чыга бара. Ярый сөйләсен, кайгысы беразга гына булса да онытылып торыр...

Төшке аш керттеләр. Солдат кулыннан ризыкларны алып цемент идәнгә куйдык. Икәү булгач, күңеллерәк булып китте. Яшь матрос ашый да башлады. Аңа карап минем дә ашыйсым килде.

— Марусям мине эзли микән? — дип куйды ул.

— Булмас, башка диңгезче белән танышып та өлгергәндер...

— Моның алай булуы мөмкин түгел!

— Ышанма син кызларга, хәзерге заманда Ромео белән Джульетта мәхәббәте юк ул...

— Син миңа караганда өлкәнрәк булсаң да, минем кебек кызлар сөя белмисең икән?

— Бәлки шулайдыр да.

— Ә менә мин сөя белдем, Маруся да өзелеп ярата башлады.

— Ничек таныштыгыз соң аның белән?

— Алтын Мөгез култыгы буенда, медуза тоткан чакны.

Аның сөйләве миңа ошап китте. Үзем дә сизмәстән бирелеп тыңлый башладым егетне. Кайгыларымны онытып торыйм, йөрәгемнең әрнүе басылмасмы. Икебез дә борчуларыбызны беразга гына булса да мәхәббәт мажаралары белән сүндерик...

— Нечкә тал чыбыгы белән су хәшәрәтен ярга чыгарып азаплана идем. Кулы белән судан медузаны чыгарып, алдыма ук китереп тә куйды. Шундый батыр, тапкыр кыз булып чыкты ул. Исем-акылым китте.

— Шуннан, шуннан?

— Маруся белән киногa бардык. Ул безнең Себер кызлары кебек эре сөякле түгел, сөйкемле, күңелемә хуш килгән гүзәлне беренче тапкыр очратуым. Башыма төшкән бәлагә дә аның аркасында юлыктым.

— Ачыклап сөйлә, юньләп белмәгән кыз өчен башыңны балта астына кую ярыймыни?

— Иң биек кыядан диңгезгә сикереп төшәргә әзер мин аның өчен.

— Ничек инде ул алай?

— Менә болай. Экипажда төшке аштан соң, Маруся белән вәгъдәләшкәнчә, коймa тактасын шудырып очрашуга чыгып киттем. Көткән ул мине. Диңгез буе бакчасында озак кына йөрдек. Аерылышып флот экипажына кайтсам, кичке аш беткән. Ә минем эчтә бүреләр улый. Нишләргә? Экипажда ларек бар безнең. Шунда бардым. Төреп алырга кәгазь юк. Тизрәк казармага кереп, аны-моны уйламастан, бер тумбочка янына килеп, стенадан күземә чалынган плакатны умырып алдым да, яңадан ларекка чаптым. Печенье, повидло кебек кирәк нәрсәләр алдым да казармага кайтып ашадым. Ротабызда берәү дә юк иде. Ишек янында торган кизү генә кем беләндер телефоннан сөйләшә. Егетләр экипаж клубына киногa киткәннәр. Караватыма сузылып яттым, хыялга бирелдем. Маруся белән бергә булган минутларны күз алдыма китереп, рәхәтлек тойгылары кичерәм. Татлы йокыга гына киткән идем, кичке барлауга команда булды. Егетләр дәррәү кубып казарма уртасына тезелә дә башладылар. Мин дә алардан калышмыйм, торып бастым да үз урынымны алырга ашыктым.

— Күптән түгел генә гадәттән тыш вакыйга булган ротабызда,— дип игълан итте старшина, вольно командасы бирелүгә.

— Нәрсә булды икән? — диештек без, гаҗәпкә калып.

— Рота кинода вакытта, минем тумбочкам өстендә эленеп торган иптәш Сталин портретын кемдер явызларча ертып ташлаган. Моның эзенә төшмичә отбой булмаячак,— дип зәһәрләнеп сүзләрен чәчте ул.

Рота политругы аның янына баскан, әледән-әле казарма уртасында тезелгән егетләргә сөзеп кенә карап ала. Мин үземнең гаепле икәнлегемне әйтә алмый торам. Рота кизүе минем фамилиямне шундук старшинага әйтеп тә өлгерде. Ә тегесе, җәһәт кенә караватым янына барып тумбочкамны ачты да, аннан повидло төрелгән портретны тартып та чыгарды.

Отбой булуга, мине ашыгычлык белән рота кызыл почмагына, аннары моңарчы бер дә аяк басмаган экипаж политбүлек начальнигына алып киттеләр. Нигә иптәш Сталинны мыскыл итеп повидло төрдең,— дип бәйләнәләр.

— Бәйләнерләр шул. Минем дә эш синеке шикеллерәк булырга охшый, кемдер өстемнән язып биргән, күңелем шулайрак сизә,— дидем яшь диңгезчегә.

— Ризасызлык була инде ул. Экипажда эшче командада калдыруларына борчылып, кемнәрнедер сүккән идем. Флотка мин эшче булырмын дип килмәдем, ә сугыш корабына, диңгезләр гизәргә, кызыл флотчы булырга килдем...

Яшь матрос, сөйләвеннән туктап нәрсәдер уйлап торды, аннары яңадан бәйнә-бәйнә Марусясы белән булган мәхәббәте турындагы хикәятен дәвам иттерде. Аны тыңлап, үзем дә беренче тапкыр гашыйк булуымны искә төшердем. Зәй кызы иде ул. Алай ук сөя алдым микән мин? Сигез елдан артык вакыт үтеп тә киткән. «Син кайтканчы мин олыгаермын, яшь-яшь кызлар үсеп киләләр, күзең шуларның берсенә төшсә, мин нишләрмен»,— дип язган хаты әле дә саклана миндә аның.

— Мәхәббәтемнең чынлыгын аңларсың әле син,— диде яшь моряк.— Маруся мине табарга тиеш. Күңелем белән тоям...

Шул вакыт тимер ишек ачылды. Сакчы солдатның кулында хатын-кыз сумкасы бар иде.

— Әйттем бит,— әнә ул сумка минем Марусямныкы,— диде дә егет ишеккә таба атлады. Ишек шундук ябылды да. Яшь диңгезче, авыр сумканы тотып минем яныма килде. Гаҗәпләнүемнең чиге булмады. Сөйләвенең дәреслеккә чыгуы башымны әйләндереп җибәрде. Матроска мин сокланып, кызыгып карап алдым.

— Табасына ышанган идем. Бу әле башы гына. Тозактан коткаручы да Марусям булыр әле. Күр дә тор...

Ул шунда сумкасының бер читенә торба итеп куелган газитне алып идәнгә җәеп куйды, бер-бер артлы күчтәнәчләрен тезеп куярга керешге. Ул гүя тоткынлыкта түгел, ә күңелле очрашуда иде.

Диңгезчеләр кыстамыйлар. Бер-береңөчен үләрдәй булып яшисең диңгездә. Яшь матрос әлегә диңгездә булмаган, хезмәте яңа гына башланган. Мин тозлы диңгез суында башым белән мең мәртәбәләр чумып чыккан булганлыктан, аның тәкъдимен кабул итеп, бабам кебек аякларымны бөкләп утырдым. Ләкин бер генә ризыгын да ашарга булдыра алмадым. Тамагымнан үтмәде.

— Бөтен кешедә дә синеке кебек хыялый мәхәббәт булмый инде ул,— дип куйдым.

— Нишләп хыялый булсын. Күрәсең бит, һәммәсе дә үз урынында.

Яшь матросның исеме Игорь иде. Үзе белән бик дуслашып киттек. Кайда тууын, ничек үсүен, хәрби флотка килүен сөйләп алды. Үз нәүбәтемдә мин дә аңа тормышымның кайбер якларын ача башладым. Игорь миңа сокланып, игътибар белән карый. Диңгез тормышы аны бик тә кызыксындырды. Ике көннең ничек тиз үткәне дә тоелмады. Гүя, мин монда, бу подвалга командировкага гына килгәнмен дә яшь матрос белән сөйләшеп, аерылышыр алдыннан поезд көтәбез. Ә поездыбыз һаман килми дә килми генә...

Ял көне булгангамы, безне чакырып борчымадылар. Билгесезлек җанны кимерә. Ярый әле янымда Игорь бар. Аның белән аз булса да җиңелрәк. Ул тиздән коткарылачагына бик ышана. Ике сүзенең берсендә:

— Мәхәббәтем мине монда кертте, моннан йолкып та алачак,— ди. Күрәсе иде аның Марусясын. Шулай ук бик тә гүзәл, ут кыз микәнни? Егет арыды, йоклап китте. Аңа ияреп мин дә шинелемә төренеп ятып карыйм — кая ул, йокы алмый. Башымда уянган меңнәрчә вакыйгаларның барысын да күз алдыма китерергә тырышам...

Майланмаган арба кебек шыгырдап ишек ачылуга сикереп тордым.

Түр идәнгә җәйгән шинелемә барып утырырга өлгермәдем, яңадан камера ишеге ачылды.

— Киен, төрмәгә китәсең,— диде дежур офицер. Айга якын сузылган сорау алулардан, дөресрәге тинтерәтүләрдән соң тәүге мәртәбә ачык һавага алып чыктылар. Тышта апрель. Әнә, түбә кыегыннан тамган суда чыпчыклар коена. Алар ирекле. Нигә миндә дә кош җаны түгел, Татарстаныма очып кайтыр идем. Булмый шул. Дүрт ягымда таш дивар...

Киң тимер капка янында торган ябык машина янына китереп бастырдылар.

— Бар, кереп урнаш,— диде сакчы ишек ачып. Могҗиза! Фургон эчендә кеше кысылып кына сыярлык тар карцерлар. Алар машинаның бер ягында дүртәү, икенче ягында тагын шулай ук. Барлыгы сигезәү икән. Кереп утыруым булды, янәшәдәге карцердан кемдер шакып та алды. Әһә, мин ялгыз түгел, димәк. Җавап бирмәдем. Камераның өске өлешендә тәрәзә сыман тар гына уелма бар. Ул да тимер челтәр белән капланган. Менә нинди кадерле кош икәнмен мин. Янәсе, очып китмәгәем. Кайчандыр машина белән хуҗасыз этләр җыеп йөргәннәрен күргәнем бар иде. Аермасы шунда: фургоны тәбәнәк аларның. Ә бу машинада карцерлар эшләп куйганнар. Безнең өчен, кешеләр өчен. Биеклеккә дә хәйран гына. Рәхмәт инде, ярый әле эттән аера беләләр. Эт җыючы фургонга тутырсалар, нишләр идең. Хәер, эттән кайсы ягыбыз белән аерылабыз соң без?..

Машина озакламый кузгалып та китте.

Кешене кеше иткән дә, гүргә керткән дә тел, дигән сүзне ишеткәнем бар. Гаделсезлекне күрсәм, яки берәрсе ярамаган сүз әйтсә, усаллана торган идем. Менә хәзер фургонда, аның эчендәге кечкенә тар карцерда кысылып борылырга куркып утырам. Сикәлтәле юллардан машина мине төрмәгә алып бара. Курку дигән нәрсәнең мәгънәсен аңламый башладым. Кире алып кайтмый торган юлга чыктым! Тикшерүченең тонык күзләре, ак чырае күз алдыма килә. Ул мине һаман озата бара сыман. Җелегемә үтте, имансыз җан! Шөкер, җебеп төшмәдем. Алда ни күрәселәремне бер Ходай белә, сабырлыклар бирсен...

Машина каядыр килеп туктады. Мин иң соңгысы булып җиргә төштем. Алты кеше булганбыз икән. Безне кызыл кирпечтән салынган зур йортларның берсенә таба алып киттеләр. Кергәч, стенага йөз белән каратып бастырдылар. Аннары төрмә надзирателе кемне кая кирәк шунда алып китә башлады. Мине беренче каттагы төрмә карцерына керттеләр. Киңлеге ике метрдан да артмас, озынлыгы дүрт метр чамасы үзенең. Сул ягында таш караваты, түшәмендә челтәрле калфак белән капланган тонык утлы электр лампасы да бар. Түр стенаның түшәм белән тоташкан җирендә беркайчан да юылмаган тимер рәшәткәле тәрәзә күренә. Стеналары бөрчек-бөрчек күпереп торган известь кыйпылчыклары белән чуарланган. Ишек янында бәдрәф урынына лакан. Менә шушы тар салкын камерада миңа җиде көн, җиде төн яшәргә туры киләчәк. Таш караватта урын-җир дигән нәрсәнең әсәре дә юк. Матроска уйлар дингезендә йөзеп яшәргә ярамаган тагын. Шинелем белән бүрегемне үземдә калдырулары әйбәт булды. Болай булгач түзәрмен, түзмичә кая барасың.

Күзләрем таш капчыкны капшый. Түшәмнән сибелгән тонык яктылыкта, билгеле, әллә ни күреп булмый. Шулай да текәлеп карый торгач, юеш стенаның бер урынында ниндидер язу сыман сырларга күзем төште. «Смерть» дигәнен уку бәхетенә ирештем. Ә икенчесен һич кенә дә булдыра алмадым. Ботинкамны салып таш стенага кунган известь кыйпылчыкларыннан арындырганнан соң гына бер хәрефен таныдым. К хәрефеннән башланган сүз иде. Ничек кенә зиһенемне җиксәм дә башка хәрефләрен ачыклый алмадым.

Төрмә тормышының карцердан башлануы миңа яхшылык вәгъдә итми иде. Тышта апрель җиле исә. Тәрәзәчекнең бер өлгесе ватылып төшкән җиреннән кергән саф һава агымының электр лампасы калпагындагы пәрәвез челтәрен тибрәтүеннән сиздем мин аны. Күнелем белән тоям, җылы җил ул. Караватка басып, тышка карыйсым килде. Өскә үрелдем. Шулвакыт ишек кактылар һәм аның уртасындагы кечкенә тәрәзәчегеннән адәм йөзе күренде:

— Төш аннан тизрәк! — диде ул.

Цемент идәнгә сикереп төшкәч:

— Әллә тышка да күз салырга ярамыймы? — дип әйтергә өлгермәдем:

— Яңадан тәрәзәгә үрелсәң, тагын да начаррак камерага күчерәм, — дип, надзиратель мине кисәтеп тәрәзәчеген каты итеп япты.

Вакыт бик әкрен үтте. Аякларым туңа башлады. Дымлы камера идәне сап-салкын, почмакларында балык кылчыгы төсле вак бозлар, йөреп тормасаң туңа башлыйсың...

## Икенче бүлек

Үсмер чакта бик тиз үсәсе, өлкәннәр арасына керәсе килә. Авыл мәктәбен тәмамлаганда нинди генә хыяллар килми егет башына! Өйрәнгән-укыган фәннәрнең нигезенә төшәсең, алай гынамы соң, шул фән буенча зур белгеч булып китәсең килә. Һәр мизгелең хыял белән

үтә. Мәктәптә укыган чагымда «Яшь ленинчы» газетасына язышып, үзара кайнар бәхәсләргә кереп, дәртләнеп яшәдем. Яраткан газетабызның актив хәбәрчеләрен, шагыйрьләрен, хикәячеләрен үзләрен күрмәсәм дә, исемнәре күз алдымда тора. Менә алар: Әгъзәм Камал, Җәвад Тәрҗеманов, Габдулла Галиев, Гарәфи Хәсәнов, тагын, тагын, бик күпләр күз алдымнан үтәләр. Хәтер дигәнең бик нечкә, садә, күкләрдә йөртә, йөрәкне телә, шуңа да кеше җанының үзәгедер инде ул. Менә шуларны тояр, аңлар өчен яши дә инде адәм баласы дөньяда.

Хәтер... Кил, кил син миңа. Бүген бар нәрсәдән дә кадерлерәк син миңа. Салкын камераның бөрештерерлек газабын җиңешергә кил. Кайда нинди ялгышлык җибәрүемне аңларга ярдәм ит. Яшәү өчен көрәштә үземнең хаклы булуымны исбат итешергә кил!

Уйларым һаман саен яшьлек елларыма алып китә. Яшь каләм тибрәтүчеләрдән Шәрәф Мөдәррис күз алдыма килеп басты. Аның белән 1935 елның сентябрь башында очраштым. Шул көннән башлап флотка алынганчы аралашып яшәдем. Казан педагогия институтының Зур Кызыл урамында кайчандыр монастырь булган йортта тулай торак иде. Без яшьләр, ял көннәрендә шунда җыелабыз. Әллә кайдан күренеп торган гөмбәзендә — клуб итеп җиһазландырылган зал, ул көнне яшь шагыйрьләр, һәвәскәр артистлар җыелган иде. Шунда дустым Шәрәф Мөдәррис «Самурай Сәйдүн» дигән шигырен сөйләде. Янәшәдә студент дусларым: Бәян Гыйззәт, Габдулла Галиев, Шәрәф Әхмәдуллин. Хасан күле буендагы Ерак Көнчыгыш вакыйгаларына багышланган иде Шәрәфнең бу шигыре. Сөйләп бетерүенә, залны көчле алкышлар күмде. Шул күңелле кичәдән соң өч-дүрт көн үткәч, Шәрәф минем фатирыма килде. Ул борчулы, сөмсере коелган, үзе берәзлексез як-ягына карый. Нәрсәдәндер шикләнә сыман. Янәсе, квартирамда башка кеше күренмиме?

— Комсомол өлкә комитетында эшләүче, миңа туган тиешле Галим абый Мөхәммәтҗанов кулга алынган. Тирәмдәге иптәшләр кырын карый башладылар. Нишләргә дә белмим...

Шәрәфнең сүзләре шиккә салды. Мин яшәгән йорттан Татарстан авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе Шәмсетдиновны НКВД кешеләренең төнлә алып киткәннәре күз алдыма килә. Ә Шәрәф дустым усал телле, үз сүзен шундук әйтеп бирә. Аның бу ягын күптәннән белсәм дә, туганы өчен генә борчылмый торгандыр, тагын да берәр нәрсә борчый булыр,— дип уйлап:

— Абыең җәл, шулай да түземле бул, бәлки аны аклап чыгарырлар,— дигән идем шул вакытта аңар.

— Торагыбыздагы тумбочкам өстендә язылып бетмәгән бер шигырем онытылып калган, шуны кайсыдыр кабахәте комсомол бюросына тапшырган, үземне чакырдылар, әле шуннан туры киләм,— дигән иде ул. Нинди шигырь икәнлеген сораганым исемә төште. Венгр шагыйре Шандор Петефидән тәрҗемәм дигәне күз алдыма килде. Җүләр син, шыр җүләр, дустым. Әнә Лермонтовның «Шагыйрь үлеменә» дигән шигырендә патшаларга каршы нинди генә юлларны укымадык. Тәрҗемәң басылмаган да бит әле, шуның өчен борчылып йөрисеңме?

— Менә син аларга, шигырь безнең заманга карамый.,— дип исбат ит...— Җитди сөйләшүдән соң, кырт кисеп укуын ташлап китәргә уйлавын әйтте ул. Чигенә торган егетләрдән түгел иде. Бәлки, аның вакытлыча китеп торуы урынлы да булгандыр.

Дустым Шәрәф мин флотка китәсе елны яңадан Казанга кайтты, укуын дәвам иттерде. Беренче китабы чыкты. «Үскәндә» дигән исеме күңелемә сеңеп калган. Шәрәф мине флотка озатты. Озакламый Ерак Көнчыгышка аның хатлары килә башлады. Хат саен шигырь. Үзе миңа хикәяләр язып торырга киңәш бирә. Язам, сызам, диңгез тормышыннан иҗат иткәннәрен кат-кат эшләп, диңгезче капчыгыма җыям. Исән-сау

туган якларыма кайтсам, китап итеп бастырып чыгарырга өметләнәм. Менә хәзер бу газаплы минутларда шагыйрь дустымның миңа багышланган шигъри юллары исемә төшеп китте.

Моңсу булма, туган, күрешербез,
Вакыт житми — жиргә аумасак.
Жәйге гөлләр белән күмелербез,
Язгы ташкын белән акмасак...

Ватан сугышы башланыр алдыннан җибәргән иде миңа бу шигырен. Ул минем өчен — җыр! Менә таш капчыкта көйләп йөрим аны. Кем дә булса, күрсә иде минем хыял дөньясына чумып, рухымны төшермичә дәртләнеп җырлап йөрүемне!

Тавышымны күтәребрәк җибәргәнмен, күрәсең. Камера ишегенең кечкенә тәрәзәчеге ачылып китте.

— Төрмә йоклый, ә син җырлыйсың, яп ипи шүрлегеңне! — дип каты итеп кисәтте надзиратель. Ирексездән туктарга туры килде. Шундый матур истәлекле хәтирәләр билгән иде күңелемне. Шундук барысы да чәлпәрәмә килеп бетте.

Сугышта булдым, «язгы ташкын белән акмадым». Әмма юлыма капкын куйганнар. Мин шуның корбаны хәзер. Рәхимсез капкан тешләрен ача алырмынмы? Монысы инде, рухымның ныклыгына бәйле. Табышмагымның иң мөһиме менә шул. Игорь дигән яшь диңгезченең эше ничек тәмамланды икән? Коткарырга тиешләр аны, яшь-яшь кешенең киләчәген җимермәсләр... Дустым Шәрәф бу минутларда кайларда йөри икән? Минем тозакка килеп капканымны сизә микән? Ул хатларын гел шигырь белән тәмамлый иде.

...Көчле җилдә океан чайкалса да,
Гадел иптәш, зинһар, тибрәнмә.
Күрешкәнче сакал-мыек чалланса да,
Без мәңге дус, һичбер шикләнмә!

Кадерле дустым, әйтелгән җылы сүзләрең йөрәгемдә күзләрем йомылганчы сакланыр! Мин аларны менә хәзер дә кабатлыйм әле. Күпме генә хатларыңны көтеп алып укымадым. Миңа җибәргән кочак-кочак «Фронт хакыйкате», «Суворовча кысу» дип аталган үзең чыгарышкан газеталарны Тын океан крейсерында үзем белән хезмәт иткән диңгезче татар яшьләре белән бергәләп укыдык. Шул газетада басылган «Тупчы Ваһап» дип аталган поэмаң — дастан ул. Минем өчен дастан! Салкын карцерда хәтер йомгагымны сүтәм. Көндәлек дәфтәрләремә язылганнарны күңелдән кабатлыйм. 1941 ел. Владивосток шәһәре. Без, яшь диңгезчеләр, флот экипажында яшибез. Сугыш башлангач, шулай беркөнне, безне ерак атаулардан эвакуацияләнүче командирларның гаиләләрен портка килеп туктаган океан пароходларыннан каршы алырга алып бардылар. Сахалин, Николаевск, Куриль якларыннан кайтучыларны дәүләт вәкилләре Себернең ерак шәһәрләренә оешкан рәвештә озатырга килделәр. Без, яшь диңгезчеләр, китүчеләрнең мал-мөлкәтләрен пароходлардан тимер юл вагоннарына төядек. Күрәсең, Япония белән иртәме-соңмы бәрелеш көтелә. Японнар инде күптәннән безнең чикләребезгә хәрби көчләрен туплыйлар. Алар Хасан, Халхин-гол сабакларын онытканнар.

Искә төшерәм: безне шул көннән башлап коры җир сугышларына да өйрәтә башладылар.

Көнбатышта безнең кебек егетләр немец фашистлары белән сугыша. Шулай бервакыт сикәлтәле юлдан хәтсез баргач, Уссури тайгасына килеп кердек. Тау елгасы янында туктадык. Безнең полигон шушында икән. Ату күнегүләре үтә башладык.

Буш арада якын-тирәдәге куаклардан кура җиләге, кызыл карлыган җыеп ашадык. Аннан соң парашюттан төшкән «десант»ны каршылау

башланды. Үрмәләп барып, «күктән төшкән дошман»ны камап алдык. «Ура» кычкырып, аңа ташландык. Өйрәнүләребезгә яхшы бәя бирделәр.

Төшке аш вакытында Казан егете, дустым Миргали Монасыйпов белән кәрзин үреп, елгада балык тоттык. Сай гына суда ярыйсы гына зур балыклар йөзә. Тик аларны тотучылар гына юк. Уссури крае миңа бик ошый, суы тәмле, табигате матур. Туган авылым Әлмәткә, ямьле Зәй буена кайткандай булдым.

Кичкә таба яңгыр сибәләп китте. Минем тормышымда бернинди дә үзгәреш юк әле. Төштән соң докка бардык. Ремонтны тәмамлап киләләр. Кораб палубасында Миргали белән очраштык.

Инструментальныйда Фәһимәне күрдем. Аның күзләрендә сөйкемле караш сизелә. Кем белә, бәлки ялгыша да торганмындыр. Кызның күңеле күтәренке. Бүгенге көнгә кадәр аның егете бармы, юкмы икәнен дә әйткәне юк. Иптәшләр күрмәгән арада гына аның яныннан үтеп китмәкче идем дә, Миргали сизде...

Төшкә кадәр киемнәребезнең пөхтәлеген тикшерделәр. Аннары мин сәгать бишләргә кадәр ял иттем. Тревогалар еш булганлыктан, болай рәхәтләнеп йоклау безгә бик аз эләгә. Сугышчан һәм политик белемне «отлично»га үзләштерүчеләрне бүген паркка алып баралар. Анда «Пограничниклар» исемле спектакль күрсәтәчәкләр. Бөтен уй, фикер театр караудa түгел, «кара күз»не күрергә өметләнүдә. Паркта кызны очратсам иде.

Сәгать алтылар тирәсендә строй белән шунда юнәлдек. «Альбатрос» җыры бик матур яңгырый. Җырлаган саен күкрәк киңәя, күңел күтәрелә бара. Паркка да килеп җиттек. Безгә таралырга команда булды. Прожектор белән яктыртылган түгәрәкне үткәндә Фәһимәне күрдем. Аның янына ашыктым. Ни күрим, кыз янына бер матрос килеп баскан. Күрәсең, кызның танышы булырга тиеш. Нишләргә? Матроска да комачауларга ярамый, сабыр итим. Тизрәк агачлар арасына шылдым. Егет кызны үзенә карата ала икән, анысы аның үз булдыклылыгы. Фәһимә бүген кара костюмнан. Менә «кара күз» мине күреп алды. Матросны калдырып, яныма килде. Мине көтеп торган икән. Без аның белән бик озак сөйләшеп йөрдек.

Тагын бер якташым бар. Аның исеме Моталлап, фамилиясе Хөсәенов. Ул да безнең яктан, Әлмәт районы Бишмунча авылыннан. Ул бүген минем янымда булып китте. Күзләремә туп-туры карап:

— Беләсеңме, Локман,— диде.

— Бернәрсә дә белмим.

— Син оныт Фәһимәне...

— Ни өчен?

— Соңыннан үзең аңларсың.

Якташымның болай сөйләшүе бик сәер тоелды. Башта аптырап калдым. Күрәсең, ул Фәһимә белән миннән алданрак танышып өлгергән...

Кич кубрикта дневальный булып тордым. Нарядка китүчеләр таралгач, өлкән лейтенант Афзал Низаметдинов килеп керде. Устав буенча аңа рапорт бирдем. Ул бүлмәне тикшерә башлады. Бер тумбочканы ачты, анда тәртипсез аунап яткан кәгазь кисәкләренә күрсәтеп:

— Бу чүп нишләп монда?—диде.

Мин җавап бирмәдем. Бер читтә сөялеп куелган винтовканы күреп алды:

— Хуҗасы кем?—дип сорады. Мин дәшмәдем.

— Нигә анда калдырырга рөхсәт бирдең?

— Хуҗасы хәзер килеп җитәчәк,—дидем.

Дежурный Низаметдинов мине шелтәләде. Аның алдында шәм кебек басып тордым.

— Старшинаң кайда?

Ул арада булмады, кубрикка старшина да килеп керде.

— Чиратсыз ике наряд язагыз дневальныйга,— дип боерып, өлкән лейтенант чыгып китте.

Бүлмәгә винтовка хуҗасы Моталлап килеп керде.

* * *

Кичә чик буендагы Краскино поселогы тирәсендә егермедән артык япон солдаты чигебезне бозды. Бәрелеш нәтиҗәсендә ике яктан да яраланучылар булды. Шайтан тавында булып узган бу хәлне «Боевая вахта» газетасында да язып чыктылар. Ә Америка газеталары зур бәрелеш булган дип күрсәтергә тырышканнар.

Нәкъ шул көннәрдә көчле тайфун башланды. Җилнең тизлеге секундына 26 метрга җитә. Таң белән торып, походка әзерләндек. Диңгез шауласа да, яр буенда, чатлама суык иде. Сәгать сигездә походка чыктык. Башта командирыбыз Алексей Васильевич Волков сөйләде:

— Бу сезнең өчен чыныгу булыр. Сугышта мондый походлар еш булачак. Диңгезчеләр дошманга өермәдәй ташланырга тиеш.

Ул Балтика диңгезчеләренең немецларны ничек кыйнаулары турында мисаллар китерде.

Аннары старт бирелде. Чаңгылар белән диңгез култыгының көнчыгыш ягына таба киттек. Суык. Урап кайтканда музыка белән каршыладылар. Музыка тавышы тәнгә рәхәтлек, йөрәккә дәрт бирде. Безнең взводтан өч кенә кеше артта калды. Дүрт сәгать егерме минут эчендә илле километр араны үткәнбез.

Аннан кайткач, мине старшина чакырып алды:

— Сиңа сугышчан бурыч тапшырыла.

— Үтәргә әзер! — дидем мин.

Үзебез яшәгән казармалардан шактый ерактарак диңгез буенда яшерен пост бар. Шунда нарядка киткән бер диңгезче иптәшебез каты авырган. Дустым Миргали белән шул диңгезчене носилкага салып алып кайтырга тиешбез.

Караңгы төшеп килгәндә, юлга чыктык. Буран. Карга бата-бата атлыйбыз. Диңгез шаулаганы аермачык ишетелә башлады. Юлсыз җирдән бару бик тә авыр. Үргә күтәрелеп түбән төшкәндә, чәнечкеле тимер чыбык корылмаларына килеп төртелдек. Күп уйлап тормадык, кулыбыздагы носилканы чыбык өстенә салып чыктык. Дулкыннарның яр ташларына бәрелеп шаулаганы безнең күңелләрне күтәрә. Ни әйтсәң дә яр буенда яктырак. Көмеш су тамчыларының сибелүе безгә аермачык күренә. Көч-хәл белән «Яшен» постына килеп җиттек. Авыруны алып кайтырга туры килмәде. Хәле яхшырган. Бераз җылынгач, каравыл начальнигы безгә кайтырга рөхсәт итте.

* * *

Кораб күптән ачык диңгездә. Вахтага басар алдыннан палубага чыгып, диңгезгә карап тордым. Бу тирәләрдән чираттагы тайфун инде үткән, шулай да диңгез әле һаман тынычланып бетә алмый.

Еракта диңгез өстенә кара төтен тасмасы сузылган. Без аңа якынайган саен ул зурая бара. Бераздан аларның сугыш кораблары икәне беленде.

Шторм көчәйде, күңел болгана башлады, баш авыртайды. Югыйсә, җиде-сигез баллы штормнарга гына бирешә торган кеше түгел идем.

Янымнан үтеп киткән матросларның да йөзләре агарган. Күрәм, алар да диңгез авыруы белән җәфалана...

Бу поход өч көннән артык дәвам итте. Татар бугазын үтеп, Камчаткага якынаюыбызны офицерлардан гына белдем. Диңгез бу тирәдә каракучкыл булып тора. Материк ярлары, дөя сырты сыман булып, Төньякка таба сузылган. Ярдан әллә ни ерак булмаганлыктан, мин барысын да аермачык күрәм. Менә нинди икән ул Охот диңгезе ярлары.

Тревога! Сигнал тавышын ишетеп, диңгезчеләр шундук сугышчан урыннарына килеп бастылар. Пулеметлар, туплар, торпедалар тизлек белән хәрәкәткә килде. Диңгездә дулкыннар шаулашып тәгәри. Җил дулкын тауларын ак күбеккә әйләндереп корабка сибә.

Озак та үтмәде, еракта зур гына бер шхуна күренде.

Сугышчан рубкадан:

— Тикшерү партиясе матросларына әзерләнергә! — дигән боерык алынды.

Ашкынып көтә башладык. Шхуна белән безнең корабның арасы барган саен кыскарды.

— Нәрсә дип безнең суларга керде икән ул?

— Төрлечә булгалый... Шторм курстан да яздыра. Усал ният белән дә су чикләрен бозалар,— диде старшина.

— Тукталырга!

Бу сигналга суднода игътибар итмәделәр. Ул үз юлы белән йөзүен дәвам итте. Шхуна ничек кенә тиз бармасын, без аны яңадан куып җиттек.

— Тукталырга!

Шхунадан монысына да җавап булмады.

— Кыланалар, ачуым килмәгәе...

— Нептун патшалыгына китәселәре килгәндер.

Сигналга буйсынмагач, кисәтеп дежур туптан аттык. Шхуна янында су өстендә ак томан барлыкка килде. Шартлау яңгырады.

Шхуна, кача алмагач, кечкенәлегеннән файдаланып, бөтен тизлегенә нейтраль суга омтылды. Без, якын ук килеп, аның белән янәшә бара башладык. Бортына тәрәлдек тә шхуна палубасына төштек.

Башларына киң эшләпә, өсләренә су үткәрми торган җиңел киемнәр кигән кешеләр, бер-берсенә сыенып, палубада хәрәкәтсез торалар иде.

Тикшерүләр вакытында шхуна капитаны:

— Без — япон балыкчылары, көчле су агымына эләгеп, курстан яздык. Гафу итегез,— диде.

Япон шхунасының тикшермәгән җирен калдырмадык. Штурман рубкасында СССРның Хәрби Диңгез базалары билгеләнгән топографик карталар, шушы тирәдә Ватаныбызның иминлеген саклап йөзүче сугыш корабларыбыз төшерелгән фотопленкалар таптык. Тикшерү партиясе җитәкчесе өлкән лейтенант Афзал Низаметдинов бу дәлилләрнең барысын да күрсәтеп акт язды. Аннары, кораб командиры Алексей Васильевич боерыгы буенча, шхунаны якындагы бер портыбызга борылырга мәҗбүр иттек.

* * *

Ерактан килеп туктаган сәүдә корабын бушатырга крейсердан кешеләр билгеләнде. Алар арасында мин дә бар. Без Америкадан яңа гына кайткан йөк корабына юнәлдек. Палубага аяк баскач, уйламаган җирдән, әле моннан алты гына ай элек корабтан киткән Куйбышев өлкәсе егете дустым Салих Шакиров очрады. Без кочаклашып күрештек. Ул озынча буйлы, аксыл йөзле матур кеше. Япон диңгезендә хезмәтне бергә башлап җибәргән идек. Салих эш беткәч, безнең стар-

шинадан рөхсәт алып, мине каютасына алып керде. Кунак итте. Шунда өстәл янында ашыкмыйча гына башыннан үткәннәрен сөйләп алды.

— Корабыбыз Архангельск портыннан ике сугыш корабы сагы астында Америкага юл тоткан иде. Баренц диңгезен үтүгә, безне инглиз кораблары каршы алды. Зур бер кәрван булып, Атлантика океанына чыктык. Көтелмәгән җирдән фашист самолетлары һөҗүм итте. Озатучы сугыш кораблары һава пиратларына ут ачсалар да, кайбер судноларга бомбалар эләкте. Анда-санда ут көлтәләре күтәрелде, безнекенә дә бомба эләкте. Машинабыз сафтан чыкты. Палубадагы зенит пушкасы кубарылып диңгезгә ауды. Үлүчеләр, яралanучылар булды. Ут астында корабның тишелгән урнын ямадык... Самолетларны куып җибәргәч, үзебезне буксирга алдылар. Көч-хәл белән генә Нью-Йорк портына барып җиттек. Анда докка ремонтка керттеләр.

— Ничек кайттыгыз? — дип сорадым мин аңардан.

— Өч ай дигәндә Панама каналы аша Сан-Францискога килдек. Анда йөкләр кабул итеп, туган ил ягына юл тоттык.

Салихның башыннан күп нәрсәләр үткән, ул барысын да кичергән. Мин аны элек яхшы белгәнгә, сораулар биреп аптыратып бетердем. Үзе белән элемтәне югалтмаска булып аерылыштык. Менә бит ул дөнья. Берәүләр ерак илләр гизә, ә мин сугыш корабында сугыш күрмичә гомер үткәрәм. Диңгез тормышы катгый, анда кешеләр зур чыныгу үтә. Хәрби тормыш авыр булса да, аның үзенә күрә матур яклары да бар. Хезмәткә эләкмәгән булсам, Япон диңгезен кайчан гизгән булыр идем әле мин.

Иртән диңгез култыгына сөт сыман аксыл томан җәелгән иде. Кояш, табигатьне ямьләндереп, томанны бик тиз тарата башлады. Җыештыру эшләренә катнашырга югары палубага чыктым. Эшләрне бетергәч, барыбыз да, механизмнарны тикшереп карарга дип, сугышчан урыннарыбызга бастык. Кичә, диңгезгә чыгып, эре калибрлы туплардан ату күнегүләре үткәргән идек. Хәзер тупларны чистартабыз. Мине, Миргалине, Хөрмәтне ярга такта алырга чыгардылар. Безнең кораб яр буеннан, читтән аеруча мәһабәт булып күренә. Диңгез култыгының уртасына кадәр сузылган. Ачык диңгезгә чыгып китәргә әзер булып тора...

* * *

Яңгыр болытлар йөзә. Бер иртәдән алып кичкә кадәр яныбызга килеп туктаган тимер баржадан снаряд бушаттык.

Мин палубаны юа торган швабраны, бик искергән дип, диңгезгә ыргыткан идем. Боцман моның өчен чираттан тыш өч наряд бирдерде.

Шәһәр борын төбендә генә булса да, теләгән вакытта чыгып булмый. Культпоходлар туктатылды. Палубада яңа кешеләр күренгәли башлады. Мондый хәл сугышчан әзерлек кертелгән вакытта гына була торган иде. Япон диңгезендә дә сугыш давылы кубарга тора, ахрысы.

Кичке эшләр беткәч, дустым Миргали янына килдем. Ул альбомын ачкан да ерак Татарстандагы сөйгән кызы Мөршидәсенең рәсеменә карап утыра. Мине күрүгә, үпкәләгән сыман:

— Рәсемеңне нигә бирмисең инде, күрмисеңмени альбомымның бер бите буш тора. Бирмәсәң, альбомыма керми калырсың, — диде.

Аның бу сүзләре миңа сәер булып тоелды.

Ә кичен корабта чын мәгънәсендә бәйрәм булды. Безгә бөтен илгә данлыклы үзбәк артисткасы Тамара Ханым килде. Күкрәгендә депутат значогы. Хөрмәт йөзеннән корабыбызда депутат флагы күтәреп каршы алдык. Вахтадан бушагач, барыбыз да концертка бардык. Тамара Ханым СССР халыклары телләрендә: русча, үзбәкчә, әзербайҗанча, әрмәнчә,

казакъча жырлады. Кул чабулардан кораб клубы гөрләп торды. Тамара Ханымның сугыш шартларында хәрби диңгез корабына килүе күңелләребездә онытылмаслык хатирә булып калды.

* * *

Боцман Семиликов безнең артиллеристлар бүлекчәсенә корабның чылбыры белән запас якорен чистартуны йөкләде. Мавыгып кына эшләгәндә, рассыльный:

— Тизрәк булыгыз, кубрикка җыелыгыз,— диде.

— Тикмәгә генә эш бүлдереп чакырмаслар, нәрсә булса да бардыр,— диде Миргали, мине ашыктырып. Без кубрикка килеп кергәндә, анда басар урын да калмаган иде. Түрдә озынча өстәл янына баскан артиллеристлар командиры безгә мөрәҗәгать итте:

— Эшегездән аерып сезне монда җыю миңа да күңелле түгел. Шулай да мин моны кирәк дип таптым. Ярты гына сәгать элек, безнең башняда хезмәт итүче Моталлап... приказ үтәүдән баш тарткан. Аны зенитчылар белән эшкә җибәргән идек. Ул бармаган. «Мин үзебезнең зур калибр башнясы кешеләре белән генә барам»,— дигән.

Командир Николай Герман янында Моталлап басып тора. Мин командирның сүзләрен тыңлаганда Моталлап өчен бик борчылдым. Аның шул мизгелдәге йөз хәрәкәтен күзәттем. Ул бер агара, бер кызара, күзләрен түшәмдәге электр лампасы калфакларына текәп, тын да алмый тора.

Моталлапның йөрәге тупасланганын, иптәшләренә һич тә ачылып бетмәвен, үз җаена гына карап яшәргә тырышуын мин моңарчы аңлап житкерми идем. Менә хәзер барысы да ачылды. Аның бу хәлгә төшүенә кызганып карыйм. Информациядә Моталлап комсомол җыелышында тикшерергә һәм иптәшләр судына бирергә кирәклеге әйтелде. Мин аның нинди приказ үтәүдән баш тартуын соңыннан гына белдем. Аңа кыргыч белән палубаны кырырга кушылган булган. Ул шуны үтәмәгән. Аның бу эше өчен нинди җәза бирелер, хәзергә әйтүе кыен. Уйламыйча эшләнгән тәкәбберлек дип карадым мин моны. Дустым Миргали дә бу фикер белән килеште.

...Дөньям караңгыланды. Мөнирә апа соңгы хатында бертуган абыемның Сталинград фронтында һәлак булуын хәбәр иткән. Хаттагы кыска гына юлларны укыгач, нишләргә дә белмәдем. Кара кайгыда торганда, яныма дустым Миргали килеп житте. Аңа хәсрәтемне әйттем. Ул миңа:

— Чыдам бул,— диде.

Әнә шул авыр хәсрәтемә ялганып көз килеп житте. Әле күптән түгел генә яшеллеккә төренгән табигать алтын төсенә манчылды. Кочак-кочак яфрак коела. Әйтерсең дә дөньяның матурлыгы коелган яфраклар сыман кими. Бу хәләтне үзгәртердәй шатлыклы минутлар да булгалады. Корабка бүгенге почта «Тревога» газетасының берничә номерын алып кайтты. Ерак Көнчыгыш политидарәсе Хабаровск шәһәрендә татар телендә газета чыгара башлаган. Газетаның редакторы — Бари Корбанов. Әле моңарчы ана телендә Көнбатыш фронтларындагы газеталарны гына укый идек. Үзебезнең газетабыз булуга да сөендек. Аның битләрендә авиациядә, диңгез флотларында хезмәт итүче якташларыбызның парчалары, репортажлары, мәкаләләре урын алган.

Мөнир Мазунов, Әдип Маликов, Хәниф Кәрим, М. Савельев шигырьләре сан саен дип әйтерлек басылганнар. Шул ук атнада, редакциягә үзебезнең корабта хезмәт итүче татар яшьләренең хәрби белемне ничек үзләштерүләре турында очерк язып җибәрдем...

Диңгез өстенә аксыл куе томан җәелгән. Кораб, вак шадра дулкыннарны борыны белән ярып, билгеләнгән якка юл тота.

Дингезчеләр һәрберсе үз эше белән мәшгуль. Тулы сугышчан хәзерлектә торабыз. Эре калибрлы туп башнясында без утыздан артык кеше. Мин югарыга снарядлар биреп торам. Янымда берничә булышчы да бар. Алар команда гына көтеп торалар.

— Каушамаска! — дип куям мин аларга. Снарядларны бәрми-суктырмый гына божра ялгашына урнаштырып, югары озату — безнең төп эшебез. Моның өчен күпме генә күнегүләр, өйрәнүләр үтмәдек.

Төшке ашны да постларыбызда ашарга туры килә.

Дингездә кем беренче булып ут ача — шул җиңүче. Сугышны минутлар түгел, секундлар хәл итә. Моны барыбыз да бик яхшы аңлыйбыз.

— Беләсеңме, Локман,— ди башня электригы Нәшһәт Киреев.— Әле генә мин югары палубада булдым. Эскадраны дингез авиациясе саклап бара икән. Бик күп самолетлар күрдем...

— Бу минем өчен зур яңалык.

— Кая таба юл тотабыз икән?

— Куриль атаулары ягына булса кирәк.

Шулвакыт югарыдан команда бирелде. Башня механизмнары дәррәү хәрәкәткә килде. Мин җитәкчелек иткән божра яшен тизлеге белән бер әйләнеп алды. Берничә снаряд уктай югарыга менеп тә китте. Минут үтмәгәндер, саңгырау гына шартлау тавышы башняны калтыратып алды. Егетләр стеллажлардан снарядларны яңадан әйләндерү божрасы ялгашына тәгәрәттеләр.

Берничә залптан соң отбой командасы яңгырады. Шулай да сугышчан постларны ташламаска дигән әмер бирелде. Матрослар башня эчендә калдылар.

Башня наводчигы Геннадий Очелков, буш вакыт булды исә, мине үз янына чакырып ала да өйрәтергә керешә. Бу юлы да мин аның янына ашыктым.

Штурвалга кулымны куярга өлгермәдем, башня командиры өлкән лейтенант Николай Герман телефон трубкасын тоткан килеш:

— Бадыйкшанов, сине корабль командиры сугышчан рубкага чакыра,— тиз бул,— диде.

Артиллеристлар миңа карап куйдылар. Ышанырга да, ышанмаска да белмәдем.

— Сиңа әйтәләр бит,— дип, яңадан фамилиямне кабатлагач кына броня ишеккә юнәлдем.

Салкынча дымлы җил йөземә бәрелде. Кораб әле бер якка, әле икенче якка авышкан, күбекле дулкыннарны икегә яра. Аның ике ягында да эскадра миноносецлары чайкалалар. Күктә эскадрилья оча, самолетлар корабтан шактый ерак. Тик берсе генә безнең кораб өстеннән очып бара.

Мин палуба буенча сугышчан рубка ягына таба тарттырылган бауга тотына-тотына ашыгам. Шкафутны үткәндә, зур гына дулкын бортка сикереп, мине юып алып китә язды.

Палубада күзәтүче матрослар гына постта тора. Мин югарыга күтәрелә башладым. Башка уй килә: «Командир ник чакырды икән?» Рубкада — хәрби дингез штабыннан килгән югары чинлы офицерлар. Мин командир янына килеп:

— Сезнең чакыру буенча, өченче башня кызыл флотчысы...— дип рапорт бирдем.

— Күктә сезнең кемегез бар? — диде командир.

— Беркемем дә юк,— дидем кыю гына.

— Сезгә очучы Батталовтан радиограмма, ул кемегез була?

— Салих Батталовмы? Ул күренекле татар шагыйре,— дидем мин.

Элемтә офицеры кулыма радиограмманы тоттырды.

Салих абый белән өч ай элек Владивостокта, Җамал апа йортында очрашкан идек. Энесе Фоат Батталов та шунда иде. Ул минем кайда, ничек, кем булып хезмәт итүемне сорашты. Аның дингез

авиациясендә хезмәт итүе исемә төште. Мөлаем йөзле, коңгырт күзле, зур гәүдәле Салих Баттал күз алдыма килеп басты.

Командир миңа башняга кайтырга рөхсәт бирде.

Егетләрнең шагыйрьне күрәселәре бик килә иде. Алтын мөгез култыгына кайтып якорь салгач, командирдан шагыйрь Салих Батталны крейсерга кунакка чакырырга рөхсәт сорадым.

Ул теләгебезне үтәргә вәгъдә бирде...

Ике көн үтүгә, кораб палубасына зур гәүдәле, киң җилкәле хәрби диңгез очучысы Салих Баттал күтәрелде.

— Командирыгыз чакыруы буенча килдем,— диде ул.

Салих Баттал башта кораб белән танышып йөрде. Кичен диңгезчеләр клубында аның белән очрашу үткәрелде.

Унике яшь тулар-тулмастан Тигәнәле авылы болыннарына ат сакларга йөрүләрен искә алды, авиациядә хезмәт итүе, иптәшләре турында сөйләде. Шигырьләрен яратып тыңладык. Ул сугышчан походларда безнең эскадраны озата баруларын да әйтте.

Ай тулган, күгебезнең иң якты чагы сыман хәтердә калды ул очрашу. Кунакны зурлап озаттык...

* * *

Сугышчан поход иде бу. Эскадра Япон диңгезенең көньяк ягына озын юлга чыкты. Безне вак кораблар, миноносецлар, су асты көймәләре озата. Әллә нидә бер генә материк ягыннан авиация дә күренеп китә. Кышкы штормнар вакыты булганлыктан, җиле дә бик усал. Өстебездә кыска тун, башыбызда малахай бүрек булса да, вахтада торганда, суык капшый-капшый тәнгә үтеп керә. Зенитчыларга бигрәк тә читен. Алар салкын җил-давылда да һәр мизгел ут ачарга әзер торалар. Турбиналар нык эшләүдән безнең башня калтырап тора. Атуын атмадык әле, шулай да авиация һәм торпеда атакаларын каршыларга әзер торабыз... Мин Сормово шәһәреннән хезмәткә килгән дустым Оленькин белән янәшә наводка постында утырам. Ул да параваннар[1] кую командасына билгеләнгән. Сигнал бирүләрен көтеп кенә торабыз.

Тревога. Барыбыз да дәррәү аякка бастык. Параваннар куярга башнядан атылып чыгып киттек.

Диңгез өстендә иләмсез җил. Дулкыннар палубага ыргылып кына тора. Без, тарттырылган корыч бауга тотына-тотына, корабның урта өлешенә йөгерәбез. Бик тиз генә үз урыннарыбызга җиттек. Оленькин тимер чыбыктан үрелгән бауны ыргагыннан ычкындыра башлады. Без дә койрык бауларын чишәбез. Тиз ычкындырдык. Оленькин генә нишләптер озаклады. Шулчак кинәт көтелмәгән хәл булды. Ычкынып киткән параван Оленькинны диңгезгә бәреп төшерде. Бу шундый тиз булды ки, без абайлап та өлгермәдек. Зур тизлек белән йөзгән кораб Оленькиннан ераклаша барды.

«Борт артында кеше» сигналы бирелде. Дежур пушкадан да аттылар. «Харап кына булмаса ярар иде»,— дип уйлап, тиз генә борт кырыена килдем дә, коткару бөятен йолкып алып, диңгезгә ыргыттым. Ләкин Оленькинга минем тәгәрмәч барып җитмәде. Диңгезгә моторлы көймәне төшердек. Бу эш белән боцман Семиликов җитәкчелек итте. Кораб батучыга таба чигенде. Оленькинның башы әле һаман күренә. Бозлы дулкыннар аны капларга тырыша. Бер коткару бөяте аның янына ук төште. Әмма ул монысын да тота алмады, жебеп авырайган киеме комачаулагандыр. Моторлы көймә якынайганда гына Оленькинның башы күмелде. Матрослар багорлар белән тирә-юньне күпме айкасалар да, егетне таба алмадылар.

---

[1] Параван — минага каршы корал.

Базага соң гына кайттык. Мин үзем белән ничәмә еллар хезмәт иткән Оленькинның һәлак булуына ышанырга да, ышанмаска да белми йөрдем. Ләкин хакыйкатьтән качып буламы соң? Дусны югалту бик авыр булды.

Командир кушуы буенча аның флот киемнәрен, козырексыз фуражкасын кораб исеме язылган тасмасы белән бергә посылкага салып әнисенә җибәрдек...

## Өченче бүлек

Бу таш капчыкка юл кайчан, ничек башланды соң? Нинди ярамаган, законга сыймаган җинаять эшләп ташладым соң? Хәтер йомгагымны сүтәм, кайда абынганымны табарга тырышам. Юк шул, юк, берни дә исемә төшми.

Камера акрынлап үзенең салкынлыгын сиздерә башлады. Цемент табуттан торып басарга туры килде. Аякларым шактый ук туңганнар икән. Сабырлык белән генә идәнгә басып йөргәләргә керештем. Үзем һаман уйлар дөньясында, һәр көнемне хәтерләргә тырышам. Корабта бер генә дә кыек эшем булганын исемә төшерә алмагач, сирәк кенә ярга чыккалаган вакытларымны күз алдыма китереп бастырам. Менә бит, 1944 елның 26 апрель киче исемдә уелып калган. Владивосток шәһәренең Давыллар Борыны урамындагы Җамал Заһидуллиналар йортына Тын океан хәрби диңгез флоты һәм авиациясе бүлекчәләрендә хезмәт итүче бер төркем яшьләр җыелган иде. Аларның барысын да мин чакырган идем. Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көненә багышлап уздырылачак әдәби кичәгә җыелган идек. Приморьеның Сучан, Артем кебек шахтерлар яши торган җирләрдән килүче яшь кызлар да житәрлек булды анда. Беренче сүзне Ерак Көнчыгыш авиациясендә хезмәт итүче шагыйрь Салих Батталга бирдек. Ул Тукаебызның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштырды. Аннары без Тукай шигырьләрен яттан укыдык. Кичәдә яр буе оборонасында хезмәт итүче танышым Сафар, диңгезче дус-ишләрем: офицер Афзал Низаметдинов, Солтан Ибраһимов, Миргали Монасыпов, Нәшһәт Киреев, Хөрмәт Гыйльфанов, бертуган Галимҗан һәм Сабир Мөхәммәтҗановлар, Татарстанның Әлки районы Яңа Чаллы авылы егете Абдулла Билалов, Салих Шакиров... Дусларым шактый күп килгәннәр иде. Тукай шигырьләрен яратып тыңладылар. Һәммәсенең исләре китте. Кичә барганда Сафар Сәрдаров сәгатенә карап алды да, радиоалгычны Мәскәү дулкынына куйды. Йорт эче тып-тын калды. Башкалабыз бөек Тукай иҗатына багышланган татар сәнгате осталары концертын тапшыра башлады. Мәшһүр җырчыларыбыздан Мәрьям Рахманкулова, Хәлидә Зәбирова, Гөлсем Сөләйманова, Асия Измайлова, Разия Тимерхановаларның җырлауларын сокланып тыңладык.

Ничек оештырдым соң әле мин бу күркәм кичәне? Акрынлап йомгакны сүтеп, елларны артта калдыра барам. Һәм...

Безнең крейсер, Алтын Мөгез култыгында дәү алкалы колакчасыннан ике якка да якорьларын суга төшергән дә, тыныч кына тора. Мин караңгы төшкәнне түземсезлек белән көтәм. Алдан сөйләшеп куелганча, көймә көтәм. Озакламый ул мине алып китәчәк. Крейсерның койрык өлешендә вахтага таныш булмаган офицер белән матрос баскан. Алар мине ярга чыгарачак түгел. Бердәнбер чара — үзем хезмәт иткән орудиеләрне борып, шуннан үрмәләп көймәгә төшәргә. Боларның барсы да алдан уйланып куелган. Караңгы төшкәнне генә көтәсе бар. Наводчик дустым Геннадий Очелков белән сөйләшелеп куелган. Ул минем өчен үлеп тора. Уку отрядыннан бирле без гел бергә хезмәт итәбез. Серләребез килешә, фикерләр уртак.

Көймә киләчәк. Бездән йөз метрлар чамасы гына еракта торган йөзмә кран ягыннан килергә вәгъдә биргән иде минем танышым. Дустым

Геннадий инде күптән тупларны кирәкле юнәлешкә борып та куйган. Тирә-юньгә каранып алдым да, туп өстенә менәргә әзерләндем. Күзләрем үткен, карыйм, көймә дә килеп җитә язган. Мәче тизлеге белән тупка менеп атланып алдым да алга таба үрмәләдем. Уртадагысыннан шуышам. Билемдә манил арканы бар. Көймә килеп җиткәндә арканның бер башын туп очына чалып, көймәгә шуып төштем.

— Җитезлек тә бар икән үзеңдә,— дип куйды каршылаучы. Акрын гына йөзмә кранга таба иштек көймәне. Ярга чыгу белән, булышканы өчен танышыма рәхмәтемне әйтеп, порт сукмакларыннан Давыллар Борыны урамына элдердем. Ә инде кайтканда культпоход белән чыгучыларга кушылып кергәнемне сизми дә калдылар. Чөнки һәммәсе дә җиренә җиткерелеп уйланылган иде. Кичә генә башымнан үткән кебек хәтеремә төшкән бу вакыйганы, менә хәзер таш камерада күз алдыма китереп хәйран калам. Шул вакытта эләккән булсам, фронтка штраф батальонына җибәрелгән булыр идем. Әмма бу нахакка тинтерәтүләреннән мең мәртәбәләр җиңелрәк булыр иде...

1945 елның сентябрь ае. Крейсер ерак походтан кайтып Алтын Мөгез култыгына якорь салуга, яңалык ишеттек. Безгә хәрби журналистлар, язучылар Константин Симонов белән Борис Горбатов килә, диделәр. Мин читтә каламмы соң? Каршыларга, күрергә ашыктым. Аларның крейсерыбызда булулары минем өчен бәйрәмгә әйләнде. Борис Горбатовның «Буйсынмаслар» дигән повестен «Правда» газетасыннан укыган идем. Үзен күреп бер-ике сүз алышасым килде. Бу минутны ничек көтеп алырга да белмәдем. Әдәби кичә крейсерның клубында үтәчәк. Очрашуны Константин Симонов башлап җибәрде. Очрашуның әдәби өлешендә алар үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Тын да алмыйча тыңладык. Бик тә танылган язучылар иде алар ул чакта.

Нигә соң әле мин боларны исемә төшерәм? Төшерергә кирәк шул. Очрашу вакытында кемгә булса да ялгыш сүз ычкындырып куймадыммы? Чөнки гадәтемне беләм, эчемдәге тышымда, күңелгә килгән сүзне әйтергә ашыгам. Әйтми калсам, яшәргә комачаулаган кебек ул миңа. Юк, юк инде, юк! Бер гаебем юк! Йә, Хода, нинди гөнаһларым өчен мондый җәзага тартасың?..

Камера буйлап арлы-бирле йөри-йөри шактый арылды, аякларым талды, хәлем бетте. Күзләрем стенага терәтелеп салынган таш табутка төште. Күрәсең ул тоткыннар өчен карават вазыйфасын үти торгандыр. Аның өстендә бернәрсә дә юк. Шунда үземнең ничек ауганымны да белмәдем.

Күпме йоклаганмындыр белмим, үзәкләремә үткән салкыннан туңып уяныл киттем. Башта кайда икәнлегемне чамаламый тордым. Бәсле стенага күзем төшкәч кенә төрмә карцерында икәнлегем исемә төште. Сикереп торып тимер ишекне кагарга тотындым.

— Туңам, башка җылырак җиргә күчерегез!

Кечкенә тәрәзәчекнең ачылуын шактый көтәргә туры килде. Менә кып-кызыл йөзле бәндәнең башы күренде.

— Нигә дулыйсың? Басып кына тора торган камерага эләгәсең киләмени?

— Бик туңдым, кайнар су булса да бирегез, бераз җылыныр идем.

*Ахыры бар.*



## Заһид Фәйзи

# СЕРЛЕ БҮЛӘК

хикәя

Ашыгып килеп кергән Хәйбри Исламович секретарь кызның башыннан сыйпап узарга өлгерде. Кабинетына кергәч, пальтосы белән бүреген утыргычка ташлады да телефоннан сөйләшә башлады.

— Хәерле иртә, Мойсей Абрамович! Яхшы гына әйләнеп кайттыңмы? Әйе, шулайдыр: синең сәфәрләр уңышсыз буламы соң!.. Димәк, гозеремне дә үтәгәнсең? О-о, таудай рәхмәт үзеңә, рәхмәт! Болай булгач, миннән бер коньяк инде... Күп була дисеңме?.. Алай димә! Эш әйбернең зурлыгындамыни — кирәгендә бит. Күрәсең, Сигезенче Март якынлашып килә... Рәхмәт! Озакламам, үзем кереп алырмын.

Күңеле күтәрелеп киткән башлык «Кубәләгем» көенә такмаклый-такмаклый йөренеп алды да телефон аркылы өлкән мастер Афанасьевны чакырды.

— Эшләр ничек? — дип каршылады ул аны.

— Үзебезнеке ярыйсы, Хәйбри Исламович, — дип зарлана башлады сүзнең нәрсә турында барасын алдан ук белеп торган Афанасьев. — Тәмам бәгырьгә төште бу алкашлар. Мифодейның тәртибен цехкомда тикшергәнгә кайчан гына бит әле. Ай азагы җиткәндә генә тагын түбәгә суккандай итте, дуңгыз!

— Тереләй суя алар безне, Егор Афанасьевич, тереләй!.. Исерүен күрүгә, кеше күзеннән читкәрәк яшерә белмисез үзен.

— Аны ләх чагында кеше күзеннән яшереп йоклатулар азмыни инде, Хәйбри Исламович: чишенү бүлмәсе дә, электриклар мастерское да, баскыч астындагы эмульсия склады да калмады бит хәтта!.. Башын өзәсеңмени, аңламагач!..

Бераз тынлыктан соң, цех начальнигы:

— Нишлибез инде, Егор Афанасьевич? — дип, өлкән мастерга төбәлде. — Әгәр Мифодейга биргән детальләрне бүген-иртәгә эшләп җыю цехына тапшырмасак, тагын премиядән колак кагабыз.

---

* Заһид ФӘЙЗИ (1933) — язучы, «Язмыш борылмалары» дигән китап авторы. Казанда яши.

Афанасьевның моны тыңлап торганда ук кашлары җыерылып, яңак мускуллары калтырана башлаган иде.

— Белмим, кайчан бетәр бу томабашлар көен көйләп яшәү?..— диде ул, хәвефле тавыш белән.— Мин фрезерчы түгел, өлкән мастер лабаса! Ул атналар буе эчеп йөрсен, ә мин, участок начальнигы, сменадан калып, аның өчен детальләр ясыйм, җитмәсә!.. Болай алган премияләр тамагыма аркылы килә башлады инде, Хәйбри Исламович...

— Миңа җиңел дисеңме әллә?! Дөньясы, тәртипләре һаман шундый булгач, нишлисең?..

— Алар белән нервы туздырып торырга түгел, куарга кирәк!

Хәйбриев үртәүле итеп кеткелдәп алды:

— Анысы кыен эш түгел. Тик Мифодей булмаса, нишләрбез соң? Ни әйтсәң дә, эчмәгән көннәрендә, өстендә торып эшләтсәң, заданиене төгәл үтәп бара бит әле. Эх, гөрләп торган завод ни хәлгә төште — күз алдында таркалып бара бит!.. Мифодейдан котылырга ашыкмыйк әле. Ни әйтсәң дә, шулар белән, чиләнеп булса да, заданиеләрне үтәп барабыз бит әле.

— Алкашларның эштә ләх булып йөрүен яшереп, аларны гафу итү үзе бер җинаять, Хәйбри Исламович,— дип көрсенеп алды Афанасьев.

— Заводның «Коллектив килешүе»ндә, «Цехта эчүчелек, хезмәт тәртибен бозу аркасында план үтәлмәсә, аның өчен цех җитәкчеләре һәм инженер-техник хезмәткәрләре премиядән мәхрүм ителә», дигән пункт булгач, нишләмәк кирәк?.. Оперативкаларда кадрлар җитмәүдән зарлана башладыңмы: «Сез дә җитәкчеләр бит, эзләгез, табыгыз үзләрен!» — дип кырт кисә директор.— Аптыраган бу алкашлар белән, баш каткан!..— дип, борын тишекләреннән тәмәке төтене бөркеде Хәйбриев.

— Күрәсез, минем үз эшем дә муеннан, Хәйбри Исламович! Көнозын чабып, эт булам. Алкаш өчен дә эшлә, җитмәсә. Булдыра алсам, карарман. Һәрхәлдә, бу соңгысы булачак,— дип, Афанасьев чыгып китте.

Әле генә күңелсез хәлләр турында сөйләшүгә карамастан, Хәйбри Исламовичның кәефе күтәренке иде. Ул техник укыту бүлегендә утыручы хатыны Дилбәр ханымга: «Бүген соң кайтам — эш күп»,— дип шалтыраттыда тәэминат бүлеге башлыгы Мойсей Абрамовичка ашыкты. «Шулкадәр үткер бу халык, теләсә, әйберне җир тишегенә кереп эзләп табар мәгәр! Яһүдләр, без татарлар кебек, бер дус тапканчы унысы белән дошманлашмый шул. Аларның элемтәсе, дуслары булмаган җир юк! — дип сокланып барды ул.— Эш, мәшәкатьләр белән вакыт узганы сизелми дә, хатын-кызлар бәйрәме җитәргә дә санаулы көннәр калып бара...»

Бу вакытта Дилбәр ханым иренең кабул итү бүлмәсенә килеп керде. Секретарь кызның болай да кыска күлмәк итәген күтәрә төшеп, ботларын ачып утыруын күреп, уңайсызланып китте. Чибәркәй, бизәнү әйберләрен өстәлгә таратып салган да, язу машинкасына сөяп куйган көзгегә төбәлгән хәлдә, чия төсенә буялган озын тырнаклы бармак битләре белән чигәләренә кызыл йөгертеп маташа иде.

— Хәйбри Исламович үзенмәде? — дип сорады Дилбәр ханым.

— Юк иде шул.

— Миңа фломастер кирәк иде, кереп алыйм булмаса.

— Алыгыз,— диде кыз, артык илтифат күрсәтми генә. Үзе бизәнүен дәвам итте.

Дилбәр ханым, фломастер эзләп, өстәл тартмаларын караганнан соң, тумбочканы ачкан иде — күз явын алырдай бизәкле пакетларны күреп, аһ итте! Икесендә ике төстәге япон косынка-бантлары ялт итеп тора! Ул, көзге кебек ялтырап торган кием шкафы каршына килеп, аларның башта берсен, аннары икенчесен муенына урап карады. Косынка-бантлар, чыннан да, сокланырлык матурлар иде. «Менә бу бүләк, ичмасам! Үзе белән унбиш ел гомер итеп, болай ук игътибар күрсәткәне юк иде әле. Началь-

ник булганнан бирле Хәйбриемнең күңел җылысы белән игътибары бермә-бер артты үземә, алланың рәхмәте. Вакыт белән исәпләшмичә эшләп, арып кайтуын белеп, үзен тәрбияләвем өчен шулай хөрмәт итәдер инде, җаныем. Бәйрәмнәр җиттеме, зуррак премия алдымы — бүләк кайтарып бирә. Ничек бу иргә җаның эремәсен?.. Минем мондый әйберләрне яратканымны белеп, берьюлы икене алдырган, җитмәсә. Ярый, боларны күргәнне үзенә сиздермим әле. Вакыт җиткәч, җылы сүзләрен дә әйтеп, үз кулы белән бирсен», — дип уйлады Дилбәр ханым. Пакетларны кире урынына куйды да, фломастерны алып, кабинеттан чыгып китте.

Аның шатлыктан түбәсе күккә тигән иде! Шул ук вакытта, секретарь кызның үзенә ихтирам күрсәтмичә, теләр-теләмәс кенә сөйләшкәненә ачуы да чыккан иде. «Аз гына сөйләшә дә белми. Әйтерсең эштә түгел, әнисе йортында утыра, ябалак күз! — дип үртәлде ул. — Кирәк бит, эш урынында шулай тугарылып утырырга!.. Кайткач, Хәйбриемнең колагына шыпшыйм әле, эшкә йөргәндә азрак тыйнаграк киенсен бу оятсыз».

Дилбәр ханым 8 Март көнен аерым бер түземсезлек белән көтеп алды. Завод, бу бәйрәмне зурлап, мәдәният сараенда уздырырга әзерләнгән иде. Кыска эш көне тәмамлануга, эшчеләр өс-башларын алыштырып килергә тизрәк өйләренә таралса да, болай да чиста, матур киенгән инженер-техник хезмәткәрләр ашыкмадылар. Алар, мәдәният сараена туры заводтан барасы итеп, иркенләп чәчләрен тарарга, өс-башларын карап, көязләнергә тотындылар. Дилбәр ханым ире бүләген — япон косынка-бантын тагарга әзерләнеп, иң матур, иң купшы күлмәген киеп килгән иде. Ул, башка хатын-кызларның бизәнүенә исе китмичә, эчтән генә: «Чак кына түзегез, мин сезне аһ иттерәм әле!..» — дип, иренең шалтыратканын, чакырып бүләк биргәнен көтә. Тик, кичәгә китәр чак җитеп килүгә карамастан, Хәйбриеннән хәбәр юк әле. «Җитәкче кеше бит, берәр җитди эш чыгып, шуның белән чабадыр, мөгаен», — дип, үзен тынычландырып, бәйрәм тантанасына китте.

Мәдәният сарае балкып тора! Бөтенесе бәйрәмчә матур итеп киенгән, күңелләре күтәренке. Ягымлы елмаю, котлау сүзләре. Мондый җирдә хатын-кызны иң затлы, иң модалы кием кем өстендә, кем ничек бизәнгән, кемнең буй-сыны, йөрешләре, кешеләр арасында үзен тотышы ничек — шулар кызыксындыра бит. Ул гына түгел, соңыннан иркенләп гайбәт чәйнәр өчен, алар кемнең сөяркәсе бар һәм ул аны җәмәгатеннән ничек яшерә — шуны да күзәтәләр. Дилбәр ханым арада кызыктырырлык матур киенгән хатыннарны күреп алган саен, эчтән генә: «Эх, хәзер муенымда теге, Хәйбри кайтарткан косынка-бант булса, барысының күзе миндә булыр иде!» — дип, уфтанып ала.

Тантана башланыр вакыт җиткәнне белдереп кыңгырау шалтырауга, кешеләр залга агыла башлады. Фойедагы зур гөмбәзле абажур лампалары берәм-берәм «юкка» чыга бара. Бервакыт Дилбәр ханым иренең секретарен, аның муенында теге затлы бүләкне күреп, коелып төшмәсенме?!.. Тәненә утлы кырмыскалар сибелде, әйтерсең! Ул бер мәлгә гаҗиз булып, катып калды. Өстенә нәзек билен кысып торган ялтыравыклы күлмәк кигән секретарь кыз башын югары чөеп, вак-вак адымнар белән өздереп атлап, залга кереп бара иде. Дилбәр ханым үз күзенә үзе ышанмыйча, тагын бер игътибарлап карады: шул — ире бүлмәсендә күргән косынка-бант иде кызның муенында. Ул, зәһәренә чыдаша алмыйча, кичәне ташлап кайтып китте.

Өйдә беркем дә юк: иртәгә дәрескә барасы булмагач, балалары дәү әниләренә киткән иде. «Бәлки, юкка гына гөнаһланам, юкка гына ут йотамдыр? Казан тикле Казанда андый бүләкләрне кайтартучы бер Хәйбри генә дисеңме. Алайса, нигә соң ничәмә йөз хатын-кызның берсендә дә андый косынка-бант юк — нишләп иремнең секретаренда гына?» — дип баш ватып, тынычланмакчы булды Дилбәр ханым. Юк, күңеленә төшкән шик белән йөрәгендә кабарган ачу болай гына бетәрлек түгел

иде. Шуңа да карамастан, ул үзен кулга алып, бәйрәм ризыклары әзерләргә керешә. Башта, итнең шулпа өчен яхшы җирен генә салып, аш куйды. Аннары мәшәкатьле эш — гөбәдиягә тотынды. Тик, ни генә эшләмәсен, йә кулыннан пычагын төшереп җибәрә, йә сукыр кеше кебек ишеккә килеп төртелә. Каударланмаска, җайлап кына эшләргә тырышуына карамастан, бәллүр рюмка идәнгә төшеп, челпәрәмә килде. Пыяла кисәкләрен җыеп алганнан соң, бераз эше көйләнеп, токмач кисә генә башлаган иде, үткен пычак бармак очын уеп алды. «Бер дә болай булганы юк иде, бу хәерлегә түгел, ахры... Хыянәт итүе дөрес булса — үзенең дә, җелегенә төшеп, иманын укытам мәгәр!..» — диде Дилбәр ханым, бармак очындагы канны суырып.

Ул табынны тәмле ризыклар, эчемлекләр белән тутырып, матур итеп бизәп куйганнан соң, иңенә бәйрәмнәрдә, кунаклар алдында гына кия торган кысан билле ефәк халатын элеп, аякларына укалы чүәкләрен эләктерде. Аннары, трюмо алдына утырып, тырнакларын игәүләп лаклады, чәчләрен тарап-матурлап куйды. Һәм, иреннәрен буяп, хушбуй сөртенде дә көзге каршына басты. «Йә, минем кай җирем ким ул буяуга батып, өстәл артында бот күрсәтеп утыручы ябалак күздән?» — диде Дилбәр ханым, билдән түбән киңәеп киткән, санына сыланып торган халатын сыпыргалап. Һәм шунда, ботлары күренебрәк торсын өчен, халатының аскы төймәләрен дә ычкындырып җибәрде.

Өенә кайтып керүгә, Хәйбри Исламович икенче дөньяга килеп эләкте диярсең!

— Квартирымны бутамыймдыр ич?! Синме бу, Дилбәр? — диде ул, хатынының чибәрләнеп, яшәреп китүенә, өстәлнең аш-су белән тулып, балкып торуына таң калып. Һәм бәхетле, татлы сәгатьләргә өметләнгән кайнар хисләрен киметмәс өчен, аның маңгаеннан үбеп алды:— Ничек шулкадәр яшәрдең дә, шулкадәр чибәрләнеп киттең бүген?! Тьфү, тьфү, күз тимәсен! Нинди уңайдан бу?

— Әйттең сүз! Үзең тантаналы кичәдән кайтып киләсең, үзең нинди уңайдан дип сорап торган буласың,— дип елмайгандай итте Дилбәр ханым, эчендәге чыраена чыгармаска тырышып.— Бүген мин түгел, син мине шулай каршы алырга тиеш идең дә...

— Шулай да бит, һаман нәрсә дә булса кырынлык чыгып тора шул,— дип, ире кызу-кызу чишенергә тотынды.— Балалар юкта, аулакта яшьлекне искә төшереп, рәхәтләнеп бәйрәм итик әле бер!

— Әйе шул...— диде Дилбәр ханым, елмайган булып.

Хәйбри чистарынып, эчке киемнәрдән генә калып, чачаклы пижамасын киеп җибәргәч, ниһаять, дипломатындагы косынка-бантны тартып чыгарды:

— Исәнлек-саулык, бәхетләр телим! — диде, аны хатынының муенына салып. Шуннан соң, шампан шәрәбен ачарга тотынгач кына Дилбәр ханымның:

— Косынканың икенчесе кая соң?! — дигән тавышы яңгырап китмәсенме!

Хәйбри өнсез калды, беравык ни әйтергә белми торганнан соң гына исенә килеп:

— Нинди икенчесе? — дигән иде, хатыны:

— Менә шундый ук косынканың икенчесе! — дип, кунатакта белән иренең баш түбәсенә китереп тә тондырды. Хәйбри Исламович кулындагы шампан шәрәбенең бөкесе атылып китеп, күзләреннән очкыннар чәчрәде!

— Ни булды, Дилбәр?! — диде ул, бер кулы белән түбәсен,, икенчесе белән эчемлеге ташып бетеп барган шешә авызын каплап.

— Мә, монысын да себеркеңә бүләк итәрсең! — дип, косынканы иренең йөзенә ыргытты Дилбәр ханым.— Мине юләргә санныйсың икән. Мин дә сиңа күрмәгәнеңне күрсәтәм болай булгач, күрсәтәм!..

— Ни булды, Дилбәр? Ни өчен җенләнәсең?
— Сиңа бот күрсәтеп, түшен ачып йөрүче яшь себерке кирәк икән — бар! Бүгеннән чыгып кит, эзең булмасын!
Шунда гына Хәйбри хатынының кабинетына килеп бүләкләрне күреп киткәнен, аның берсен секретарь кыз муенында күргәнен сизенеп алды.
— Кешечә әйтеп, аңлатып булмас идеме шуны? — диде.
Дилбәр ханымның тынычланырга исәбе юк иде.
— Дүрт ягың кыйбла, хәзер үк чыгып кит! — дип, авыз да ачтырмыйча ярсына бирде ул.— Моннан соң начальник булып калырмын дип уйлама да — директорыңа керәм. Ә себеркеңне, барып, чәченнән цехка сөйрәп чыгарам! Эшләмичә, бизәнеп-ясанып, ирләрне аздырып ятмасын анда, кәнтәй! Ю-ук! Мин моны болай гына калдыраммы соң?!. Ике бала анасы булсам да, йөзем дә, ботларым да ул ябалак күзнекеннән ким түгел минем! — Дилбәр ханым, канатландырып, халат чабуларын ачып җибәрде:— Әнә, күрәсеңме нинди алар!.. Синең ул пумала башың булса, минем яшь бөркеттәй спортчым бар!..
— Җитте сиңа, елан! — дип кычкырып җибәрде ир.— Үзең гаепле килеш, котырган эт кебек ташланган буласың тагы!
Нервылanудан куллары калтыранган Хәйбри аракы шешәсен тешләре белән генә ачып, фужерны тутырып салды да бер сулышта эчеп, бәллүрне идәнгә бәреп, челпәрәмә китерде.
Иренә хыянәт итмәү генә түгел, чит ирләрне якын да җибәргәне булмауга карамастан, кайнарлыгы белән нинди ярамаган сүз ычкындырганын аңлап алгач, Дилбәр ханым тәмам коелып төшкән иде. Күзләренә яшь бәреп чыкты.
— Җитте, чылатма күзләреңне, ул чын яшь түгел, юынтык су гына!.. — дип җикерде Хәйбри. Бу исә ха тынын тагын да куркыта төште.
— Йа раббым! Шулкадәр җансыз булырсың икән, Хәйбри! — диде Дилбәр ханым, яшьләрен сөртеп.— Ирләрнең кешелеклесе, сөяркәсе булса да, бүләкнең матуррагын үзе белән кайгы-шатлык кичереп тормыш итүче хатынына бирә. Ә син... Ярый әле косынкаңны миңа да биреп өлгермәгәнсең. Кичәгә тагып барып, адәм мәсхәрәсенә калыр идем. «Хәйбриев хатыны белән сөяркәсен берочтан киендерә икән», — дип көләрләр иде.
Бүләкләрне сейфына яшерә белмәгәненә эчтән генә үкенеп, Хәйбри күбеп чыккан төбәсен ышкып алганнан соң, рюмкаларга аракы салды да берсен хатынына сузды:
— Мә, нервыңны тынычландыр да, ир артыннан тикшереп йөрүнең, аның эш урынына килеп өстәлләрендә актарынуның түбәнлек икәнен аңларсың, бәлки.
— Мин болай да яхшы аңлыйм,— диде Дилбәр ханым, рюмканы ирс кебек бер талпынуда бушатып.— Бәйрәм газете чыгарганда фломастер кирәк булмаса, килеп йөргән булыр идем, бар!..
— Алайса, югары белемле инженер буларак, әйт әле, коэффициентның нәрсә икәнен беләсеңме?
— Пычагыма кирәге бар коэффициентларың!..
— Сиңа шулай шул, үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын. Миңа исә коэффициент премияне хәл итә. Ә премия — акча ул. Ә син аны миннән ныграк яратсаң да, якты, җылы бүлмәдә генә утырганга, белмисең.— Хәйбри аракы салып, су кебек кенә эчеп җибәрде дә, ачынып, сөйләп китте:— Безнең — цех начальникларының коэффициент артыннан чабып, кем әйтмешли, артларына кыл да сыймый!..
Иренең исерүен күреп куркуы арткан Дилбәр ханым, кыйнап ташламасын дипме, йомшарганнан-йомшара бара иде.
Хәйбри Исламович дәвам итте:
— Мең гарык инде ул алкашлардан, мең гарык! Эштән куар идең үзләрен, алыштырырга кеше юк. Ә алар, шуннан файдаланып, теләгәнчә

эчә, заказларны вакытында үтәмиләр. Шуның аркасында коэффициент киселә — премия югала. Моннан үзең генә каза күрсәң бер хәл иде, коллективны кайгыртырга кирәк бит. Шуңа күрә ирексездән алкашларның эчеп прогул ясауларын завод җитәкчеләреннән яшерергә, табельләренә сигез сәгатьне куеп барырга мәҗбүр буласың. Ә мин, цех начальнигы, секретарьга ялган табель алып барырга куша аламмы? Әгәр ул моны завод җитәкчеләренә җиткерсә, минем баштан сыйпамыйлар бит... Шуңа күрә, телисеңме-теләмисеңме, үзен җайларга — «авызына май каптырырга» туры килә. Синең җенеңне чыгарган бүләк менә шуның өчен ул, чүпрәк баш! Ә син, әллә нинди спортчылар белән саташкан килеш, миңа эт кебек бәйләнеп ятасың, җитмәсә. Болай гына үтмәячәк бу, белеп тор!..

Шунда Дилбәр ханым:

— Ул — ачудан әйткән сүз генә. Гөнаһым булмагач, мине берничек тә гаепли алмыйсың — курыкмыйм. Ә мин секретарең белән кайларда нишләп йөргәнең төшерелгән фотоларны проходной каршына ябыштырып, бөтен заводка фаш итәм әле үзеңне! — дип, ирен яңадан китереп кысмасынмы!

Хәйбринең түбәсенә салкын су койдылар, әйтерсең! «Бу кадәр елан булыр икән! Минем кайларда нишләгәнне ничек фотога төшерде икән, җен?!» — дип уйга калды. Һәм шунда ирексездән күз алдына өйләнгәнче булган яшьлек мизгелләре килеп басты. Дилбәр белән ул — бер-берсенә атлыгып торган егет һәм кыз — еш кына, Идел, Казан елгасы буйларына чыгалар иде. Табигать кочагында хыялларының чиге юк! Сөйләшмәгән сүзләре калмый. Балалар кебек куышып, шаярып-уйнап алалар. Һәм шул вакытта матур-матур күренешләрне фотога төшерәләр иде. «Бу еланны су буйларында тырышып-тырышып фотога төшерергә өйрәтүләрем үз башыма булган икән», — дип, эчтән генә уфтанып алды Хәйбри Исламович. Һәм шундук әлеге хәлгә китергән сәбәпләрне дә исенә төшерде.

Көннәрнең берендә, айлык премиясез калу куркынычы тугач, секретарен чакырып:

— Бу айнымас баш Мифодей белән нишлибез, гүзәлем? — диде ул, шаяргандай гына итеп.

— Нишләп без аның аркасында акчасыз калырга тиеш, Хәйбри Исламович? Тотабыз да табеленә прогул көннәре өчен сигезлене куеп чыгабыз. Башка цехларда шулай итәләр бит, — диде кыз, аптырап калмыйча.

Начальник буларак, үзен гаепле күрсәтәсе килмәгән Хәйбри Исламовичка шул гына кирәк иде, әлбәттә.

— Син — минем икенче канатым, таянычым, гүзәлем! Үзең кара инде алайса... — дигән булды.

Шуннан соң, секретаре, күзләрен уйнатып, бер алдына, бер артына төшә башламасынмы Хәйбри Исламовичның! Эштән соң көтеп алып, машинасына утырып кайта башлады хәтта. Башта җилбәзәк кызның кыланышларын кызыкка санаган Хәйбри Исламович, тора-бара, үзе дә мавыга башлады. Эштән кайтышлый сигарет өчен киоскага туктадымы, кызыкайга туңдырма йә конфет алып бирә. Елмаешалар, шаян сүзләр сөйләшеп, көлешәләр. Әгәр бүгенге хәл килеп чыкмаса, ихтимал Хәйбри Исламович секретаре белән гөнаһлана да башлаган булыр иде. «Шушы хәлләрне күзәтеп, фотога төшереп йөргән икән, ә! Әгәр араны тизрәк көйләмәсәм, моның бөтен завод алдында хурлыкка калдыруы бар лабаса», — дип уйлады Хәйбри Исламович.

Ул һаман аңына килә алмагандай утырыр иде, хатынының:

— Ник телеңне йоттың, әйтер сүзең калмадымыни? — дигән сүзләреннән айнып китте.

— Нәрсә әйтим? — диде Хәйбри, юк гаебен танырга мәҗбүр булып.

Дилбәр ханым: «Секретаре белән чуалмагае?» — дип шикләнеп йөргән булса да, ире артыннан күзәтергә кирәк дигән уйны башына да китергәне

юк иде. Шулай да: «Фотоларны проходной каршына ябыштырып, бөтен заводка фаш итәм әле үзеңне!» — дип, кыек атып туры тидерде мәгәр. Моңа шатланырга да, көенергә дә белмәде ул.

— Ничек намусыңны саклап калып булсын бу мәхшәрдә, тирә-юньдә бөтен нәрсә алдауга, бозыклыкка корылган бит! — дип ачына бирде Хәйбри.— Юк, булмый болай! Премияләренә төкерәм дә мин дә синең кебек тыныч эшкә күчәм. Кешегә ни — миңа шул. Алган кадәр акчабыз җитәр: юрганыңа карап, аягыңны сузарсың...

— Юк инде, эшеңнән китмисең, ә менә гөнаһлы эшләреңнән ваз кичәсең! Ике балаңны үстереп аякка бастырасың барын онытма!

— Яшерми генә әйт әле, Дилбәр, теге... спортчың булуы дөресме? — диде үзенең дә күңелен көнләшү корты кимерә башлаган Хәйбри.

— Әй, юләр, юләр! Кызулык беләнн әйткән сүзгә ышаналармы?! — дип, ачусыз гына тавышын күтәреп алды Дилбәр ханым.— Мин, ике бала анасы, алдымны-артымны уйламыйча, сиңа — унбиш ел гомер кичергән иремә хыянәт итәргә башыма тай типкәнме әллә?!

— Алайса, мине ничек фотога төшереп йөрдең, әйт әле? Безнең фотоаппарат та ватык түгелме соң?

Дилбәр ханым көлеп куйды:

— Үземне түбәнсетеп, ир артыннан күзәтеп йөримме соң, аллам сакласын! Ә бу серне беркайчан да белмәячәксең! — Аннары ул үтемле итеп, өстәде:— Син секретарең белән ялашып, премия ясасаң, мин хыянәт кылып, хезмәт хакымны арттырсам, тормыш буламы, Хәйбри?!

— Бетте, Дилбәр, башы-азагы шул!

— Юк, Хәйбри, мин сиңа болай гына ышанмыйм әле!

— Ничек ышандырыйм соң, алайса?

— Ипи тотып ант ит!

Хәйбри исерек булса да, кулына ипи кисәген алганчы, кунатакта төшүдән күбеп чыккан түбәсен кашып, уйланып торырга мәҗбүр булды. Бары шуннан соң гына:

— Мин генә түгел, икебез дә ант итәбез! — диде ул, икмәкне алып.

— Нишләп мин ант итәргә тиеш, Хәйбри, гөнаһым юк килеш?

— Син дә ант итсәң, Дилбәр. Минем дә сиңа тәмам ышанасым килә.

— Һай, җаным, ышанмыйсың икән! — диде Дилбәр ханым, һаваланып.— Кая, бир, ант итәм!

Икесе дә:

— Башы-азагы шул. Әгәр хәләл җефетемә хыянәт итсәм, шушы ипинең төсен күрмим! — дип тәүбә кылганнан соң, Дилбәр ханым иренең күгәреп, кибән башы кебек очлаеп чыккан түбәсен ягымлы гына сыйпап алды.

— Кая, үзенә берәр төрле май сөртим, булмаса.

Шунда Хәйбри Исламович:

— Маташма! Эштә: «Кухня ремонтлаганда түбәмә әйбер төште»,— дип, акланырмын. Ярый әле кызулык белән синең күзеңә фонарь куймадым. Югыйсә, икебез дә кеше күзенә күренә алмас идек!..— дип, беренче зәфаф кичендәге кебек кайнарланып, хатынын кочып алды.

# ШӘРИФ БИККОЛГА 70 ЯШЬ



Башкорт шагыйре Шәриф Биккол исеме Татарстанда күпләргә билгеле дип уйлыйм. Нигәме? Ватан сугышыннан кайткач, Казанга килеп (Наҗар Нәҗми белән бергә килүләре турында үзе үк шигырь язуны сорап торган легенда-истәлекләр йөри!), шагыйрьләрдән күп дуслар табып, иҗат уңышлары белән уртаклашып, үзе дә татар матбугатында күренеп, соңыннан да Хәсән Туфан, Зәки Нури, Гөлшат Зәйнашевалар белән аралашып, дус булып яшәгәнгәме? Һәм — монысын да әйтми кала алмыйм! — әнә шул беренче килүендә үк Казаннан бик матур кыз алып китеп, безнең кияү булып, татар кызы белән гомер иткәне өчен дә, бәлки? Әйе, аларын да беләбез. Әмма Шәриф ага бездә барыннан да бигрәк җырчы шагыйрь буларак популяр: аның сүзләренә күп җырлар җырлана бездә (радиодан да, төрле концертларда да менә 40 елга якын яңгырый алар!), һәм иң кызыклысы — унбишкә якын җырына көй канатын татар композиторлары куйган. Һәм кемнәр диген! — М. Мозаффаров, С. Садыйкова, Р. Яхин, Ә. Бакиров,, Х. Вәлиуллин, Ф. Әхмәтов һ. б. Менә кайбер җыр исемен дә атап үтим: «Нигә генә икән», «Төшерәм исләремә», «Кешеләргә барам». Соңгысы бигрәк үзенчәлекле яңгырый бит: әйе, шагыйрь гомере буе «кешеләргә бара», аларны, йөрәкләрне, халыкларны якынайта. Бу очракта безнең халыкларны — татар белән башкортны, игезәктәй ике туган халыкны... Уйламаганда төрле бәхәс, үпкә-сапкаларга юлыгып, хәтта әрләшеп тә ала торган, әмма тагын айнып, дуслыкка, туганлыкка йөз белән борылган, гаҗәеп, «феномен» диярлек уртак язмыш ияләрен... Йә, шагыйрь башкача була аламы соң инде?! Хисле, моңлы, уйчан зат бит ул!

Менә алдыгызда Шәриф аганың 70 яшь тулу уңае белән тәкъдим ителә торган шигырьләре... Алар белән дә күренекле башкорт шагыйре безгә якыная, әйе, шиксез, «кешеләргә бара» дип ышанам мин.

Рәдиф ГАТАШ

●

## Шәриф Биккол

### Туфан елмаюы

*Бөек шагыйрь Х. Туфанның якты истәлегенә*

Җырларында ул —
нечкә җан,
газапта —
булат иде;

жаны тартканнар алдында
ул сабый була иде...

Зар белмәде,
бөгелмәде —
Туфанга бу ят иде:
кеше кыяфәтендәге
Илаһи бер Зат иде!

Какса-сукса да заманы,
өтсә дә ыжгыр җиле,
Туфан йөзендә
өзлексез
елмаю балкыр иде!

Ул чырай сыта белмәде —
ачуы чиктән ашса,
хәтта
нәфрәтен кадады
зәһәр елмаю аша!

Кайгылар куера калса
тәкатьсез аңнарымда,
Туфанның шат елмаюы
балкый күз алларымда!

## Әнием киңәшләре

Әниемнең вафатына күпме заман...
Әмма әйткән киңәшләре энҗе сыман:
җан түремдә балкып тора әле һаман!

...Җиткерергә иде сезгә шуны чамам...

«Юкка бәхәс корырга дип ярсып торма,
юл авыр дип, адымыңны кире борма;
аякларың тартмый икән — юлга чыкма,
тәгәрәгән тәгәрмәчкә таяк тыкма.

Үз йөгеңне үзең илт — чит иңгә салма,
кемдер синнән киңәш көтсә, телсез калма;
бушка килгән хәрам сыйны тамчы йотма,
бер дә юкка кулларыңа камчы тотма.

Дусларыңның дусларына исәп корма,
дошманыңның пошканына авыз ерма;
ярдәм кулы суз бәндәгә — ярдан этмә,
кемнәрнеңдер көмешеннән өлеш көтмә.

Сөмсезләнеп һәр чакырган җиргә барма,
ачык авыз алдында да борчак ярма;
синнән өлкән бар тәкъдирдә — түргә узма,
буең җитмәс нәфис ярга нәфсе сузма.

Тынчып яткан үле күлдә балык сөзмә,
көткәннәрнең өметләрен берүк өзмә;
кирәкләрең бар чагында читкә китмә —
йорт-илеңне таянычтан мәхрүм итмә.

Бурыч — иман, вакытында түлә, тотма,
ачуыңны чыгара тор — эчкә йотма;
күңелеңне изгелектән сүрелдермә:
ата-баба әманәтен боза күрмә!»

...Әнкәемнең киткәненә күпме заман,
ә энҗеләр әвәлгечә балкый һаман...

Сулышымның актыккысын алгангача
Һәр киңәшкә тугры калу — минем чамам!

## Көткәннәргә авыр...

Аерылышулар авыр:
өзелә лә бавыр!
Күзкәйләреңнән яшь тамар,
җаныңа ут кабар;
мең газап
таш булып явар,
йөрәккә кан савар...

Киткәнне дә,
көткәнне дә
сагыш моңга салыр;
сагышлардан котылу юк —
качсаң,
эзләп табар;
сарыларга сабышырсың —
була күрче сабыр!

...Кайтасы кеше бер кайтыр,
көткәннәргә авыр!

## Чакыра башлар инде...

Кәккүк кунды күк тирәккә,
чакыра башлар инде:
гомерем күпме калганын
дөньяга фашлар инде...

Чакыра торгач,
көтмәстән
тотлыгып калмагае:
болай да зарлы башымны
кайгыга салмагае...

Улатасым килми хиснең
котырган өермәсен:
сөенмәсен җаһил җаннар,
дусларым көенмәсен...

## Яннарымда түгел, җаннарымда...

Киттең,
борылып та карамадың...
...Калдым
ни үле дә,
ни тере.
«Хак Тәгаләм,— дидем,—
дуамалың
айныгыры,
тәүбә иткере!..»

Ялваруым
җилгә җилгәрелде —
кабул кылмагандыр Ходаем:
йөрәгемне кырган теләгемә
кул куймагандыр ул, мөгаен...

Яннарымнан киттең бөтенләйгә...

...Юк, юк —
хаталанам, күрәсең:
яра эзе булып,
син һаман да
җаннарымда кала бирәсең...

# ШИГЪРИЯТ



Шушы елның 18 маенда шагыйрә ЭНҖЕ МӨЭМИНОВАГА 70 яшь тула.

Энҗе Һилалетдин кызы Мөэминова 1924 елның 18 маенда Әлмәт районының Яңа Кәшер авылында туган. Аның әтисе Әлмәтнең нәселдән килгән оста тимерчесе була, шуңа күрә бу гаиләгә еш кына авылдан авылга күчеп йөрергә туры килә. 1931 елга кадәр алар Тымытык авылында яши, аннан кабат Әлмәткә кайталар.

1941 елда Әлмәт урта мәктәбен тәмамлагач, Э. Мөэминова хезмәт юлын башлый. Ул башта Әлмәт районының Югары Мактама мәктәбендә, аннан соң Мәмәт һәм Габдрахман авылларында балаларга математика фәне укыта. 1944 елда Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетына читтән торып укырга керә. Ике елдан Ташкент педагогия институтының көндезге бүлегенә укырга күчә һәм 1948 елны аны тәмамлап, Габдрахман авылына укытырга кайта. Шунда 1974 елга кадәр укытучы булып эшли.

Энҗе Мөэминованың беренче китабы Татарстан китап нәшриятында 1961 елда басыла. Шуннан соң аның «Әниләргә һәм нәниләргә» (1964), «Шигырьләр» (1966), «Синең өчен язам», (1968), «Үрдәгем үпкәләде» (1969), «Бүләгем» (1970) һәм башка күпсанлы китаплары дөнья күрә. Шагыйрә олкәннәр өчен дә һәм балалар өчен дә бердәй активлык белән иҗат итә. Э. Мөэминованың матбугатта сүз алган байтак каләмдәшләре аның әсәрләренең уңышлы якларын билгеләп үттеләр, укучы тарафыннан яратып кабул ителүен әйттеләр.

Шагыйрә хәзер дә тынгысыз иҗат утында яна, үз укучыларына яңадан-яңа әсәрләр бүләк итә.

«Казан утлары» журналы редакциясе шагыйрәне олы юбилее белән кайнар котлый һәм аңа иҗат уңышлары тели!

## Энҗе Мөэминова

### «Мин сине я — ра — там!»

Шагыйрьләр бит, бөтен гомерләре буе
Китә алмый егет чагыннан.
Шагыйрәләр, җырларына кертеп һаман,
Тәүге мәхәббәтен сагына.
Бик тиз генә кайтып килим әле мин дә
Тәүге мәхәббәтем янына.

Оныклар бит әнә:
«Сөйлә, сөйлә!» — диләр,
«Мәхәббәт ул ничек килә?» — диләр.
... Беренче мәхәббәт була,
Була соңлаганы.
Табылып югалганы була,
Җавапсыз калганы,
Минем өлешемә туры килде мәхәббәтнең
Хәбәрсез югалганы...
Аның ни икәнен белми идем әле,
Көтми идем әле.
Көтмәгәндә килде!
Бер көнне ул
Мин укыган класс бүлмәсенә
Үзе килеп керде!
Һәм килде дә:
— Үзең генә укы, яме! — диеп
Серле кәгазь бирде.
Учымдагы кәгазь кисәгеннән
Тәнемә ут капты.
Йөгерә-атлый өйгә кайттым.
Олы гаеп эшләгән бер кеше сыман,
Кача-поса
Әлеге серле хатны ачтым!
Сүзләр җемелди! Хәрефләр сикерә!
Өч кенә сүз иде анда!
Бары өч кенә!
Өч кенә сүз иде
Конверты да, адресы да булмаган ул хатта:
«Мин
сине
я — ра — там!»

...Шул минуттан башлап минем белән
Әллә нәрсә булды!
Бар дөньям онытылды.
Күз алдымда таныш шәүлә,
Колагымда — таныш тавыш.
Йөрәгемдә әллә шатлык,
Әллә сагыш.
Сүзләр йөрәгемә уелдылар.
Ә соң хатны, хатның үзен кая куярга?!
Ертыргамы? Юк, юк, кулым бармый!
Иркен өйдә урын таба алмыйм —
Уч төбемә сыйган кош теледәй
Шушы нәни хатны яшереп куярдай.
Кайда гына куйсам да,
Аны кемдер табар сыман,
Йөрәгемнең изге сер сандыгын
Ачып карар сыман.
Өйгә сыймас шушы изге хискә
Җавап сүзен әйтер өчен,
Чара таба алмый,
Янып-көеп йөргән көннәрдә,
Хәбәр килде аңа — китәргә!
Фронтка! Сугышка!
... Озатып калдым аны,

Сөю катыш моңсу карашына
Җавап итеп:
«Сау бул! Китәм!...» — диеп кенә
Әйтә алдым бары.
Ә ул, шулай китте дә, югалды...
Минем өчен мәңге онытылмаслык булып,
Йөрәгемә уелып, әлеге өч сүз калды:
«Мин
        сине
                я — ра — там!»

Аңа җавап сүземне мин,
«Мин дә сине бик-бик яратам!» — дип,
Бар табигать ишетерлек итеп,
Урманнарга әйттем, әйттем кырларга.
Әйттем аны очар кошларга мин,
Шигырь сүзе итеп яздым,
Җырларыма керттем.
Инде менә, изге яуда хәбәрсез югалган
Тәүге сөю сүземне мин,
Сезгә сөйләп биреп бүген,
Дөньяга фаш иттем!
... Гомеремдә бик күп хат укыдым мин,
Укыдым да, күбесен оныттым.
Ләкин менә бусын бүген дә әле
Күңелемдә саклыйм — онытмыйм!
Өч кенә сүз иде анда бары,
Конверты да юк иде хәтта.
Зур тормышка булган мәхәббәтнең
Яралгысы иде ул хатта:
«Мин сине я — ра — там!»



# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XII СЪЕЗДЫ АЛДЫННАН

Инде хәбәр иткәнебезчә, шушы елның 3 июнендә Татарстан язучыларының чираттагы XII съезды җыела. Шул уңайдан редакция язучыларга түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать итте:

***1. Язучыларыбызның XI съездан соң үткән 5 елдагы иҗатына һәм аерым әсәрләргә карата Сез нинди фикердә?***

***2. Әдәби процессны оештыру ягыннан бу елларда Татарстан Язучылар берлеге һәм әдәби басмалар башкарган эшләрдән Сез канәгатьме? Сезнеңчә, XI съезд карарлары тиешле дәрәҗәдә үтәлдеме?***

***3. Әдәби фондның алдагы эшчәнлеге нинди булырга тиеш?***

***4. Алда торган съездан Сез нәрсәләр көтәсез?***

***5. Иҗат берлегебез татар әдәбиятын тагын да үстерү өчен нинди мөһим чаралар үткәрергә тиеш дип саныйсыз?***

Түбәндә редакциягә алынган җаваплар урнаштырыла.

## Владимир Корчагин:

**1.** Урыс телендә иҗат итүче язучыларның соңгы биш елда басылган әсәрләре турында мин шуны әйтә алам: өлкән һәм урта яшьтәге әдипләрнең күбесе иҗат осталыгын тагын да арттырды һәм үз әсәрләрендә җәмгыять өчен мөһим булган темаларны яктыртты; шул ук вакытта әдәбият мәйданына бер төркем өметле яшь каләм ияләре килде, алар укучы каршындагы тәүге сынауларны уңышлы үтте. Беренче төр әдипләргә мин Г. Паушкин, Р. Кутуй, Ә. Мушинский, Д. Вәлиев, И. Киндер, Н. Орешина, Н. Бедяев һәм Р. Кожевникованы кертер идем. Ә инде соңгы елларда актив иҗат иткән яшьләр дигәндә, әлбәттә, М. Вәлиева, С. Малышев, Р. Сабиров, В. Трофимов, Н. Алешков, С. Гордиенко, Е. Сухов, Н. Кондудин, Е. Бурундуковская, О. Левадная һәм башкаларны күздә тотам.

**2.** Минем фикеремчә, Татарстан язучыларының соңгы съезды карарлары, нигездә, үтәлә шикелле. Ләкин яңа сайланган җитәкчеләр китапны басучы һәм таратучы оешмалар белән эшләүнең реаль нәтиҗә бирердәй юлларын тапсыннар иде.

**3.** Әйе, язучылар социаль яктан бер дә якланмаган бездә: аларның ышанычлы хезмәт хакы да юк, түләүле ял да бирелми, авырып киткән чагында язучы кеше матди яктан тәэмин дә ителми, дәвалау-сихәтләнү учреждениеләреннән дә җитәрлек файдалана алмый. Элекке елларда бу мәсьәләләрдә әдәби фонд ярдәм итә иде. Ә хәзер ул вазифаны кем, кайсы оешма үз өстенә алыр икән? Үзеннән-үзе аңлашыла: әгәр дә әдәби фонд инде терелә алмый икән, ул чагында Язучылар берлегенең бу эш белән шөгыльләнә торган махсус бер бүлеге булырга тиеш.

**4.** «Алдагы съездан ни көтәсез?» дигән сорауга элекке елларда бик купшы сүзләр белән җавап бирәләр иде һәм андый вәгъдәләр, ышандырулар, нигездә, буш сүз булып кала иде. Чөнки талантлы язучы ул үз әсәренең язмышын тулысынча үзе хәл итә, аңа бернинди карарлар һәм директивалар да ярдәм итми. Ә мин исә алдагы съездан чынлап та үтәлердәй конкрет планнар көтәм. Ул карарлар язучының социаль-көнкүреш шартларын яхшыртуга юнәлгән булсын иде. Шулай ук әсәрләрне дөньяга чыгару мөмкинлеге дә артсын иде.

5. Хәзерге чорда иң мөһим мәсьәлә булып укучылар даирәсе белән бәйләнешне өзмәү тора. Әгәр дә укучысы юк икән — әдәбият яши алмый. Хәзер безнең җәмгыятьнең коммерция ягына кискен авышуы хәлне бик хәвефле итә. Шуңа күрә Татарстан язучыларының әсәрләрен бастырып чыгару мәсьәләсе бүген гаять тә житди төс ала, ул үзенә зур игътибар сорый. Югыйсә, бездә ни килеп чыга: сәүдә оешмалары алдан ук акча түләп куймагач, нәшрият китапка тираж оештыра алмый. Ә сәүдә оешмасы исә чыкмаган һәм сатылмаган китап өчен алдан акча түли алмый. Шулай итеп, эт — эткә, эт — койрыкка дигән шикеллерәк килеп чыга. Бередә инде аңлашыла — хөкүмәт ярдәменнән башка уңай якка үзгәреш ясап булмаячак. Кыскасы, әдәбиятны үстерү өчен реаль ярдәм кирәк.

## Басыйр Рәфыйков:

Чиләбе өлкәсе

1. Миңа калса, «Татарстан язучыларының XII съезды» дип язу үзе үк дөрес түгел. Нигә ул Татарстан һәм аның мәркәзе Казан язучыларының гына съезды булырга тиеш әле?

Илнең башка төбәкләрендә һәм башка илләрдә яшәгән 5 миллионнан артык татар арасында да язучыларыбыз бар бит әле. Алар күтәргән темалар да халкыбызның үткәнен һәм бүгенгесен яктырта бит һәм, күп вакытта, үзенчәлерәк тә яктырталардыр әле. Алар шул төбәкләрдә яшәгән халыкның яңа, безгә билгеле булмаган сыйфатларын, башка милләттән булган халыклар белән булган бәйләныш, мөнәсәбәтләрен ачалар.

Үткән XI съездда чит төбәкләрдән килгән татар язучыларына караганда, Мәскәүдән килгән урыс язучыларының һәм башка республика (хәзер башка дәүләт дип әйтик) телендә язучы кунакларның саны күпкә артык иде.

Минемчә, бүгенге татар әдәбиятының төп бурычы: татар халкын уяту, берләштерү, туплау, аны борынгы данлы — шанлы дәрәҗәсенә күтәрү. Тагын халкыбызның уңай һәм тискәре якларын күрсәтү, бөек тарихын ачу, онытылган, халыкка билгеле булмаган шәхесләрен барлау, югала барган телен, гореф-гадәтләрен торгызу. Кабатлап әйтим, бу мөһим бурычларны Татарстан язучылары белән генә эшкә ашырып бетереп булмаячак.

1992 елның 19 июнендә узган Бөтендөнья Татар Конгрессында Президентыбыз Минтимер Шәймиев: «Татарлар кайда гына яшәсәләр дә, безнең мәдәниятебез бер. XX гасыр башында татарларда милли тормышның берничә үзәге барлыкка килде. Уфа, Оренбург, Мәскәү, Петербург, Уральск, Троицк һ.б. Бу шәһәрләр, еш кына, хәтта Казанның үзе белән көндәшлек итәргә сәләтле мәркәзләр иделәр. Кызганычка каршы, соңгы елларда аларның мәркәзлекләре бетерелде. Бу үзәкләрне торгызу өчен барысын да эшләргә кирәк»,— дигән иде. Ә нәрсә эшләнә? Бу якларда яшәүче татар халкы, аларның тарихы, бүгенге көне турында язучылар берәр әсәр иҗат иттеләрме? Мондый житешсезлекләр иң башта әдәбиятыбызның таркаулыгыннан, илдәге милли-әдәби көчләрне бербөтен итеп туплый белмәүдән килеп чыга бит.

Ә XI съездан соң үткән бишьеллыкка килгәндә, иҗади уңышлар байтак булды. Халыкның аңын уятырлык, үткәненә, бүгенге көненә бәя бирерлек байтак әсәрләр дөнья күрде. Мондыйларга мин М. Хәбибуллинның «Шайтан каласы», А. Расихның «Ишан оныгы», Ә. Еникинең һәр яңа әсәрен, Р. Батулланың «Сөенбикә кыйссасы», Ә. Баянның «Урланган ай», Г. Тавлинның «Афәт», Аяз Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога» әсәрләрен кертер идем.

Бу әсәрләр әдәбиятыбызның олы адымнар белән алга барганлыгын, тарих кантарларын актарганын һәм бу эштә татар язучыларының башка республикалар әдәбиятыннан түбән булмавын раслый.

Әмма, кызганычка күрә, безнең кайбер әдипләребез, урыс әдәбиятының иң ямьсез күренешләреннән үрнәк алып, безнең халык өчен бөтенләй чит-ят әсәрләр иҗат итәләр. Яшьләр тарафыннан гына түгел, олылар тарафыннан да шатланып, көтеп алынган һәм шактый көчле әсәрләр бастырган «Идел» журналы Владимир Казанскийның «Мокытлар заманы» повестен биргән. Бу, русча әйтсәк, «низкопробный» әсәр, яшьләрне нәрсәгә өнди, нәрсәгә чакыра соң? Аңлатыгыз шуны, тәнкыйтьче иптәшләр!? Инде Ләбиб Леронның «Шайтан шаяруы» дигән каһкаһәле хыялый кыйссасын алыйк. Бу — татар әдәбияты тарихындагы иң пычрак, иң җирәнгеч әсәр. Бу әсәр «Идел»нең битен дегеткә буяган.

Шундый әсәрләргә ияреп тер инде. Чиләбедә чыга торган «Дуслык» газетасы «Елмаеп-көлеп» кенә менә мондый анекдотлар да бирә башлады:

— Яратасыңмы?

— Яратам.

— Өйләнәсеңме?

— Өйләнмим.

— Төш алайса.

Поэзиягә килгәндә, уңышлар шактый булды шикелле. Шартлар авыр булуга карамастан, эчтәлекле матур-матур җыентыклар чыктылар. Мин алар арасыннан Г. Афзал белән И. Юзеев китапларын аерым әйтер идем.

**2.** Әдәби процесс Татарстан язучылар берлегендә ничек баргандыр — әйтүе кыен. Әмма, чит төбәкләрдә яшәүче язучылар ул турыда хәбәрдар булмадылар. Безнең әйтик, Чиләбе өлкәсенә бүген Язучылар берлеге һәм әдәби басмалар башкарган эшләр килеп җитми.

Хәер, бу елларның иң әһәмиятле, иң күренекле хезмәте — «Татар поэзиясе антологиясе». Бик авырлык белән булса да, ул минем кулга да эләкте. Аны төзеп, эшкә кертеп, бастыра алган иптәшләргә түбәнчелек белән баш иям.

**3.** Союзда әгъза булып тору яшәгән урынга бәйле иде элек. Чиләбе язучылар бүлеге, билгеле инде, урыс язучылары бүлеге. Аның әдәби фондында мин 1974 елдан бирле әгъза булуга карамастан, бер мәртәбә дә, берниндн дә ярдәм алганым булмады. Ике тапкыр путевка сорап биргән үтенечем дә кире кагылды. Взнос түләп кенә үземнең әгъза икәнлегемне белеп яшәдем.

**4.** Булачак съезддан нәрсә көтәм? Киләчәктә Татарстан Язучылар берлеге безне дә үз кешеләре итеп санасын иде.

**5.** Бөтен татар язучыларын ярдәм оешмага тупларга кирәк. Язучылар берлегенең җитәкчеләре һәрбер язучының эшенә, яшәешенә, кирәк икән иҗатына ярдәм кулын сузарга тиештер дип уйлыйм.

Һәм иң соңында китап мәсьәләсе. Чиләбе, Троицк, Магнитогорск шикелле татарлар күп яши торган калаларда хәзер бер генә татар китабы да юк. Газета-журналлар кыйбат, аларны алдыручы аз. Казан радиосының да һаман зур эфирга чыкканы юк. Ә телевидение турында әйтәсе дә юк инде... Юкса татар халкы Россия җирендә, урыслардан кала, сан ягыннан икенче урынны алып торган милләт бит.

Ә чынбарлыкта мәкалдәгечә: «Исәпкә бар, санга юк»быз.

## Ркаил Зәйдулла:

**1.** Әлбәттә, гәҗит-журналларның саны арту сәбәпле әдәби әсәрләрне дөньяга чыгару өчен мәйдан киңәйде. Ләкин бу шатлыклы күренешнең сыйфат мәсьәләсенә тәэсире булмады диярлек дә мөмкин. Киресенчә, бу болганчык заманда күбрәк чүп өскә калыкты шикелле...

Шулай да әдәби мохитта күңелгә куаныч өстәп торучы вакыйгалар да җитәрлек. Тарихка булган кызыксынуның артуы сөендерә. Күпме әсәр укучы кулына килеп керде. Тик җанда бер моңсулык та яши. Соңармадыкмы? Әрмәниләр, гөрҗиләр җиң сызганып тарихи романнар дөньяга чыгарганда, без бит, производство романы дип, колхоз рәисе белән парторг арасындагы конфликт дип шау-гөр килдек. Безнең фәлсәфәбез, дөньяга карашыбыз шул тирәдән узмады. Милли үзаңның үсмәвендә, шиксез, язучыларның да гаебе бар. Карагыз инде сез, адәм көлкесе: берничә ай гына элек күрше Русиянең думасына сайлауларга байкот игълан иткән авыл халкы шундый ук бердәмлек белән бии-бии депутатлар сайлый. Өч ай эчендә фикере шулай тиз үзгәрә алган халыкны милләт дип атап буламы? Хурлык бу безнең барыбыз өчен дә! Өстәвенә, шул миңгерәүләнгән халыкны сайлауларга барырга өндәп чыгыш ясаган язучылар да булды. Җил кайсы якка иссә, шунда авышып тору түгелме соң бу? Мондый очракта әдәбиятның дәрәҗәсе турында ничек сөйләнергә мөмкин?..

Билгеле, халкы нинди — идарәчесе дә шундый, дип акланырга да буладыр... Әмма халыкның визит карточкасы итеп беркайчан да Табеевны түгел, ә миңа калса, Хәсән Туфанны таныдылар. Бүген дә хәл шулайрак булса кирәк. Шуңа күрә язучыларыбызның бик чиста, керсез булуларын күрәсе килә... Гомумән, әдәбият аксакалы сүзен үлчәп сөйләргә, гамәлләрен дә олпатлык белән кылырга тиештер дип уйлыйм.

**2.** Мин үзем дә моннан берничә еллар элек Язучылар берлеген «язучылар колхозы» дип атаган идем. Хәзер уйлыйм: ул вакытта минем тарафтан яшьлек максимализмы булган, ахрысы бу. Канәгатьсезлек бар анысы. Тик кем генә хәзер

тормыштан канәгать соң? Барыбер беркем дә тормышны ташлап китәргә җыенмый ич...

Язучылар берлеген НКВДлар, ГПУлар белән бер вакыттарак, бер максаттан чыгып большевиклар оештырган дип икърар итүчеләр дә бар. Билгеле, Сталинга язучыларны бер кулга җыю файдалы булгандыр. Тик язучыларның үзләренең дә бергәрәк җыйналырга теләвен онытып бетермәскә кирәк. Бүтән илләрдә дә язучыларның, шагыйрьләрнең берлекләре, синдикатлары, ассоциацияләре бар. Бу авыр заманда язучылар да бер-берсенең иңнәрен тоярга телиләр икән, монда нинди зыян табарга мөмкин?

Аннары, колхозлар да таралмады бит әле. Киресенчә, сөекле Татарстан тупрагында, шәхсән Шәймиев әфәнде җитәкчелегендә, колхозлар гөрләп чәчәк атып утыра. Безнең берлек тә яшәр... Структурасы ничек булыр, ансын киләчәк күрсәтер.

3. Әдәби фондның алдагы эшчәнлеге турында берни дә әйтә алмыйм.

4. Әгәр дә язучы элеккеге еллардагы кебек бу съезддан ниндидер күрсәтмәләр көтсә, ул кызганыч вә көлке булыр иде. Съездда күптән күрмәгән каләмдәшләрне күрергә, әдәбият хакында гәп сатарга мөмкин. Бу, үзе генә дә инде безнең заманда зур вакыйга!

5. Язганда без язу өстәле белән икәүдән-икәү калабыз. Әсәр яхшы килеп чыгармы, аның татар әдәбиятын үстерүгә нинди өлеше булыр — иҗат берлегенең моңа бернинди дә катнашы юк. Безнең барыбызны да Вакыт галиҗәнапләре хөкем итәр, ә Аллаһы Тәгалә ярлыкар.

## Гариф Ахунов:

Минемчә, сораулар бик зурдан кубып куелген. Алар ике съезд арасында татар әдәбиятына кемнең күпме өлеш керткәнен, димәк ки, татар әдәбияты нинди юнәлештә үскәнлеген, аның нинди уңышлары, нинди кимчелекләре барлыгын исәпләргә мөмкинлек бирмиләр.

Миңа калса, сораулар менә мондыйрак булырга тиеш:

**Беренче сорау:** Ике съезд арасында Сез нинди әсәрләр яздыгыз?

**Җавап.** Мин ике съезд арасында «Гомер юлы» романын, «Акча күктән яумый», «Тимерханның яшьлеге» повестьларын, «Кыйбатка төшкән үлем», «Мәрьям — ут күбәләге» хикәяләрен, күп кенә публицистик мәкалә һәм әдәби портретлар яздым. 20 серияле «Тукай» нәфис фильмы өчен, кинорежиссер Әхтәм Зарипов белән бергәләп, җиде сериянең сценарием иҗат иттем.

**Икенче сорау.** Ике съезд арасында нинди җәмәгать эшләре алып бардыгыз?

**Җавап.** Татарстанның мәдәният фондын җитәкләдем. Язучылар берлегенең идарә әгъзасы буларак, аның барлык утырышларында катнаштым, язучы-каләмдәшләремнең материаль хәлен җиңеләйтергә булыштым. «Казан утлары»ның редколлегия әгъзасы буларак, ике мең биттән артык кульязма укыдым. Төркиядә төрки язучыларының күмәк берләшмәсен төзүдә катнаштым.

**Өченче сорау.** Нинди әсәрләрегез БДБ илләрендә һәм башка чит илләрдә тәрҗемә итеп басылды?

**Җавап.** Казагыстанда һәм Төркмәнстанда «Хәзинә» романым казакъ һәм төрекмән телләрендә басылды. «Идел кызы» романым Төркиядә төрек теленә тәрҗемә ителә. Шушы ук роман урысча, улым Рәшит Ахунов тәрҗемәсендә, Мәскәүдә һәм Казанда басылып чыкты. Үзем башкорт язучысы Галим Хисамовның 20 табаклы повесть һәм хикәяләрен татарчага тәрҗемә иттем.

**Дүртенче сорау.** Татарстанның мөстәкыйльлеге хакына ниләр эшләдегез?

**Җавап.** «Ватаным Татарстан», «Татарстан хәбәрләре», «Казан утлары», «Татарстан» журналларында мәкаләләр бастырдым, татар әдәбиятының җитмеш елда үзәк әдәби журналыбыз булган «Казан утлары»ндагы чагылышын тасвирлап һәм анализлап язган «Олы юлның тукталышлары» дигән зур очеркым дөнья күрде. Радио-телевидениедә татарча һәм урысча чыгышлар ясадым.

**Бишенче сорау.** Язучылар оешмасы яшәргә тиешме? Аның лидеры булырмы?

**Җавап.** Һичшиксез. Көрәшкә чыккан гаскәр командирсыз була алмый. Аның лидерын съезд сайлар.

**Алтынчы сорау.** Әдәби фонд яшәрме?

**Җавап.** Әйтүе кыен. Аның язмышы Россиянең һәм Татарстанның нинди юнәлештә үсүенә бәйле булачак.

**Җиденче сорау.** Язучылар берлегенең ике съезд арасындагы эше ничек бәяләнергә тиеш?

**Җавап.** Гадел рәвештә. Объектив. Бәяне съездда барлык язучылар бирергә тиеш. Татар әдәбиятының саф тәненә чуан булып чыккан әрсез һәм сәләтсез ялачылар түгел.

**Сигезенче сорау.** Ике съезд арасында әдәби хәрәкәтебездәге иң зур кимчелек нәрсә?

**Җавап.** Гадел уйлый, гадел яза, тирән анализ ясый һәм югары сәнгатьне халтурадан, һөнәрчелектән аера белә торган тәнкыйтьчеләрнең әдәбият мәйданыннан китүендә, башбаштаклыкка, ялачыларга юл куюында.

**Тугызынчы сорау.** Татар әдәбиятының киләчәге нинди булыр?

**Җавап.** Якты булыр, зур булыр дип өметләнем. Тирән белемле, кыю йөрәкле, талантлы яшьләр үсеп чыкты. Барлык жанрда да. Съездның зур булып, житди булып узуын телим.


**Редакциядән:**

**Журналыбызда 5 сан рәттән урнаштырылып килгән «Татарстан язучыларының XII съезды алдыннан» дигән бу анкетаның сораулары башта машинкада бастырылып 90 нан артык язучыга җибәрелде. Алар арасында әдәбиятның төрле жанрында татар һәм урыс телләрендә иҗат итүче әдипләр, географик яктан караганда, төрле шәһәрләрдә яшәүче өлкән, урта, яшь буын вәкилләре бар иде.**

**31 мартка кадәр — бу көнне журналның 5 иче саны типографиягә тапшырыла — барлыгы 25 язучыдан җавап алынды. Былтыгы 1 саннан башлап һәр санда берничә әдип җавабы журналда урнаштырыла килде.**

**Укучылар күргәннәрдер: редакция тарафыннан куелган сорауларга язучыларыбыз төрлечә җавап бирәләр. Безнең фикеребезчә һәм соңгы елларда республикабызда урнашкан иҗтимагый-сәяси тормыш раслап торганча, мондый төрле карашлар чагылу хакыйкатьне тулырак аңларга ярдәм итә, төрле тайпылышлардан саклый кебек. Уртак эшне яхшырту өчен дә фикер һәм тәкъдимнәрнең күбрәк булуы зарур. Татарстан язучыларының июнь аенда булачак зур җыены да шуны раслар дип уйлыйбыз.**

# АНЫҢ ЯШӘҮ РӘВЕШЕ



Яшь аермалары шактый булса да, университетта без бер чорда укыдык. Ике генә курска алда иде ул. Шулай да, аралашып яшәдек дип әйтә алмыйм. Хәер, андый шәриктәшлек өчен мөмкинлек тә, андый хаҗәт тә булмаган аңарга. Бик табигый: без әле яңа гына мәктәп бетереп килгән, малайлыгы чыгып җитмәгән унҗиде яшьлек егет кисәкләре... Ә ул инде (60 нчы еллар башында) яше белән утыз ягына авышкан, күп җир-сулар күргән, төрле халыклар арасында яшәп, телләрен, гореф-гадәтләрен үзләштергән, кыскасы, бу дөньяның шактый «лаеш шулпасын чөмергән», азау теше чыгып, акыл утырткан ир-егет иде. Үз группаларындагы яшьтәшләре белән дә артык әвәрә килеп йөрмәде шикелле. (Ә яшьлектә күңелнең күңелен күреп, заяга вакыт уздыру өчен җайлар күп инде ул!). Тулак торакларда яшәп мәшәкатьләнмәде, әдәби түгәрәкләрдә яки кыз-кымыз җыелган җирләрдә, кайберәүләребез кебек, «даһи шигырьләр» укып йөрмәде...

Йөргән җире аның бүтән: фәнни китапханә иде. Көндәлек мәшәкатьләренә сарыф иткән вакытыннан тыш, иң күп гомерен ул шул мирасханәдә — кульязмалар, борынгы китаплар дөньясында уздырды. Шуңа күрә, ул студент булып бик хәтердә дә калмаган. Белеме белән дә, үз-үзен тотышы белән дә ул — укытучылар составы вәкиле сыман тоела иде. Безне укытып йөргән өлкән укытучы, доцент кебекләрдән аерылмый диярлек иде. Аерылса да, тарихи белеме, үткәнне һәм киләчәкне күзаллавы белән, фәкать уңай якка гына аерылгандыр.

Мәгарәгә бикләнеп белем алган Әбүгалисина белән Әбелхарисларны хәтерләткән аның бу үҗәт максатчанлыгы ул чакта без яшьләр өчен бераз сәеррәк тоела иде. Әмма хәзер — еллар аша карагач, Миркасыймның бу яшәү рәвеше, омтылышы бик тә аңлашыла.

Аның тарих-филология факультетының татар бүлегендә уку белән генә чикләнмичә, өченче-дүртенче курслардан соң, тарих буенча да белгечлек алуы, шул рәвешчә ике бүлекне бетерүгә ирешүе дә бүген яхшы аңлашыла. Халыкның узганын, хәзергесен аңлар өчен аның телен, әдәби фикерен белү никадәр мөһим булса, тел-әдәбиятның серләрен ныклап төшенер өчен шул халыкның тарихын да төпченеп өйрәнү зарур. Нәтиҗәдә, Миркасыйм Госманов университетны һәм филолог, һәм тарихчы буларак, ягъни ике белгечлек алып тәмамлый. Бу исә аңа борынгы кульязмалар дөньясына иркенләп керергә мөмкинлек бирә.

Корсаклар чагыштырмача тук булса да, күңелләр ябык, өметләр сыек ул заманнар өчен мондый максатчанлык,

фанатикларча фәнгә бирелү икеләтә, өчләтә зарур иде. Рус колониальполитикасының «прогрессивлыгын», совет чорында СССР халыклары ирешкән «казанышларның» әһәмиятен күперткән мөтәтарихчылар өчен шәп еллар иде алар. Каганлык, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларын объектив өйрәнеп, тарихи дөрес бәяләмә биреп аңлату мөмкин дә түгел иде диярлек.

Кытайда туып-үскән, Тянь-Шань тауларын айкаган, казакъ далаларын иңләгән, Борынгы Ефәк Юлларын кичкән, төрки халыклары тарихы буенча шактый «белем биштәре» булган «яшь студент»-галимгә нишләргә кала? Тагын да белемне тирәнәйтергә, фәнне фән, тарихны тарих санап хакыйкатьне расларга. Булган белем, җыелган акыл бер бәреп чыгар әле!

Һәм чыкты да! Без бүген Миркасыйм Госманов турындагы белешмәләрдә менә мондый мәгълүматләр укыйбыз. Ул — тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан фәннәр академиясе академигы, Казан университетының татар халкы тарихы кафедрасы мөдире, фәнни-тикшеренү археографик лабораториясенең гыйльми җитәкчесе, республикада чыга торган абруйлы басмаларның редколлегия әгъзасы... Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. Европа, Азия, Америка илләренә барып, төрле фәнни конференция-җыеннарда лекция-докладлар ясаучы халыкара масштабта мәгълүм галим. Ә бит 1958 елны Казанга килгәндә аның монда бер таныш-белеше дә, таянып ноктасы да булмый. Казандагы гомерен, аның беренче төнен вокзалның «көтү залындагы такта эскәмиясендә» кунып уздырудан башлаган кеше ул *(«Казан утлары», 1992, 4 сан, 107 б.)*.

Бүгенгегә кадәр исән-имин яшәп, алтмыш еллык гомеренең кырык еллабын татарның рухи дөньясын өйрәнүгә багышлаган галим-әдипнең хезмәтләрен бер яклы гына килеп, бер төсле бизмән белән генә үлчәп, бәһаләп бетерү һич мөмкин түгел. Хезмәтләренең бөтен нечкәлекләрен кертеп колачлап бетермәсә дә, Миркасыйм Госманов эшчәнлеген төп өч өлешкә бүлеп карарга була шикелле. **Язма истәлекләрне, әдәби-тарихи чыганакларны җыю, өйрәнү һәм бастырып чыгару, ягъни археограф эшчәнлеге; популяр әдәби китаплар авторы буларак (ул 1970 елдан Язучылар берлеге әгъзасы), язучылык эшчәнлеге; һәм, ниһаять, фәнне оештыру буенча административ җитәкчелек эшчәнлеге.**

Шушы шартлы схема буенча, иң элек, төрле җирләрдә, төрле елларда басылып чыккан кайбер китап исемнәрен атап китү дә урынлы булыр бу очракта. «XVII—XVIII гасыр татар тарихи чыганаклары», «XIV—XVI гасыр Җүчи Улусының ярлыкаш актлары», «Хөсәен Фәезхановның изге хыялы», «Каурый каләм эзеннән», «Үткәннән — киләчәккә»... Боларның кайберләре үтә фәнни стильдә язылса, кайберләре әдәби-популяр телдә иҗат ителгән. Шунысын да искәртеп узыйк: Миркасыйм Госманов татарча да, русча да, хәзергечә әйтсәк, ике дәүләт телендә дә иркен яза ала торган кеше. Миңа калса, бу китапларның иң мөһим ягы шунда: галим татар тарихын ничек булганча объектив яктыртырга тырыша.

Без хәзер үзебез дә әкренләп — кыйтгалардан кыйтгаларга җәелеп, ерак гасырлардан килә торган тарихыбызның тар болгар җирлегенә генә сыя алмавын аңлый башладык шикелле инде. Бу юнәлештә безнең буыннар өчен башлап сүз әйтүче кешеләрнең берсе — Миркасыйм Госманов булды. Җүчи Улусына, ягъни Алтын Урда чорына караган документаль истәлекләр хакында 1979 елда ук — тар болгарчылыкны күпләр дин-иман иткән заманнарда ук — зур күләмле фундаменталь монография язып, аны бастырып чыгару үзе хакыйкатькә омтылу юлындагы бер кыюлык иде.

Академик әзерлек һәм 30 еллап төрле архивларда, халык арасында йөреп кулъязмалар җыеп өйрәнү практикасы галимгә әдәби мирасыбыз, фольклор байлыгыбызның яңа катламнарын күтәрергә мөмкинлек бирә. «Хан кызы», «Яр-яр» җырларының яңа вариантлары, «Түләк-Сусылу» дастанының борынгы тексты табылу үзе ни тора!..

Язма хәзинәлегебезгә тирән керү элекке мәдәни хәятыбызны киңрәк иңләү, аның күренешләрен дөресрәк аңлау өчен җирлек тудыра. Бу хәл үз нәүбәтендә аңа табигый рәвештә татар тарихындагы байтак бөек шәхесләрнең мирасларына яңача караш ташларга, алар хакында торгынлык елларында да кыю-кыю фикер әйтергә мөмкинлек бирә. Хөсәен Фәезханов, Шиһабетдин Мәрҗани, Габделҗаббар Кандалый, Миртахетдин Акмулла, Габдерәхим Утыз Имәни, Риза Фәхретдин, Сәит Вахиди... Бу бөек затларның шактый күләмле китапларының яки алар хакында махсус хезмәтләрнең дөнья күрүендә Миркасыйм Госмановның роле зур. Ул бу басмаларның кайберләренә кереш сүз язды, кайберләрен җыеп туплады, аларны текстологик яктан редакцияләде, искәрмәләр белән шәрехләде, кайберләре турында аерым китаплар язып чыкты.

Җегәре ташып торган бу талантлы шәхес әгәр төп вакытын әдәбиятка гына багышлаган булса, һичшиксез, кызыклы язучы булыр иде. Хәер, яшьрәк чакта — 1960—1970 елларда язылган китаплары да аның чын әдәби каләм иясе булуын раслый. Язучыларга багышланган белешмә китабында Миркасыйм Госмановның бу юнәлештәге эшчәнлеге хакында мондый сүзләр бар: «...язучы-галим укучы яшьләр арасында тарих фәнен киңрәк пропагандалау максаты белән, фәнни-популяр жанрга мөрәҗәгать итеп «Киек сукмакларында», «Серле балбал», «Таулар, үзәннәр иленә сәяхәт» исемле китапларын бастыра. Халкыбызның борынгы тормышын өйрәнүче тарихчы-археологларның хезмәте, кызыклы табышлары, ачышлары хакында сюжетлы хикәяләр рәвешендә язылган бу китаплар укучыга тарих, археология буенча киң фәнни мәгълүмат бирүләре белән әһәмиятле». Үзебездән өстәп әйтсәк, яшьләр өчен үтә мавыктыргыч, өлкәннәр өчен бик гыйбрәтле китаплар алар!

Фәнне оештыру буенча җитәкчелек эшчәнлегенә килгәндә, табигый, һәр зур галим үз тарафдарларын, үз шәкертләрен, үз мәктәбен булдырырга тиеш. Ә мәктәп кадәр мәктәп булдырыр өчен, әлбәттә, тиешле шартлар һәм күпмедер дәрәҗәдә хакимиятлек тә кирәк. Өлкән укытучы, доцент, профессор, кафедра мөдире, проректор, академик... Болар — фәнни оештыру, үстерү эшендә зарур баскычлар. Хикмәт — кемнең күпме баскычка күтәрелеп үз биеклеген ала алуында. Миңа калса, Миркасыйм Госмановның бу юнәлештәге эшчәнлеге өчен аның татар халкы тарихы кафедрасы мөдире, бигрәк тә Казан университеты проректоры булып эшләгән еллары аеруча мәгънәле һәм нәтиҗәле булды. Ул — университетның җитәкче постында эшләгән елларда татар тарихы фәнен, гомумән, мәдәниятен үстерүдә байтак игелекле эшләр башкарылды. Турыдан-туры аның инициативасы һәм актив катнашы нәтиҗәсендә, бу мәшһүр югары уку йортында Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре дип йөртелгән аерым факультет оешты. Милләттәш студентларыбыз ишәйде. 1988 елда КДУда махсус археографик лаборатория булдырылды. Шуның нәтиҗәсендә, берничә дистә еллар халык арасыннан төрле



*Миркасыйм Госманов Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсендәге сирәк китаплар бүлегендә аспирантлар белән. 1978 ел.*

шәһәрләрдәге архивлардан бөртекләп җыелган дистә меңләгән борынгы язма истәлекләренең сакланып калуына, өйрәнелүенә ирешелде. Саный китсәң, ул кылган яхшы гамәлләр байтакка җыйнала.

Галим белән бергә эшләгән, аның белән аралашкан, йөрешкән кешеләр яхшы белә булыр: ул — бик актив, холкы белән шактый кызу һәм кискен шәхес. Бер уйласаң, андый хәрәкәтчән, тынгысыз кеше бүгенге сәяси катаклизмнар заманында төрле социаль төркемнәр арасына керешеп, җәмгыять буталышының эпицентрында булырга тиеш тә кебек. Юк, Миркасыйм Госманов андыйлардан түгел. Аны фани сәясәтнең — сәяси кампанияләрнең теге яки бу ягына аудара алмассың. Ул — көндәлек ыгы-зыгы күбеге белән мәңгелеккә кала торган кристалларны бик яхшы аера. Хәер, вакыйгаларны һәм тарихи төшенчәләрне объектив бәяли алмаган зат нинди галим була соң! Ул бит белә: бөек империяләр һәм бөек шәхесләр булган. Алар туган, беткән... Дөньяны тетрәткән Каганатлар, Алтын Урдалар, гүзәл Сарай шәһәрләре булган — барысы да вәйранга чыкканнар...

Шул ук вакытта аерым халыкларның гына теләгенә, аерым төркемнәрнең мәнфәгатьләренә буйсынмыйча, буыннардан буыннарга күчеп кала торган, әһәмиятләрен югалтмый торган фактлар һәм факторлар да бар. Ниһаять, теләсә нинди шәхесләрдән, лозунг һәм тәгълиматлардан өстен Хакыйкать, объективлык дигән нәрсә дә бар дөньяда. Иҗтимагый хәятнең, тарихның эзлеклелеген, дәвамлылыгын шулар тәэмин итә. Болар белән дә кемдер даими шөгыльләнергә тиеш, уңга-сулга тайпылмыйча, дигәндәй... Минемчә, Миркасыйм Госманов шундыйрак иманны тота. Өстәвенә, профессор-остаз, мөдир-администратор өчен бу болганчык, нәфесләрне аздыргыч заманнарда моңарчы булган гыйльми кадрларны саклау, аларга алмашка яшьләрне әзерләү эше дә мөһимнәрнең мөһиме. Аерым предприятиеләр, институтлар гына түгел, төгәл бер дәүләтләр, империяләр җимерелгән, таркалган шартларда...

Болгавыр замана әледән-әле алга яңа сораулар куя. Болары аз дигәндәй, дөньяның үзе төсле искеләрен дә яңарта: безнең бүгенге яшәвебездән, кылган гамәлләребездән тагын берничә дистә, йөз еллардан соңниләр калыр икән? Гомумән, без бик ерак дип санаган, моннан биш-алты йөз еллар элек булган хәлләр, чыннан да, бик еракмы соң?

Бер генә мизгелгә уйлап багыйк: сиңа кырык, илле яки алтмыш яшьме? — озын гомер кичтем дисеңме? Юк бит, күз ачып йомганда үткән дә киткән!.. Шуңа күрә, Тарих дип әйтәбез икән, без аны син үзең күреп белгән бабаң яки атаң туган, яки фәлән инкыйлаб, социаль тетрәнү елларыннан гына түгел, иң кимендә меңәр ел элек булган чорлардан башлап өйрәнергә тиешбез. Бик гади, наив, әмма мәңгелек хакыйкать — үткәнсез бүгенге юк, бүгенгесез киләчәк юк.

Әгәр халык үзен җиһан таныйрлык милләт булып яшәргә тели икән, тагын бер бәхәссез хакыйкатьне искә төшерик: андый халык хезмәт итә белергә, тарихи истәлекләрен, бүгенге талантларын саклый, бәһали алырга тиеш, һәм ниһаять, үзенең узганын бик яхшы белергә, киләчәген күзаллый алырга тиеш.

Безнең замандашыбыз, олуг шәхес, галим-әдип Миркасыйм Габделәхәт улы Госмановның бөтен иҗаты, ул барлап, саклап калырга тырышкан мирас байлыгы безне әнә шуңа өнди.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН.**
1994 ел, март.

**Миркасыйм Госманов**

# КОТСЫЗ ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ

Әдәбиятыбыз классигы Гаяз Исхакый мирасын барлау максаты белән профессор Ибраһим Нуруллин Төркиягә барган иде. Кайтуга ук, минем янга кереп, юка гына бер китап сузды:

— Табышлар күп. Монысы синең өчен кирәклерәк шикелле.

Минем алда Икенче бөтендөнья сугышыннан элек Берлинда Гаяз Исхакый тарафыннан чыгарылган «Яңа милли юл» журналының бер саны иде. Риза казыйның рәсеме төшерелгән тышлыгында ук: «Әсәр төрек илләренең олугъ мөфтисе Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренә багышланды»,— дип язылган. 1936 елны, ягъни шул елның 12 апрелендә, Уфада вафат булган киң колачлы галимнең кабатланмас эшчәнлегенә, авыр тормыш юлына тәгәл багышланган 7—8 номерлы куш сан — махсус матәм саны.

Мөхәррир тарафыннан язылган әтрафлы баш мәкалә. Анда, объектив сәбәпләр аркасында, мәрхүм хакындагы мәгълүматларның тулы булмавы, ул елларда хөкем сөргән тәртипләр аркасында аларның тулы була алмавы да, шуңа күрә кайбер хаталарның да китү ихтималы ачык күрсәтелгән. Башка мәкаләләр дә шундый ук туры сүз, ихлас рух һәм әчкерсез кайгы белән язылганнар.

Әмма әлеге моңлы материаллар арасында миңа иң көчле тәэсир ясаганы, хәтта бөтен халәтемне тетрәтеп, күңелләрне әрнетеп җибәргәне — ул мәрхүм Риза казыйның үз хатлары булды.

1933—1935 елларда Финляндиядә яшәүче Гыймадетдин Җәмалетдинга адресланган бу биш хат журналның 34—38 битләрендә басылган. Автографлардан алынган фотокүчермәләр рәвешендә. Алардан совет хөкүмәте тарафыннан эзлекле рәвештә барлык хокуклардан мәхрүм ителгән, шул юл белән мөфти дәрәҗәсендә торган килеш ярлылыкка, ачлыкка хөкем кылынган карт галимнең ни дәрәҗәдә авыр хәлгә, искитәрлек рухи фаҗигагә дучар ителүен күрергә мөмкин.

Кытлык елларында Финляндиядән үзенә азык-төлек, киемлек тукымалар җибәреп торучы кешеләргә рәхмәт йөзеннән язылган бу хатларны һәм журналда басылган башка документларны җентекләп укып торгач, шул нәрсә дә ачыкланды: Риза казыйның Финляндиядәге адресатлары бер Гыймадетдин әфәнде белән генә чикләнми икән. Димәк, аның безгә мәгълүм булмаган башка хатлары да табылуы ихтимал дигән сүз. Әгәр, Финляндиягә барып, Гыймадетдин Җәмалетдинның шәхесен ачыклап, аның замандашларын, дус-ишләрен барлап, махсус эзләнә башласаң?!

Әмма, шундыйрак уй-ниятләр белән йөргән чакта, миңа төньяктагы Хельсинкига түгел, бәлки бөтенләй икенче тарафка — Анкарага таба сәфәр чыгарга туры килде. Төркия Тарих Җәмгыятенең (академия кебегрәк оешманың) XI халыкара конгрессына катнашу максаты белән. (Бу Җәмгыятьнең 1986 елгы X корылтаена махсус чакырылган булсам да, бары 1990 елның сентябрендә уздырылган җыелышына гына катнашу мөмкинлеге туган иде.)

Конгресс утырышларыннан бушаган сәгатьләрдә, бигрәк тә кичләрен, Төркиядә яшәүче кайбер кардәшләребез белән очрашырга, озак-озак әңгәмәләшергә насыйп булды. Аерата Истанбулдагы Мәрмәрә университетыннан доктор Надир әфәнде Дәүләт белән еш гәпләшергә туры килде. Ул мине күренекле тюрколог, профессор Әхмәт ага Тимер, җирле татарлар арасындагы мәгълүм җәмәгать эшлеклесе, үткен каләм иясе инженер Мәхмүт ага Таһир һәм яшь галимнәрдән Сәйдә ханым Арсланбәк, Фазыл әфәнде Агишлар белән таныштырды.

Яңа танышлар белән күңелле һәм файдалы әңгәмәләр вакытында мин Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләренең мирасы белән кызыксынуымны, аның бай һәм катлаулы эшчәнлеге, фаҗигале язмышы хакында бер китап та яза башлавымны әйттем. Мәҗлестәшләрнең кызыксынуларын күргәч, Риза казыйның Финляндия татарларына язган мәктүпләрен эзләвемне белдердем. Моны ишетүгә Мәхмүт ага елмаеп куйды:

— «Яңа милли юл»да басылган ул мәктүпләрнең үзләре хәзер миндә саклаңалар...

Ачылып калган авызымны яба алмыйча тордым!

— Иртәгә үк аларның копияләрен китерермен,— диде Мәхмүт ага, мине тынычландырырга теләгән төсле ашыгып.

Ксерокопияләр, чыннан да, Ризаэтдин хәзрәтнең автографларыннан эшләнгән иде. Тик «Яңа милли юл»да басылганнары түгел, бәлки башка мәктүпләр иде болар. 1922—1935 еллар арасында Вәлиәхмәт Хәким дигән кешегә язылган биш хатның төп нөсхәләреннән эшләнгән копияләр. Алтынчы ксерокопия галимнең 1926 елда мәгълүм җәмәгать эшлеклесе Габдерәшит казый Ибраһимовка (1853—1944) язылган бер хатыннан эшләнгән өзек кенә булып чыкты. Җиденче копиянең ике ягында Диния нәзарәте тарафыннан 1923 елны Финляндия татарларына җибәрелгән тәшәккер (*рәхмәт*) язуы һәм бер рәсми документның күчермәләре теркәлгән иде.

«Алганга алты да аз» дигән хикмәт бар. Мин дә, шуна муафыйкъ рәвештә, копияләрне «әләктерүгә үк», хатларның оригиналларын ышанычлырак шартларда саклау, моның өчен аларны авторның үз ватанына кайтару зарурлыгы хакында «тугылый» башладым. Һәрхәлдә, икенче көнне, без кайтыр юлга җыенып яткан чакта, хушлашырга дип килгән Мәхмүт ага, Казандагы танышларына күчтәнәч итеп төрек чәйләрен, университет китапханәсе өчен «Казан» журналының, «Ерак Шәрекъ» гәзитенең төпләмнәрен әманәт итеп тапшыргач, чак кына уйланып торды. Аннары, әллә ничек моңлы гына, шул ук вакытта ихласлы өмет белән елмаеп, тагын бер конверт сузды:

— Монысын да алып кайтыгыз. Сездә, бәлкем, чыннан да яхшырак сакланыр...

Минем кулда Ризаэтдин Фәхретдиннең үз кулы белән язган хатлары иде!


Анкара аэропортыннан күккә күтәрелеп, илгә таба очкан чакта да, күп тә узмый, Америка Кушма Штатларын гизеп йөргән көннәремдә дә, мин еш кына Мәхмүт аганың әлеге моңлы елмаюын искә төшереп дулкынландым. Хәзер дә, Риза казыйның хатларын укып, күчереп, анализлап утырган вакытларымда да, шул хисләремне кабат кичерәм. Еракларда яшәгән мөхтәрәм илдәшебез инде мәрхүм Мәхмүт ага Таһирның (1922—1991) ышаныч һәм өмет белән өретелгән әлеге серле елмаюында да, Ризаэтдин хәзрәтнең моң һәм сагыш белән тулы мәктүпләрендә дә мәгълүм бер уртаклык, аваздашлык барлыгын тойгандай булам.

* * *

Гыймадетдин Җәмалетдинга адресланып, «Яңа милли юл» да нәшер ителгән биш хатка, шунда ук өзеге басылган, мәгәр Вәлиәхмәт Хәкимгә күндерелгән бер мәктүпкә, Анкарада миңа Мәхмүт Таһир биргән алты хатка, бер рәсми тәшәккер язуына, аннары шул истәлекләрне саклаучы тарафыннан «Азат хатын» журналында басылган *(1990, № 12)* янә бер хатны өстәсәк, безнең өчен яңа документларның гомум саны ундүрткә җитә. (Кайбер хатларның һәм башка документларның эчтәлегеннән күренгәнчә, Р. Фәхретдин тарафыннан бу елларда чит илләргә җибәрелгән мәктүпләрнең саннары болар белән генә чикләнми, әлбәттә.) Аларның җидесе Вәлиәхмәт Хәкимгә, бишесе — Гыймадетдин Җәмалетдинга, берсе — Габдерәшит Ибраһимовка һәм соңгысы, гомумән, Финляндия татар җәмгыятенә адресланган. Хатларның эчтәлегенә күчкәнче, адресатлар хакында да берничә сүз әйтү кирәк булыр.

В ә л и ә х м ә т Х ә к и м (1882—1970) элекке Сембер губернасына (хәзерге Нижний Новгород өлкәсенә) караган Зур Рбишча авылында туган, төрле мәдрәсәләрдә белем алган, беркадәре вакыт Ханкирмән (Касыйм) шәһәрендә имам булып торган, 1914 елда Финляндиягә күчеп китеп, Хельсинкида яшәгән нижгарлы якташыбыз. 1917 елда, Финляндия мөстәкыйль дәүләт булып яши башлагач, В. Хәким шундагы татар җәмгыятен оештыру эшенә катнаша. Шактый вакытлар мәчеттә имам, Финляндия мөселманнары җәмгыятенең рәисе булып тора. 1921—1922 елларда, безнең илдә махсус оештырылган коточкыч ачлык хөкем сөргән чорда, ачларга мәрхәмәт йөзеннән америкалылар төзегән АРА оешмасы белән актив хезмәттәшлек иткән, бәхетсезлеккә тарыган илдәшләренә ярдәм кылу юлында зур тырышлыклар күрсәткән шәхес *(«Казан» журналы, Истанбул, 1971, № 4, 26—27 бб.)*.

Гыймадетдин Җәмалетдин Хельсинкига иң элек күченеп килүче татарлардан исәпләнә (туган һәм үлгән еллары хәзергә мәгълүм түгел). 1925 елда Финляндиядә Ислам җәмгыятен оештыручы һәм аны озак яшәтүче җәмәгать



(15)

حرمتلو حکیموف افندی! السلام علیکم ورحمة الله
وبرکاته. آرا آرقلی ییبه‌رگان پامسلیقه‌گز. نی
وبجی آوغوستده سلامت بو لعقب آلدق. الله تعالی
سزگه، بو طوغوده اشتراک ایتوچیلر، یاردملاشوچیلارنه
همه‌سینه سلامتلک، طنچلق، آخرتده دنیاده
ظفر وفلاح، سعادت و نجاح میسر ایتسه ایدی.
بزی فوق العاده فلاکتدن آرالاب قالوگز. برابرینه
الله تعالی سزنی ورفیقلرگزنی هم آخرت قورقنچلرندن
خلاص ایتسون ایدی.
سزدنگ اسمگزدن ایلیدی اوچیونچی مرتبه پامسلیقه
آلدم، اورالرگز. نک اسمگزنی، کیم یاردمی برله ییبه‌روگنی
همیشه ده بله آلمادق. درست، دعا قیلیو ورحمت
اوقوا ایچون مفصل آدرسلر، اسملر بلنمولا لازم توگل
مشغولای بولسه ده اکی مشقتلی وقتلرده یاردم محموده
ییتکان رحمت ایبه‌لرینک کمرایکالیرنی بله سمز
کیله. بو طوغوده مکاوگه ده حظ یازغان ایدم.
"جمعیت خیریه" طرفندن ییبه‌رله در، دیبو دنه
باشقه جواب بولمادی. هر حالده همه‌گزگه رحمت
وخیر دعاء.

رضاء الدین بن فخر الدین
اوفا [illegible]

۱۹۲۲ ایل
۱۰ آوغوست

*Ризаэтдин Фәхретдиннең Вәлиәхмәт Хәкимгә язган хатының фотокүчермәсе. 1922 ел, 10 август.*

эшлекләреннән. Риза казый 1914 елны Финляндиягә барганда аның белән очрашуы, якыннан аралашуы хакында шаһитлек итүче бер фоторәсем сакланып калган (*Сафия Әхсән Буре*. *Имам Лотфи әл-Исхакый хәзрәтләре. Тампере, 1945, 46 б.*). Гыймадетдинның хатыны Фатыйма (1883—1978) Актук авылында туган. Аларның кызлары Халидә ханым — күренекле тюрколог галим, җәмәгать эшлеклесе Гомәр әфәнде Даһирның хатыны (*«Казан», 1980, № 23, 65 б.*).

Габдерәшит казый Ибраһимов (1853—1944) XIX йөз ахырында һәм XX гасыр башында зур активлык күрсәткән мәшһүр җәмәгать эшлеклесе, сәяхәтче, дин галиме һәм публицист, шул чорда киң колач җәйгән милли-азатлык хәрәкәтенең күренекле идеологларыннан берсе. Чыгышы буенча Себердәге Тара ягыннан. Белем алуын Якын Шәрекъ илләрендә дәвам иттереп, иҗтимагый эшчәнлеген мөселман дөньясында күтәрелгән колониализмга каршы азатлык көрәше тәэсирендә башлап җибәргән шәхес. 1895—1898 елларда Истанбулда «Чулпан йолдызы» исемле чуар эчтәлекле, корама телле брошюра-журналлар бастырып, аларны яшерен рәвештә Россиядә дә тараткан. 1902 елдан башлап Петербургта, аннары Казанда журнал тибындагы «Мирьәт» («Көзге») альманахын (барлыгы 22 сан), 1907 елда Петербургта «Өлфәт» («Бердәмлек») газитен, аннары шуның дәвамы рәвешендә «Нәҗат» («Котылу») журналын чыгарган. Болардан тыш, аның тарихи публицистика, сәяхәтнамәләр, тәрҗемәи хәл рухында язылган китаплары да бар.

Яңа дәвердә Россия мөселманнары арасында барлыкка килгән иҗтимагый һәм сәяси тенденцияләрне оста тоя белүе, шулар хакында эзлекле пропаганда алып баруы, актуаль мәсьәләләр буенча җәмәгатьчелек фикере тудыра алуы өчен Галимҗан Ибраһимов аны берничә мәртәбә «тарихи кыңгырау» сыйфатында характерлый. Мөселман халыкларына чын азатлыкка чыгар өчен үзара берләшү зарур дип инанган. Россиядә хөкем сөргән колониаль тәртипләрне кискен рәвештә кире каккан Габдерәшит казый 1917 елдан соң урнашкан большевистик тәртипләрне дә кабул итми, шуңа күрә чит илгә һиҗрәт итә. Гомеренең соңгы өлешен ул, элеккечә төрле илләргә сәяхәтләр ясавын дәвам иткән хәлдә, Төркиядә уздыра. Җыеп әйткәндә, Габдерәшит Ибраһимовның да катлаулы һәм каршылыклы эшчәнлеге, гаҗәп бай әдәби-публицистик мирасы әле бер дә өйрәнелмәгән. Мәгәр узган чор иҗтимагый тарихыбызны, бигрәк тә милли-азатлык хәрәкәтебез тарихын әтрафлап белер, дөрес аңлар өчен аның шәхесе һәм эшчәнлеге аерата игътибарга лаек.

Анализлана торган хатларның күпчелеге ничек барлыкка килүен дөрес аңлар өчен тагын бер мәсьәләгә тукталу зарур. Ул — АРА оешмасының эшчәнлеге. Моңарчы безнең әдәбиятта бу оешма хакында рәтләп бернәрсә дә язылмады. Янә телгә алынган хәлдә дә гел берьяклы һәм нигездә тискәре фикер әйтелеп килде. Әмма аның 1921—1922 елларда СССРда, бигрәк тә безнең Идел буенда хөкем сөргән коточкыч ачлык чорында АКШ хөкүмәте тарафыннан хәйриялек, ягъни рәхим-шәфкатьлелек максатыннан барлыкка китерелгән, нәтиҗәле эшләгән махсус гуманистик оешма икәнлеген икърар итмичә мөмкин түгел. (Әгәр иҗтимагый аңыбыздагы безгә хас тенденциоз берьяклылык, әхлакый кыргыйлык, элементар әдәпсезлек — имансызлык киләчәктә бераз кимемәсә, ихтимал, бу көннәрдә чит илләрдән килүче ярдәмне дә без соңрак, — бер хикмәт белән аякка бассак, — шулай ук «империалистларның алдашуы», «хәйриялек битлеген киган шпионлык казынулары» дип тә бәяләрбез, бәлкем?..)

Тарихи документлардан күренгәнчә, АРА оешмасының эшчәнлегенә чит илләрдә яшәүче татарлар да актив катнашканнар икән. Моның хакында шул елларда Финляндиядә торган тарихчы Габдулла Батталның (1883—1969) бер мөһим истәлеге сакланып калган. Әлеге оешма ярдәмендә СССРда яшәүче илдәшләренә ярдәм кулы сузу мөмкинлеге туугач, алар, төрле исемлек төзеп, азык-төлек җибәрә башлыйлар. Мәсәлән, 1922 елның башында ук Казан, Уфа һәм башка шәһәрләрдә ачлыктан интегүче татар укымышлыларына да азык-төлек посылкалары җибәрәләр. Посылкалар рәсми рәвештә Хельсинкидагы имам Вәлиәхмәт Хәким исеменнән җибәрелә. Шундый исемлекләрнең берсендә түбәндәге шәхесләр атала: Җәмалетдин Вәлиди, Мөхетдин Корбангали, Ризаэтдин Фәхретдин, Галимҗан Баруди, Һади Атласый, Нәҗип Гасрый, Хәсәнгата Габәши, Мөхлисә Буби, Фатих Әмирхан, Муса Җарулла Биги, Кәшшаф Тәрҗемани, Фатих Кәрими, Габдерахман Гомәри, Фатих Мортазин һ. б. (А. Баттал-Таймас. *«Казанлы төрек мәшһүрләреннән». 1. Ризаэтдин Фәхретдин углы. Истанбул, 1958, 29 б.*).

Истәлек авторының әйтүенә караганда, тиздән посылкаларның исән-имин тапшырылуы хакында күпчелек очракта русча, ара-тирә татарча язылган җавап

хатлары, рәхмәт-тәшәккер язулары килә башлый. Шулардан Г. Баттал китабында кайберләре басылган. Бу урында без Фатих Әмирхан хатын тулысынча күчерүне лаек табабыз (аның өзеген М. Таһир «Азат хатын» журналының 1990 елгы соңгы санында бастырган). Чөнки Ф. Әмирхан мәктүбе белән якыннан һәм тулысынча танышу безгә 1921—1922 елларда хөкем сөргән ачлыкның дәһшәтлелеген, чамасын дөрес күзалларга ярдәм итә. Ниһаять, Риза Фәхретдин хатларының табигатен, хосусыятләрен дөресрәк аңлар өчен дә бу кырыс документның әһәмияте бик зур. Менә ул мөһим хат.

**«Хөрмәтле В. Ә. Хәким әфәнде!**

**Бүген 29 мартта Сезнең АРА аркылы минем исемгә йибәргән бүләгеңезне алдым. Шәхсән мин Сезнең таныштырмы, юкмы — белмим. Чөнки АРАның мондагы шөгъбәсендә (*бүлегендә* — М. Г.) Сезнең тулы исемегезне әйтә алмаганлар, бары «В. А. Хәким» дип кенә әйткәннәр.**

**Көтелмәгән(дә), уйламаганда, өмет ителмәгәндә килгән бу бүләк мине шатландырды гына түгел, бәлки гаять көчле тәэсирләндерде: кайдадыр, ватанындан еракларда, бәлки дә шәхсән үзең белән таныш булмаган даирәләрдә сине искә алучы, сине кайгыртучы дустларыңның барлыгын белү, шуны хис итү, бу — рух күтәрмәслек бер нәрсә түгел. Бу хәзер, без аларны түзеп уздыра торган караңгы көннәрдә, якты, нурлы бер эз булып сызылып китә, киләчәккә өметле карашын китерә: инде арган-талган газапларга (...?) ял итәргә имкян бирә, күңелгә көч китерә — менә шул нәрсәләрне алып килде миңа Сезнең бүләгеңез. Менә шул нәрсәләрнең хасиле — җәмгысе өчен мин Сезгә, бирадәр, үземнең самими тәшәккерләремне гарыз итәм.**

**Ачлыкның соң дәрәҗәсенә йитеп килә торган Татарстанга елның иң авыр айлары йиткән вакытларда килгән бүләгенез минем өчен зур мадди йиңгеллек һәм уңгайлык китергәнлеген дә хосусый сурәттә әйтми китә алмыйм. Хәзер ул мәсьәлә Татарстанда гаять кискен һәм гаять өметсез бер хәлдәдер. Чын мәгънәсе белән ачлыктан шешенеп, урам уртасында үлеп ятулар, адәм мәетесе ашаулар, хәтта адәм суеп ашаулар монда инде гади бер эш дәрәҗәсенә килделәр.**

**Шулай, берадәр, искә төшерүеңез, кайгыртышуыңыз һәм мадди яктан зур уңгайлык ясавыгызның барысы өчен мин Сезгә тагы бер кат рәхмәтләр укыйм.**

**Сәлам вә хөрмәт гарыз итеп:**

***Фатих ӘМИРХАН.***
***29.III.1922.***

**P. S.** ***Вакытыңыз мөсагыйд (***мөмкин бирәр — ***М. Г.) булса, үзеңезне миңа, бер ачык хат белән генә булса да, танытсаңыз — мәмнүн булырмын.*** **Ф. Ә.»**

Ф. Әмирхан хатының соңгы өлешләрен укыган чакта ирексездән хәтергә Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» повесте килә. Ул повестьне моңарчы киң җәмәгатьчелектән яшереп маташуларыбызның да сәбәпләре аңлашыла төшә: чын дөреслек — кырыс тормышның үзе чагылган икән ул әсәрдә! (Киресенчә булса, меңләгән-меңләгән, кат-кат басылган соцреализм «шедеврлары» арасында аңа да урын табылган булыр иде, шәт...)

Әгәр хөкүмәт тарафыннан язучы сыйфатында рәсми рәвештә танылган, гражданлык хокукларыннан аерылмаган Фатих Әмирханга Финляндиядән килгән бер азык-төлек посылкасы шундый зур тәэсир ясаган икән, ул чакта рухани булганлыгы өчен бөтен хокуклардан мәхрүм ителгән Риза казыйның чал сакалын күз яшьләре белән чылата-чылата рәхмәтләр укуы аңлаешлы инде...

* * *

Риза Фәхретдингә беренче посылка 1922 елның 24 февралендә үк килгән була. Моны раслый торган хатның беренче өлешен алыйк:

**«Хөрмәтле В. Ә. Хәким әфәнде!**

**Әссәләмегаләйкүм вә рәхмәтуллаһу вә бәрәкәтәһү.**

**Безнең исемебезгә күндерелгән посылкаңызны ошбу көн «АРА» складыннан сәламәт алып, чәй, каймак берлә сыйландык. Халыкларның посылка алуларына кызыгып йөрсәк тә, үземезгә килүен өмид итә алмыйдыр идек. Өмид булмаган вакытта беренче мәртәбә Сездән ошбу нигъмәтләр килде,— бөтен гаиләмез чиктән**

**тыш шатлануына сәбәп булдыңыз. Сезгә нинди генә дога кылырга да белмим — тыела алмый егъладым. Инде Аллаһы тәгалә Сезгә дөньяда вә ахирәтдә мөкяфат кылсын** *(әҗерләр бирсен* — **М. Г.)».**

Моннан соң хат авторы, Ф. Әмирхан шикелле үк, посылка җибәрүченең кемлеген белергә теләвен әйтеп, аның белән очрашу-очрашмау ихтималын сораша. Шул ук көнне мөфти Галимҗан Баруди һәм казый Кәшшаф Тәрҗеманиларның да гаиләләре өчен посылкалар килүен белдерә. Ниһаять, посылкада нәрсәләр булуын санап чыга: 56 кадак яхшы он, 27 кадак дөге, 3 кадак та 3 чирек чәй, 22 кадак куертылган сөт, 9 кадак май. Бу саналган әйберләрнең бәясе Уфада ул көннәрдә «сәвит акчасы берлә 15 миллион берлә 20 миллион арасында» булуын беләбез.

Икенче посылка килү хакында Р. Фәхретдиннең шул ук елның 5 июнендә язган мәктүбеннән белергә мөмкин *(«Азат хатын», 1990, № 2)*. Монда да хат авторы посылка җибәрүченең төгәл исемен белми әле. 10 августта, ягъни өченче посылка килгәч язылган хат та шулай ук «Хөрмәтле Хәкимев әфәнде» дип башланган. Аның кемлеген төгәлрәк белергә теләгән хат авторы болай яза: **«Дөрест, дога кылу вә рәхмәт уку өчен мөфәссаль (***тулы* — **М. Г.) адреслар, исемләр беленү лязым түгел, шулай булса да, иң мәшәкъкатле вакытларымызда ярдәмемезгә йитешкән һиммәт ияләренең кемләр икәнлекләрене беләсемез килә».**

9 сентябрьдә язылган дүртенче хаттан (гәрчә «Яңа милли юл» да аның өзеге генә басылган булса да), ниһаять, Риза казыйның посылка җибәрүче исемен төгәл белгәнлеген аңларга мөмкин. Чөнки хатның стиле бераз гадиләнә төшеп, самимирәк рух алган. Моны хат авторының нечкә ирония белән бер гыйбрәтле вакыйганы искә төшерүе дә раслый: **«Бу көн Оренбург, Уфа, Труйский, Петропавел байлары Финляндия мөселманларының эшләренә эшләргә, хәтта арттырып йибәрергә дә риза булмакчылар. Мәшһүр байлардан беренең: «Әүвәлге байлыгым кайтса иде, астыма бер сырма, баш очыма бер мендәр алып калыр идем дә, шуннан башкасыны тәмам вөҗүһе хәйратка (***хәйрия чараларына* — **М. Г.) сарыф итәр идем»,** — дип, егълап җан биргәненә ишеттем». Моннан Риза казыйның элгәрге татар байларының күпчелегенә хас саранлык, вакчыллыкны искә төшерүен аңлавы читен түгел. **«Бу сүзләрне язудан максудым,** — дип дәвам итә автор, — **Финляндия мөселманларының һиммәтләре өчен рәхмәт уку...»**

Бишенче хат: **«Мөхтәрәм бәрадәр мелла Вәлиәхмәт әфәнде!»** — дип, төгәл адресат белән башлана (14 октябрь, 1922). Бу юлы «Гомәр әфәнде Галяэтдин аркылы йибәргән биш йөз фин маркасы» исән-сау тапшырылу раслана һәм мондый ярдәмне күрсәтүчеләргә рәхмәт укыла. Хат ахырында кызы Зәйнәпнең Петербургта укуга керә алмыйча кире кайтуын язып, В. Хәкимнән аның өчен артык борчылмавын үтенә. Димәк, моннан элек тә, Зәйнәпкә ярдәм күрсәтүне сорап язылган тагын бер хатның булганлыгы бәхәссез. Шулай булгач, киләчәктә Риза казыйның Вәлиәхмәткә адресланган башка хатлары табылуы ихтимал икән.

1921—1922 еллардагы ачлык чорында Финляндия татарлары Риза казыйга, яисә югарыда исемнәре аталган ун-унбиш кешегә генә ярдәм итү белән чикләнмәгәннәр. Түбәндә төгәл күчереләчәк рәсми документ моны тулысынча исбат итә.

**«Тәшәккер»**

**1923 ел, 10—20 июньдә Уфада булган бөтен Русия мөселманларының голяма вә мөтәвәллиләре җыелышында, Диния нәзарәтенең вәкиле казый Кәшшафетдин хәзрәт Тәрҗемани тарафыннан ясалган докладка карагаңда, Финляндиядә торучы мөселман карендәшләребезнең ач мөселман карендәшләре файдасына бик зур һиммәт иткәннәре күренде.**

**Нәдүәдә** (җыенда — М. Г.) хәзер булган голәма һәм мәхәллә вәкилләре бу эшләре өчен Финляндия мөселманларына тәшәккер итәргә бер тавыштан карар бирде, бу эшне сезләргә ирештерүне һәйәте риясәткә *(рәисләр коллегиясенә* — **М. Г.) тапшырды.**

**Инде һәйәте риясәт нәдәүнең бу тәшәккер вә рәхмәт укуын сез Финляндия мөселманларына ирештерә вә сезнең хакыңызда хәер-догада каладыр.**

*1923 ел, 27 июнь.*

**Диния нәзарәтендә рәис:** **Ризаэтдин бине Фәхретдин.**
**Нәдүә рәисе:** **Габдерахман Гомәри.**
**Сәркятип:** **Шәһәр Шәрәф».**

(Имза-автографлар «Эчке Русия вә Себер мөселманларының Диния нәзарәте» дигән язулы түгәрәк мөһер белән расланган.)

Риза Фәхретдиннең моннан соңгы Финляндиягә язылган безгә мәгълүм хатлары 30 нчы елларга карыйлар. Ихтимал, 1921—1922 еллар кытлыгы узып, НЭП чоры башлангач, Финляндиядән азык-төлек җибәреп торуның артык кирәге калмагандыр. Ихтимал, 20 нче елларның икенче яртысына караган Риза казый мәктүпләрендә сүз башка мәсьәләләр буенча баргандыр. Һәрхәлдә, киләчәктә табышлар өстәлә торса, мәсьәлә тәгәлрәк ачыклана төшәр.

30 нчы елларга караган хатларның беренчесе Гыймадетдин Җәмалетдинга адресланган һәм ул 1933 елның дүртенче сентябрендә язылган. Сәламнән соң, туп-туры мәсьәләгә күчеп, хат авторы болай дәвам итә: **«Тарафыныздан ихсан** (*бүләк*—**М. Г.) ителгән чәй, шикәр, дөге, он—янларында язылганга муафикъ вә дөрест рәвештә—почтадан тапшырылды. Безнең өчен Кадер кичәсе вә гайд көне олугъ бәйрәм булды. Аллаһы тәгалә Сезгә үз мәрхәмәтенә лаекъ рәвештә мәкяфат** (*бүләк-әҗерләр*— **М. Г.) кылсын, мәңгелек бәхет вә сәгадәт берлә мөшәррәф итсен иде».**

Ләкин посылканы алып, аның хакта рәхмәт хатын язып өлгергәнче бер сәеррәк вакыйга да булып ала: **«Почтадан алганымдан соң бер сәбәп берлә адресыңыз заигъ** (*юк*—**М. Г.) булды. Шуның өчен бу мәктүбемне йомышыбызны башкарырлык бер кеше аркылы йибәрергә мәҗбүр булдым».**

Бу хатка һәм әле генә китерелгән өзеккә махсус игътибар итүнең сәбәбе шунда ки, НЭП чоры узып, индустриализация кампаниясенә һәм коллективлаштыру шаукымына тотынган Совет илендә тагын кытлык, ачлык башланган иде. Бездәге хәлләрне яхшы күзәтеп торган читтәге кардәшләр, хаттан күренгәнчә, карт галимгә тагын ярдәм кулын сузалар. Әмма Риза казыйның үз илендә исә аның хокукын чикләү, хәтта эзәрлекләү эше янә дә көчәя бара. Адрес югалу хакындагы хәбәр шуның бер мисалы. Моның шулайрак икәнлеген шул ук елның 21 сентябрендә шул ук Г. Җәмалетдинга язылган икенче хат тулысынча раслый: **«Өч елдан артты чит мәмләкәтләрдә булган әхбабларымыз** (*дусларыбыз*—**М. Г.) берлә хәбәрләшкәнебез юк. Кыйсмәтемез** (*өлешебез, язмышыбыз*—**М. Г.) шуңа мәҗбүр итте, урман арасында гомер итүче заһидлар** (*дәрвишләр, аскетлар*—**М. Г.) рәвешендә гомер сөрдек. Бәлки хәлемезгә шул эш мәслихәт булгандыр. Аллаһы тәгалә хөкеменә ризамыз».**

Сүз уңаенда тагын бер кешедән **«25 сум сәвит кәгазе»** килгәнлеген әйтеп, посылка хакындагы повестканы алгач кичергән үз хисләрен тасвирлый: **«...әгәр башка вакытлар булса иде, посылка китап кына була күрсен иде дип теләгән булыр идем; хәзер бу сәгатьтә ризык кына була күрсен иде дип, теләп торамын».**

Автор бу хатында, форсаттан файдаланып, Уфада алтын-көмешкә һәм чит дәүләтләр акчасына сәүдә итүче махсус Торгсен магазиннары (безнең хәзерге валюта кибетләренең элгәрге «бабалары»!) эшли башлавын искәртә.

Кинаяне дөрес аңлап алган Г. Җәмалетдин, яңа посылка белән тиз генә азык-төлек, кием-салымлык тукымалар җибәргән чакта, Америка долларларын да күндерә. **«Җәмагатем,—ди 19 нчы ноябрьдә язган хатында Риза казый,—үз-үзен тыя алмый шатлыгыннан үксеп-үксеп егълыйдыр... намазлыгы өстендә яшьләрен коеп утырадыр».** Чөнки **«бу нигъмәтләргә вә бу дәүләтләргә ирешү безнең хыялымызда юк иде... Без ул киемлекләрне унбиш елдан бирле күгәнемез, хәтта күргәнемез дә юк иде».**

Америка долларларының кыйммәте исә алтын хисабына 44 сум 78 тиенгә туры килгән. **«Безнең өчен,**— ди хат авторы,—**бу байлык Сөләйман гъәләйһессәлам байлыгыдыр. Рузане ничек үткәрермез?—дип борчылып йөргән вакытымызда бу борчылудан тәмам котылдык. Иншалла, гомеремез булса, рамазан шәрифне вә мөбарәк гайдләрне камил рәхәтлектә, мондан егерме еллар мөкъаддәм** (*элегрәк*—**М. Г.) вакыттагы рәвештә үткәрермез».**

Посылка урынына чит ил акчасы җибәрүнең җайлылыгы беленгәч, Г. Җәмалетдин 1934 елгы бәйрәмнәр алдыннан да Р. Фәхретдингә алтын хисабы белән 46 сум җибәргән икән. 30 декабрьдә язган хатында Риза казый: «Без инде шул акчадан ризык алып файдалана башладык»,— дип хәбәр итә.

1935 елның 21 маенда Вәлиәхмәт Хәкимнән махсус посылка килеп төшә. Анда кием-салым өчен кирәкле тукымалар була. Шул көнне үк язылган мәктүптә мондый сүзләр бар: **«Мәзкүр комачлар бүген 21 майда сәламәт тапшырылдылар... Мин бер генә төрле нәрсә дип зан** (*фикер*—**М. Г.) иткән идем. Анда ирләр вә хатыннар өчен ярарлык төрле нәрсә бар икән. Рәфикъәмез** (*җәмагатебез*—**М. Г.) берлә икәүемезнең, мондан соң гомеремез булса, ике сәнә мөддәтендә** (*ике ел дәвамында*—**М. Г.) күлмәк-ыштан, кульяулык кайгысы китте, ихтияҗымыз тәэмин ителде».**

Уфадан 3 августта Вәлиәхмәт Хәкимгә җибәрелгән хатта Р. Фәхретдин аңар истәлеккә үз китапларын сала алмавы (китапларының төрле елларда таланып,

әрәм-шәрәм булып бетүе) хакында ачынып яза. Чөнки шул елның 7 июлендә Хельсинкидан язылган хатта галимнең басылып чыккан китаплары соралган икән. Фикеремчә: бу үтенеч белән В. Хәким автордан ядкяр-истәлек алу теләгеннән генә түгел, бәлки олы галимнең хезмәтләрен чит илләрдә пропагандалау, мөмкин булса, яңадан бастырып чыгару ниятеннән дә мөрәҗәгать иткән булырга тиеш. Һәм мондый адым, ихтимал, бер В. Хәким башында гына туган фикер нәтиҗәсе булмаса кирәк. (Һәрхәлдә, 1945 елда Финляндиядәге Тампере шәһәрендә Р. Фәхретдин кереш мәкалә язган «Гани бай» исемле китап латин хәрефләрендә басылып чыгу бу фаразны куәтли төшә дип уйлыйм.)

Чит илдәге татар зыялыларының үз туган илендә авыр шартларда интеккән карт галимнең мирасы, тормыш юлы белән кызыксынулары шактый әзлекле булганга охшый. Мәсәлән, 1935 елның 3 декабрендә Уфадан Гыймадетдин Җәмалетдинга җибәрелгән хатта — Ризаэтдин хәзрәтнең моңарчы безгә мәгълүм иң соңгы хатында — адресатның үтенечләренә җавап рәвешендә язылган түбәндәге моңлы һәм гыйбрәтле сүзләрне укыйбыз:

**«Үземез бер хәлдә көнләр үткәреп торамыз. Бу кадәр озын гомерле булырмын дип фикерләмидер идем. Һиҗри берлә 1275 ел җөмадис-л-ахир 7 сендә дөньяга килгәнмен (милади берлә** *(искечә)* **1858 ел 31 декабрь —** *(яңа стильдә)* **1859 ел 12 гыйнварда). Икенче анамдан дөньяга килгән кечкенә бер туганымыздан башкалары (үз анамдан дөньяга килгәннәре) һәммәсе күчеп беттеләр. Замандашларым да калмады. Гомеремне язу вә бозу һәм дә аны төзәтү берлә үткәрәмен. Язганларымны укучылар булачакка өмидем юк, өмидкә урын да юк. Ләкин язу вә моталәгә берлә шөгыльләнү сәбәпле, кайгылар онытыла вә гомер тынычлыкта үтәдер. Бу эш олугъ ганимәт. Һәрхәлдә кешеләр кулларына йөк булмасам иде, Аллаһы тәгаләнең мәрхәмәте берлә иманлы бәндәләрдән булып, йөнеллек үзрендә дөньядан күчсәм иде».**

Моннан соң хат авторы Финляндиядәге танышларын, җөмләдән Гыймадетдинның бөтен гаиләсен — Фатыйма ханымны, кызы Халидә белән улы Зәкине махсус атап, аларның һәрберсенә үзеннән «сәлам вә хәер-догалар» тапшыруын үтенә. Бер сүз белән әйткәндә, бу хат үзенә күрә бер хушлашу, бәхилләшү хаты кебегрәк яңгырый. Сагыш та бар монда, тормышны өзелеп сөю белән бергә язмышка карата үпкә хисләре дә сизелә. Шушы сыйфаты ул хатны карт галимнең шул ук 1935 елның 5 февралендә академик А. Н. Самойловичка җибәргән моңлы бәхилләшү мәктүбе белән аваздаш итә (**карагыз:** М. Госманов. *Үткәннән киләчәккә. Казан, 1990, 65—67 бб.).*

Риза хәзрәт үз көннәренең санаулы калуын яхшы тойганга охшый. Киләсе елның язында, 14 апрельдә ул инде вафат була.

1922—1935 еллар арасында Уфадан Хельсинкига җибәрелгән, безнең өчен соңгы вакытларда гына мәгълүм булган моңлы, күңелсез һәм гаять гыйбрәтле хатларның эчтәлекләре менә шулардан гыйбарәт. Сәлам хатлары гына түгел, әйтерсең лә коточкыч елларның кырыс кайтавазлары болар!

* * *

Хатлар белән якыннан танышуга һәм бүгенге чынбарлыгыбызны искә төшерүгә, әллә ничек күңелсез, котсыз булып китә. Ни өчен соң бездә кеше, кешенең белеме, аңы, акылы шул кадәре дәрәҗәсез, кадерсез? Әгәр чынлап теләгән булса, татары һәм башкорты бергә биш-алты миллионны тәшкил иткән бер халык йөзек кашыдай кадерле галимен, чит илләрдән өзек-өзек килгән посылкаларга каратмыйча, үзе дә тәрбияли алмас идемени?! Ахыр чиктә сүз чит илләрдән килгән азык-төлек посылкалары ярдәмендә ачлыкны җиңү хакында түгел. Ара-тирә генә килгән ашамлык белән ач үлемнән котылып булмый. Сүз игътибарда, бәла-каза вакытында хәлгә кереп, ярдәм кулын суза белүдә — күңел җылылыгында, бәрәкә-берлектә.

Фикерләрем төгәлрәк аңлашылсын өчен, Риза казыйның югарыда исеме аталган Габдерәшит Ибраһимовка язган (7 март, 1926 ел) хатыннан бер өзек китерәм:

**«Киләсе май 30ында ислам нәдүәсе (***җыены, корылтае* **— М. Г.) җыелу өчен хөкүмәт әзен (***рөхсәт* **— М. Г.) бирде. Көтелмәгән манигъләр зоһур итмәсә, бәлки, җыелыр. Ләкин безнең үз халкымызда фикер вә һиммәт, әхлак вә хәмийәт (***дәрәҗәлелек* **— М. Г.) къәбиләндән эшләр ифлас итте (***юкка чыкты* **— М. Г.).**

**Арамыздагы ихтилаф вә ифтиракъ (*талаш һәм тартыш*—М.Г.) көндән көн артып вә көчләнеп барадыр... Үзем нәдүә итү берлә, таралган ризыкымны эзләп, бер тарафка юнәлмәк вә ятачак (*кумелэчәк*—М. Г.) урыным артыннан йөрмәк фикерендәмен. Хәзерге хисабым Кашгарга китеп, берәр мәдрәсәгә керү, табылса, балалар укыту, иман вә гыйбадәт үгрәтеп шөгыльләнү вә санаулы сулышларымны шунда тәмам итүдер. Башка урынга барырлык мадди икътидарым (*көчем*— М. Г.) юк. Ихтимал, кабергә дә күчәрмен. Исән булсам да, ихтимал, бер йиргә дә йөри алмамын. Чөнки ихтиярым үземдә түгел».**

Шулай, дәвамлы хөкем сөргән ачлык, ялангачлык өстенә, әсирлек тә килеп кушылган икән. Үз илендә, үз ватанында да урмандагы дәрвиш кебек яшәгән икән Риза казый!..

Котсыз, шыксыз тормыштан туйган мизгелләрендә ул ерак Кытай җирендәге Кашгар мәдрәсәләрендә яки Әфган якларында бала укыту хакында хыялланган. Бөтенләй түземе беткән сәгатьләрендә каләм тотып кәгазь өстенә иелгән. Шулай, имеш, «кайгылар онытыла», шулай, имеш, күңелсез, котсыз «гомер тынычлыкта үтә»...

Ә бәлки мондый минутларда ул мөхтәрәм Закир әфәнде Рәмиевнең хикмәтле юлларын искә төшергәндер:

**Каләм!..**
**Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,**
**Ни моңлы уйларың бар—сөйлә безгә!..**
**Кара туфрак тулы мәзлум нидасы,**
**Алар кемдер... Алар кемнәр фидасы?..**

* * *

«Йосыфны сатып ни алгайлар?»—дип көрсенгән икән XIV йөз шагыйре Сәйф Сараи, Йосыф пәйгамбәрнең агалары тарафыннан коллыкка сатылу вакыйгасын искә төшереп. Риза казый Фәхретдин ише кешеләрнең, туган халкының рухи пакълеге, бәхете өчен гомерен биргән, сүзнең чын мәгънәсендәге гуманист олы затыбызны интектереп, без дә нинди казанышларга ирештек?!..

«Бер ул гына ачыкмаган, башка миллионнар да...»—дип, акланырга ашыкмыйк. Миллионнар дигәч тә, ул саннарның 20 һәм 30 нчы елларда репрессияләнеп, йөзләгән лагерь-төрмәләрдә, төрле себерләрдә башлары җуелган бихисап ватандашларыбызга күбрәк каравын да онытмыйк. Минемчә, безнең бөтен бәла-казаларыбыз—хәзерге көндә кул сузып, дөньялар буйлап теләнеп йөрүләребез дә—ахыр чиктә миллионнарын санаган, шул миллионнарны «калкан» һәм «идеал» иткән хәлдә, аерым Кешенең, конкрет Шәхеснең кыйммәтен, дәрәҗәсен санга сукмаудан килә.

Аерым шәхесләрен, конкрет затларны хөрмәтли, ярата белмәгән кешеләр, теләсә нинди халыкны да олылый алмас. Үзенең эшчән, фидакарь улларын кадерли белмәүчеләр, халык буларак, башкалар алдында үзен раслый алмас, ихтирам казанмас.

Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдиннең ачы язмышы, фаҗигадә кичкән соңгы еллары, ниһаять, безнең бүгенге иҗтимагый чынбарлыгыбыз—матди мөмкинлек һәм ташландык рухи халәтебез моны тулысынча раслый шикелле.

Ләкин еракларга таралган, кыйтгалар буйлап сибелгән илдәшләребездән кайберәүләрнең аның авыр көннәрен игътибар, рәхим-шәфкать, ярдәмчеллек җылылыгы белән күркәмләп җибәрү фактлары бу күңелсез, кырыс нәтиҗәләрне бераз йомшарта, шомарта төшкәндәй була.

Ихтимал, халкыбыз табигатенә ят булмаган андый тирән тамырлы изге сыйфатлар әле дә бетмәгәннәрдер. Бәлки алардан яңа үрентеләр үсеп чыгар. Бәлки, шул үрентеләр ишәюдән, тимер көпчәкләр белән таптатылган, мазутланып пычранган рухи «кырларыбыз» яңадан яшәрер?..

* * *

Әгәр югарыда китерелгән мәгълүматлар белән генә чикләнсәк, Риза казый Фәхретдиннең 1920—1930 еллардагы рухи халәте, эшчәнлеге хакында шактый берьяклы фикер калыр иде. Хәер, аның хакында моңарчы—соңгы елларда барлыкка килгән үзгәрүләргә кадәр—бездә гел берьяклы фикер йөртү хөкем сөреп килде. Хәтта галимнең хезмәтләреннән файдаланган, эшчәнлеген тәкъдир иткән хәлдә дә, аны «максатчан» тәнкыйть итмичә узылмый иде.

Аның күпкырлы эшчәнлегенә, инләнмәс диярлек дәрәҗәдәге бай мирасына беркадәрә гаделрәк (бары бер кадәре генә!) бәя бирергә омтылулар да заманында «тимербетон» каршылыкларга очрады. Шуны күрсәтә торган бер гыйбрәтле вакыйганы искә төшерү файдалы булыр сыман.

1967 елны Мөхәммәт Мәһдиев белән мәрхүм Мөхәммәт ага Гайнуллинның «Татарская литература и публицистика начала XX века» исемле китабына күзәтү ясаган идек *(«Казан утлары», 1967, 7 сан)*. Мәкаләдә, хезмәткә югары бәя бирү белән бергә, андагы кайбер ачык калган мәсьәләләргә, җөмләдән, Фатих Кәрими, Риза казый Фәхретдин эшчәнлегенең берьяклырак, таррак яктыртылуын күрсәтеп, андый мөнәсәбәтнең сәбәпләрен анларга тырышкан идек. Юл уңаенда революциягә кадәр чыккан татарча гәзит-журналларга бездәге бәя бирүдә «туласмлык» (мәсәлән, наширдән — редакторны, монысыннан аерым авторны аера алмау кебек) гадәте хөкем сөрү дә күрсәтелгән иде. Мәкалә чыккач, китап авторының әлеге күзәтүдән канәгать калуын белдем: киң күңелле Мөхәммәт ага Гайнуллин, гадәтенчә рәхмәтләр әйтеп, минем белән шактый ачык әңгәмәләшкән, мәкаләдә куелган мәсьәләләр белән килешкән иде.

Әмма тукмаклар өскә икенче яктан ишелеп төштеләр. Тәнкыйтьне 1968 елның гыйнвар аенда уздырылган зур конференциядә Камил ага Фасеев башлап җибәрде.

Тарихны һәм элекке әдәби процессны яктыртуда соңгы вакытларда «җибәрелгән политик хаталарны» фаш итүгә багышланган озын доклад өлкә комитеты секретарьлары чыгышы кебегрәк яңгырады. Һәрхәлдә, президиумдагы өлкә комитеты вәкиленең докладчы белән килешә-килешә баш кагып утыруын яхшы хәтерлим. Төп тәнкыйть безнең әлеге мәкалә кисәгенә юнәлгән иде («мәкалә кисәге» дим, чөнки анда әйтелгән фикерләр, соңрак «әтәч булып кычкыруларга» караганда, чеби кебек чүтелдәүдән ары узмаган иде әле...). Янәсе, авторлар «буржуаз дин әһелен» идеаллаштыралар, янәсе «Р. Фәхретдиневнең «Бөек Октябрь революциясенә каршы булуын» күрмәмешкә салыналар, янәсе, буржуаз гәзит-журналларга бәя бирүдә «бердәм агым теориясенә» ияреләр, шунысы белән алар башка төрки халыкларның вәкилләрен дә дөрес юлдан яздыралар һ. б. һ. б. Озын сүзнең кыскасы, безне буржуаз милләтчелектә гаепләү иде бу.

Җавап өчен сүз сорау нәтиҗә бирмәде — институт директоры, бәйләнеп йөрмә әле дигәндәй, кулын гына селтәде. Бары икенче көнне, рәислек итүче мәрхүм Җәмил ага Гыйльманов кына, форсатын китереп, мине трибунага чакырды. Ләкин, җавап никадәр дәлилле булмасын (һәрхәлдә, докладтан соң кичә генә исәнләшмичә узып китүчеләр яңадан күренә башлаганнар иде...) тәнкыйть дәвам итте. Февральнең дүртесендә «Социалистик Татарстан» гәзите битләрендә «Әдәби хәрәкәтнең алгы сафына!» дигән зур редакцион мәкалә басылып чыкты. Аның тәнкыйть өлешендә шул ук гаепләүләр, шул ук Риза казыйны битәрләү, шул ук «бердәм агым» карачкысы һ. б. Димәк, Р. Фәхретдин мирасын барлауга каршы юнәлгән хәрәкәт, әгәр монарчы «Шура» журналына минем тарафтан төзелгән библиография китабының корректурасы сүтелүен дә исәпкә алсаң, сәяси кампания кыяфәтен ала башлаган иде.

Әмма шунысы гыйбрәтле, әлеге тәнкыйть кампаниесе аны оештыручылар өчен тискәре нәтиҗә бирде. Миңа исә файда гына китерде. Беренчедән, шул шау-шулар тынып өлгермәгән хәлдә, үзләре дәшеп алып, мине Язучылар союзына кабул иттеләр. Икенчедән, әлеге кабат «таяк ашаудан» соң мин саграк кылана башладым. Берәр яңарак фикер әйтергә теләгән чакта, мантыйк-логикага басым ясаган хәлдә, аны төрле яклап дәлилләү, фактлар нигезендә тугылыйтугылый раслау гадәтенә күнектем. Өченчедән, баш тәнкыйтьчебез шуннан соң әдәбият тарихы мәсьәләләренә кагылмас булды. Кыскасы, Сталин-Жданов рухындагы күсәкчеләр чоры, нигездә, уза башлаган иде инде.

Шулай да минем үзем өчен хәл ителеп бетмәгән мәсьәлә дә бар иде әле. Әйтик, тәнкыйтьчеләр тарафыннан гел кабатланган: «Әгәр Риза Фәхретдинев чыннан да прогрессив кеше булган булса, ни өчен Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң ул мөфти булып торган?» — ише сорау. Күпкә кадәр мондый сорау минем баштан чыкмады. Ләкин миндә ул чак кына икенчерәк редакциядә яңгырый иде: мөфти буларак Риза казый халыкка, илгә нинди начарлыклар эшләде, нинди зарар китерде икән?

Гадәттә, Р. Фәхретдинне гаепләүчеләр, мөфтинең чит илләрдә таралган әллә нинди бер «васыятен» телгә алып, мәгънәле генә баш кагып куялар иде. Янәсе: «Алып барган бит контрреволюцион пропаганда эшен!» Гаҗәп, Финляндиядәге татарлар арасында таралган ул **«васыяттә»** нинди «крамола» бар икән?

Ләкин Финляндия ерак, чикләр йозаклы!

...1989 елның җәендә Финляндиядән килгән илдәшләребез Габдулла әфәнде һәм Өлкән ханым Алилар белән танышып, дустанә әңгәмәләшеп утырган чакта, мин баштан һич тә чыкмый йөргән әлеге сорауны кабатлап, кунакларга үтенеч белдердем:

— Шул васыятьнең копиясен табып булмас микән?!.

— Ник булмасын,— диде Габдулла әфәнде.— Яхшы хәтерлим, андый нәрсә заманында кулдан-кулга йөргән иде.

Күп тә узмый, дәресрәге 1990 елның башында, Хельсинкидан пакет килеп төште.

Өлкән ханым тарафыннан язылган ачык хат белән бергә, «васыятьнең копиясе дә бар иде. Шунда ук укып чыктым һәм аны телгә алып, мәгънәле баш чайкауларның оятсыз гайбәт, максатчан яла нәтиҗәсе икәнлеген аңладым. Минем алда әллә нинди серле «сәяси васыять» түгел, бәлки гадәти вәгазь тексты ята иде. Андый вәгазьләрнең, җөмләдән Р. Фәхретдин тарафыннан язылганнарының да, археографик эзләнүләр вакытында әллә ничә мәртәбә очраганын хәтерлим. Кулдан язылган текстның гектограф ысулы белән гадәти гәзит кәгазендә күбәйтелгән нөсхәләрен...

Шул ук вакытта Хельсинкидан килгән текстны бастыру белән дә ашыкмадым. Беренчедән, элекке мирасыбызны гел каралту, җөмләдән Риза казый өстенә дә пычрак атулар чоры артта кала башлаган иде. Хәзер аның вәгазь-васыятен аклап маташу — ул ике икең — дүрт, яисә суны юеш дип раслау белән бер иде.

Икенчедән, вәгазь текстын галимгә багышланган китапта урнаштыру мәгъкульрәк булыр, дип уйладым.

Өченчедән, мин шулай уйланып, китап өчен материаллар җыюны дәвам итеп йөргән чакта, вәгазьнең башкорт телендәге варианты, Риза казыйның чын васыяте белән бергә, басылып та чыкты *(«Агыйдел», 1990, 4 сан. Р. Утәбай публикациясе)*.

Хәзер инде Риза Фәхретдиннең 20-30 нчы елларда язган хатлары, олуг галим һәм фикер иясе кичергән трагик халәт белән якыннан танышкач, укучыларга вәгазьнең документаль төгәл текстын да тәкъдим итү урынлы булыр дип уйлыйм. Аның эчтәлеген әлеге хатлар белән чагыштырып карау мөфти Ризаэтдин Фәхретдин өстенә элек бездә ташланган гаепләүләрнең никадәре ялган, никадәре оятсыз яла икәнлеген артыгы белән расласа кирәк.

Габдулла әфәнде Али көндергән копия Гыймадетдин Җәмалетдин тәкъдиме буенча Финляндия татар җәмгыяте тарафыннан нәшер ителгән тексттан эшләнгән икән. Алар исә текстны «аны ватандагы Мәркәзе диниядән сары начар кәгазьдә» гектораф ысулы белән күбәйтелгән нөсхәдән алганнар. Копиянең сыйфаты әйбәт. Хельсинкида җыелган текст исә, вак-төяк хәреф хаталарын исәпкә алмаганда, канәгатьләнерлек дәрәҗәдә. Әйдәгез, аны бергә-бергә укып чыгыйк. Текст, имлясы сакланган хәлдә, тулысынча китерелә (бары тыныш билгеләренә генә төзәтүләр кертелде; төп текстта, анализга җиңел булсын өчен, абзац башларына квадрат җәяләр эчендәге тәртип саннары куелды.

**[0] «Мөселманларның мәркәзи Диния нәзарәтенә караган барча ислам җәмәгатенә.**

**Дини вәгазь.**

**Бисмиллаһи — иррәхмән ир-рәхим.**

**[1] Хөрмәтле дин карендәшләремез!**

**[2] Ошбу мөбарәк гайд көнендә, шушы сәгатьдә бөтен дөнья мөселманлары мәсҗедләргә җыелалар: пакь йөзләрен йиргә куеп, саф күңелләре берлә дога кылып, Аллаһе Тәгаләдән максудларын сорыйлар. Сезләр дә бөтен эшләрегезне куеп, Аллаһе Тәгаләнең рәхмәтендән өмид итеп, ошбу урынга җыелгансыз. Барчамызны яраткан, һәртөрле нигъмәтләр белән тәрбия иткән, бөтен дөньяны юктан бар кылган Аллаһе Тәгалә хәзрәтләренә бәндәчелек күрсәтү, дога кылып хаҗәтләреңезне сорау өчен килгәнсез. Аллаһе Тәгалә Коръәне Кәримдә әйтә: «Иннәд-динә гъиндә-л-лаһе-Ислам»,— ди. Ягъни: «Аллаһ каршында мәкъбуль булган дин — Ислам дине»,— ди. Безләр ошбу көндә, Әлхәмдулиллаһи, Ислам динендә яшимез. Аллаһе Тәгаләнең рәхмәте аркасында борынгы бабаларымыз Ислам динен кабул иткәнләр, безне дә шул юлга күндергәниләр, Ислам тәрбиясе биргәнләр, мәңге бәхетле булуымызга сәбәп булганлар. Ошбу Ислам диненә ирүемез өчен сөенергә, Аллаһе Тәгаләгә шөкер итәргә тиешлемез; Ислам динен кабул итүләре өчен борынгы бабаларымызга дога кылырга бурычлымыз — барысы да Аллаһның рәхмәтендә булсыннар!**

**[3] Хөрмәтле кардәшләр!**

**[4] Безнең Ислам динендә булуымыз — Аллаһның зур нигъмәте. Үзеңезнең Аллаһ кашында[1] Хөрмәтле булган Ислам динендә булуыңызны онытмаңыз! Пәйгамбәремез Мөхәммәд Салаллаһу гъләйһиссәләмнең үз өммәтенә ирештергән вәгазь-нәсыйхәтләрен хәтереңездән чыгармаңыз — аларны исеңезгә төшерегез!**

**[5] Коръән-Хәдис күрсәтүе буенча «мөселманлар бер-беренә дин карендәшләре»дер. Шуның өчен бер-береңез белән яхшы торыңыз, кардәшләр рәвешендә яшәңез, дуслык, тынычлык, өлфәт вә мәхәббәт берлә гомер итәргә тырышыңыз; үзеңезгә сөйгән[2] яхшылыкларны мөселман карендәшләреңез өчен сөеңез, үзеңез өчен яратмаган нәрсәләрне мөселман карендәшләреңез өчен дә яратмаңыз. Дин карендәшләреңезне рәнҗетмәңез, аларга хыянәт итүдән, алдаудан сакланыңыз! Кешеләргә яхшылык тели торган булыңыз, бер-береңезгә зарарлы булуны теләп тормаңыз, сүз йөртмәңез, кешеләрнең араларын бозмаңыз, бер-береңезне чагып, мөселман кардәшләргә зарар итүдән сакланыңыз! Араңызда үпкәләшүләр, рәнҗетүләр булса — килешеңез, бирәчәк бурычларыңызны кыяматкә калдырмаңыз — дөньяда вакытларыңызда ризалашыңыз!**

**[6] Шәригатьтә каты рәвештә тыелган нәрсәләрдән: исерткеч эчү, отыш уены уйнау, дөньяда кеше малына хыянәт кылу, урлау, фәхеш кылу, мөселманнарга золым кылу, ялган сөйләү, вәгъдәдә тормау кебек начарлыклардан бар көчеңез белән сакланыңыз!**

**[7] Ата-аналарыңызны хөрмәт итеңез! Сәламәт вакытларында хезмәтләрен кылып, догаларын алып калырга тырышыңыз; үлгәннәреннән соң үзләрен онытмаңыз, алар өчен догалар кылып, изгелекләр итеп рухларына багышлаңыз!**

**[8] Хатыннарыңыз берлә яхшы көн күреңез: бер-береңезгә шәфкатьле, мәрхәмәтле булыңыз, бер-береңезнең хәтерен калдырудан, каты сүз әйтүдән сакланыңыз; бер-береңезгә ярдәмче — сердәш булып торыңыз, бер жан, бер тән кебек булып гомер итеңез; бер-береңезгә юаныч булыңыз, шатлыкларыңызны, кайгыларыңызны уртаклашыңыз!**

**[9] Балаларыңызны Ислам холыклары берлә холыкландырырга әдәпле, инсафлы, дийанәтле[3] итеп үстерергә тырышыңыз. Иң башлап баларыңыз өчен үзеңез яхшы күчергеч булыңыз!**

**[10] Карендәшләреңез, тирә-күршеләреңез белән тыныч торыңыз; карендәшләреңезнең хәлләрен белеп, сорашып, катнашып йөреңез! Бигрәк тә кыз-хатын карендәшләреңезгә ригайәле[4], шәфкатьле булыңыз; картларга, карчыкларга, мескенләргә, ятимләргә ярдәмле булыңыз!**

**[11] Динеңез хакында игътибарлы булыңыз, дин-дийанәтеңездән аерылмаска тырышыңыз! Фарыз намазларыңызны калдырмаңыз, мәсҗедләреңезне яхшы тәрбия итеңез, пакъ-пөхтә, җылы итеп тотыңыз, мәсҗедләреңезне тагать-гыйбадәттән мәхрүм итеп тотмаңыз! Мөмкин кадәр биш вакыт намазга йөреңез, җомга намазларыннан бер дә калмаска тырышыңыз! Диннең һәм дини оешмаларның үзәге булган мәсҗедләреңезне — Диния нәзарәтен беренче дәрәҗәдә кирәкле белеп, үзеңезнең җаныңыз — иманыңыз кебек күреп сакларга тырышыңыз, мәсҗедләреңездән — Диния нәзарәтеннән аерылсаңыз, динеңезне саклый алмассыз, бу эшне жинелгә генә санмаңыз[5].**

**[12] Дин хадимләреңез — имам вә мөдәррисләреңезне көчеңез йиткән кадәр яхшы тәрбия итеңез, сез аларның дөньяларын кайгырышсаңыз; алар күңел тынычлыгы берлә сезнең динеңезне, ахирәтеңезне кайгыртырлар — бу нәрсә хәтереңездән чыкмасын.**

**[13] Дөньяның гомере бик кыска, шул кыска гомереңезне заигъ кылмаңыз, вакытларыңызны бушка үткәрмәңез, һәрвакытта динеңез, яки дөньяңыз өчен хаҗәт булган нәрсәләр берлә мәшгуль булыңыз, үзеңезне яхшы исем берлә искә төшерерлек эшләр эшләп китәргә тырышыңыз! Үзеңез төрле һөнәрләрне үгрәнеңез һәм балаларыңызны да һөнәргә үгрәтеңез, һич вакытта ялкау булмаңыз, бөтен эшләрне тырышып эшләңез, коры сүз кешесе булмагыз — эш кешесе булыңыз. Мөселманлыкыңызны эшлекслелек берлә сүздә һәм эштә тугърылык берлә күрсәтеңез!**

**[14] Гайд вә җомга көннәрнең һәм башка бәйрәмләрнең хөрмәтләрен саклаңыз. Малыңызны исерткеч, отыш уены кебек харам урыннарга әрәм итүдән бөтен көчеңез берлә сакланыңыз! Балаларыңызны да шул юлда тәрбия итеңез — дөнья вә ахирәт бәхетле булырсыз.**

---

[1] Кашында — янында, каршысында.
[2] Сөйгән — теләгән.
[3] Дийанәтле — динле, дин тотучы.
[4] Ригайә (ригаять) — кайгыртучанлык, химая, ярдәмчеллек.
[5] Санмаңыз — санамагыз.

**[15] Хөрмәтле мөселманлар!**

**[16] Сезгә соңгы сүз шул: һәммәңезгә мәгълүм, бер кеше дә бу дөньяга мәңгегә килмәгән, гомеремез кыска — үтә дә китә: һәркемгә үлем киләчәк, һәркем бу дөньядан күчәчәк. Үлем — ахирәткә керә торган бер капка, шул капкадан кергәндән соң дөньяда эшләгән бөтен эшләрегездән җавап бирәчәк бер көн бар! Һәр кеше бөтен мәхшәр халкы алдында, Аллаһе Тәгалә хозурында хисап бирәчәк! Ул көндә дөньяда булган малларның, бала-чагаларның, дуст-ишләрнең — һичберсе файда итмәячәк. Ул көндә бары дөрест иман, изге гамәл, пакь күңел генә файда итәчәк. Менә шушы хәлләрнең башыңызга киләчәген оныт-маңыз — кыямәт көне өчен әзерлек күрәңез, мөбарәк Ислам дининең күрсәткән юлы берлә йөреңез!**

**[17] Аллаһе Тәгалә хәзрәтләре күңелләремезне пакь, иманларымызны сәламәт кылсын!**

**[18] Барчаңызга хәерле гомерләр, киң ризыклар насыйп итсен, дин вә дөньяңызны төзек кылсын; үзләремезгә, балаларымызга һәм барча әһле Исламга тәүфикъ — һидайәт[1] бирсен!**

**[19] Әҗәлемез йитеп, бу дөньядан сәфәр кылсак, газиз иманымызны юлдаш итсен иде.**

**[20] Амин!**

**[21] Мөселманларның мәркәзе Диния нәзарәтендә рәис вә мөфти:**

***Ризаэтдин* бине *ФӘХРЕТДИН*».**

Бездә элек Риза казый Фәхретдин өстенә өзлексез гаеп ташлауларга, аны «совет чынбарлыгы»ның дошманы рәвешендә сурәтләүләргә нигез булган «документлар»ның берсе, югарыда махсус күрсәтелгәнчә, «чит илләрдә таралган» «васыяте» иде. Хәзер, төгәл текст белән танышкач, аның чит илләргә махсус «җибәрелгән» сәяси документ түгеллеген белдек. Шулай аңлау һәм аңлатуның мәгълүм оешмалар тарафыннан таратылган максатчан ялган икәнлеге дә ачык күренеп тора. Димәк, большевик прокурорларның һәм аларга сукырларча ияр-үчеләрнең «васыять» тирәсендә хисләр куертуы бер дә гаҗәп түгел. Кызганыч ки, шундый дөрес булмаган фикер Уфа публикациясендә дә кабатлана («сары төстәге кәгазьгә язылып, Финляндиядә яшәүче мөселманнарга күндерелгән»). Мондый раслаудан «васыять» мөһаҗир татарларга махсус адресланган кебегрәк тәэсир туа.

Әмма бу һич тә дөрес түгел. Автор мөрәҗәгать иткән адресатлардан күренгәнчә, вәгазь элекке СССРның РСФСР өлешендәге мөселманнарга тулаем адресланып сөйләнгән һәм шундагы мәхәлләләргә таратылган (тексттан 0, 2, 3, 14 һәм 20 пунктларны чагыштырып карагыз). Кабатлап әйтәм, гектограф ысулы белән күбәйтелгән андый вәгазьләрнең, дөресрәге саргаеп беткән начар сыйфатлы гәзит кәгазьләренә басылган шундый текстларның берничәсен халык арасында кульяз-малар эзләп йөргән чакларда үземнең дә күргәнем бар иде. Аларны, гадәттә, авылларда муллалык итүчеләр саклый һәм үзләре вәгазь сөйләгән чакларда файдаланалар иде.

Икенчедән, укучылар үзләре дә күргәндер, вәгазьдә агымдагы сәясәткә кагылган бер сүз дә юк. Автор үзенең һәрвакыттагы идеалына абсолют рәвештә тугъры булып калган — ул сәясәттән аңлы төстә читтә торган. Аның барлык теләге кешеләрдә күркәм холык, рухи пакьлек, ихлас кешелеклелек, дөрес иман һәм табигый динлелек тәрбияләү.

Өченчедән, вәгазь текстында чит илләрдә яшәүчеләр хакында махсус бер сүз дә юк. Финляндия басмасының кереш сүзендә дә аның автор тарафыннан җибәрелүенә бернинди ишарә юк. Киресенчә, анда «кулымызга килеп төште, тарихы язылмаган, нә вакыт язылып таралдыгы билгеле булмаса да» кебек очраклылыкка ишарә итүче мәгълүматлар гына китерелә.

Соңгы өзектән вәгазьнең «тарихсыз» таралуы хакындагы фикер махсус игътибарга лаек. Өстәвенә текстта бернинди конкрет фактка, елы-көне, вакыты-чоры төгәл мәгълүм булган бер вакыйгага да ишарә юк. Шулай булгач, гыйльми һәм фәлсәфи хезмәтләрендә, хәтта хосусый хатларында да документаль төгәллеккә эзлекле тугърылык саклаган галим өчен очраклымы икән мондый күренеш? Юк, әлбәттә.

Фикеремчә, безнең алда конкрет бер елгы гает бәйрәмендә генә укылу һәм таратылу өчен язылган вәгазь түгел. Игътибар итегез: анда нинди гает икәнлеге дә әйтелмәгән — корбан гаетеме, ураза гаетеме?... Димәк, безнең алда 20

[1] Һидайәт — тугъры юл.

еллардан алып, 30нчы елларның урталарына кадәр кулланыла торган үрнәк вәгазь тексты. Әлбәттә, кайбер ачыклаулар кертеп (мәсәлән, нинди гаетикәнлеген әйтеп), хаҗәте чыга калса, бераз кыскартып, яисә өстәмәләр ясап сөйләр өчен җайлаштырылган үзенчәлекле күчергеч вәгазь. Мөфти хәзрәтләре үзе дә аны, һичшиксез, үзгәртә төшеп, кабат-кабат сөйләгән; аннан шул еллардагы шәһәр һәм мәхәллә имамнарының да үрнәк алганлыгында шик юк. Ниһаять, әсәрнең үзендә дә аның жанрына карата «дини вәгазь» дип ап-ачык күрсәтелгән.

Шулай итеп, безнең алда гадәти генә конкрет вәгазь түгел, бәлки гаять үзенчәлекле, озын гомерлелеккә исәпләнгән үрнәк вәгазь, хәтта махсус иҗат ителгән вәгазь-программа икән.

Вәгазьнең программа югарылыгына күтәрелә алырлык сәләтен тәэмин итә торган бер сыйфаты аның дөньяви мәнфәгатьләр белән охрави, ягъни ахирәткә бәйле омтылыш-максатларны бергә кушып, үреп бара алуында. Риза казый кайбер уртакул вәгазьчеләр кебек, динлелекне дөньявилыкка каршы куймый. Аның инануынча, бары җир өстендәге дөрес гамәлләр белән көтелгән тормыш аркылы гына кешеләр ахирәттәге бәхет-сәгадәткә ирешә алачак. Яки, икенчерәк итеп әйтсәк, нурлы ахирәткә лаек булыр өчен адәм балалары җир өстендәге кыска мөддәтле гомерләрен пакь иман, хәләл (хәзергечә әйтсәк — намуслы!) хезмәт, дөрес ният, үрнәк булырлык гүзәл әдәп-әхлакъ, гаделлек белән уздырырга тиешләр.

Ихтимал, вәгазьнең нәкъ менә шушы сыйфаты — махсус программа югарылыгына күтәрелә алуга сәләтлелеге, халык арасында киң таралуы, ел саен кабатлануы аңа карата булган большевистик һөҗүмнәрне барлыкка китергәндер. Ихтимал, нәкъ шуның өчен чит илләргә җибәрелгән «политик васыять» идеясе дә махсус урыннарда әвәләнеп, «факт» рәвешендә безнең күсәкле пропагандистларга, агач атеистларга тәкъдим ителгәндер. Әмма ләкин безнең сталинчыл сугышчан идеологларыбызның бу вәгазьгә карата дошманнарча кыланулары, шул юнәлештә үҗәтлек күрсәтүләре аларның шыр наданлыкларын да, тәмам кешелексезлекләрен дә шәррән ярып фаш итте. Моның шулай икәнлеген исбатлар өчен бер генә эксперимент ясап карау да җитә.

Мәгълүм булганча, большевистик идеология дини тәгълиматларны тулаемы белән кире кагып, дини әхлакның кыйммәтеннән йөз процентка баш тарту принцибын алга сөрде. Ягъни тегендә ак булса, монда — кап-кара; тегендә хак булса, монда — гел ялган. Шушы принциптан чыгып, вәгазьнең бер-ике җөмләсендәге хәбәрлек сүзләрен (вәгазьче киңәшләренең «үзәген») уңай хөкемнән аның ук инкяр формасына яки киресенә күчереп карыйк. Көтелмәгән нәтиҗә килеп чыга. Мәсәлән, бишенче абзацтан дүртенче җөмләне кабат укып чыгыйк һәм әле генә әйтелгәнчә үзгәртеп укыйк: **«Кешеләргә яхшылык тели торган булмагыз, бер-берегезгә зарарлы булуны теләп торыгыз, сүз йөртегез, кешеләрнең араларын бозыгыз, бер-берегезне чагып, мөселман кардәшләргә зарар итүдән сакланмагыз!..»**

Шундый ук экспериментларны алтынчы, җиденче, сигезенче, унынчы һәм башка абзацлар белән дә уздырып карарга мөмкин.

Минем мондый алымым белән килешмәүчеләр, «гел бер якка каерып җибәрүдә» гаепләүчеләр дә табылыр, бәлкем. Андый тәнкыйтьчеләремә тугызынчы абзацны карарга киңәш итәм һәм аның алдына шундый сорау куяр идем: әллә **без моңарчы, тулаем алганда, балаларыбызны динле, әдәпле, инсафлы, ниһаять, туган телле итеп тәрбияләп үстердекме?**

Әгәр тәнкыйтьчем бу мисал белән дә канәгать булмаса, аңар унберенче абзац буенча тагын бер сорау тәкъдим итәр идем: гыйбадәтханәләрнең, җөмләдән мәчетләрнең йөздән туксан тугызын җимереп, туздырып, пычратып бетермәдекме соң?!. Шулай ук уникенче абзацны алыйк... Хәер, аңлаган, аңлауга сәләтле кеше өчен әйтелгән хәтлесе дә җитеп торыр сыман.

Тагын бер ачыклый төшәсе мәсьәлә дә бар. Ул анализлана торган истәлеккә ни өчен моңарчы **васыять** дигән исемнең тагылу сәбәбе.

Васыять дип, гадәттә, бераүнең үзе үлгәннән соң аның кушуы, теләге буенча нәрсәләр эшләргә тиешлеген игълан итә торган хосусый акт документының төренә әйтәләр. Васыять хөкеме мәрхүмнең балаларына, якыннарына, хәтта дуслары һәм танышларына адреслана. Димәк, бер кеше тарафыннан язылган ике-өч васыятьнең булуы да ихтимал.

Васыять телдән генә әйтелгән рәвештә игълан ителергә дә мөмкин. Әмма күп очракта ул махсус документ рәвешендә язылып, әгәр эчтәлеге таләп итсә, шаһитлар тарафыннан да расланган була. Үзенең тиздән үләчәген сизгән, үлемнең реальлеген аңлаган айнык акыллы кешеләр васыятьләрен, гадәттә, алдан ук язып

куялар. Ризаэтдин хәзрәтнең дә шундый васыяте бар. Аны Р. Үтәбай тапкан һәм башкорт телендә бастырып чыгарган иде. Югарыда әйтелгән һәм алда китерeләчәк кайбер фикерләрем төгәлрәк аңлашылсын өчен шул васыятьнең «Агыйдел» журналы буенча *(1990, № 4, 137 б.)*[1] татарчага кире кайтарылган текстын укып чыгыйк:

## «Кәшшаф казыйга[2] васыятем

**Вакыт йитеп дөньядан үтсәм, башларына килгән беренче вакыйга булганлыктан, балаларым дәһшәт эчендә калырлар вә ни эшләргә белми гажиз булып йөрерләр. Шуның өчен үземне дәфен итү хезмәтен сезгә тапшырамын — Сез шуны тәмам башкарсагыз иде. Балаларга мөнасиб[3] хезмәтләрен кушып торырсыз. Үзенә хас вазыйфасы булганлыктан җеназамны ахун Җиһангир[4] укыр. Шуннан соң гәүдәмне чана белән булса да, арба белән булса да, каберлеккә килтерерсез. Мөселманлар каберләре арасына дәфен кылу иҗтиһадыны күрерсез[5]. Ләхет өлгергәч, үзең төшереп, шунда куерсың.**

**Дәфен тәмам булгач, Коръән укылыр. Шуннан соң халыкның торып кайтып китүләре мәтлуб. Хакымда иҗаби да, сәлби дә сүзләр булмасын иде. Әгәр дә иманы тәлкыйн итүче булса ризамын.**

**Ошбу дәфен хакында булган мәсрафны китапларым өчен миңа тиешле булып калган акчадан сарыф итсәң иде. Һәркем үзенең хәленнән мәмнүн булып калсыннар вә миңа рәнҗемәсеннәр иде.**

**Дәхи Диния нәзарәтенә тапшырылган, берәр генә нөсхәдән гыйбарәт булган язма әсәрләремнең мәхфүз булуларына дикъкать итүеңне, заман мөсәгъәдә кылып, аларны бастыру мөйәссәр булса, тәсхихләренә игътинаэ кылуыгызны сиңа тауcыйә кыламын.**

***1336-1354 ел, 21 зөлхиҗҗә — 15 март[6].***
***Мөфти Ризаэтдин бине ФӘХРЕТДИН.***
***Күчермә асылына муафикъ.***
***Рәис наибе Кәшшафетдин казый Тәрҗемани.***

Шулай итеп, васыять дигән нәрсә үз үлеменең реальлеген яки якынлыгын икърар иткән кешенең соңгы берәр ихтыярын, конкрет теләген игълан кыла торган махсус документ икән. Димәк дини үгет-нәсыйхәт жанрында язылган, гектограф ысулы белән күбәйтелеп, нәзарәт карамагындагы «барлык мөселманнарга» таратылган вәгазьне «васыять» дип атау, әгәр махсус эшләнмәгән булса, элементар наданлыкның, мантыйксызлыкның да галәмәте икән. Бөтен бер кавемгә (эчке Русия мөселманнарына), хәтта төгәл бер милләткә васыять әйтү ул бары пәйгамбәрләр өчен генә мөмкин булган миссия! Риза казый исә үзен гадәти генә җир кешесе дип белгән...

Минемчә, бу очракта, әлеге вәгазьгә карата «васыять» сүзе аңлы рәвештә махсус..кулланылган булырга охшый. Чөнки 20нче елларның башыннан алып,

---

[1] Публикациядә документның ни рәвештә саклангалыгы, күчермәнең кем тарафыннан, кайчан эшләнүе төгәл әйтелмәгән. Ләкин эчтәлеге һәм эслүб-стиле буенча аның Риза казый каләменнән чыкканлыгы шик тудырмый.

[2] Кәшшаф казый — Кәшшафетдин Тәрҗемани (1877-1943), Диния нәзарәтендә озак еллар казый булып торган кеше, Р. Фәхретдиннең иң якын фикердәшләреннән. Риза казый үлгәч репрессияләнгән, Вологда төрмәләренең берсендә ачлыктан үлгән.

[3] *Мөнасиб* — тиешле, муафикъ.

[4] Ахун Җиһангир — Җиһангир Абызгилдин — Уфадагы беренче мәхәллә мәчетенең имамы, шәригать мәсьәләләре һәм астрономия буенча китаплар, дәреслекләр авторы; 1937 елгы репрессия корбаны.

[5] Р. Фәхретдингә кадәр үлгән мөфтиләр нәзарәт ихатасы эчендә күмелгәннәр. Риза казый беренчеләрдән булып шул традицияне җимерә — үзен гади халык күмелгән җиргә, гомуми зиратка күмүләрен васыять итә. Арба-чананы телгә алу исә, мәетле табутны кешеләр үзләре күтәреп мәшәкатьләнмәсеннәр дигән теләктән гыйбарәт.

[6] Ризаэтдин хәзрәт шул елның 12 апрелендә вафат булган.

Сүзлекчә: *мәтлуб* — таләп ителгән теләк; *иҗаби да, сәлби дә сүзләр* — уңай да, тискәре дә сүзләр (ягъни мәет һәм кабер өстендә митинг сыман «сүз боткалары» оештырулар); *иманы тәлкыйн* — яңа кабер тирәсеннән халык киткәч укыла торган иман; мәсраф — чыгым, тотылачык акча; *мәмнүн булу* — риза, канәгать булу; *мәхфүз булу* — саклану; *мөсәгъәдә кылу* — ирек бирелү, мөмкинлек булу; *мөйәссәр булу* — җиңеллек булу; *тәсхихләренә игътинаэ кылу* — төзеклегенә игътибар итү, *тауcыйә* — тапшыру.

барлык гражданлык һәм кешелек хокукларыннан мәхрүм ителгән хәлдә, изоляцияләнеп яшәгән «мөфти Ризаэтдин Фәхретдинев» хаким даирәләр тарафыннан үлемгә хөкем ителгән шәхес иде. Физик рәвештә булмаса да, иҗтимагый җәһәттән үтерелгән кеше иде ул. Бездә элек киң таралган, иске аң буенча хәзер дә кулланыла торган «политик мәет» дигән гыйбарәне искә төшерегез... Ә үлемгә хөкем ителгән кешенең соңгы сүзе, соңгы ихтыяры, белгәнебезчә, васыять дип атала.

20 нче елларның беренче яртысында язылып, киң җәмәгатьчелеккә таралган вәгазь дә безнең ул чаклардагы хаким катламнар тарафыннан васыять рәвешендә кабул ителгән. Аның бер нөсхәсе Финляндиягә барып эләгү факты исә эзәрлекләү һәм җәзалау органнары тарафыннан совет дәүләтенә каршы коткы сыйфатында бәяләнгән. Васыять сүзе дә, бәлки, шул даирәләрдә барлыкка килгәндер...

Менә ни өчен галим үзе үлеп, тагын 20-30 ел үткәч тә Сталин күсәкчеләре әллә нинди «сәяси васыять» хакында сүз куертуны дәвам иткән. Менә ни өчен Гаяз Исхакыйның 1954 ел, 12 апрельдә, язучы вафатыннан өч ай элек, Хәлидә туташка җибәрелгән хаты да бездә гел «васыять» дип атап йөртелгән...

... Әйе, 20-30 нчы елларда мөфти Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләре большевиклар тарафыннан иҗтимагый рәвештә үтерелгән, иң кимендә шундый үлемгә хөкем ителгән шәхес иде. Соңгы вакытларда матбугатта кат-кат игълан ителгәнчә, үлү, ягъни тәннән җан аерылу процессы кешенең караңгы туннельгә кереп китүе, аннары туннельнең икенче башындагы яктылыкка таба омтылуы, елышуы кебегрәк була, имеш. Ихтимал, соңгы унбиш-егерме ел тормышын «урман эчендә гомер итүче заһидлар рәвешендә», ягъни большевизм төрмәсе караңгылыгында уздырган Риза казый өчен дә икенче дөньяга күчү перспективасы «туннель»нең теге башындагы яктылыкка таба бару булып тоелгандыр.

Аның каләменнән чыккан соңгы документлар — ихлас рухлы вәгазь дә, тыйнак табигатьле васыять тә — галим өчен караңгы туннельгә әверелгән чынбарлыкның ахырындагы яктылыкка ышаныч кебегрәк яңгырыйлар.

Бер үк вакытта алар җир өстендәге тормышның соңгы өмет чаткыларын да, яшәүнең мәңгелеген дә хәтерләтә...



Фәнис Яруллин

# «СӨЕМБИКӘ ЕГЕТ САЙЛЫЙ»

Кайбер әсәрнең язылу тарихы үзе үк мавыктыргыч бер әсәргә тиң була. «Сөембикә егет сайлый» музыкаль-лирик комедиям шундый катлаулы язмышлы әсәрләрнең берсе булды. Хәер, бөтенесен дә баштан башлыйк әле.

Моннан сигез-тугыз еллар элек миңа Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының баш режиссеры Валерий Раку шалтыратты да: «Безне татар әсәрләре куймауда гаеплиләр. Менә без шул тәнкыйтькә колак салып, татар әдипләре белән бәйләнешкә керергә уйладык. Берәр музыкаль комедиягә либретто кирәк иде. Яза алмассызмы? Дөрес, бездә Нияз Курамшович Даутов вакытыннан ук калган бер либретто бар анысы. Заманында театр аны репертуар планына да керткән булган. Ләкин аны бу килеш куярлык түгел. Бәлки шуны карап чыгарсыз, ул автор белән бергәләп эшләсәгез дә риза»,— дип үзенең гозерен белдерде.

Шушы сөйләшүдән соң без аның белән очрашырга булдык. Ул берничә көннән миңа Мөхәммәт Муллануровның «Сабантуй»дигән әсәрен күтәреп килеп җитте. Фасил Әхмәтов бу либреттоның кайбер арияларына музыка язды инде. Шушы кысадан бик чыкмыйча эшләсәгез әйбәт булыр иде. Чөнки автор белән килешү төзелгән, композитор да, либреттист та акчаларын алган, хәзер аларны төшереп калдырып булмый»,— диде Раку.

Мин бу либреттоны укып чыгып, үз сүземне әйтергә вәгъдә биреп калдым. Һәм мин аны шул ук көнне укып та чыктым. Дөресен әйтергә кирәк, либретто бернинди драматургия кысаларына сыярлык булмаганлыктан, моңарга соавтор булып көч түгүдән мәгънә юклыгы ап-ачык иде. Язарга уйлаганда, өр-яңа сюжет кирәк булачак! — мин менә шундый нәтиҗәгә килдем. Дөрес, драматургиядә әз-мәз тәҗрибәм булса да, музыкаль әсәрләр өчен либреттолар язып караганым юк иде. Безнең татар әдәбиятында «Башмагым», «Күзләр» кебек заманында шаулап барган музыкаль комедияләрнең либреттоларын укып чыктым. Ләкин болар гына җитми иде. Китапханәдән «Йөз либретто» дигән китап кайтарттым. Тик бу китап әллә ни файдалы булып чыкмады. Анда музыкаль комедияләрнең тулы либреттолары түгел, ә сюжетлары гына язылган иде. Төрле сюжетлар уйлый башладым. Күңелдә конкрет фикер тугач, сюжетымның планың төзеп яңадан Валерий Ракуны өемә чакырдым. Ул минем тәкъдим белән ризалашты. Ул көнгә композиторлардан Фасил Әхмәтов белән Ренат Еникеевны да дәшкән идем. Валерий Раку опера театрының әдәби бүлек мөдире Рәмзия Такташ һәм Таубе фамилияле бер режиссер белән килде. Алар килгәндә Фасил Әхмәтов белән Ренат Еникеев бездә утыралар иде инде. Һәммәбез утырышкач, мин язылачак әсәремнең

сюжеты белән таныштыра башладым. Ләкин Раку белән Таубе татарча белмәгәнлектән, сюжетны урысча сөйләргә туры килде. Сюжет барсына да бик ошады.

— Давай, тиз арада яза башла,— диде Раку,— бөтенләй язып бетергәнне көтмә, бер пәрдәне язу белән безне чакыр. Укырбыз, фикерләшербез.

Аннары ул Фасилга борылып:

— Музыканы син язарсың дип уйлыйм,— диде.

— Минем инде биш-алты ариям әзер,— диде Фасил.— Бер шәп кенә увертюра язып җибәрсәм яртысы булды дигән сүз.

Туачак әсәребез шәрәфенә «дога» кылганнан соң кунаклар таралышты. Икенче көнне үк эшкә керештем. Әсәр шактый җиңел барды. Бер атна дигәндә аның беренче пәрдәсе әзер иде инде. Тагын Ракуларны чакырдым. Бу юлы алар белән СССРның халык артисты Азат Аббасов та бар иде. Әсәремнең язган кадәресен укып, һәр җөмләне урысчага тәрҗемә итә-итә авызда телләр әйләнмәс хәлгә килде. Татарча язылган шигъри либреттоны «на ходу» гына тәрҗемә итү җиңел түгел иде. Бәлки мин аның бөтен мәгънәви нечкәлекләрен биреп тә бетерә алмаганмындыр, Валерий Ракуның чырае бозылды: «Это у вас получилось бытовая комедия. Пусть Галиасгар Камалцы ставят вашу комедию. А нам нужно что-то возвышенное»,— дип, мине пыр туздырып ташлады. Аның белән килгән Таубе: «А мне это нравится»,— диде. Аңа каршы Раку: «Если тебе нравится, ставь сам, а я отключаюсь от этого»,— диде.

Бәхәс китте: кемгә нәрсә ошаган, кемгә кай җир ошамаган... Бәхәсләшә торгач: «Моны музыкаль комедия итеп түгел, комик опера итеп эшләргә кирәк»,— дигән нәтиҗәгә килделәр. «Опера итеп эшләп чыксаң, үзем куям»,— диде Таубе. Шунда Азат Аббасов: «Татары оперу не жрут»,— дип бу фикерне кире каты. Әгәр операны сәхнәгә чыгарсак, беркем йөрмәячәк, опера яратучы тамашачыга классика да житкән, янәсе.

— Үзем куючы режиссер булам, әйдә, әр-яңадан тотын, кызыклы опера чыгарга тиеш бу материалдан,— дип, Таубе минем кырылган кәефне күтәрергә маташты.— Беркемгә карама, минем белән генә эшлә. Мин Казан кунакханәсенең бер номерында торам. Биюләрне минем хатын куяр. Ул театрда балетмейстр.

Таубе миңа телефон номерен бирде. Мин шуннан соң һәр күренешне язган саен аңа шалтырата башладым. Ул Мәскәүдә яшәүче режиссер иде, монда аны вакытлыча эшләп торырга Валерий Раку чакыртып китерткән булган икән.

Либреттоны тулысынча шигырь белән язып чыгарга айдан артык вакыт китте. Эшне бетергәч, җиңел сулап, хезмәтемне театр карамагына тапшырдым. Ул чакта художество советы житәкчесе Азат Аббасов иде. Либреттоны әдәби бүлек мөдире Рәмзия Такташ кулына биргәч, озакламый берәр хәбәр әйтерләр, дип көтә башладым. Ләкин атна арты атналар, ай артыннан айлар үтте — хәбәр-хәтер булмады. Ул арада Таубе Мәскәвенә кайтып китте. Ракуга шалтыраттым, ә ул исә: «Мин аны Фасил Әхмәтовка бирдем»,— диде. Фасилга шалтыраттым: «Әйе, Раку аны миңа биргән иде, ләкин минем авырып торган чак иде, атна-ун көн үтүгә ул аны кире алып чыгып китте»,— дип җавап бирде. Аптырагач театр директоры Рүфәл Мөхәммәтҗановка шалтыраттым, ул: «Без аны урысчага тәрҗемә иттерәчәкбез, хәзер аңа подстрочник ясыйлар. Урыс режиссерлары татарча материал белән эшли алмыйлар бит инде»,— диде.

Әкрен-әкрен бу әйбер шулай онытыла башлады. Шалтыратсаң, кемдә икәнен дә белмәделәр. Мин театр белән договор төземәгән идем, билгеле инде күпме эшләгән эш бушка китте.

Бу урында: «Куярлык булмагач нигә эшләткәннәр соң?» — дигән сорау туарга мөмкин. Моңа җавап бик гади иде: «опера театры житәкчеләрен татар авторлары белән эшләмәүдә гаепли башласалар, менә без фәлән-фәлән кешеләргә мөрәҗәгать иттек, ләкин татар язучылары пешмәгән булып чыкты, дип тәнкыйтьчеләрнең авызын томаларга мөмкин иң. Ә бит либретто ярамаслык түгел иде, минемчә. Хәтта: «Татары оперу не жрут»,— дигән Азат ага Аббасов та аның турында: «Әсәр бик лирично, монда жырчы өчен бөтен мөмкинлекләр бар»,— дигән иде. Танылган жырчы Венера Ганиеваның да: «Моңа музыка язып сәхнәгә куючы булса, Сөембикә ролен рәхәтләнеп башкарыр идем»,— дигән сүзе ишетелде.

Бу либретто опера һәм балет театрында шулай «баткач», бераз вакыт мин моңа карата сүрелеп тордым. Ләкин туккән көчне әрәм итәсем килми иде. Аны яңадан музыкаль комедия өчен гадәти пьеса рәвешенә кертеп проза һәм шигырьне аралаштырып язып чыктым. Инде кая бирергә? Марсель Сәлимҗановка бирергәме әллә дип, аңа берничә тапкыр шалтыратып-

шалтыратып карадым, ләкин туры китерә алмадым. Аннары әсәремне К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрына илттердем. Ул чакта анда баш режиссер булып Дамир Сиражиев эшли иде. Дамир әсәрне озак кына укымый йөрде. Бәлки ул татарча язылган пьесаларны укый да алмагандыр, татарча сөйләшүе такы-токы иде.

Берничә тапкыр шалтыратып та рәтле җавап ала алмагач, кул селтәдем. Ярар, мин әйтәм, бәлки ул үземә генә шәп күренәдер. Дамир Сиражиевка ошамагандыр. Ә ошамаган нәрсәне һәркем йөзгә бәреп әйтә алмый дип үземне тынычландырырга тырыштым. Шул чорда китап нәшриятына пьесалар җыентыгымны әзәрләп ята идем, «Сөембикә егет сайлый»ны да җыентыкка кертергә булдым. Җыентык кульязма хәлендә китап нәшриятында чыгарга үз чиратын көтеп ятканда, кайсыдыр редактор, менә бу музыкаль комедиягә әйбәт, карап кара әле дип композитор Луиза Батыркаевага биргән. Луиза Батыркаева ул чакта китап нәшриятында музыкаль редактор булып эшли иде. Әсәрне укып чыккан, ошаткан. Аннары безгә килгән. Килгән дим, чөнки без ул көнне өйдә юк идек. Батыркаеваның килгәнлеген белгәч, икенче көнне аңа шалтыраттым. Ул: «Әгәр театр аны үз репертуарына кертсә һәм минем белән договор төзесә, мин моңа рәхәтләнеп музыка язар идем» — диде. Әмма театрда аны укып караучы булмады. Озакламый Дамир Сиражиевны баш режиссерлыктан алдылар. Коллектив яңара башлады. Театрга әдәби бүлек мөдире булып яңадан Алик Гарәфетдинов кайтты. Ул тузан җыеп яткан папкалардан театр өчен пьесалар эзләгәндә минем «Сөембикә егет сайлый»га юлыккан. «Бер сулыш белән укып чыктым, бик ошады,— диде ул соңыннан миңа.— Озакка сузмыйча артистларга да укыдым. Укыган вакытта егерме сигез артист бар иде. Шунсы кызык: пьеса һәммәсенә дә ошады. Бөтен коллектив ошаткан әйбер сирәк була ул. Без моны һич кичекмәстән репертуар планына кертәбез».

Мин инде моңа бик үк ышанып җитми идем. Тагын берәр нәрсә килеп чыгар дип көттем. Ләкин эшләр әйбәт кенә бара башлады. Куючы режиссер итеп Илдар Хәйруллинны чакырдылар. Репетицияләр башланды. Гадәттә әсәрне куйган режиссерлар әле теге, әле бу җиренә «бәйләнәләр». Илдар Хәйруллин алай «бәйләнеп» йөдәтмәде. Бары тик бер-ике эпизодка гына: «Менә болайрак итсәк ничек булыр икән»,— дип, үз вариантларын кертте.

Менә 1992 елның 23 апреле, ягъни премьера көне килеп җитте. Премьерага барырга әзерләнеп ятканда телефон шалтырый. «Берәрсе алдан ук котларга уйлаган, ахрысы»,— дип трубканы алдым.

— Сезгә Сөембикә Вәлиева шалтырата,— диде трубкадагы тавыш,— мине ишеткәнегез бардыр дип уйлыйм.

— Бар, бар. Радиодан җырларыгызны яратып тыңлыйм.

— Ярый, ишетүегез әйбәт. Әле дә менә гастрольләрдән кайтып төштем. Күрәм: афиша. Анда «Сөембикә егет сайлый» диелгән. Сез ни өчен пьесага Сөембикә исеме куштыгыз? Сөембикә изге исем. Ул ничек егет сайларга мөмкин. Сөембикә безнең Ханбикәбез ләбаса...

Мин бу пьесадагы Сөембикә белән ханбикәнең бернинди уртаклыгы юклыгын, әсәрнең тарихи әсәр түгеллеген, ә бүгенге көн тормышыннан алып язылганлыгын, Сөембикә исемен исә үз героема матур саф татар исеме булган өчен генә куелуын аңлатырга тырыштым. Тик ул:

— Кичкә кадәр пьесагызның исемен алыштырыгыз, юкса мин чара күрәчәкмен,— диде.— Мин обком, министерство ишекләрен тибеп кенә ача торган кеше. Редакцияләрдә дә танышларым җитәрлек.

— Аның хәзер берничек тә исемен алыштырып булмый. Гомумән, мин аны алыштырырга теләмим. Пьесадагы бөтен җырлар аның исеменә, әсәрнең төп героинясына яраклаштырылган. Аның характерын күздә тотып язылган.

— Алыштырмасагыз үзегезгә үпкәләгез. Мин сезне судка бирәчәкмен. Әле гастрольләрдә йөргәндә Сөембикә исемле бер хатынны судка биреп кайттым. Ни өченме? Сөембикә исеме йөрткән башы белән икенче тапкыр иргә чыккан. Ике баласы бар, җитмәсә.

— Тормышта ни булмас,— дидем мин моңа каршы.— Сөембикәләр дә аерыла инде. Ә инде Сөембикә исеме йөрткәнгә генә сез аны судка биргәнсез икән — бу сезнең наданлыгыгызны гына күрсәтә.

— Минем дүрт дипломым гына бар,— дип пыр тузына башлады Сөембикә ханым.— Фронтларда йөргәндә дә, тыныч тормышта да мин үз исемемне тапламаска тырыштым. Ә монда «Сөембикә егет сайлый». Бу нинди әхлаксызлык? Кичкә кадәр исемен алыштырмасагыз, театрыгызны шартлатачакмын.

Мин һәр Сөембикәнең ханбикә түгеллеген аңлатырга тырыштым. Алайга китсә Мөхәммәтләр, Гайсәләр, Йосыфлар һәммәсе пәйгамбәр булсынмыни дип карадым, ләкин Сөембикә ханымны туктатырлык түгел иде. Мин трубканы куйдым. Бу сөйләшүдән соң күңелдә ниндидер авыр тойгы калды. Нәрсә бу? Бездә бит әле дә кайберәүләр үзләренең әхлаксызлыгын, культурасызлыгын үзләренең дипломнары белән капларга тырышалар. Дипломың бар икән, димәк, син югары культуралы, имеш... Ә бәлки бу Сөембикә ханымның артык наивлыгыннан киләдер? Әнә бит ул ничек югары «категория»дә фикер йөртә. Үз исемен аклар өчен ничек тырыша. Тик дүрт дипломлы Сөембикә ханым ике баласы белән икенче иргә чыккан ниндидер Сөембикәләрне судка биргән чакта, Казан ханбикәсе Сөембикәнең дә өч тапкыр иргә чыкканын уйлап карасын һәм дөньяда аерылулар, яңадан кияүгә чыгулар элек-электән булганлыгын исенә алсын иде.

Мин бераз лирик чигенеш ясап алдым. Әле бит премьера узмаган. Театрны шартлатмадылармы? Сөембикәбез үзенә егет сайлый алдымы?

Сөембикә ханым Вәлиева шалтыраткач, тегенди-мондый күңелсезлек илеп чыкмагае дип, бу хәлне театрдагы җитәкче иптәшләргә дә әйттем. Алар шундук ишекләргә егетләр куйдылар.

Аллага шөкер, бомбалы кешеләр күренмәде. Премьера әйбәт узды. Артистларга да, миңа да бик күп чәчәкләр бүләк иттеләр. Премьерадан соң сәхнә артына җыелышып чәйләр эчтек, спектакльнең уңышлы һәм уңышсыз якларын тикшердек. Шунда барлык артистларга Сөембикә ханым Вәлиева белән булган әңгәмәне сөйләп бирдем. Көлешеп алдык. Шулчак берсе: «Все хорошо, что хорошо кончается»,— дип куйды.

Әйе, ахыры хәерле беткән очракта барлык авырлыклар да онытыла ул.



Мәхмүт Әхмәтҗан

# ШИГЪРИЯТ АША ТӘРБИЯ

Татар кебек үз-үзен сакламаган һәм ассимиляциягә нык бирелә торган тагын нинди халык бар икән бу дөньяда? Ә бит Урта Азиядә, Кавказда, Балтыйк буе илләрендә, хәтта Украинада да мондый хәл юк!

Фаҗигагә тиң бу бәла белән милләт үзе, иң беренче чиратта, аның зыялылары көрәшергә тиеш! Әлбәттә, Татарстан һәм туган ил турында без соңгы елларда шактый яза башладык. Ә бит моннан дистә еллар гына элек күренекле әдипләребез «Мәскәүдән нур алдылар», «Ленин белән сөйләштеләр». «Нефтебез бөтен дөньяга ага»,— дип (үзебезгә файдасы түгел, зыяны гына тиде) күкрәк кактык, «бөек рус халкына дан» җырлауны бисмилла дәрәҗәсенә җиткердек.

Ә менә Хәсән Туфан исә, дөньяның ачысын-төчесен күп татыган шәхес буларак, болай дип язган иде.

Алтын куллы халык булсаң да, син
Бәхет йөзе күрә алмадың.
Эткә ыргытылган сөяк кебек,
Аяк асларында аунадың...

..........................................

Сан ягыннан байтак булсак та без,
Сансыз халык идек Рәсәйдә.

Бу юллар 1937 елда язылган!

Нинди зур хаклык ята аларда! Ә күпләр моның урынына: «Без бәхет илендә яшибез»,— дип җыр текстлары яздылар. Нишлисең, һәркем дә замана баласы шул! Ләкин Хәсән Туфан шул заманныкы булмаганмыни?! Әйе, озак еллар буена әдипләребез: «Татарстан — туган илем, туган җирем»,— дип язарга батырчылык итмәделәр. Чөнки бу зур гөнаһ саналды. Украина шагыйре В. Сосюра «Минем Украинам» дигән кечкенә күләмле бер шигыре өчен, тәмуг газаплары күрде. Шуңадыр, Татарстанга кунакка яки эш белән килүчеләрне җитәкчеләребез: «Приветствуем вас на казанской земле» (бу Казан губернасына ишарә ясау иде),— дип сәламләделәр. Курыктык шул, курыктык...

Һәм моны кемгәдер сылтадык та әле. Андыйларга Равил Фәйзуллинның афоризмга тиң түбәндәге дүртьюллыгы белән җавап бирергә кирәк:

Җаныңның ваклыгын
Сылтама заманга.

Куркырга, өркергә
Җай бар ул һаман да.

Шагыйрь Рәдиф Гатауллин исә болай дип яза:

Тирә-якта тынлык,
Ә куркаклар шаулый...
Яу шау-шуы купса —
Куркак якын бармый.

Куркаклык дигәннән, бу сыйфат үзеннән-үзе генә тумый, тормыш шартлары аркасында, катлаулы психологик компонент буларак формалаша ул. Иң аянычы шул: бу стереотипны вату, юкка чыгару бик тә кыен. Шамил Маннапов бу турыда ачынып болай ди:

Тел яшергән яшь килендәй
күпме еллар дәшмәдек.
Ил нужасын тарта-тарта,
сабыр гына эшләдек.
Дәшәлмәдек —
яман сөлек
каныбыз суырганда,
яла ягылган халыклар
җиреннән куылганда...

Әйе, тарихта «бөек» исеме белән хөрмәтләнгән татар халкы әнә шул хәлгә төшкән иде. Бүген үз асылыбызга кайту юлында очраган күп кенә каршылыклар җиңелсә дә, тынычланырга бик иртә әле. Тырышсак, берләшсәк, бер халык икәнлегебезне аңласак, һәртөрле тарих сынауларын уңышлы үтәчәкбез.

Ләкин бүген Казан кебек күп шәһәрләрдә татар балаларының иң зур күпчелеге туган телдән, мәдәнияттән аерылган. Республикабызда татар теле дәүләт теле дип игълан ителсә дә, әлегә бу кәгазьдә генә кала. Моңа җәмәгатьчелек тә гаепле: бездә чын мәгънәсендә татар теле өчен көрәш җәелгәне юк. Туган телне сәхнәдән пропагандалау урынына, кайберәүләр һаман да әле катнаш никахка мәдхия җырлыйлар. Нигә, мәсәлән, Гамил Афзалның түбәндәге юлларын һәрбер сәхнәдән һәм радио-телевидение аша яңгыратмаска икән:

Ана телем, сине өзелеп ятратканга,
Очам дисәк, безгә булдың канатлар да:
Дошман белән көрәшкәндә — үткен кылыч,
Балдай татлы — дуслар белән сайрашканда.
Җырларның да иң татлысы синдә генә.
Уйларның да иң татлысы синдә генә.
Туган илнең, туган телнең матурлыгы
Якты илһам бирми икән кемгә генә.

Телләрне сортларга бүлү килешмәс иде, һәркемгә үзенеке кадерле. Равил Фәйзуллин әнә ничек яза:

Гавами ул,
бик гади тел.
Минем телдә иген үсә,
сөт парлана, җеп эрләнә,
нефть чыга, тире иләнә...

Әйе, үз телеңдә беренче аваз салу, «әттә», «әннә» дип үрелеп кулларыңны сузу — мәңге онытылмаслык сәхифә... Әмма, югарыда әйткәнчә, соңгы вакытларда ата-ана телен санга сукмау ниндидер чиргә әйләнеп бара. Кайберәүләр «кухня телен» (ата-ана телен) белмәү белән, мактаныша ук башладылар. Янәсе, алар мәдәниятле, шуңа татар телен белмиләр... Хәсән Туфан шундыйларны истә тотып, түбәндәгечә язды:

Тукай абый туган телне
«Әнкәм теле» дисә дә,
Безнең өйдә шул ул телдә
Әби генә сөйләшә.

Мин бу юлларга өстәп, бүгенге әбиләрнең дә шактые оныклары белән вата-кыра чит телдә сөйләшүен әйтер идем. Телен югалтучыларны Зөлфәт «имансызлар» дип атый һәм халык өчен ачынып:

> Бездән башка кем гаепле булсын
> Башка төшкән мондый гарьлеккә?! —
> Без су сибеп үстергәнгә күрә
> Гөрләп үсте
> рухи гарипләр,

— ди. Ә бит шагыйрь хаклы: ни чәчсәң, шуны урасың. Ә динен, телен, халкын югалткан манкорттан да җирәнгеч, куркыныч тагын кем бар икән? «Татар барда — хәтәр бар» дигән әйтемнең бер сәбәбе шул түгел микән? Инде тел тарихына килгәндә, ул үзенә күрә — ил тарихы. Урысның иң беренче туздырган дәүләте — Казан ханлыгы. Бу бөтен дөньяга мәгълүм. Дөресен генә әйткәндә, күп яктан, мәсәлән, мәдәният, әдәбият, экономика, мәгариф өлкәсендә, татар дәүләте күпләргә үрнәк булып торган. Бүген дә татар теленең дөньяда иң мөһим 14 халыкара телгә керүе дә һич очраклы түгел: ул җитлеккән, үскән, бай тел. Әнә шул хәл басып алучыларның ачуын кабарткан. Алар үзләренең стратегик планы итеп татар халкын һәм аның телен ассимиляция юлы белән — бетерергә омтылганнар. 1870 елда Россия империясенең мәгариф министры Д. А. Толстой бу турыда ачыктан-ачык әйткән: «инородецларны укытуның төп һәм хәлиткеч бурычы булып аларны урыслаштыру — урыс халкы белән кушу тора»,— дигән. Әмма рус хөкүмәте бу юлда әллә ни зур уңышларга ирешә алмады. Ләкин, патшалар йөз еллар буе хыялланганны, большевиклар хөкүмәте берничә дистә елда ныклап тормышка ашыра алды. Мәсәлән, СССР дип аталган империядә 50 ел эчендә 194 милләтнең 93 е юкка чыкты. Шундый ук язмыш башка халыкларга да киләчәк иде. Бу — фараз итү түгел, ачы хакыйкать. Әнә Зөлфәт бер дә юкка:

> Сау була күр,
> милли яшь-җилкенчәк,
> Денең дә юк синең, көнең дә.
> Туган телдән йөзен чөергәннең
> Сукыр йолдыз янсын күгендә,—

дип каргамый. Әмма, беренчедән, әлеге яшьләр татар телендәге каргышны аңламыйлар, икенчедән, динсез, денсез, телсез булып алар күктән төшмәгәннәр. Моңа — без гаепле. Чөнки бертуктаусыз бары тик «бөек рус халкы», «бөек рус теле» хакында гына яздык, сөйләдек. Шул юлда профессорлар булып, халык җилкәсендә утырдык. «Милләтче» булып гаепләнүдән куркып, ана теле турында җылы сүз әйтүдән тартындык. Бу хәл бүген дә дәвам итә. Күптән түгел бер шагыйрьнең шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Мин аңа бәя бирергә җыенмыйм, бәлки анда әйбәт әсәрләр дә күптер. Әмма китапта татар теле һәм халкы турында сүз юк... Әйтерсең лә кайбер әдипләребез башка мөхиттә яшиләр инде... Кемдер бәлки, «поэзия, лирика — хисләр дөньясы ул, ә тәрбия белән педагогика шөгыльләнсен»,— дияр. Ләкин моны надан гына әйтер. «Үз үземә» шигырендә Тукай:

> Татар бәхте өчен мин җан атармын:
> Татар бит мин, үзем дә чын татармын,

— ди.

Аның «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» шигыре болай тәмамлана:

> Тик фәкать милләткә хезмәткә мәхәббәт бәндә бар,
> Бәнчә, бунда ямь дә бар, ләззәт тә бар, тәм дә бар.

Мондый юлларны бөек әдибебезнең һәрбер шигыреннән табарга була. Аның балалар өчен язган әсәрләре үзләре — бер олы белем һәм тәрбия мәктәбе.

Такташны мин дуслар белән очрашканда, дошманнар «тешләгәндә», күңел күтәренке чагында, кайгыга дучар булганда, буш вакытым булганда, болай гына да укыйм. Чөнки Такташ поэзиясе — үзенең теле, нечкәлекләре, аһәңе һ. б. белән нәкъ татарныкы! Ул үз халкының уйларын, теләкләрен бик тә яхшы белгән һәм шуларны поэзия теле белән әйтеп биргән. Дөрес, шагыйрьдә идеологик ялгышлар бар, әмма ул яшәгән чорда алар кемдә юк иде соң? Такташ әсәрләрендә гомуми сүзләр, битарафлык юк. «Авызлары, борыннары җимерелгән сүзләрне яклап» шигырендә юмор белән:

Урыс теле инде урыс белән
Сөйләшергә, әйтик, яраса,
Татар теле ул бит татар белән
Аңлашырга ярый ләбаса,—

дип әйтә.

Әдипнең «Мәхәббәт тәүбәсе», «Җырым сиңа булсын», «Алсу», «Мокамай», «Таныш түгел елмаючы», «Тун трагедиясе» кебек бик күп шигырьләре бүген дә искермәгәннәр. Аңлашыла ки, һәркем дә Тукай, Такташ була алмый, моны таләп итү урынсыз булыр иде. Ләкин инде шигырь өчен генә шигырь язу — егетләр эше түгел... Туган халкына, аның теленә, туган як табигатенә мәхәббәт тәрбияләү — иң изге таләпләрнең берсе. Рәдиф Гатауллин әйтмешли:

Әткәй мине бик бай кеше иткән:
бар дөньяны миңа калдырган;
Якты булсын өчен юлларымда
баш очымда кояш яндырган.

Әтиләр, әниләр, гомумән өлкәннәр, безгә олы өметләр багълап, һәммәбезне дә җиргә нык басып йөрергә өйрәтеп киткәннәр. Әнә шундыйлардан шагыйрьләр, язучылар, сәнгать кешеләре, галимнәр үсеп чыккан. Мин үзем, шәхсән, һәркем дөньяга шагыйрьлек галәмәте белән туа дип уйлыйм. Чөнки мәхәббәт белән поэзия бертуганнар. Сәбәбе — галәм үзе мәхәббәт үрнәге. Кояш җирне иркәли. Гүзәл табигать көчле хисләр уята. Ә без — табигать балалары. Рәдиф Гатауллинга кушылып күпләр:

Үләннәргә ятып иркәләнәм,
елгалардан уема җавап эзлим,
көн агышын тойган күзем белән
һаман Җирне комсызланып иңлим,—

дисә, бик урынлы булыр. Хәер, шагыйрьләрнең мәхәббәт турында язмаганы бар микән? Әлбәттә, юк. Йөрәгебездә бөек табигатькә мәхәббәт уты мәңге дөрли. Л. Н. Толстой Кояшның Җиргә, табигатькә булган мәхәббәтен балалар өчен язылган кечкенә хикәясендә болай тасвирлый: «Кояш җиргә җылылык (мәхәббәтен) биреп, үләннәрне, агачларны үстерә. Үләннәрне ашап, сыерлар безгә сөт бирә, кырда икмәк үсә, агачларны кисеп, утын итеп ягып, җылы өйләрдә яшибез...» Кыскасы, мәхәббәтсез тормыш та, яшәү дә юк. Мәхәббәтнең иң көчлесе исә ата-анага, туган җиргә, халкыңа, яраткан кешегә багышлана. Роберт Миңнуллинның «Әнием догалары» үзе генә ни тора! Гамил Афзалның «Дөнья матур, дөнья киң» шигырен укыганда да, мөгаен, һәрбер адәм баласы үзен бәхетле сизәр һәм шагыйрь артыннан:

Күктә кояш, җирдә гөлләр,
Алда юллар, юлда — мин,
Күктә йолдыз, җирдә ярым,
Сөйгән ярым гөлгә тиң,
Дөнья матур, дөнья киң,

— дигән юлларга ике куллап мөһер сугар. Шагыйрь өчен туган ана белән туган җир — синонимнар:

Туган җирем белән туган анам,
Сезнең өчен көенеп, утта янам,
Мирас булып сезгә җырым калсын,
Рәхмәт яусын,—

ди ул.

Ана — балага җан өрүче генә түгел, халык традицияләренә таянып, аны кеше итеп тәрбияләүче дә. Шуңа күрә анага ихтирамсызларны елан балаларына ошату тәкъбире бар. Халык әйтсә, хак әйтә шул. Һәммәбез дә Анага ихтирамлы булыйк, ул исән чакта аның фатихасын алып калыйк. Анага булган изге мәхәббәт уты бер вакытта да сүнмәсен. Әнә шагыйрь Шамил Маннапов дөрес әйтә:

Вакыт, ара, үлем аерса да,
Күңелемнән, әнкәй, китмәссең,

Син булганда чәчәк-гөлләрем сау,
Имин тора күңелем чишмәсе,— ди.

Гөлшат Зәйнашева иҗат иткән шигырьләрне мин үзем хисләнеп, тәм табып укыйм. Чөнки аларда сәнгатьчә эшләнеш тә, менә дигән эчтәлек тә бар. Менә шуның бер үрнәге:

Кояш, кояш мәңге балкый,
Мәңге нур сибә.
Кояш гомере телим мин
Әнием сиңа!

Нәкый Исәнбәтнең туган илне ана образына бәйләве дә ышандырырлык:

Китми күңелемнән минем һич
Шул сөекле илкәем;
Анда сөйгән ярлы халкым,
Анда сөйгән әнкәем.

Татар шагыйрьләре арасында Роберт Миңнуллин кадәр аналарга мәдхия җырлаучы, аларны олуглаучы башка берәү бар микән? Мин белгәннәр арасында — юк. «Әнкәйнең ак чәчләре» җыентыгында әнкәйләр турында ике дистәгә якын бик яхшы шигырьләр бар. Күбесенә бик матур көйләр иҗат ителгән. Алар эстрададан төшмиләр. Һәммәбезнең дә әнкәбез булган яки хәзер дә бар. Алар — олуг җаннар. Анасын хөрмәт иткәнне ил дә, халык та үз итәчәк. Әнә шуңа күрә балалар да, өлкәннәр дә Роберт Миңнуллинның түбәндәге юлларын үзенеке итеп кабатлыйлар:

Әнкәй безне Сөннән алып кайткан,
Сөн суында юган иң элек.
Бишек җыры көйләп төннәр буе
Без үскәнне көткән тилмереп.

Әлбәттә, әниләр — мәңгелек тема. Чөнки алар үзләре дә җирдә тереклекне, мәңгелекне дәвам иттерүчеләр. Сүз уңаенда, шуны гына әйтәсем килә: әтиләр турында шигырьләр бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Моның сәбәпләрен өзеп кенә әйтүе дә кыен. Фән теле белән әйтсәк, бу — дисбаланс һәм аңа иң беренче чиратта, ир-ат шагыйрьләр үзләре гаепле. Ә менә Равил Фәйзуллинның «Минем әти» дигән шигырь юлларын укыгач, күкрәгем киңәеп китә, газиз атамны сагынып искә алам:

Син алла да түгел, әти,
фәрештә дә түгел, әти.
Син бары әти, әти!

Бу өч юллыкта тирән мәгънә ята: әти бер генә була, аны беркайчан да, беркем дә алыштыра алмый!

Сүз уңаенда булса да, гаҗәпсенүемне әйтеп үтәсем килә: шагыйрьләрнең күпчелеге — ир затыннан. Ә әтиләр турында — ә бит үзләре дә әтиләр әле — шигырьләр юк дәрәҗәсендә. Бу бик зур хата. Онытмыйк: дөньяның тоткасы — ирләр кулында. Моны безнең өчен илаһи көчләр хәл итеп куйган...

Җәмәгать, онытмыйк: әтиләрсез дөнья булмый. Әтиләрсез бала-чага дөрес тәрбия алмый! Әти тәрбиясе алмаганнарга дөнья океаннарын хәвефсез үтүе, кыенлыклар белән көрәшүе авыр. Чөнки әтиләр авырлыкларга баш имәскә өйрәтәләр. Әйе, әтиләрен өзелеп яратучылар бар. Андыйлар ерак җирләрдә, сугыш кырларында ятып калган аталарының каберен зыярат итәргә Польша, Чехия, Словакия, Венгрия, Польша, Югославия, Германиягә барып җиттеләр. Бу «күрешү» дистәләрчә еллар буена туганнар каберлегендә яткан шәһитлар өчен түгел, вөҗдан кушуын үтәү, яшь буынга үрнәк бирү өчен кирәк иде. Әтиләр, абыйлар, бабайлар безнең бүгенгебез өчен башларын салганнар һәм аларга мәңгелек рәхмәтле булырга тиеш түгелбезмени? Әти әти инде ул. Мин шагыйрь дә түгел, үзем хакында нәрсәдер сөйләргә дә җыенмыйм. Әмма әнкәй бик кадерле булган кебек, әткәй дә гомер буена йөрәгем түрендә утыра! Ул булмаса, мин булмас, тиешле белем, тәрбия алмас идем... Без үскәндә (ә ул сугыш елларына туры килде) тормыш гаять авыр иде. Тормыш булгач, һәммәсе дә булгандыр, әмма әткәйнең, безгә — 5 баласына — кул күтәрү түгел, авыр сүз

әйткәне, кырын караганы да булмады. Тыйнаксызлык булса да, әйтим инде: мин дә, әткәй үрнәгендә, балаларыма каты бәрелергә тырышмадым...

Аңлашыла ки, поэзия — гел тәрбия кодексы гына була алмый. Әмма кешенең дөньяга карашларын формалаштыруга хезмәт итмәгән «кысыр чәчәк» әсәрләренең кемгә һәм нәрсәгә кирәге бар икән? Берәү миңа: «лириканы сиземле белергә кирәк, аның бурычы — матурлыкка мәдхия җырлау!, — дигән иде. Кем матурлыкка каршы соң? Көнчыгышның классик үрнәкләре, газәлләре беркемне дә тыныч калдырмый. Урысның Феты, Майковы, Тютчевлары да әнә шундыйлардан. Әмма алар заманны, тирә-юньне мактап җырлаганнар. Без дә төшеп калганнардан түгел, татарда да лириклар бар. Әмма бу хакта махсус сөйләшергә кирәк... Шулай да Зөлфәтнең «Димәк» дигән кечкенә шигыреннән түбәндәге юлларны китерү артык булмас кебек тоела:

Шундый эре төннең йолдызлары!
Торып бассаң,
        башың бәрелер.
Ага күктә йолдыз ташкыннары —
Шул ташкынга кушыл, и гомер!

Гамил Афзалның «Күзләр житә» шигырендәге:

Сары төскә кергән як-якларым,
Җилгә сибелә алтын яфракларым
..............................
Нидер эзли күңел, нидер көтә...
Күзләр җитә, ахры, күзләр җитә,—

дигән, беренче карашка гади генә булып тоелган, шигъри сүз тезмәләре күңелгә моңсулык өстиләр, дөньяның галилеге һәм фанилыгы турында уйланырга, күңелне сафландырырга мәҗбүр итәләр.

Туган якка, аның табигатенә мәхәббәт тәрбияләүдә поэзиянең мөмкинлекләре зур, хәтта көндәшләре дә юк бугай. Әлбәттә, һәр шагыйрь туган илен, туган халкын, аның үзенчәлекләрен үзенчә җырлый. Хәсән Туфан «И татар» әсәрендә болай ди:

Синең төп сыйфатың
Батырлык, кыюлык.
Синең бу гадәтең
Байрагың булырлык.

Әйе, татар халкы үзен сугышта да, тыныч тормышта да иң уңай яктан күрсәтте һәм күрсәтә. Республикабызның бәйсезлеге өчен көрәш барганда, бик күп яшьләребез үзләрен кыю, максатчан итеп тоттылар. Хәсән Туфан бүген исән булса, алар алдында чал башын ияр иде.

Халык тарихсыз булмый. Әмма үз тарихын белмәгән халык үлемгә дучар ителә. Моңа юл куярга ярамый. Шуңа күрә тарихи үткәнебезгә багышланган шигырьләрнең әһәмияте тагын да арта. Бу бигрәк тә Гамил Афзалның «Идел башы», «Алтын бөртек», «Китаплар язмышы», «Сарматлар», «Тарих мең дә...», «Болгарлар», «Болгар бәете», «Сөембикә сылу», «Кол Гали», «Салават батыр», «Шәехзадә Бабич» шигырьләрендә ачык чагыла.

Татарның бер төп фаҗигасе — туган илне ташлап, бәхет эзләп китүе. Урысларда андыйларны «перекати-поле» дип атыйлар. Ә бу инде һич тә мактау билгесе түгел. Рәсәйдә татар кебек сибелгән башка халык юк. Кайда авыр, агулы урыннар — тик әйбәт акча гына түләсеннәр — татар кешесе. Алар күпләп Якутия-Сахада, Красноярскида, Иркутскида, Омскида, Хакассия, Бурятиядә, Көнбатыш Себер киңлекләрендә, Урта Азияда яшиләр. Сибелгәннәр генә. Тора-бара алар телләрен, мәдәниятләрен, кыска гына итеп әйткәндә, татарлыкларын югалталар. Башка милләтләр эченә кереп, эреп бетәләр, ассимиляцияләшәләр. Гамил Афзал аларга мөрәҗәгать итеп:

Беркайда да оҗмах түгел,
Туган илеңнән китмә син,
Изге җиреңнән китмә.
......................
Ярларыңны ятим итмә,
Талларыңны ятим итмә,

ди. Ә кем-кем, әмма Афзал ага читкә китүнең, андагы тормыш итүләрнең ни икәнен яхшы белә... Мәсьәлә әле башкада да: әгәр бүген Татарстанда татар халкының ике миллионы гына яшәсә дә, Солженицын кебек үтә шовинистлар безне эт итеп мәсхәрәләмәсләр иде. Менә шулай, Америкада яшәп, коммунистларны сүгеп, кайбер держимордалар «Татарстан суверенитетка лаеклы түгел, чөнки төп халкы күпчелекне тәшкил итми»,— дип кычкырмаслар иде... Шулай итеп милли аң зәгыйфьлеге халыкның таркалуын көчәйтте. Таралу-таркалу, үз чиратында, милли аңның тагын да түбәнәюенә китерә.

Туган якның чишмәләре, күлләре, елгалары, урман, кырлары, аларда яши, үсә торган җан ияләре, җимеш-җиләк — болар һәммәсе безгә дә кадерле. Зөлфәтнең «Туган туфрак», «Ык торналары», «Коры күл», Шамил Маннаповның«Урман шавы», «Чишмә», Роберт Әхмәтҗановның «Тургай җыры», «Иделдә җәй», «Кечке кошлар», «Көзге бакча», Гамил Афзалның «Кышкы урман», «Кышкы иртә», «Идел ага», «Сабан тургае», «Көзләр җитә» шигырьләренең тәрбияви әһәмияте бик зур. Ул әсәрләрне укыган малайлар кош ояларын туздырып, песиләрне утка ыргытып, агачларны сындырып йөрмәсләр дип ышанасы килә.

Аңлатмалар бирми генә, туган якка багышланган тагын берничә шигырьдән өзекләр китерик әле:

Туып-үскән шушы җирнең ямен
Алмаштырмый икән һич нәрсәң.
Башка берни дә кирәкми,
Үзем чапкан печәннәрне
Бер туйганчы иснәсәм.

*(Сибгат Хәким, «Берни дә кирәкми».)*

Әй, Туган җир! Туган җир!
Барлыгыма сыйган кадәр
Бар яхшылык җыйган җир!

*(Равил Фәйзуллин, «Туган җир».)*

Син бит әни безгә,
Син бит изге,
Кем кулында соң, син, и Ватан?
Мин үземне, бәлки, килер буын
Ятим итмәс диеп юатам.

*(Мөдәррис Әгъләмов, «И Ватан!»)*

Нәрсә җитә үзең туып үскән
Чирәмнәрнең тәмле исенә!
Кыйгак-кыйгак диеп каңгылдашып
Йорт казлары кирә төшемә.

*(Рәшит Гәрәй, «Мендәр».)*

Бу шигырьләргә уртак нәрсә туган якны эчкерсез сөю, шул илдә тууың, яшәвең белән горурлану, шул хакта поэтик образлар тудыру...

Татарның атка гашыйклыгын бөтен дөнья беләдер кебек. Зөлфәтнең «Ат йокысы», «Ике ат турында баллада», «Атлар чаба», «Ат карагы», Салисә Гәрәеваның атлар турындагы бик матур шигырьләре — моның ачык мисалы. Аларны тыныч кына укып та булмый. Бу — безнең каныбызда... Шулай шул: туган якның чыпчыгы, саесканы, ала каргасы да газиз. Чөнки без аларның мәңгелек күршеләре, юлдашлары. Аларсыз Ватан төшенчәсе дә тулы булмый. Җырлагыз шагыйрьләр шул җан ияләренә мәдхия! Исегездәме, Кытайда бервакыт Мао-цзе-дун кушуы буенча, илдәге бөтен чыпчыкларны юк иткәннәр иде. Янәсе, кырдагы икмәкне ашыйлар. Әмма берничә ел үтмәде, күрше илләрдән күпләп чыпчык сатып алырга туры килде кытайлыларга. Чыпчык бер килограмм ашлык ашаса, ун-йөз килограммны (кортларны юк итеп) саклый икәнен белделәр алар ахырда.

Татар милләтенең йөз елларга сузылган империя золымы астында да исән калуында диннең роле зур. Дин ул белем алуга чакыручы бөек көч тә. Ләкин бу сүздә генә калмаган: һәр татар авылында мәктәпләр, мәдрәсәләр эшләгән. Большевиклар моны бик яхшы белделәр, халыкны, телләрне бетерү өчен, иң беренче чиратта, диннәрне юк итү юлына бастылар. Үкенечле ки, берничә буын

яшьләре динсез булып үсте. Ә динсез кешегә урлашу, кеше үтерү, эчү h. б. берни дә тормый. Әгәр татар яңадан кеше кыяфәтенә керәм дисә, ислам динен аякка бастырырга тиеш. Моңа зыялылар да өлеш кертсен иде. Хәзергә әле бу өлкәдә аз эшләнә. Шулай да Шамил Маннаповның «Картлар кайта җомгадан» дигән шигырен укып чыккач, күңел сафлана башлаган кебек булды. Шагыйрь:

Вәкарь белән, горур атлап,
Картлар кайта җомгадан.
Гүя алар чыгып килә
Узган авыр еллардан,—

—дип бик төгәл әйткән. Картлар болай диләр:

— Иншалла, инде бар халык
Яңарта хак иманын.
— Иң яманы — имансызлык,
Шуннан сакла, ходаем...

Гамил Афзал — югары дәрәҗәдәге лирик шагыйрь. Әмма ул шул ук дәрәҗәдә юмористик hәм сатирик шигырьләр иҗат итә. Әгәр миннән торса, күренекле әдибебез, Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзалның юмор-сатира шигырьләрен күп тираж белән аерым китап итеп чыгарыр hәм бөтен татар дөньясына таратыр идем. Чөнки әлеге әсәрләрнең тәрбия көче, потенциясе бик зур. Әмма — бу аерым сөйләшүне таләп итә торган мөhим мәсьәлә.

**Нәтиҗә шул: яшьләрне тулы канлы шәхесләр итеп тәрбияләү эшендә, поэзия әсәрләрен бик уңышлы файдаланырга мөмкин. Әйдәгез без аларны да үзебезгә хезмәт иттерик.**

Нурмөхәммәт Хисамов

# АЛТЫН УРДАНЫҢ ШИГЪРИ МӘДӘНИЯТЕ

Алтын Урда дәверенең иң күренекле мәдәни мирасы — ул безнең көннәргә килеп житкән бөек әдәби ядкярләр. Әдәбият гомумән рухани мәдәниятнең дәрәҗәсен, үсеш югарылыгын гәүдәләндерсә, шигъри мәдәният исә урта гасыр татар жәмгыятенең, шул чор төрки эстетик аңының офык киңлеген, сурәтле фикер потенциалын чагылдыра.



XIV йөз Алтын Урданың ижтимагый-сәяси тарихында чәчәк ату, дәүләт кодрәтенең биек ноктасы буларак билгеләп үтелгән кебек, әдәби-шигъри үсеш җәһәтеннән дә алга китү дәвере буларак каралырга хаклы. Безгә килеп житкән әдәби мирас Алтын Урда сәнгатькәрләренең иждади багланышлары гаять киң колачлы булуын, нәфисәи ихтыяҗларының, шигъри зәвыкләренең гажәеп камил һәм тирән икәнлеген күрсәтә. Ул чор әдәбияты синкретик характерда булганлыктан, әдәби әсәр аша шул дәвер зыялысының рухани дөньясы хакында гына түгел, заманының фәлсәфи аң дәрәжәсе, галәм турындагы төшенчәләре, төгәл фәннәрдән алган мәгълүматы хакында да фикер йөртергә мөмкин. Ягъни әдипнең дөньяга карашы, эрудициясе эпик яки лирик әсәрендәге үзенчәлекле чигенешләр ярдәмендә бәян ителә. Тарихны һәм дөньяны колачлавы исә башлыча әсәрләренең шигъри фактурасы, сурәтле тукымасы аша тәгъбир кылына. Сәйф Сараиның «Сөһәйл белән Гөлдерсен» дастаныннан кызның егеткә мөнәсәбәтен чагылдырган мәгълүм өзекне генә алыйк:

Сөһәйлне күрдейү әйләнде бәр дик,
Гөнәш гәрдендә йөргән йер дик.

(Сөһәйлне күргәч, бөтерелде кош мамыгы кебек,
Кояш тирәсендә әйләнгән Жир кебек.)

Бу — Коперниктан күп элек теркәлгән фикер. Галәмне аңлауда төгәл фәннәр ирешкән казанышларны Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә дә күп очратабыз.

Алтын Урда әдәбиятының шигъри казанышлары хакында конкрет хөкемгә күчкәнче, XIV йөз әдәбиятын хасил иткән, аңа таяныч булган әдәби алшартларны карап үтәргә тиешбез.

Урта гасыр төрки әдәбияты XIV йөзгә кергәндә шактый бай тарих кичереп, төрле әдәби тәҗрибәләр ясап карый. Сюжеты дини-китаби чыганактан алынып, шигъри башкарылышы халык шигърияте традициясе нигезендә хәл ителгән Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы, аңардан ике гасыр чамасы элек язылган «Котадгу белек», чоры белән Кол Галигә якын Әхмәт Йөгнәкинең «Һибәтел хакаик»ы, Әхмәт Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани лирикасы, Йосыф сюжетына, ягъни бу очракта Кол Галигә ияреп язылган берничә төрек поэмасы — урта гасыр төрки шигърияте XIV йөзгә әнә шушындый мирас белән килеп керә. Өч гасыр дәвамында шигъри тәҗрибәләр ике традиция нигезендә дә — халык шигъре белән дә, гарузга таянып үсүче классик шигырь белән дә эшләнеп килене. Фарсы поэзиясенең йөзен исә бу чорда Низаминың һәм Сәгъдинең бөек әсәрләре билгели. Алтын Урда дәүләте ике зур мәдәни үзәкне — Хәрәзем белән Идел буен бергә туплый. Фарсы телле поэзия белән төрки телле шигъриятькә үзара тыгыз бәйләнеш өчен бу уңдырышлы җирлек тудыра. Дөрес, фарсы-төрки әдәби аралашуы төрки әдәбиятның бөтен тарихы буена килә. Йосыф Баласагунлыдан Кол Галигәчә андый бәйләнешләр әлеге аерым махсус шартларга бәйле булмый. Әмма соңгы очракта шагыйрьләрнең шигъри фикерләвенә әдәби мохит органик йогынты ясаган. Кайбер шагыйрьләр ике телдә дә бердәй талант белән иҗат иткәннәр. Мәсәлән, Мөхәммәт Хуҗа бәк Хәрәзмигә шигъри заказ биргәндә, шагыйрьнең дөньяга билгеле «фарсы дәфтәрләрен» искә төшерә. Кыскасы, XIV йөз төрки-татар шигърияте ирешкән зур казанышлар шушы ике традиция, дөресрәге, соңгы казанышларын бергә кушу нәтиҗәсендә барлыкка килә.



Шигъри фикернең иң үзенчәлекле күрсәткече булып метафора тора. XIV йөзгә кадәрге төрки поэзиядә метафора үзенең халык шигъриятендәге гадилеген саклап килә. Дөрес, аның катлаулырак төрләрен эшләү юнәлешендә дә тәҗрибәләр ясала. Әйтик, Сули Фәкыйһнең (XIII йөз) «Йосыф вә Зөләйха» поэмасында метафора Кол Гали белән Шәййад Хәмзәдән шактый камилрәк. Инде аңарда ук фарсы поэзиясенең, хосусан Низами поэтикасының тәэсире сизелә. Әмма бу өлкәдәге югары сыйфат сикерешен титаник талант Котб ясый. Низаминың «Хөсрәү вә Ширин»ен иркле тәрҗемә иткәндә, ул Низамига хас үтә катлаулы шигъри метафора алымын үзләштереп, Идел буе татарлары дөньясына хас географик, табигый, этнографик чынбарлык җирлегендә үзенчәлекле фактурадан торган колоритлы сынландырулар эшли. Мәсәлән, ул таң атуны, Низами сыман, теге яки бу гаскәрнең җиңүе рәвешендә сынландырганда, аерым детальләргә төрки колорит бирә.

Нитәк кем чыкты ирсә собх шаһы,
Ажундин качты зәңгиләр сипаһы.
Рәван көн төлкесе күтәрде башын,—
Сата башлады галәмгә комашын.
Фәләк фирүзә гөнбад кабгын ачты,
Ажунга алтынын берьюлы сачты.
Тәмам котрүлде ирсә пәрдә йөздин,
Җиһан ас тулды, китте кеш күздин.

Таң шаһы чыккач та,
Дөньядан негрлар гаскәре качты.

Чыгып килүче Кояш башын күтәрүгә,—
Галәмгә комачын сата башлады.
Күк фирүзә гөмбәзенең капусын ачты,
Дөньяга алтынын берьюлы чәчте.
Йөздән пәрдә тәмам күтәрелгәч,
Җиһанга ас тулды, күздән кеш китте.)

Бу сурәтләр аша Идел буе төркиләренең, ягъни болгарны, кыпчакны, хәзәрне, мажарны үзендә туплаган татарларның ау җәнлекләрен, бу халыкка хас кайбер сыйфат-гадәтләрне ачык төсмерләргә мөмкин. Әйтик, җиһанга күренерлек сәүдә эпизодлары, алсу нур кылчыклары тараткан Кояшны кызыл төкләрен тырпайтып торган, төлкегә охшату, көннең төнне алыштыруын кешне ас алыштыруы итеп бирү h. б. моның ачык мисалы.

Котб метафораның тагын да колачлырагын кыска, лаконик формада куллана белә һәм үтә нәфис сурәт ясауга ирешә. Үзенә чаклы иҗат ителгән әдәби сурәтләрдән дә яңа метафора ясый. Менә ул таш сарайда Хөсрәвен ялгыз көтеп утырган Ширинне ничек тасвирлый, аның кадерле затын ничек гәүдәләндерә:

**Хәсис ташларга ул гәүһәр катылмыш,**
**Йосыф тик казгу кодыгына атылмыш.**

(Соры ташларга ул гәүһәр катылган,
Йосыфтай кайгы коесына атылган.)

XIV йөз шигъриятендә Йосыф сурәте, аның язмышы нигезендә эшләнгән үтә көчле һәм хисси бүтән метафоралар да бар. Менә яз килүнең тантаналы шатлыгын Хәрәзми нинди метафора аша бирә:

**Ачылды яз, кичте ул кем ирде**
**Чәмән Йосыфлары зиндан эчендә.**

(Ачылды яз, үлән Йосыфларының
зиндан эчендәге чагы үтте.)

Шагыйрь яфрак ярганчы бөреләргә бикләнеп яткан гүзәл яшеллекне нинди сыйдырышлы, камил һәм нәфис сурәткә төргән! Идел буе әдәбиятындагы шигъри күчемлелек тә монда искиткеч бөтенлектә чагыла.

Алтын Урда шагыйрьләре мөселман Көнчыгышының бөек шагыйрьләре белән тиңнәрчә фикерләшәләр, ярышалар. Нәзыйрә традициясе шушындый иҗади ярыштан тора. Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е дә — мәгълүм дәрәҗәдә Низаминың «Хөсрәү вә Ширин»енә нәзыйрә; Сәйф Сараиның «Гөлстане бит төрки»се дә Сәгъдинең шул исемдәге әсәренә шактый дәрәҗәдә нәзыйрә санала ала. Шигъри фикер тыгызлыгы һәм сурәт төгәллеге ягыннан Сәйф Сараи иҗаты гомумән урта гасыр Идел буе төрки шигъриятенең иң камил казанышы саналырга лаек.

Алтын Урда шәһәрләре, хосусан, аның башкаласы Сарай бай эчтәлекле һәм үтә дә җанлы шигъри тормыш белән яшәгән. Мәсәлән, Сарай шәһәрендә 1333 елда булып киткән Ибне Батута, укымышлылар даирәсендә шигъри ярыш мәҗлесләре оештырылып, анда берәр күренекле төрки яки гарәп, яисә фарсы шагыйреннән аерым юлны алып, шуның нигезендә телдән илһами шигырьләр импровизацияләнүе хакында яза. Мондый бәйгеләр «мөләммәгъ ярышы» дип аталган. Әлеге ярышлар телләр белүне, эрудиция һәм зур талант көчен таләп иткән кебек, шигъри культураның да гаять югары булуын күрсәтә.

Бу бит әле безгә килеп җиткән бөек әсәрләрнең язылу елларыннан күпкә элек шулай булган. Димәк, Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е дә, Хәрәзминең «Мәхәббәтнамә»се дә, Хөсам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан»ы да, Сәйф Сараи әсәрләре дә кинәт кенә барлыкка килмәгән, бәлки Алтын Урданың мәдәни-шигъри мохитендә моның өчен уңдырышлы, бай җирлек әзерләнгән булган.

Шигъри әсәрләрдә чагылган лирик шәхес сурәте Идел буенда укымышлылыкның бик тирәннән килүен, галимлек, мөгаллимлек, остазлык традицияләренең аерым нәселләрдә буыннан-буынга тапшырылуын күрсәтә. Шагыйрь үзенең мәгъшукасына мәхәббәт тирәнлеген төшендергәндә дә, метафораны нәселендәге әнә шул традициягә ишарәләп ясый. Кызга карата һәм кыздагы мәхәббәт хисенең шагыйрьгә шигъри илһам бирүен Сәйф Сараи менә ничек сурәтли:

**Сәна бу шивәләр берлән күнел алмак кем үгрәтте?**
**Җәмалеңне күреб, заһид тотыб гыйшкың, йулын китте.**
**Мәнем кауме кабилемнең камусы галим ирделәр,**
**Сәнең бу гыйшкың устады мәңа шагыйрьлек үгрәтте.**

(Сине бу сөйләмнәр белән күңел биләргә кем өйрәтте?
Күркәмлегеңне күреп, гыйшкыңны тотып, заһид юлын бүлде.
Минем нәсел-нәсәбемдә бары да галим иделәр,
Синең бу гыйшкыңның остазы миңа шагыйрьлек өйрәтте.)

Әхмәд Хуҗа әс-Сараи шигыренә язган нәзыйрәсендә Сәйф Сараи шигъри телнең һәм музыкаль ритмның виртуозы булып күз алдына баса.

**Дилбәремнең зөлфе сөнбел, чәһрәсе гөлзар ирер,**
**Буена гашыйк сәнаубәр, йөзенә гөл зар ирер.**
**Агзы фәстук, күрке тансук, үзе мөшфикъ яр ирер,**
**Хөснеңең җавы Хита вә Чин эчендә бар ирер.**
**Аслы алчын, сүзләре чын, күзләре татар ирер.**
**Мең яшәр һәр кем дудагы ширбәтен татар ирер.**

(Сөеклемнең чәче сөмбел, йөзкәе гөлзар булыр,
Буена гашыйк нараткай, йөзенә гөл зар булыр.
Аузы фәстүк, күрке тансык, үзе йомшак күңелле яр булыр,
Чибәрлегенең даны Кытай һәм Чин эчендә бар булыр.
Нәсле лачын, сүзләре чын, күзләре татар булыр,
Ирене ширбәтен татыган һәркем мең яшәр булыр.)

Соңгы ике юлдагы рифмаларда сүз уйнатуның нинди тапкыр һәм нечкә булуына игътибар итегез. Беренчесендә — халык исеме, икенчесендә — сыйфат фигыль. Урта гасыр Идел буе шигъриятендә татар күзләре матурлыкның үз чагылышы хисапланган, димәк.

XIV йөз Алтын Урда шигърияте гомумтөрки шигъри мәдәниятнең дә югарылыгын билгеле. Бу казанышлар җирлегендә Низамигә тиң титанның барлыкка килүе төрки шигъриятнең үсеш мантыйгы тарафыннан табигый дәвам буларак күтелә, һәм ул талант Нәваи иҗаты рәвешендә дөньяга килә. Алтын Урданың шигъри мәдәнияте бүгенге көн укучысы өчен дә үзенең сәнгатьчә һәм фәлсәфитәрбияви кыйммәтен югалтмый. Аның үсеше бик куәтле була, әмма алдагы гасырларда татар халкы башына төшкән ачы тарихи сынаулар бу шигъри биеклекне югалтуга китерә. Татар әдәбияты ул биеклеккә милләт буларак оешу һәм милли аңның янә терелүе шартларында XIX йөздә генә яңадан якыная. Утыз Имәнидән башлап Акмуллага чаклы арада үзенең барлык шигъри маясын туплап, XX йөз башындагы куәтле сыйфат сикерешенә әзерләнә.

*Чаллыда яшәүче үзешчән рәссам, тарихчы-педагог* **Венер УСМАНОВ** *рәсемнәре.*

# ЗАТЛЫ НӘСЕЛ УЛЫ



**Ибраһим Вәли Терегулов (1852–1921).** *1916 еллар тирәсендә алынган рәсем булырга тиеш.*

Гадәттә без революциягә кадәр татар мәдәниятенә өлеш керткән шәхесләрнең рәсми органнар тарафыннан расланганнарын гына атый ала идек. Ул чорда кайсыларының эшчәнлеге бер ике сүз белән генә билгеләнеп үтеп, кайсыларын тамак ялында яман сүгеп, кинәнеп яшәүчеләр бар иде. Хәзер инде күп исемнәргә хаксыз ягылган кара тап алынды. Шундыйларның берсе — мәгърифәтче, чын мәгънәсендә татар зыялысы Ибраһим Вәлиулла улы Терегулов. Ул татар милләтенең асыл уллары — Шиһаб Мәрҗани, Ризаэтдин бине Фәхретдин һәм шул чорның атаклы рус галиме В. Радловларның замандашы Терегулов язучы-әдипләр арасында да үз кеше була, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан кебек классиклар белән якыннан аралаша.

Ибраһим Терегулов 1852 елда Уфада дөньяга килә. Гимназия тәмамлаганнан соң, ул Казанның ветеринария институтына укырга керә һәм 1875 елда тәмамлап чыга. Укыту сәләтенә ия белемле егет студент чакта ук Шиһаб Мәрҗани игътибарына юлыга һәм ул аны үзенең мәдрәсәсенә рус теле-әдәбияты һәм биология фәнен укыту өчен чакыра. Институтны тәмамлаганнан соң Ибраһим әфәнде Терегулов Казанның татар укытучылары әзерли торган мәктәптә (учительская школада) укыта башлый. Бу мәктәпнең татарлар өчен генә түгел, ә Россиядәге бөтен мөселман халыклары өчен әһәмияте гаять зур. Аны бетергән шәхесләр арасында без зур сәяси эшлеклеләр, язучылар, галимнәрне күрәбез. Үз халкының горурлыгы саналган мәртәбәле шәхесләрнең берничәсен — Г. Исхакый, С. Максуди, З. Вәлиди, М. Солтан-Галиев, Ф. Туктаров, Х. Ямашев, Я. Чанышевларны санап чыгу да житә.

Казан университетында тагын физика-математика белемен дә үзләштергән Ибраһим Терегулов әлеге мәктәпнең алыштыргысыз укытучысы — остазы булып китә. Аның әдәбият, биология, физика һәм математика өлкәсендәге белеме бик күп галимнәрне шаккаттыра. Гаҗәеп эрудициясе аның кешелекле, ярдәмчел булуына һич тә комачауламый. Терегулов хатын-кызларга белем бирүне җайга сала, ятим балаларга ярдәм кулын суза, авыллардан ярлы балаларын китертеп, үз хисабына укыта. Мондый шәфкатьле эштә аңа хатыны Гайшә ханым һәрчак иңгә-иң торып ярдәм итә.

Ул «Шәрекъ» һәм «Яңа клуб»ларга нигез салып, театр сәнгатен үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә. Ф. Аитованың хатын-кызлар гимназиясен ачуда башлап йөрүчеләрдән була. Шулай ук Те-




**Рәсемдә (сулдан уңга) — Р. Әхмәров, (?) Әхмәров һәм И. Терегулов.**

регулов мәгърифәт эшендә дә үз көчен кызганмый, йөзгә якын китап тәрҗемә кыла. Ялга чыккач та ул тынгысыз җанына эш таба: Оренбурда һәм Мәскәүдә татар мәктәпләре ачуны җайга сала.

1920 елда олуг укытучыны Сәмәркандның педагогия институтына профессор итеп, биология кафедрасын җитәкләргә чакыралар.

Ибраһим әфәнде һәм Гайшә ханымның мәгънәле гомер юлы, инсафлык үрнәге булып, балаларына да күчә (аларның биш кызы арасыннан) бүгенге көндә Рәбига һәм Хәлимә ханымнар гына исән.

Ибраһим Вәлиулла улы Терегулов 1921 елның 22 ноябрендә Сәмәрканд шәһәрендә дөнья куя. Татар халкының бу асыл улы, кабатланмас акыл иясе хакында без торган саен күбрәк мәгълүматлар ачарбыз әле.

**Булат СОЛТАНБӘК.**

## Алдагы саннарда укыгыз!

Әнәс Галиев «Һәр солдатның үз язмышы» дигән повестеның икенче кисәген тәмамлады. Әсәр – Бөек Ватан сугышы көннәре, дөресрәге, гитлерчылар кулына әсирлеккә эләккән тоткын солдатның ачы һәм михнәтле язмышы турында. Автор сүз башында болай дип яза: **«Сугышның беренче елында ук безнең миллионлаган сугышчы әсирлеккә эләкте. Күбесе яралы иде. Соңгыларының язмышына мин дә дучар булдым. Әсирлеккә эләккәндә миңа нибары 22 яшь иде. 1942 елның сентябреннән 1945 елның март азакларына кадәр, төрле концлагерьларда тәмуг газабына тиң авыр юл үтәргә туры килде. Качтым, тотылдым. Тагын качтым, тагын тотылдым...»**

Бу яңа әсәрдә берниндн «шомартулар» юк, ул документаль фактларга нигезләнеп язылган.

Китап күзәтү

# ШАГЫЙРЬНЕҢ ПРОЗАСЫ

Әхсән Баянов — иң әүвәл, әлбәттә, шагыйрь. Ул татар әдәбиятында үзенә бер өслүбе, сурәтләү үзенчәлеге булган, кеше күңелен бары тик аңа гына хас чаралар ярдәмендә ачып бирүче шагыйрь буларак танылды. Ләкин Ә. Баянов укучыга прозаик буларак та яхшы билгеле. Шуңа күрә Татарстан китап нәшриятында аның проза әсәрләреннән төзелгән ике томлык басылып чыгу гадәти генә күренеш түгел. Бу — сүз сәнгате остасының туган халкы алдында хисап бирүе дә.

Әлеге әдибебезнең проза өлкәсендәге эшчәнлеге турында җыеп бер фикер әйтү нияте күңелдә күптәннән йөри иде. Бу ике томлыкның кулга килеп керүе ниятне гамәлгә ашырырга этәргеч бирде. Сүз, әлбәттә, әлеге томнарга кергән әсәрләр тирәсендә барачак. Чөнки бирегә автор үзе яраткан әсәрләрен туплаган дип уйларга кирәк.

Ә. Баянов, иҗатчы буларак, бер төрлелекне яратмый. Аның проза әсәрләрен, бигрәк тә повестьларын, шартлы рәвештә ике-өч төркемгә аерып карарга мөмкин. Аларның бер ишләре татар әдәбиятында ныклап сыналган һәм уңышлы әсәрләр иҗат итү мөмкинлеге биргән традицияләргә таянып тудырылган. Чыннан да, авторга иң беренче уңышны шушы әсәрләре китерде дә. «Яшьлегемне эзлим», «Дүрт монолог», «Аязучан болытлы һава», «Тау ягы повесте», «Төлке тоту кыен түгел» кебек әсәрләре менә шушы «ояга» керә. Икенче төр әсәрләренә исә катлаулырак төзелеш, сурәтләүдә кинаялелек, шулардан килеп чыга торган шартлылык хас. Дөрес, болары да әдәбиятның бердәм кануннарыннан чыгарылма була алмый. Тик аларда романтик буяулар гармониясенең үзенчәлекле чагыштырмасы игътибарны җәлеп итә. Ә «Ут һәм су», «Таш китап» романнары Ә. Баянов прозасына яңа тема алып килде.

Менә беренче «ояга» кергән «Яшьлегемне эзлим», «Дүрт монолог», «Аязучан болытлы һава» әсәрләре. Алар аша сугыш алды елларыннан алып алтмышынчы елларга кадәрге кеше язмышларын күзәтергә мөмкин. Ягъни чор, социаль тормыш чолганышындагы персонажларның күңел диалектикасын күреп торабыз. Укучыны бигрәк тә Әнис образы, аның язмышы тарта. Тормышның, кешеләрнең аның күзаллавы аша бәяләнүе кызыксындыра. Әнис — Ә. Баяновның әлеге әсәрләренә лиризм, яктылык, сафлык өсти торган образ.

Әнис үткән юл язучының үз язмышына да күп яклары белән охшаш. Язучы белән әдәби образның исем-фамилияләренең бер үк хәрефләрдән башлануы да шуңа киная булса кирәк. Әнис тә автор туган төбәкләрдә сурәтләнә, күрше Башкортстанның Илеш районы авылларының исеме әсәр битләренә үзгәртелмичә кереп киткәннәр.

Автор сугыштан соңгы еллар турында язганда күбрәк лирик интонацияләр белән эш итә. Чөнки Әнис үткәннәр турында, дистәләрчә елдан соң, сагынып сөйли. Аның төп юксынганы яшьлек мәхәббәте булу да бу хисне көчәйтә. Бигрәк тә «Яшьлегемне эзлим» әсәре, еллар үткәч, «акыл кергәч», узылган гомерне искә төшереп бәяләүгә корылган. Әнис, күңелендәге серле йомгакны сүтә-сүтә, укучыны җиңел генә үз артыннан ияртә. Шул елларның бөтен катлаулылыгын ачуга омтылыш ясалса да, алгы планга яшүсмернең интим кичерешләре килеп чыга. Мәхәббәтнең тагын да зуррагы — гомумән кешеләрне ярату дигәне дә бар бит. Намуслы юлдан тайпылмас өчен, яшь кешегә идеал кирәк. «Байрагым — кешелеклелек», ди Әнис. Бу аның изге максаты булып әверелә. Өч әсәр дәвамында без Әнис өчен кешелеклелек дигән сыйфатның даими булуын күрәбез. «Дүрт монолог»та аңа

хәтта өлкән туганнарының кылган эшләренә хөкемдарлык итү роле дә бирелгән. Ләкин Әнис үзенә караганда өлкәнрәк кешеләрнең гамәлләренә бәя бирүче була алмый. Хәер, тегеләр үзләре дә аңардан бу вазыйфаны алуын үтенмиләр. Тик омтылышлары бер: аларның яшьрәк вакыттагы эшләрен Әнис дөрес кенә аңласын. Шушы максат монологларның эчтәлеген һәм өслүбен тәшкил итә.

Дүрт монолог — дүрт кеше язмышы. Кеше күп кенә очракларда җибәргән ялгышларын хәтта үзе өчен дә танымаска тырыша. Бу очракта Нәркәс, Илдархан һәм Исәнбәк — өчесе дә Әнис алдында йөрәк серләрен ачып салалар, хаталары өчен аңардан гафу сорагандай итәләр. Менә шушы ачыклык, интимлык һәм серләрне сөйләгәндәге ышанычлылык әсәрнең үзенә бертөрле ягымлы өслүбен барлыкка китерә.

Ә. Баяновның Әнисе гомумән шундый кеше: аңа үз туганнары гына түгел, авылдашлары, райондашлары да акны акка, караны карага аерып куярлык, ышанычлы, башкалар язмышын хәл итәргә сәләтле кеше итеп карыйлар. Бу сыйфат бигрәк тә «Аязучан болытлы һава» әсәрендә күренә. Ул юрист-тикшерүче түгел, бары тик әхлакый бәя бирүче, гади кеше арасыннан чыгып хөкем кылучы. Шуңа күрә Әнис бәяләве укучының үз фикер йөртүе булып та чыга. Әдәби герой белән китапны кабул итүченең, шул рәвешле, бергә кушылып китүе — һәр язучының ирешергә теләгәне.

Ә. Баянов тарафыннан сурәтләнгән иң уңышлы образларның берсе — «Төлке тоту кыен түгел» повестендагы Тата (Көчле кеше) булса кирәк. Кайсы ягы белән? Күңел дөньясының тирәнлеге, уйлау сәләтенең камиллеге, фәлсәфәгә маһирлеге һәм тормышчанлыгы белән. Аны егерме алты хуҗалыктан гына торган авылга баш итеп куялар. Бу ышанычны ул фидакарь хезмәте белән казана. Әмма акылы аңа үзенчә — элеккечә булып калырга куша. «Колхозның иң рядовой дигән бер әгъзасыннан өстен булуны, әйбәтрәк яшәүне вөҗданы кабул итә алмады. Халык нинди хәлдә булса, аның җитәкчесе дә шундый булырга тиеш, дип исәпли иде. Җитәкче кеше халыкның үз тормышы белән яшәмәсә, аңарда минминлек, үзен югары тоту, һавалану дигән яман чир кузгала. Шуңа күрә андый җитәкчеләр: «мин халыктан чыктым», дип мактаналар. Халыктан чыккан яман ботак. Халыктан чыкмагыз сез, иң олы зирәклек — халыкта».

«Яшьлегемне эзлим»дәге Сафуан Кальметов образы да бөтен итеп сурәтләнә. Аны, рәтле белеме дә булмаган кешене, гомуми хуҗалык һәм авылдашлары мәнфәгатьләрен кайгыртып сугышучы солдат дип атап булыр иде. Ул «Аязучан болытлы һава» әсәрендәге Гозәер Рамазанов та гадел солдатлар сафында тора. Җөмһүриятнең иң зур җитәкчеләреннән берсе һич гөнаһсыз Ильяс Җантуринны юлдан алып ташларга тәкъдим иткәч, ул моны кискен кире кага. Рамазанов югарыдан бирелгән күрсәтмәләр белән генә яшәүче түгел, кешеләр турында аның үз фикере бар. Бу уңайдан авторның уйланулары, бу хәлләрдән чыгарган нәтиҗәсе кызыклы. «Рамазанов Җантуринны Фәсиховларга биргән булса, ...күкрәгендәге геройлык билгесе ничегрәк балкыр иде икән? Авыллардагы кешеләр нәрсә уйлар иде икән? Сабан туйлары хәзергечә күңелле була алыр идеме?» Үткән чорның бу фаҗигасе әлеге уйлануларда бөтен тирәнлеге белән ачыла.

Яшьлегемне эзлим дисә дә, Әнис тә дөресендә, гомер буе гаделлек юллап йөри. «Минем өчен гаделлек яшел төстә. Һәр яфрак, кыяк бары тик дөреслек дигән туфракта гына үсә ала. Ә ялганнан бары тик ялган ярала». Бу сүзләрнең әлеге әсәрләр циклының эчке рухын ачуда тирән мәгънәсе бар. Язучының бер герое әйткәнчә, «ялган билгеле шартларда парламент карары дәрәҗәсенә хәтле үсәргә мөмкин». Ә. Баянов сәнгать көче белән дөреслек тантанасы өчен көрәшә. Аның бу изге эшкә берничә дистә еллар элек үк керешкәнлеген искә алганда, әлеге әдибебез иҗатының әһәмияте күпкә арта.

Ә. Баянов прозасы кабул итү өчен катлаулы, анда шартлылык көчле, фәлсәфә хакимлек итә, диләр. Ихтимал, бирәдә хаклык та юк түгелдер. Ләкин алар тормышның үзеннән дә катлаулырак түгел. Аның геройлары — шул ук гади кешеләр. Тик уйлау, сөйләшү үзенчәлекләре, күбрәкне күреп, күбрәкне кичереп, киңрәк фикер йөртүләре белән, бәлки алар нечкәрәк эш итәләрдер. Монда һәр җөмләне сак уку һәм аларның кайберләре турында тукталып, уйланып тору зарур. Бары шул гына. Матур әдәбият әсәрләрен укыганда бер дә интеллектуаль көч сарыф итми мөмкин түгел ич.

«Тавыш — табигать бүләге», «Аргы яр» һәм «Мәңгелек бәхәс» әсәрләрен дә без зур бер китапның өч кисәге итеп карый алабыз. Чөнки аларда бер үк образлар хәрәкәт итә һәм алар хәл кыла торган мәсьәләләр дә әсәрдән әсәр-

гә сузыла. Язучы биредә үз иҗатындагы яңа мәүзугны — фән кешеләре тормышын, аларның характерларын, башкарган эшләренең әхлакый мәгънәсен ачуны максат итә. Ирле-хатынлы галимнәр Нәҗар белән Фәнүзә бик әһәмиятле тикшеренү эшләре алып баралар. Ул түбәндәгедән гыйбарәт — тере күзәнәкләрдәге аксым агышы механизмының серен белү ярдәмендә үлгән күзәнәкләр урынына яңаларының барлыкка килү сәләтен арттыру, шул нигездә кешенең гомерен озайту.

Бу — мәңгелек хыял. Кешеләр гомер озынайту турында бик күптәннән баш ватканнар. Әкиятләрдә үлгән кешеләргә җан иңдерә торган тереклек суын иҗат иткәннәр. Тереклек суы эчкән Локманның мең ел яшәве турындагы матур легенда шуңа бер мисал. Тик моның әхлакый ягы бар, ди автор. Кеше бу озын гомерне нинди максатка файдаланачак? Һәр кеше озын гомерле булырга телиме? Әнә Нәҗарның әнисе — гади авыл карчыгы — үлем түшәгендә ятса да, артык гомердән баш тарта. «Ясалма гомер — гөнаһ ул, көферлек. Гаделдә түгел. Минем яшьтәшләрем әллә кайчан үлеп бетте. Мин, надан кортка, яңа затлы кешеләргә чит-ят булырмын. Күңелсез булыр миңа, яшәү җәзага әйләнер». Озак яшәүнең буыннар арасында яңа мөнәсәбәтләр китереп чыгару ихтималы да бар икән әле. Гомер хәзергечә булганда, нигездә өч буын очраша. Әле алар бербереснең яшәү рәвешләрен аңлый ала. Ә биш-алты буын бергә аңлашып, җайлашып яши алырмы? Нәҗарның әнисе мәсьәләнең шушы ягы турында борчыла. Күрәбез, аны намуслылык дигән як борчый. «Аңарга кешеләрдән, яшьтәшләреннән артыгы кирәкми», «кешеләргә ничек, аңа шулай». Ә хәзерге көннең мещаннарына — затлы, дефицит әйбер, санаторий путевкасы, фатир, җылы урын өчен бер-берсенең бугазыннан алырга әзер торган кешеләргә нәрсәгә ул озын гомер? Гомерләре озаеп, үзләренең кара эшләрен алга таба да шулай рәхимсезлек белән дәвам иттерсеннәр өченме? Мондыйлар Нәҗар белән Фәнүзәнең — озак яшәү серен табып, аның даруын иҗат итүчеләрнең — үзләренә ташланмаслармы? Кабан дуңгызы белән уздырылган сынау шуңа ишарә түгелме? Болар гади генә сораулар түгел. Аларга җавап табу фән-техника үсешен тәэмин итүчеләрнең һәм аларның нәтиҗәләреннән файдаланучыларның әхлакый нигезләрен ачыклау дигән сүз.

Әсәрнең үзәк герое Нәҗар Габбасов югары әхлаклы, намуслы кеше. Аның бу сыйфатлары барыннан да элек хезмәттәшләренә һәм фәнни тикшеренү эшенә гаять бирелгән булуында ачыла. Ул шушы сыйфатлары белән эшли торган институтына, фәнгә һәм үзенә зур файда китерергә тиеш иде. Ләкин безнең җәмгыятьтә талантлы кешегә эшенә кагылмаган каршылыклар белән дә көрәшергә туры килә. Андый кыенлыклар юк икән, аларны махсус тудыручылар бар.

Биредә Ә. Баянов фән өлкәсендәге бик гыйбрәтле тормышның пәрдә читен ачып күрсәтә. Фән мәйданында, гадәттә, берничә төр кеше йөри. Иң әүвәл, әлбәттә, Нәҗардай чын кешеләр. Болар өчен тикшеренү алып бару — яшәү рәвеше дигән сүз. Тагын фәннең эчендә түгел, аның тирәсендә йөрүчеләр була. Боларның бөтен кайгысы үзләрен фән кешеләре итеп күрсәтергә омтылу. Үзеңдә булмаганны күрсәтергә тырышу исә, телисеңме-юкмы, ялганга китерә. Нәҗар эшли торган институтта да бар андыйлар. Шуларның иң типигы — лаборатория мөдире. Әсәрнең беренче кисәкләрендә автор хәтта аның исемен атауны да кирәк тапмый, бары «мөдир» дип кенә йөртә. Моның сәбәбе дә бар, чөнки бу кеше бары тик мөдир генә. Фәнни оешмада мөдирлек иткәч, ул үзен галим дип тә исәпли. Әйе, элеккерәк елларда түрәләр даирәсенә кергән кешене теләсә кайсы тармакка житәкче итеп кую бар иде. Аның теге яки бу өлкәдән хәбәрдар булы әһәмиятле дип саналмады, бары тик сәяси яктан ышанычлы булсын да, әшнәлеккә тугры калсын. «Табигатьтән бер генә бөртек тә иҗади очкын эләкмәгән» бу «мөдир» дә, эшкуарлык сыйфатларын ярдәмгә җигеп, ил, хәтта дөньякүләм мәйданга чыгар иде. Ә интрига кору дигәндә, ул моның остасы. Нәҗарны үз файдасына эшләтү өчен, аны гаепсез җирдән гаепле итүме, пычрак күңелле әшнәләр ярдәмендә Нәҗарның хатыны Фәнүзәгә психологик йогынты ясаумы, куркыту-өркетүме, бер алдыңа, бер артыңа төшеп юхаланумы — мондый кара эшләрнең бик күп төрләрен оста куллана белә «мөдир» дигәнебез. Бу хәлләр эшкә генә түгел, сәламәтлеккә дә зыян китерә башлап, Нәҗар институттан китәргә булгач, моны администрация инициативасы белән эшләнә торган гамәл итеп күрсәтергә тырышуы да мөдирнең мәкер иясе булуын күрсәтә.

Мондый интрига коруларның бөтен сәбәбе — Нәҗарның фән өлкәсендәге уңышлары һәм тора-бара аның институт директоры итеп куелу ихти-

малы булу. Көнчелек, тар күнеллелек һәм житәкчелеккә чын галим килгән очракта үзләренә көн бетәчәген сизү — менә аларны алдан аяк киенергә мәжбүр итә торган көч. Автор әсәрнең бер урынында бик дөрес әйткәнчә, «галимнәргә бары тик галимнәр генә житәкчелек итәргә тиеш».

Безнең чынбарлыкта ни өчен менә мондый хәлләр мөмкин булды? Шушы сорауга җавап эзләп борчылу Ә. Баянов каләмен алга этәрә. Сәбәпләрне язучы түбәндәгеләрдә күрә: беренчесе, хезмәткә алганда аларның теге яки бу өлкәдә эшләү сәләтләрен искә алып бетермәү; икенчедән, кешеләрне бәяләгәндә аларның төп эш күрсәткечләренең еш кына икенче планда калуы, димәк, объективлыкның булмавы; өченчедән, житәкчеләрнең үз тирәләрен ялагайлар урап алу; дүртенчедән, намуслы хезмәткәрләргә каршы булдыксызларның оешып көрәшүләренә юл куелу. Бу очракта демократия гаделсезлекне яклау чарасы булып әверелә.

Менә бу мәсьәләләр Ә. Баяновны, шәхес һәм иҗатчы буларак, җитмешенче еллар урталарыннан бирле борчый башлый һәм ул аларга каршы әсәрләре ярдәмендә көрәшә килә. Әлеге өч повестьта югарыда саналган сәбәпләрнең системасы ачып салына, аларның һәммәсе ышандырырлык итеп күрсәтеп бирелә. Кызганыч, әдәби тәнкыйть үз вакытында әлеге повестьларның идеяэстетик кыйммәтен күреп җиткерә алмады. Дөресрәге алардагы форма яңалыгына, шартлылыкка, фәлсәфи башлангычка игътибар ителеп, алар артындагы гражданлык пафосы, эчтәлеге шәйләнеп бетмәде.

Әйе, Ә. Баянов прозада сурәтләү чараларының яңа мөмкинлекләрен тәкъдим итте. Бу үзенчәлекләрнең төп сыйфатын «фәлсәфи башлангыч» дип атарга мөмкин булыр иде. Сәнгатьчә сурәтләүнең андый мөмкинлеген сирәк язучылар гына уңышлы файдалана алалар. Татар прозасында Ә. Баянов бу мәгънәдә кызыклы тәҗрибәләр ясады. Билгеле, ул моны үзмаксат итеп куймый, фәлсәфилек аның әсәрләренең табигый эремәсе. «Фәлсәфә өстенлек иткән, әсәрнең характерын билгеләгән очраклар бездә әллә ни күп түгел, хәтта бик сирәк, — ди язучы. — Шуңа күрә бу төр әсәрләр дә аерым игътибарга мохтаҗ». (Баянов Ә. Заман сурәтләре. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1985, 264 б.). Ләкин барлык язучылар өчен дә уртак бер таләп бар, ул да булса сурәтләүдә камиллеккә ирешү. Шуннан башка сәнгатьлелек була да алмый. «Мәгәр гамәлдә сәнгать дәрәҗәсенә ирешү мәңгелек проблема булып кала... Кайбер хәлләрдә формага берекмәгән яки артып калган фәлсәфик ташларның әрәмгә чәчелеп ятуын күреп күрсенергә туры килә». (Шунда ук.) Ачык фәлсәфи концепция генә сәнгатьчә камил форма алырга мөмкин. Димәк, фикерләүдәге буталчыклык формага да тискәре йогынты ясый. Ә. Баянов исә үз әсәрләрендәге фәлсәфи нигезнең бүгенгебез, киләчәгебез өчен әһәмиятле һәм ачык булуына ирешергә омтыла.

Бу әдибебез үзе дә әдәби иҗатка фидакарьләрчә хезмәт итүне яшәү мәгънәсе саный. Язар өчен мәүзуг сайлаганда да, әсәремне басарлармы, җитәкче даирәләр хупларлармы, дип уйламый. Тормышыбыздагы үзен тирән борчыган мәсьәләләрне күрә, шул уйларын укучылар белән уртаклашырга омтыла. Каләм тибрәтүне үзе өчен дөньядагы иң югары дәрәҗәдәге эш дип исәпли. Әмирхан ага Еники бер сөйләшүдә «мин беркем дә түгел, хикәя язучы гына», дигән иде. Шуның кебек, Ә. Баянов та каләм остасы гына! Ләкин әлеге сүзнең хикмәтен, кадерен белгән кеше өчен бу теләсә нинди министрлык дәрәҗәләреннән дә өстенрәк исем. Язучының ике томлыгы моны ачык күрсәтә. Андагы әсәрләрне тагын бер карап чыккач, шуңа игътибар итәсең: кайбер авторларның элекке еллардa «көн кадагына сугып» социаль заказ белән язылган әсәрләр бүген арткы планга чиккән бер көндә, Ә. Баяновның прозасы, киресенчә, тагын да кирәклерәк булып әверелә. Чөнки ул мәңгелек мәсьәләләр турында бәхәс алып бара, гомум кыйммәтләр хакында борчыла.

Җыеп кына әйткәндә, Әхсән Баянов иҗаты әлеге ике томлыкта бер бөтен һәм шактый тулы булып күз алдына килеп баса. Әдипнең татар әдәбиятын үстерүгә керткән өлеше җитди икәнен күрәбез.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН.**

## Х. ЯРМИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

# ФОЛЬКЛОР КҮГЕНДӘГЕ ЧУЛПАН

Халык иҗатын җыю һәм өйрәнүне үзенең төп максаты итеп алган, профессиональ татар фольклористикасына нигез салган, олы шәхесебез бар. Дөресрәге, бар иде. Ул — Хәмит ага Ярми. Май аенда аңа 90 яшь тулган булыр иде.

Минем, халык иҗаты дигән олы, сихри дөньяга аяк баскан чорда аның белән аралашкан, фатыйхасын алган, үгет-нәсихәтен тыңлаган бер кеше буларак, бүген аның истәлеген яңартасым, татар халкы өчен кылган изгелекләрен, олы хезмәтен икърар итеп узасым килде.

1970 елларда, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында халык иҗаты буенча аспирантурада укыган чорымда, ул фольклор секторына еш килә иде; озаклап сөйләшеп утырыр, киңәшләрен бирер иде. Сөйләшүләр ахырга якынлашып, «Йә, ярый бүгенгә...» дип спай таягын кулына ала башлауга, без, яшьләр, аны өенә озата бару өчен сикерешеп торыр идек. Шулай итеп, миңа да аны күп мәртәбәләр озатып куярга туры килде.

Ләкин бу һич тә олы яшьтәге кешегә хөрмәт күрсәтү билгесе генә түгел иде. Бу «сәфәрнең» һәрберсе тормыш, халык иҗаты, татар мәдәнияте турындагы «дәресләре» сыйфатында уза торган иде. Хәмит ага ашыкмыйча атлый, дөресрәге ул үзен култыклаган борын төртеп килүче фольклорчы белән берәр фәнни темага әңгәмә кора, йә булмаса күргән-белгәннәре турында сөйли иде. Миңа, бәхетемә каршы, шулай Хәмит агадан байтак кына «урам лекцияләре» тыңларга туры килде.

Хәмит аганың үз тормышы турында сөйләгәннәре әле дә истә. Ул — авыр язмышлы кеше... 1904 елда хәзерге Төмән өлкәсенең Төмән районы Күрән Күл авылында Хөснетдин мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Хөснетдин мулланың язмышы да фаҗигале. Мулла булуын сәбәп итеп, аны совет чорында сөргенгә озаталар һәм ул шунда вафат була. Хәмит аганың Гайшә исемле бертуганы да шундый язмышка дучар ителгән.

Хәмит ага башта үзенең әтисеннән белем ала. Октябрь чуалышларыннан соң кибетче була. 1922—1923 елларда Төмән педагогия техникумында укыганнан соң, мөгаллимлек итә, «Искра пролетариата» дигән губерна яшьләр газетасында, комсомол эшендә эшли.

1930 елда Казанга килеп педагогия институтына укырга керә. 1935—1936 елларда Язучылар берлегенең җаваплы секретаре вазыйфасын башкара, аннан соң өч ел Татарстан китап нәшриятында эшли. 1939 елда Казанда тел, әдәбият һәм тарих институты ачылгач, ул анда фәнни хезмәткәр булып урнаша. Сугыш елларында әлеге институт белән җитәкчелек итә, соңыннан халык иҗаты секторы мөдире булып эшли.

Хәмит аганың фольклор белән кызыксынып китүеерактан, яшьлек елларыннан ук башлана. 1923 елда, әле Төмән педагогия техникумында укыганда ук, ул үзенең әдәбият укытучысы белән (фамилиясе Вәлиев булып истә калган) Тура елгасы буендагы татар авылларына беренче фольклор экспедициясенә чыга.

«Фольклор чире», мөгаен, аңа нәкъ менә шул онытгысыз яшьлек егет чорларында ук йоккан булгандыр. Соңыннан ул татарның беренче профессиональ фольклорчысы булып җитешә; Тел, әдәбият һәм тарих институты секторы каршында татар халык иҗаты фондына нигез сала, аны даими уздырыла торган экспедиция материаллары хисабына тулыландыра бара. Әйтергә кирәк, әлеге фонд тулылана барып, хәзер Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни архивының олы бер өлешен тәшкил итә. Ул республикада фольклор буенча чыгарыла торган китапларның һәм фәнни тикшеренүләрнең нигезе булып хезмәт итә.

Остазыбыз үз гомерендә утызлап фольклор экспедицияләре белән җитәкчелек иткән, Себердә, Уралда, Идел буендагы биш йөзләп татар авылында булган. Җыелган материаллар нигезендә ул бик күп фәнни хезмәтләр, фольклор җыентыклары чыгарган, мәктәп балалары өчен дәреслекләр, хрестоматияләр төзегән. Илленче елларда Казан дәүләт университетында студентларга татар фольклоры буенча дәрес биргән. Фән докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе дәрәҗәсенә лаек булган. Кыскасы, остазыбыз, шул рәвешчә, чын-чынлап татар фольклористикасын профессиональ нигезгә куйды һәм татар фольклоры буенча галимнәр хәзерләде, татар фольклорының фәнни мәктәбен тудырды. Хәзер республикабызда татар фольклористикасы өлкәсендә күзгә күренерлек хезмәтләр чыга икән, татар халык иҗаты тупланмасы томнары һәм башка төрле җыентыклар әледән-әле басылып тора икән, бу — остазыбыз хезмәтенең дәвамы.



**Рәсемдә:** *«мальчишник»лар — Х. Туфан, Х. Ярми, Ш. Маннур, Г. Бәширов.*

Хәмит ага, минем белүемчә, чын-чынлап дуслыкның кадерен белүче, дуслыкка искиткеч тугрылыклы кеше иде. Мине җитмешенче елларда Хәмит аганың Хәсән Туфан, Шәйхи Маннур, Гомәр Бәширов белән дуслыгы таң калдыра иде. Хәмит аганың сөйләвенчә, алар (хәтта хатыннарын да катнаштырмыйча) еш кына бергә җыелалар һәм озак-озак утырудан ләззәт, ямь табалар, моны алар шаяртып «мальчишник» дип атыйлар иде. Шушы көннәрдә генә мин Хәмит аганың гомер иткән фатирына барып, истәлекләр яңартып кайттым. Язмаларын, фотоларын карап утырдым. Документлар арасында шул «мальчишник»ның фотосы да килеп чыкты. Күңел түреннән: «Йа, хода, җәнҗаллы, әрләш-талашлы замандашларга да шундый дуслык, мәрхәмәт, мәхәббәт нурлары салсаң иде», — дигән уй йөгереп узды. Шунда Хәсән Туфанның якын дусты Хәмит Ярминең 60 еллык юбилеена багышлап язылган шигырь дә сакланып калган икән:

Фольклорыбыз рыцары —
Туганыбыз Ярмигә,
Алтмыш елы белән котлап,
Шигырь дә сәлам бирә:
Тура суы буендагы
Туганнардан, Төмәннән
Килеп чыгып мәйданга син,
Таудан түгел, түбәннән,
Ил иҗаты күкләренә
Йолдыз булып калыктың.
Чын улы син, Хәмит туган,
Күп миллионлы халыкның.
Насыйп булсын моннан соң да,
Калкырга да, калкырга;
Фольклорның киң күгендә
Чулпан булып балкырга.

*Туганлык сәламе белән*
***(Хәсән) ТУФАН,** 15.05.64.*

Хәсән ага Туфанның бу сүзләре Хәмит Ярминең халкыбыз күңелендәге сурәтен дөрес билгеле шикелле. Минем уемча, татар фольклористикасын профессиональ нигезгә куйган, аның фәнни мәктәбен булдырган остазыбызның исеме чыннан да «фольклорның киң күгендә Чулпан булып» калыр.

...Хәмит аганың гомер иткән фатирыннан мин әсәрләнеп, уйга батып, күңелем белән гүя кабат «урам лекцияләрен» тыңлый-тыңлый кайттым. Кызык бу тормыш дигәнең: әллә кайчан үзең озатып йөргән, инде күптән мәрхүм булган кеше күңелдә кабат «терелеп», үзе сине озатып йөри. Димәк, остаз яши, остаз безнең белән.

**Рәшит ЯГЪФӘРОВ,**
фольклорчы.

### ТАТАРСТАН ЮГАРЫ СОВЕТЫНЫҢ XIX СЕССИЯСЕНДӘ

18—21 апрель көннәрендә Татарстан Республикасы Югары Советының XIX сессиясе эшен яңадан дәвам иттерде. Аның көн тәртибенә «Татарстан Республикасы Президентының 1994 елга бюджет юлламасы турында»гы, «Татарстан Республикасының 1993 елда республика бюджеты үтәлеше турындагы хисап хакында»гы, «Социаль иминлек фонды чыгымнары хисабыннан түләнгән дәвалану һәм ял итү юлламаларының хакыннан алынучы керем салымын түләүдән физик затларны азат итү турында»гы һ. б. мәсьәләләр кертелгән иде.

Аларның һәркайсы буенча сессиядә эшлекле сөйләшү булды. Югары Совет «1994 елга Татарстан Республикасы бюджет системасы турында»гы Закон проектын нигездә кабул итте. ТР Министрлар Кабинетына 25 майга кадәр икътисадый кризис хәленнән чыгару буенча Дәүләт эш программасы төзергә, шулай ук бу елның беренче яртыеллык нәтиҗәләре буенча республика бюджетын төгәеләүдә тәкъдимнәр кертергә кушылды.

Сессия эшендә Татарстан Президенты М. Шәймиев катнашты. Утырышларны Югары Совет Рәисе Ф. Мөхәммәтшин алып барды.

### ЧУВАШСТАНДА ОЧРАШУЛАР

1994 елның 1 апрелендә Чувашстан Республикасы Президенты Н. Федоров белән Татарстан Республикасы вице-президенты В. Лихачевның очрашуы булды. Яклар, үзара икътисадый, мәдәни һәм фәнни-техник мөнәсәбәтләрнең торышын тикшереп, Дуслык һәм хезмәттәшлек турында ике яклы килешү төзү юлы белән, аларны ныгыту һәм үстерү кирәклеге турындагы нәтиҗәгә килделәр.

### ФИРКАНЕ ТӘГЪДИР ИТҮ БУЛДЫ

26 апрельдә «Казан» милли-мәдәни үзәгендә Россия бердәмлек һәм татулык партиясенең (ПРЕС) Татарстан бүлеген тәгъдир итү булды. Анда катнашу өчен Мәскәүдән партиянең лидеры, ПРЕСның Федерация советы рәисе, Россия хөкүмәте вице-премьеры Сергей Шахрай килде.

С. Шахрай Г. Тукай һәйкәленә чәчәк бәйләмнәре салды, рәссамнар берлегенең күргәзмәләр залында Илдар Ханов әсәрләрен карады, Вахитов районы колхоз базарында булды.

### ТАТАРСТАННЫҢ МИЛЛИ РАДИОСЫ БУЛАЧАК

Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты утырышында Татарстанда Милли радио оештыру мәсьәләсе каралды. Бу эшне хәл итүдә республиканың элемтә, мәдәният, халык мәгарифе министрлары һ. б. катнашты. Башкарма комитет 1994 елның беренче июненнән дә соңга калмыйча озын дулкыннарда тапшырулар башлау турында карар кабул итте. Журналист Римзил Вәлиев Милли радионың баш мөхәррире итеп билгеләнде.

Яңа информация чыганагын дәүләт финанслаячак.

### ТАТАРСТАН — ХАЛЫКАРА ЖУРНАЛДА

Рәсемнәр белән бизәлеп чыга торган «Яңа дөньяга паспорт» исемле Россия — Америка журналының чираттагы саны нәшер ителде. Андагы кызыклы язмаларның, фоторәсемнәрнең зур күпчелеге Татарстан Республикасына багышланган. Дөньяның 100 дән артык иленә таралучы журнал җөмһүриятебезнең икътисадый, социаль һәм мәдәни тормышын киң яктырта.

### ШИГЪРИЯТ БӘЙРӘМЕ

Башка еллардан үзгә буларак, быел Г. Тукайның туган көне (26 апрель) Халыкара шигърият бәйрәме итеп үткәрелде. Бу бәйрәмгә тугандаш Башкортстаннан халык шагыйре Нажар Нәҗми, Төркиядән Шәрәфетдин Айбарс, Төньяк Осетиядән Владимир Царукаев, Кырымнан Диләвер Осман, Мәскәүдән Виктор Кочетков һәм башка кунаклар килгән иде.

Шигърият митингны Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары шагыйрь Зиннур Мансуров ачып җибәрде һәм Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирү турында Җөмһүриятебез Президенты Указын игълан итте. Быелгы лауреатлардан язучы Нурихан Фәттах, рәссам Илдар Зарипов, дирижер Фоат Мансуров исемнәрен мәйдандагы халык алкышлап каршылады.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев исә быел Гаяз Исхакый исемендәге премиягә лаек булган Нажар Нәҗмигә («Татар теле» шигыре өчен) һәм Рахмай Хисмәтуллинга («Кыйбла җиле» китабы һәм әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге өчен) махсус дипломнар һәм акчалата бүләк тапшырды.

Шигърият җыенда, ерак араларны якын итеп килгән кунаклар белән бергә, фронтовик

шагыйрь Кави Латыйп, Әхсән Баян, Рахмай Хисматуллин, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Разил Вәлиев, Мәдәррис Әгъләмов, Харрас Әюпов, Флера Гыйззәтуллина, Салисә Гәрәева, Лена Шагыйрьҗан, Фәүзия Бәйрәмова, Шәмсия Җиһангирова, Эльмира Шәрифуллина, Газинур Моратов, Ркаил Зәйдулла, Рафаил Газизов, Рифә Рахман һәм башкалар чыгыш ясадылар.

Шигырь бәйрәмендә халкыбызның яраткан җырчылары, композиторлары, музыкантлары, нәфис сүз осталары да катнашып, нур өстенә нур өстәделәр.

27 апрельдә бер төркем әдипләр һәм кунаклар Арчадагы сәнгать мәктәбендә һәм Кырлайдагы Тукай музеенда булдылар.

## ХАЛЫК ЯЗУЧЫЛАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Язучыларның Г. Тукай исемен йөртүче клубында соңгы вакытта кызыклы очрашулар еш булып тора. Апрель аенда, мәсәлән, ике кичә татар халык язучылары — Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреатлары Аяз Гыйләҗев белән Әмирхан Еникигә багышланды.

Очрашулар барышында һәр ике әдипкә дә күп санлы сораулар бирелде.

## Ә. ЕНИКИ — ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ

Татар әдәбиятын төрек теленә тәрҗемә итүдә әлегә кадәр очраклылык хөкем сөрә иде. Киләчәктә бу эш тиешенчә җайга салыныр кебек — ниһаять, чын җәүһәрләребезгә дә игътибар күрсәтә башладылар: «Төрек әдәбияты» журналының быелгы апрель санында Әмирхан Еникигә урын бирелде. Монда аның сурәте, тормышы һәм иҗаты турында белешмә, күләмле интервьюсы һәм «Кем җырлады» хикәясе басылып чыкты.

Төркиядә әдәби басмалар күп, алар арасында сурәтле, чагыштырмача күп тиражлы айлык фикер һәм сәнгать журналы «Төрек әдәбияты» үзәк урынны алып тора.

Алга таба «Төрек әдәбияты» белән «Казан утлары» журналлары арасында иҗади хезмәттәшлек ныгыячак.

## ХУҖА ӘХМӘТ ЯСӘВИГӘ БАГЫШЛАП

29 мартта Татарстан Фәннәр Академиясе, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, җөмһүриятебез Мәдәният министрлыгы һәм Татар дәүләт фольклор үзәге төрки халыкларның бөек шагыйре Хуҗа Әхмәт Ясәви тууының 900 еллыгына багышланган фәнни конференция үткәрде. Анда күренекле галимнәребез, фән эшлеклеләре, язучылар Әхмәт Ясәвинең шәхесенең һәм аның иҗатының татар әдәбиятына, тарихына йогынтысы хакында сөйләделәр. Шул ук көнне кичен К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры бинасында, ошбу олуг шәхеснe тагын бер мәртәбә зурлап искә алып, мөнәҗәтләр кичәсе үткәрелде.

## УФАДА ШАГЫЙРЬ КИЧӘСЕ

Март аенда Уфадагы төрки «Рамазан» милли-агарту үзәге, Башкорт дәүләт университеты, М. Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия театры, «Нур» татар дәүләт театры, Башкортстан Язучылар берлеге һәм «Башэнергобанк» татар шагыйре һәм драматургы Илдар Юзеевнең иҗат кичәсен үткәрделәр. Башкорт дәүләт опера һәм балет театрында узган бу әдәби җыенда Башкортстан театрлары И. Юзеевнең сәхнә әсәрләреннән өзекләр күрсәттеләр, күренекле эстрада җырчылары аның шигырьләренә язылган җырларны башкардылар. «Татарстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелү уңае белән, И. Юзеевне якташлары — Янавыл районы вәкилләре, Башкортстанның халык шагыйре Нәҗәр Нәҗми, күренекле шагыйрь һәм драматург Әнгам Атнабаев, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Динис Бүләков, Башкортстандагы татар язучылары берлеге исеменнән академик Рәиф Әмиров һ. б. котлады.

Башкортстан Президенты М. Рәхимов Указы белән, Илдар Юзеевкә Башкортстан Республикасының Мактау язуы тапшырылды.

## КҮҢЕЛЛӘРДӘ — ГАЯЗ ИСХАКЫЙ

Халык депутатларының район Советы сессиясе карары нигезендә, Сарманның матур бер яңа урамына мәшһүр язучыбыз Гаяз Исхакый исеме бирелде.

* * *

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Г. Исхакыйның «Алдым-бирдем» пьесасы сәхнәләштерелде (режиссеры — П. Исәнбәт). 1—3 апрель көннәрендә аның премьерасы зур уңыш белән үтте.

## «ВАТАН» ҖӘМГЫЯТЕНДӘ

Яңарыш чорында туган мөстәкыйль «Ватан» җәмгыяте (президенты — Дамир Гыйсметдинов) үзенең эшчәнлеген елдан-ел яхшырта бара. Ул чит илләрдәге милләттәшләребез, андагы татар җәмгыятьләре белән тыгыз элемтәдә тора.

Җәмгыятьнең март аенда узган конференциясендә башкарылган эшләр һәм алда торган мөһим чаралар турында файдалы сөйләшү булды.

Конференция әлеге абруйлы җәмгыятьнең эшлекле әгъзасы Илдус Садыйковны вице-президент итеп сайлады.

## АВСТРИЯ КУНАГЫ ДА КАТНАШТЫ

Мөселман дөньясы өчен иң изге саналган Рамазан бәйрәме көннәрендә Казанның мәдәният сарайларында «Ватан» җәмгыяте һәм Казан шәһәр хакимиятенең мәдәният идарәсе оештырган концертлар булып узды. Анда Австриядән килгән кунагыбыз — Вена симфоник оркестрының атаклы пианисткасы, Гран-при бүләгенә лаек булган профессор Мариам ханым Джива Җения дә катнашты. Шунысын да әйтик, Мариам ханым — Көнчыгыш халыкларының сәхнә йолдызларын яхшы белүче һәм биюләрен оста башкаручы буларак та киң танылган

сәнгать әһелләре. Җөмһүриятебез тамашачылары аның һәр чыгышын — уенавын да, биюен дә — бик яратып кабул иттеләр.

### «КИЛЕНБИКӘ ТАҖЫ» ИЯЛӘРЕ

20 апрельдә Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, «Ак калфак» Бөтентатар хатын-кызлар ассоциациясе, «Сөембикә» журналы Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында «Киленбикә» исемле тамаша-бәйге үткәрделәр. Анда БДБ мәмләкәтләреннән, Россиянең өлкә һәм республикаларыннан, җөмһүриятебез районнарыннан килгән иң булдыклы, иң зирәк, иң сабыр, иң һөнәрле өч буын вәкилләре үзләренең осталыкларын күрсәттеләр.

Бәйгедә җөмһүриятебезнең Теләче районындагы Олы Нырсы авылыннан мөгаллимә, дүрт бала анасы Нурания Гыйльметдинова җиңүче дип табылды. Икенче урынга Мәскәү каласыннан Татар зыялылары клубы директоры, язучы, 2 бала анасы Нәзифә Кәримова лаек булды. Өченче урын Ташкент каласында яшәүче мөгаллимәгә, өч оныгы булган өлкән киленбикә Венера ханым Латыйповага бирелде. Аларның һәркайсына «Киленбикә тажы» һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

### «ЯЛКЫН» ЖУРНАЛЫ БӘЙРӘМЕ


12 апрельдә К. Тинчурин исемендәге театр бинасында «Ялкын» журналының чыга башлавына 70 ел тулуга багышланган юбилей бәйрәме булды. Аны, кереш сүз белән, журналның баш мөхәррире — язучы Җәүдәт Дәрзаман ачты. Бәйрәмгә, котлау өчен, Татарстан мәгълүмат һәм матбугат министры Ислам Әхмәтҗанов, Татарстан Югары Советыннан даими комиссия рәисе язучы Разил Вәлиев, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев, Татарстан китап нәшрияты директоры Харис Әшрафҗанов һәм күп кенә газета-журналларның баш мөхәррирләре килгән иде.

Кичәдә журналның бик күп санлы бүгенге укучылары, ветеран журналистлар, әдәбият һәм сәнгать әһелләре катнашты.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен, Татарстан Республикасы Язучылары берлеге идарәсе рәисе урынбасары, шагыйрь Зиннур Мөҗип улы Мансуровка һәм идарәнең оештыру эшләре буенча сәркатибе, шагыйрь Мансур Әхмәт улы Шиһаповка «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тынлыктагы сурәтләр*



## АЙ ТОТЫЛГАН КӨН

Яшь рәссам Әлфия Ильясова миңа үзенең нәзакәтле келәм-гобеленнары аша гына билгеле иде. Аның зәгъфран, алтынсу-ком җирлектә «утрау-утрау» гүзәлләрдәй тезелеп киткән нәкышьләре, кысан калыплар эчендә тукылган келәмчелек сәнгатеннән бигрәк, саргайган шигырь тулы китап битләрен, ерактан игътибарны җәлеп иткән дивар бизәкләрен хәтерләтә иде. Ә рәссам кыз үзе әкияттәге сөю сүзләрен, сиздермичә генә бизәк эченә яшереп, сөйгәненә үзе үргән келәм аша «хат җибәргән» тукучы булып килеп баса иде. Шунлыктан ирекле иҗатка, сүз сәнгате, шигъриятнең сурәтлелегенә омтылган нечкә шәхес Әлфия Ильясованың җанлы язу — нәкышь сәнгатенә килүе зарури иде. Чөнки аның бу төр иҗат юлында фикер-уй ягыннан тирәнрәк, күпьсыешлы, символик эчтәлекле рухый сәнгать тудыра алуы тәгаен иде.

Менә — иҗаткар белән икенче очрашу. Шәхси күргәзмә... Дивар буйлап тезелеп киткән сын-сурәтләр... Төсле могҗизалар, якты сүрәләр, ясыйн-фатыйхалар... Гаҗәп мавыктыргыч өлкә тапкан рәссам: монда ислам мохиты, мөселман дөньясы, Коръән укудан, дини риваятьләр тылсымлы догалар тыңлаудан туган тойгылар, четрекле вә гүзәл «төш күрүләр», хыял тарафлары — күкләр, фәрештәләр, пәйгамбәрләр, хаҗга баручы мосафирлар, Җәбраиллар һәм башка шундый рәсем-гыйбарәләр... Дин

тирәсендә, әхлак тирәсендә, рухи сафлык, күңел пакьлеге турындагы хадисләр; җан азыгы, күңел азыгы эзләп, гади чынбарлыктан, дөньяны бугазлап алган матди җирлектән күкләргә, изге хыял катламнарына ашу, шунда рәссам күңеле уйлап чыгарган тәмуг-җәннәтләрдә көйрәү, яшәү, үлем авазларын «татып» карау, нечкә, изге тойгылар бишегендә әле авыз итмәгән хис-сиземләүләр эчендә тибрәлү. «Гарәфәт тавы», «Кадер киче», «Мәрьям пальма агачы янында», «Гайшә бакчада», «Хаҗга баручылар», «Муафикъләр», «Зөләйха» — һәр мөселманны тетрәткән бу тирән мәгънәле образлар рәссам тарафыннан әйтерсең лә кыяр-кыймас, орыныр-орынмас кына, көмеш челтәрләр, алтын җепселләр, пәрәвезләргә охшаган ефәк сызымнар белән генә кадерләп, олылап сурәтләнгән. Әлбәттә, бу Коръәнне, андагы сурәләрне турыдан-туры тасвирлау, иллюстрацияләү түгел, ә мең еллар буе халык күңелен биләгән рухи дәрьяны олылау, динне, кешенең әхлагын, иманын чистарта торган кодрәтле көчләрнең берсе итеп тану, бөекләү һәм моны шагыйрьләрчә тоеп, гүзәллек эквивалентлары аша мәдхияләү. Гүзәл пейзажлар, тылсымлы агачлар кыяклы-кыяклы асыл тирәкләр, хур кызларына охшаган түгәрәк йөзле Мәрьям-Гайшәләр шуның турында сөйли. Ләкин бу төпсез коедай иксез-чиксез караңгы күкләр, чиксезлек дәрьясында йөзгән асыл кыз-йолдызлар («Җидегән йолдыз», ак киемгә төренгән, көеп күмер булган җан иязләренә охшаган бәндәләр, шомлы канатлы кошка тартым сәер җанварлар — болар барысы да назлы сурәтчелек, беркатлы пассажлар гына түгел; авторның мәсләге: адәмнәрне тупаслыктан, ваемсызлыктан йолып, рухың, иманың, дөньядагы эшләрең турында исап-хисап бирәчәк «теге дөнья» турында уйланырга өндәү; яхшылык-залимлекнең гыйбрәтле үрнәкләрен күрсәтү — тормышны бөтен катлаулыгы — «ак һәм кара», якты һәм караңгы якларын кыю кабул итәргә, савап эшләр кылырга чакыру...

Борынгылыкны Әлфия архитектура, йөз үзгәлеге, тарихи киемнәр аша гына бирми... Рух, хәтер аша, кешелекнең беренчел, балачак сәнгате образлары аша хатирәләргә тырыша: монда Мисыр фрескаларының, Шәрекъ миниатюраларының самими матурлыгы; Гарәбстан чүлләренең алтын җемелдәве, дөя әркәченә охшаган зур-зур таулар, пальма яфрагына ясалган сыман кечкенә-тәвәккәл бәби-сыннар, борынгылык хиссиятен тудырган дәртле ритмнар, ә кайчак ислам дине чоры, аның әдәбияты күзалланырлык абстракцияләр...

Нәккашьнең «Ай тотылган көн» әсәренең төп өлешен чит цивилизацияләрдән килгән очу тәлинкәсенә охшаган айлы-кояшлы утлы бизәк пәйда булган күк сурәте алып тора... Ул — алгы планнан арткы яссылыкка кадәр бертуктамый уңнан-сулга, сулдан-уңга дулкын сыман барган хәрәкәт өеренең иң югары ноктасы. Гаҗәпләнгән сакаллы ир һәм кулы белән могҗизага ишарәләгән хатыннан гыйбарәт төркем дә, тәсбих тотып гөнаһлары авырлыгыннан тауга иңгән мыеклы мөселман да, канатларын җәеп очкан изге ак үрдәкләр, корбан малы — ак сарык бәтие дә, уртада яулыкларын җилфердәтеп тауга менеп барган хатыннар төркеме дә шул якты ноктага омтыла. Югарыда быргыда уйнаучы, ак йөзле нәни куллы Җәбраил алтын манзарага күрсәтеп, аңа ут өреп, яктыртып тора... Авыш-тәвеш китерелгән хәрәкәтчән җир катламнары, әйтерсең, убылып, юкка чыгып бара... Бу — курку катнаш гүзәл зилзилә бары тик яхшы кешеләрне, изге адәмнәрне генә үзенең тарафдары, чордашы итеп кабул итә... Рәссам кечкенә аяк-куллы, түгәрәк йөзле каһарманнарына иркен киемнәр кигезеп, йомшак алтын-яшел, кызыл таплар белән — табигать балалары итеп сурәтли... Аларның иман, күңел кәгъбәсе пәйда булган ноктага омтылулары гадәти булып кабул ителә... Димәк, татар дөньясында яңадан иман яңарту, сәяси тормышта, мәдәният өлкәсендә, рухи хаяттә барган яңарыш турында фикер кузгата яшь рәссам.

Әлфия Ильясованың бөтен асылы Шәрекъ дөньясы, Шәрекъ сәнгатенең азсүзлеге, төсләр тылсымы, аһәңлелегендә.

Әлфия — үзе дә камиллеккә омтыла, акылның, иҗатның бөеклегенә инанып яши һәм... могҗизалар көтә...

Мәскәүдә «арт-миф» күргәзмәләрен, Казандагы милли мәдәният музеенда, Туран күргәзмәләрен караучыларда тирән кызыксыну уяткан Әлфия Ильясованы хыялының канатлы-йолдызлы җилләре кайларга алып китәр икән? Изгелеккә, камиллеккәдер, мөгаен.

**Розалина ШАҺИЕВА**

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Әлфия Ильясованың «Ай тотылу» исемле рәсеме.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган шагыйрь, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Мөдәррис Әгъләмов.

**М. КОЗЛОВСКИЙ фотосурәте**

**Тышлыкның беренче битендә төсле сурәтләр, 1941 елның 1 нче саныннан башлап, «Туран» фонды коллекциясеннән алынды.**

## ДУСЛЫГЫБЫЗ ДӘВАМ ИТСЕН!

Мөхтәрәм милләттәшләр!

1994 елның икенче яртысы (июль, август, сентябрь, октябрь, ноябрь, декабрь айлары) өчен «Казан утлары» журналына язылу дәвам итә.

Журналыбызга язылу бәһасе, башка басмалар белән чагыштырганда, шактый арзан.

Инде язылу тәртибенә кагылышлы бер үзенчәлек турында да искәртеп үтик. Әйтик, элемтә бүлекчәләрендә әбүнә тартмалары (абонящиклары) булган кешеләр өчен «Казан утлары»на ярты елга язылу бәһасе 6024 сум торса, журналны өйгә турыдан-туры почтальоннар китергәндә, бу сан 6600 сум була. (Шул уңайдан, быел җөмһүриятебездә ике төрле каталог чыгарылды.) Кыскасы, сезнең өчен кайсы вариант отышлырак — шунысын сайлагыз, кадерле дуслар!

---

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
„Союзпечать"

**АБОНЕМЕНТ** на ~~газету~~ журнал 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

Количество комплектов: 1

на 1994 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | X | X | X | X | X | X |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|
| | | |

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

на ~~газету~~ журнал 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

| Стоимость | подписки | ___ руб. ___ коп. | Количество комплектов: | 1 |
|---|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___ руб. ___ коп. | | |

на 1994 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | X | X | X | X | X | X |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

## «Казан утлары» — иң яхшы бүләк!

Форсаттан файдаланып, без районнардагы хакимият башлыкларына, колхоз-совхоз, предприятие-учреждение җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәбез: күркәм эшләре өчен, хезмәт алдынгыларын «Казан утлары» журналы белән бүләкләүне быел да оештырсак иде. Чөнки журналның һәр саны — һәртөрле кызыклы, мавыктыргыч роман-кыйссаларга, шигырь-поэмаларга, әдәбият-сәнгать яңалыкларына, тарихи, фәнни язмаларга гаять бай китап-энциклопедия бит ул!

1994 елның икенче яртысына әзер әбүнә кәгазен (абонемент үрнәген) тәкъдим итәбез. «Казан утлары»н июль—декабрь айларында алдырырга теләүче һәркем, шушы квитанциягә үзенең тулы адресын, исем-фамилиясен язып, аны үзе яшәгән җирдәге элемтә бүлекчәсенә тапшырырга тиеш.

Индексыбыз — 73210.

Онытмагыз һәм оттырмагыз!

### ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ — МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

Обл. тип., г. Кострома

# ЯҢА КИТАПЛАР




РАВИЛ ӘМИРХАН, ВАХИТ ИМАМОВ. **Татарларның Ватан сугышы.** Яр Чаллы «КамАЗ» газета-китап нәшрияты. 1993, 80 б. Тиражы — 165 000 данә.

Китап Чаллы эшмәкәрләре бертуган Рәфис, Нәфис Кашаповларның һәм Илфат Гыйльмазовның матди ярдәме белән чыгарылган, тарих буенча өстәмә дәреслек буларак, республикабызның мәктәп һәм гимназия укучыларына адреслана.

Ул: «Бәйсезлек өчен көрәш» һәм «Яшерелгән тарих» дигән ике бүлектән тора.

«Тарих көзгесе ачык күрсәтә: татарның чын, тулы мәгънәсендәге Ватан сугышы 1549 ел чикләре белән билгеләнә»,— диелә беренче бүлектә.

Бу китап татар халкының азатлыгын яклап тигезсез яуларда шәһит киткән газиз туганнарыбыз рухына багышлана.

ИЛДАР ЮЗЕЕВ. **Таныш моңнар.** Сайланма әсәрләр *(Поэмалар)*. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993, 304 б. Тиражы — 2000 данә.

Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты шагыйрь Илдар Юзеевның бу китабына аның төрле елларда иҗат ителгән иң яхшы поэмалары тупланган.

Татар шагыйре полковник Хәйретдин Мөҗәйгә багышланган «Язылмаган поэма», ерак гасырларны гәүдәләндергән «Таш диварлар авазы», Тукай образын тудырган «Очты дөнья читлегеннән», адәм баласының иң газиз хисе — мәхәббәт турындагы «Таныш моңнар», «Мәхәббәт китабы» поэмалары әлеге җыентыкта үзләренең лаеклы урыннарын алганнар. Тирән фикергә һәм якты хискә бай әсәрләрдән торган бу җыентык киң катлам укучыларга юллана.



Бәясе 330 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог